
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2000



*Хәсән Туфанга 100 ел*



**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2000*

# 12

**(938)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Факил Сафин, Мәгъсум Хуҗин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Флүс ЛАТЫЙФИ. Бәйсез этләрне атарга. *Роман-нәсер* .......... 5
Шәүкәт ГАЛИЕВ. Сулар ага, уйлар ага. *Шигырьләр* .......... 45
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Күңелем серләре. *Куен дәфтәрләреннән.* Ахыры .......... 50
Нур ӘХМӘДИЕВ. Сөюебез күптән күккә ашты. *Шигырьләр* .......... 90
Әхсән БАЯН. Уйлар дәрьясында. *Хәтер дәфтәреннән* .......... 94
Гәрәй РӘХИМ. Татар мадонналары. *Шигырьләр* .......... 122

ХӘСӘН ТУФАННЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Зур талант, якты шәхес иде... *(Шагыйрь турында әдипләребез)* .......... 126
Xәsәn TUFAN. Tөrle yıllardan şigırlәr .......... 181

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Нәҗибә САФИНА. Ил турында «Ил» китабы *(Рецензияләр конкурсына)* .......... 140

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

5—Маидә (Табын) сүрәсе .......... 145

САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Шамил МОНАСЫЙПОВ. Сәйдәшнең сихри моңы .......... 157

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВАГА 50 ЯШЬ

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Әнә шундый йөрәк! .......... 170

РОЗА КОЖЕВНИКОВАГА 50 ЯШЬ

Роза КОЖЕВНИКОВА. *Шигырьләр* .......... 172

ФАТИХ ХАЛИДИНЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН. Мәгърифәтче әдипләребездән берсе .......... 174

Еллык эчтәлек .......... 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 188

ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Розалина ШАҺИЕВА. Казанның җәмигъ мәчете .......... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман-притча Ф. ЛАТЫФИ «Непривязанных собак пристреливают»; А. ГИЛЯЗОВ «Сокровенные мысли» *(окончание)*; А. БАЯНОВ: «На волнах раздумий»; стихи Ш. ГАЛИЕВА, Н. АХМАДИЕВА, Г. РАХИМА.
«К 100 летию Х. Туфана»: «Яркий талант, светлая личность» *(поэты и писатели о своем современнике)*.
«На конкурс рецензий»: Н. САФИНА рецензирует новую книгу Р. Зайдуллина.
«Коран на татарском языке».
«К 100 летию С. Сайдашева»: статья Ш. Монасыпова «Волшебная музыка Сайдаша».
В номере отмечается 50 летие писательницы и общественной деятельницы Ф. Байрамовой и поэтессы Р. Кожевниковой. (Статьи М. Валиева и Р. Зайдуллы).
«Наш календарь»: к 150 летию просветителя Ф. Халиди посвящена статья З. МУХАМЕТШИНА.
Библиографический список опубликованных произведений в журнале за 2000 год.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Соборная мечеть Казани»—гипотеза Казанских археологов; поэт Р. Курбан.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": F. LATIFI'S novel «They shoot not tie dogs», A. GILIAZOV «Innermost thoughts»(finishing). A. BAIANOV «on the waver of thoughts»; the verses of SH. GALIEV, N. AKHMADIEV, G. RAHIM.
"Commemorating the 100 th anniversary of H. Tufan": «A clear talent, light personality». (Poets and whiters about thear contemporary)
"Review competition": N. SAPHINA'S review about R. Zaidullin's new book.
"Koran in Tatar language".
"Commemorating the 100 th anniversary of S. Saidashev": SH. MONASIPOV'S article «Saidashev's magic music».
"Jubilees":the 50th anniversary of writer and public benefactor F. Bairamova and poet R. Kojevnikova. (Article of M. VALEEVA and R. ZAIDULLA).
"Our calendar": Z. MUKHAMETSHIN'S article devoted to 150th anniversary of F. Khalidi.
Bibliography list of work published in magazin in 2000 year.
The diary of social and cultural life.
In our covers: «Kazan cathedral moque» - hypothsis of Kazan archaeologist; poet R. Kourban.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.11.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7542 Заказ Э-469
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



# Флүс Латыйфи

# БӘЙСЕЗ ЭТЛӘРНЕ АТАРГА

РОМАН-НӘСЕР

*Сугыш елларында туган, балалык һәм үсмерлек еллары үтә дә дәһшәтле, авыр чорларга туры килгән, әмма сынмаган, сыгылмаган, хыялларына хыянәт итмәгән, бүген дә дөньяның төп йөген җигелеп тартучы замандашларыма багышлыйм.*

Автор

Яннымда гына юеш борынлы, икесе ике якка сәлперәеп төшкән олы колаклы йонлач эт бөтерелә. Кара кучкыл бөдрәләре арасыннан йоп-йомры күзләре генә елтырый. Ә үзен күзгә күренмәс җепләр белән миңа бәйләп куйганнар диярсең. Мин урамга чыксам, ул да урамга теркелди, бакчага керсәм, капка астыннан ул да шунда шуыша. Су буена төшәсен—ул да минем арттан. Кыскасы, мин кайда, ул—шунда...

И әйбәт тә кыз инде бу Лилия! Көчекне миңа ул табып биргән иде бит. Инде әллә кайчаннан бирле эт алырга кызыгып, шул уй белән янып, хыялланып йөргәнемне каян белгән диген! Телем белән әйткәнем дә юк иде ләбаса! Ул иң яшерен серем, хыялым иде. Нәни генә көчектән хыянәт-хөсетлекне, сату-сатылуны белми торган тугры дус, уяу һәм батыр иптәш тәрбияләп үстерәсем бик килә иде минем. Менә бу йон гөнҗәләсе шул хыялымның тормышка аша башлавы бит инде. Аны мин кушканнарымны үтәргә, ни теләгәнемне күземнән карап та аңларга өйрәтәчәкмен әле. Этләр барысын да аңлый, сизенә, бары тик теле белән әйтеп бирә генә белми, диләр. Шулайдыр! Шулай булмаса, ул энәгә сапланган җеп шикелле гел минем арттан теркелдәмәс, күзем генә карап тормас иде. Тагын әле икенче бер хыялым да бар минем. Хәзер менә бөтен малайларны шаккатырырлык тачка ясарга җыенам. Ул барысыныкыннан да әйбәтрәк тә, җинелрәк тә, уңайлырак та булырга тиеш. Шуларны уйлый-уйлый арба-тачка ясыйм. Менә ясап бетерербез дә Ык буена төшеп китәрбез.

—Шулай бит, Тигр!

Дүрт аяклы дустым әллә мине хуплады, әллә, тизрәк ясап бетер,

дип әйтергә теләве булды, янгыравык тавыш белән ләнгелдәп куйды:

—Һау, һау,—диде.

—Әйе, дускай, шулай!—дидем мин һәм, Тигрны үземә тиң күрүемне белдерергә теләп, мангаеннан сыйпап куйдым.—Безнең рәхәт көннәр алда әле...

Көне генә әллә нинди бүген. Әле Лилия искә төшә, әле һәр сүземә койрык болгап торучы Тигр белән сөйләшәм, әле әнкәй кушып калдырган эшләрнең чутсызлыгыннан хәйран вә вәйран булам. Арбаны да тизрәк ясап бетерәсе килә. Әмма барысын да берьюлы эшләп булмый икән шул. Нигә кешенең дүрт кулы, дүрт аягы юк икән, дип тә уйлап куясың әле. Ат урынына йөгерер идең, берьюлы әллә ничә эшне эшләр идең. Тизрәк булыр иде.

Булмый икән булмагач... Инде бетерәм дип кенә торганда урамның теге ягыннан кемнеңдер әче итеп сызгырганы, яшелле-күкле тавыш белән сузып кычкырганы ишетелде:

—Ха'ис! Ха'ис, дим...

Кемнәр икән, дип борылуым булды, кизәнеп сугарга күтәрелгән чүкечем кадак тоткан бармакка килеп тә төште. Әйтерсең тырнак астына берьюлы ун энә тыктылар... Ясый башлаган арба сабын бер якка, чүкечне икенче якка тондырдым. Авыртуга чыдый алмыйча, баш бармагымны авызга каптым да сыңар аякта сикергәләргә тотындым.

Беләм бит инде, беләм юкса кем сызгырганын. Шул кара чутыр Гыйльфан булмый кем инде тагын шулай "Ха'ис" дип кычкыра ала!

Исемемнең чыны Харис минем. Дөрес, башта ул Барис булган. Тик мулла бабай аны, "мөселманча түгел, килешмәс" дип, Хариска алыштырган. Монысын әнкәй сөйләде. Хәер, миңа барыбер—Харис ни дә, Барис ни! Ике чабата бер кием түгелмени?! Сугышның кыл уртасында әнкәйне газаплап, артык тамак булып дөньяга килгән малайга ярамаган тагы.

Әнә шул сакау тәре Гыйльфан аркасында кулны кара канга батырдым. Авыздан чыгарып карадым, баш бармакның тиресе суелып чыккан, саркып кан тама иде.

Хет ичмасам "р" хәрефен дөрес әйтергә өйрәнсен иде. Шул "р"га житсә, тамак төбендә нәрсәдер былкылдый, теле агач шикелле ката Гыйльфанның. Шул каһәр суккан "р"ны әйтмәс өчен кыр талаша. Без "су керергә барабыз" дибез, Гыйльфанныкы башкача—"су коенып кайтыйк". "Бару"ны әйтмәс өчен, бөтенесен "кайту"га алыштыра да куя. Әнә хәзер дә мышкылдап килеп житкән, канлы кулны да күрмәмешкә салышып, үзенчә сукалап ята:

—Әйдә Ык буена, чумып кайтабыз!..

Әйтерсең инде ул барып житкән, кайтасы гына калган.

—Юк!—дидем мин, ана да, үземә дә үртәлеп.—Әнә... синең аркада...

—Ничек? Ни... минем жилкәдә?

Аның шул үзе өчен каһәрле "р" хәрефен әйтмәскә хәйләләп маташуын күргәч, ачуым берьюлы басылып китте тагы. Жәлләп куйдым әле. Үзем ачыкавыз булганга ул гаепләме?! Артка яшереп торган бармагымны чыгарып күрсәттем. Гыйльфан, мескен, кызганды, ахрысы, күзләре зур булып ачылды, аннары челт-челт йомылды, сузып әйтеп куйды:

—Ниш-лә-ә-әдең? Ниш-нишләт-тең?

—Әнә... чүкеч белән суктым,—дидем мин биш-алты адым читкә очкан тачка сабына күрсәтеп.—Тачка ясамакчыем...

Гыйльфан, аны күрмәгән дә шикелле, башы белән минем бармакка ымлады:

—Син ана... теге ни... си! Сисән, бер көндә яп-яңа бармакка әйләнә.

Ышанмадым. Авырткынны шулай жинел генә бетереп булса, күпме кеше көне-төне бүлнис юлын таптар идеме?

—Сөйләмә юкны,—дидем. Тагын кан тама башлаган бармакны

ашыгып авызга каптым.—Тап-тын жүл-ләрне бармакка сияргә!—Болары авызына кәнфит капкан кешенекедәй әвәләнеп чыкты.

—Һы... ышанмасаң... үзенә кара... Мин белгәнемне әйттем. Безнең әби әйтә, сидек житмеш чиргә дәва, ди.

Кем белә?! Бәлки, дөрестер дә... Гыйльфанның әбисенең белмәгән нәрсәсе юк. Яз буе, жәй буе әрәмәдән үлән жыя. Карт-коры бүлнис урынына аның янына йөри. Дөресен генә әйткәндә, мин анардан бераз гына шикләнәм дә әле. Им-томчы бит! Ниләр кыландырмас! Ә Гыйльфанның үзенең күнеле әйбәт аның. Алдаша да белми. Кояшта купшакланган битендә әнә күзләре генә елтырый. Чынлап әйтә ахрысы.

—Хәзер... Сынап карыйбыз аны,—дидем дә сарай артына йөгердем.

Жылы, кайнар агым килеп бәрелүгә жәрәхәтле бармакны ялт итеп кире авызга тыгуымны сизмичә дә калдым. Авырту бетмәде генә түгел, тагын да әрнетебрәк сызларга керешге. Ачуым чыкты. Белгән, белгән бу кара тәре! Юри әйткән! Чабатадай жәелгән авызына берне сылыйсым килеп китте. Янына ыргылдым.

—Син... син... әллә мине дивана дип белденме, бармакка сияргә? Таптың жүләрне, ә-ә?

Кыяфәтем күзге әтәчнекедәй сугышчан булгандыр, ахрысы, Гыйльфан шыпан-шыпан гына артка чигенә башлады.

—Мин бит... Мин... әби әйткәнне генә әйттем. Кем сиңа кушкан әле,—диде дә кинәт миңа карап шаркылдарга керешге, тотлыга-тотлыга әйтеп бетерде.—Чып... чып-чыгың очып китә бит!

Ихатага таба борылып, чалбар изүен тәртипкә китергән арада ачуым басыла төште тагы. Шулай да хәтерем калганны сиздерерлек итеп әйттем әле:

—Юк, су кер-рергә бар-р-мыйм, эт сугар-р-ып йөр-рергә минем вакытым жук!—дидем.

Гыйльфан күзләрен челт-челт йомып бер миңа, бер ясала башлаган тачкага карап алды да жилкәсен сикертеп чыгып китте. "Теләсәң нишлә", янәсе.

Аһ, тагын ялгыштым. Үпкәләттем бит!.. Тачкага тәгәрмәч кирәген оныттым. Беләм бит, беләм бит юкса! Вак тешле, аш тәлинкәсе чаклы, миңа кирәкле тәгәрмәч анарда гына. Хәзер шуны сорап кара инде!.. Яз көне булса, мин аны рәхәтләнеп ун шәмәйгә алыштырып ала идем. Күзе кыза иде Гыйльфанның аларга. Жәй көне кем шәмәйле уйный!?. Юкса әнә эченә кургаш койган өч аткыем, егермеләп шәмәем бар. Хәер, бирер идеме икән әле?! Лилия каршында үзенең генә батыр буласы килә бит аның. Имеш, ул гына оста. Ул гына әллә ничә тәгәрмәчле, чылбырлы тачка ясый ала.

Аңа калса, мин шәмәйне оста ясыйм. Безнең очта беркем дә алай ясый алмый. Кызганыч, кызлар шәмәйле уйнамый. Күрер иде, белер иде Лилия кемнең кем икәнен. Безнең оч, дигәнем—авылдан бер ярты чакрым читтәрәк утырган мытыес утары. Хәер, авыл дисәң дә, Вәрәш авыл ук түгел ул. Район үзәге бит. Авылларда, колхозларда үстерелгән бөтен ашлык шушында жыела. Пищпром дигән оешма бар. Ачлык йә сугыш була калса дип, анда көне-төне бәрәнге, кишер, чөгендер киптерәләр, прәннек пешерәләр, кәбестә, яшел помидор тозлыйлар. Аны әнкәйнең дә алып кайтканы бар. Авыздан сулар килә инде шул яшел помидорны күргә. Әле тагын "Кызыл көч" дигән инвалид артиле дә эшләп тора. Анысында күлмәк-ыштан тегәләр, арба-чана, тәгәрмәч тугымнары ясыйлар, дуга бөгәләр. Бөтен районны дер калтыратып торучы райком дигән оешма Вәрәшнең нәкъ уртасында. Әле аның тагын райисполком дигәне бар. Анысы да тетрәтә, тик көче райкомныкыннан кайтышрак, ди. Авылдан читтәрәк якшәмбе көннәрне олы базар була, шимбә көнне кечкә базар. И андагы байлык, андагы муллык! Берәр калак, берәр калак итеп йомарланган ак май, ит, сөт, он, ярма, балчыктан ясалган кызыл чүлмәкләр, иләкләр, сыбызгылар, уенчыклар... Урыс авылларыннан маржа-

лар тозлы кыяр, помидор, хәтта кавын белән карбызга хәтле алып киләләр. Атнасына һичьюгы бер барып йөри торган, мангаена "Когиз" дип язылган китап кибете дә, малайларга бигрәк тә кирәкле әйберләр—кармаклар, әле яңарак кына күренә башлаган лампалы радиоалгычлар, патефон табалары, пионер быргылары һәм, хәтта, ялтыравык тәгәрмәчле, кыңгыраулы велосипед—сәпидләр сатыла торган, халык арасында, нишләптер, "кутмәк"[1] дип йөртелүче кибет тә, аптека да шунда. Бер мәктәп кенә түгел, әле үсә төшкәч, алла бирса, танцыларга—сад бакчасына да шунда йөрисе. Шулай да, Вәрәш малайлары безне яратып бетерми, "мытыеслар" дип йөри. Чөнки мытыесның үз клубы, кибетләре, хәтта ашханәсенә хәтле бар. Вәрәшләргә бик ялынып тормыйбыз әле. Механик булып эшләүче Шәйхелмәрдәнов абый әйтмешли, "Мытыеслар самый сусамый". Моның нәрсә анлатканын бик төгәл белеп бетермәсәк тә, "самый"ның иң әйбәт, ин-ин дигәнне белдергәнен генә чамаламаслык малайлар түгел без. Димәк, мытыеслар төшеп калган халык түгел, иң әйбәт кешеләр, дигән сымакка туры килә ул. Вәрәшләрнең безне бик үк яратып бетермәве дә шуннан. Дәрес бетсә, ике арада сугыш-бәрелеш чыгасын көт тә тор! Хәер, без аларга бәйләнергә жай калдырмыйбыз, кыңгырау шалтырауга ялт ишеккә!..

Дөрес, малайларны укытучылар дәрестән алда чыгармый. Без түзәбез. Ә кызларга ышаныч зуррак. Хәйләкәр бит алар. Кызлар ярдәм итә.

Берзаман Вәрәш малайлары күбәеп, көчәеп китте. Шулай булмый!.. Алар арасында бер класста өч-дүрт ел утыручылар бар. Сентябрьдә килмәгәннәр иде... Беренче кар төшкәч, өй борынча йөреп, барысын да пыранлатып китереп тутырдылар. Жиде класс белемне мәжбүри иткәннәр, дигән хәбәр йөрде. Имеш, жиде класс белеме булмаганнар Совет илендә яши алмый и яшәмәскә тиеш. Әткәй белән әнкәй нишләр инде, дип борчылдым әле шул чакта.

Минем әткәйнең бер класс белеме юк. Ни өчен дигәндә, ул әле борынгы заманнарда, революциягә чаклы ук, мәдрәсәдә, үзе әйтмешли, белем эстәп яткан да... шуның белән вәссәлам! Шул эстәп кенә алган белеме белән дә рәхәтләнеп эшли әле. Мытыеста акча чутлап утыра. Тагын Вәрәштәге ниндидер "эре кеше"[2] мәктәбендә өлкәннәрне укытып йөри. Шунысы гажәп, бер грамм совет белеме булмаган кешегә кинәш сорап киләләр. "Хатыйп абый, минә шул каһәр суккан дебит-кредитны чыгара алмыйм. Очын-очка ялгап кына бирсәнә!" имеш. Мәдрәсәдә генә өйрәттеләр микәнни соң ул дебит-кредитны. Юкса, техникумдыр, курстыр кебек жирләрдә менә дигән төпле белем алган, диплом күтәреп кайткан кешеләр. Әллә юри кыланалар, әллә чынлап та белмиләр, анламассың тагы. Житмәсә, абый-апалар алгебра белән тригонометриядән мәсьәлә чиштереп интектерәләр. Бигрәк тә Гөлфиясе чәүчәләк. Көнегүләрен, мәсьәләләрен язып-бозып утыра-утыра да, "Тагын чыкмый бит инде",—дип елап, әткәй янына кантурга йөгереп керә дә китә. Андый авыр мәсьәләләрне чишәргә әткәй шул мәдрәсәдә өйрәнгәндер инде!

Дөрес, әткәйнең белеме бар инде аның, түлке, шулай да, сәвитчә түгел. Әйтәм ич, абый белән апалар укый торган морфологияне ул "сарыф" ди, синтаксисны "нәхү" дип көлдерә. Анынча, геометрия—һәндәсә, география—жәгъръфия, логика—мантыйк... Алгебраны исә ул әлжәбер, дип кенә жибәрә. И укып та караганнар икән мәдрәсәләрдә! Кайчагында миңа, мәктәптә укыткан фәннәрне мыскыл итеп, әткәй юри шулай әйтәдер сыман тоела башлый, хәтта. Безнең башлар гына житәрлекмени! Ә безгә мәктәптә һаман бер нәрсәне тукыйлар: ул тузанлы-сөремле мәдрәсәләрдә көне-төне дин сабагы ятлап, чүбек чәйнәп, еллар буе сөрсеп ятудан башканы белмәгәннәр, диләр. Әйтерсен, безнең мәктәп

[1] "Культмаг" сүзеннән бозып ясалган.

[2] РКШ—"рабоче-крестьянская школа"дан кыскартылган сүз.

тузанлы түгел (чат тузан бит инде!), әйтерсең, бездәге кәрәчин лампалары сөрем чыгармый гына яна! Алай булгач, нишләп минем әткәй сөрсемәгән икән? Ул бит инде, алай фикер йөртсән, ин сөрсегән кеше булырга тиеш. Бер яктан, укытучыларга ышанмыйча да ярамый, икенче яктан, әткәйнекен дә читкә тибәрәсе килми! Уйлый-уйлый башың катарлык. Шулай дисең дә кул селтисең. Белемне кайда алсаң да ярамый микәнни?!

Ә баш катарлык әйберләр күп икән ул дөньяда! Ул дин дигәнең, мәдрәсә дигәнең шундый иске, череп таркалган бер нәрсә булгач, нигә бүген дә һаман шундый куркыныч микән соң? Әле беркөнне әткәй белән әнкәйнең сөйләшкәнен тынлап яттым. Очраклы рәвештә генә... Без бит сәндерәдә. Безнең йоклап киткәнме, йокламаганмы икәнне алар каян белсен?!

—Сина әйтәм,—диде нигәдер әнкәй авыр сулап,—шул мәдрәсә турында сөйләп балаларның башын әйләндермәсән иде. Укысыннар тыныч кына. Мәктәпләрендә дин сабагы укытмасалар да, начарлыкка да өйрәтмиләр...

—Һы,—дип куйды әткәй.

Озак кына берни дә эндәшми яттылар. Бераздан әткәйнең ризасыз тавышы ишетелде:

—Ачуым килә шул... Әле беркөнне тагын шул хакта сүз чыкты. Теге Закирны әйтәм, партком булып йөри бит... Шул казып чыгарган. Җыелышта авыз тутырып сөйләп яткан була. Имеш, арабызда белгечлекләре буенча дипломсыз кешеләр дә бар. Аларны специалист булып кайткан яшьләр белән алыштыру турында уйларга вакыт, янәсе. Кем бакчасына таш ыргытканын беләсең инде.

—Әйтсен,—диде әнкәй көрсенеп.—Эт өрә торыр, кәрван йөри торыр...

—Соң үзенең ботыннан тотып селкесәң, авызыннан хисап эшенең "Х" хәрефе дә төшми ләбаса! Куштанланып, түрә-мүрәгә тәлинкә тотып кына кеше булып йөри бит!

—Син дә куштанлан. Өйрән. Бу дөньяда шунсыз яшәп булмый, ахрысы,—диде кинәт әнкәй бөтенләй ят тавыш белән.

Безнең әнкәйне, юк-бар гаугага, бәхәскә, ыгы-зыгыга катнашмаганы, гайбәт сөйләргә дә, тынларга да яратмаганы өчен, күрше-тирә хатыннары "эреләнә" дип йөри икән. Ул хакта кемнәндер ишеткәнем бар иде инде. Аннан мондый сүз ишетермен дип көтмәгән идем, йоклаганга салышып ятуымны да онытып, колакларымны торгыздым.

—Гомердә түрәләргә койрык болгый белмәдем, моннан кире дә ялагайланмам,—диде әткәй басынкы гына, әмма кискен иттереп.—Эштән кусалар куарлар... Анысын булдыра алмыйм. Нәселебездә андыйлар юк иде, булмады, булмаячак та...

Монысы нәкъ безнеңчә, Сәүбановларча әйтелде. Әткәй өчен горурланудан күкрәкләрем кинәйгәндәй булды, рәхәт булып китте. Шул рәхәтлектән йоклап киткәнемне сизми дә калганмын.

Әмма бераздан кемнеңдер тыелып кына елаганыннан уянып киттем. Өй эче караңгы, күзгә төртсәң берни күренерлек түгел иде. Чарасызланып елау тавышы астан, әнкәйләр йоклый торган карават ягыннан килә икән.

—Соң безнекеләрне ничек харап иттеләр,—диде әнкәй яшьләрен йотып.—Мин бит бөтен тирә-якка укымышлылыгы белән даны чыккан Әбүгалисинә хәзрәт токымыннан. Әткәйне беләсең, утыз җидедә алып киткәннән бирле кайда икәнен дә, хәтта, исәнме-юкмы икәнен дә ишеткән юк. Ичмасам, туганнарыннан берсен исән калдырмадылар. Мин бит бүген аксөяк булып, кеше арасында йөзем ак, күңелем пакь булып йөрисе кеше идем. Бабакай әйтә торган иде: "Һәр кеше кимендә җиде буын бабасын белсен,—дип.—Сез дә белегез, горурланыгыз. Нәселебез шәҗәрәсе Карабик морзаларга барып тоташа",—дип. Шул токымның соңгы кыйпылчыгы бит мин. Гарәп-фарсы телләрен, Коръән кәримне яттан

белгән башым белән, бүгенге көндә үземнең кем икәнемне белдермәс өчен, башымны диванага салып, надан бер авыл хатыны рәвешендә йөрергә мәҗбүрмен. Әй,—дип куйды ул кинәт кенә.—Хәзер ул белемнәрнең кемгә хаҗәте бар? Бу наданнар аның кадерен беләмени?!

—Шулай да, бабайга рәхмәт,—диде әткәй сабыр гына.—Вакытында ул кисәтмәсә, көнендә чыгып китә алмаган булсак, без бүген кайда, кемнәр арасында һәм нишләп йөрер идек?! Исән булыр идек микән әле...

—Анысын аңлыйм мин...—Әнкәй тагын уфтанып куйды.—Тик менә балалар туганнары барлыгын, тамырларын белмичә үсә. Олыгайгач ялгызларына кыен булыр...

Байтак кына сүзсез яттылар. Инде йоклап китәм дигәндә генә колагыма үземнең исем килеп керде, күзләрем ачылды. Әткәй сөйли икән.

—Син алай үзеңне соңгы кыйпылчык, дип кистереп, аерып куйма әле,—диде ул.—Безнең, Сәүбановлар нәселенең дә тамыры сезнекеннән кайтыш түгел. Аннары... Төпчегебез Рәшит, Харис белән Гөлфия дә, олылары да шул нәселнең дәвамы ләбаса! Аларны кая куярсың? Алар да Сәүбан баба белән Әбүгалисинә хәзрәтнең чыбык очлары... Алар да морза!

Әнкәй кинәт кенә каршы төште:

—Аллам сакласын! Балаларның үзләренә әйтә күрмә! Әле аңларлык түгелләр... Бала-чага авызында сүз тормый. Теләсә-кайда сөйләнеп йөри башласалар, Вәрәштән дә чыгып китәргә туры килмәгәе... Күчеп йөри-йөри җык булдык бит инде. Җитте, туйдым,—диде.

Әткәй аның сүзләрен җөпләп куйды:

—Әйе,—диде.—Үсә төшсеннәр. Акыл керсен әле. Акны карадан аера башласыннар. Кайчан да булса бер әйтербез әле, алла боерса...

Боларны ишетүдән кинәт бала йоннарым кабарды, тәнем эсселесуыклы булып китте. Мин—морза баласы! Димәк, мин дә ач халыкның, ярлы-ябагайның канын имеп яшәгән мулла-мунтагай нәселеннән, нииндидер җирәнгеч аксөякләрдән. Безнең мәктәптә иң ялкау, иң булдыксыз кешене генә аксөяк, сорыкорт дип сүгәләр. Китапларда да шулай язалар, укытучылар шулай дип сөйли. Мин дә шундый каһәрле бер токымнан килеп чыкканмын микәнни? Бу сорау шулкадәр авыр һәм чишеп булгысыз катлаулы иде, ирексездән тешләрем кысылды. Бик озак ярга чыгарып ташланган балыктай аңгыраеп яттым. Тик бераздан бу шом, бу курку ниндидер канәгатьлек хисе белән алышына башлады, әллә ничек кенә рәхәт булып китте. Минем бит әллә кайларда туганнарым, абый-апаларым бар икән. Аларның кайда икәнен, хәтта, әткәй белән әнкәй үзләре дә белми. Ләкин мин беләм, ышанам, әткәй белән әнкәем начар кешеләр булмаган кебек, алар да яман адәмнәр түгелдер. Менә үсеп кенә җитим, мин аларны эзләрмен, табармын... Без якын туганнар, дуслар булырбыз! Мона минем бик-бик ышанасым килә иде.

Әй... сүзем Вәрәш малайлары хакында иде ич әле. Әйе! Алар артык нык кысрыклый башлагач, нишләрбез инде, дип пошаманга төшкән идек. Ел буе укыйсы... укысаң-укымасаң да, чүбек чәйнәмәсәң дә шул мәктәпкә йөрисе бит! Кызлар коткарды... Кызлар дигәндә мин Лилияне күздә тотам. Аларның өе мытыес белән Вәрәш арасындагы бушлыкта. Әмма мытыеска якынрак. Юри адымнарны санап, үлчәп караган идек. Шулай булгач, безнеке булып чыга. Хәер, ул инде үзен күптән безнеке чутлап йөри. Класста иң чибәр кыз ул җитмәсә. Аның бер-бер бөртеге кимендә икешәр сантиметрлы керфекләре (алдаласам, җир йотсын менә, ипи чыраен күрмим!), өчәр-өчәрләп үргән озын кара толымнары гына да ни тора. Башка кызлар яшелле-кызыллы чәчүргечләр куеп үргән була. Барыбер килешми. Ә Лилиянеке... Ә Лилиянеке... ап-ак күбәләк! Ул аны ике толымының да очына кабартып куя, әйтерсең талпынып очкан

күбәләкләр инде. Билләһи газыйм, шулай!

Соңгы дәрес безнең—урыс теле. Лилия иплəп кенə кулын күтәрә дә инде дә килештереп, йомшак тавышы белән басынкы гына иттереп сорый:

—Мила Ахметовна! Зинһар, мина аз гына алдан китәргә рөхсәт итегез әле,—ди. Урысча сорый бит, чукынчык!

Укытучының чын исеме Миләүшә аның. Тик, нигәдер, ул үзен Мила Ахметовна дияргә кушкан иде. Без әле аны баштарак әллә маржа микән дип тә уйлаган идек. Вәрәшнеке түгел, Казан хәтле Казаннан институт бетереп килгән кеше бит. Безнең малайлар аны дөрес итеп әйтә аламыни?! Мыйлахмыйтывна килә дә чыга. Миләүшә апабыз йөрде-йөрде дә: "Авыл гыйбады икәнегез йөз чакрымнан күренә, тупаслыгыгызны барыбер җиңә алмыйсыз, Миләүшә Әхмәтовна диярсез",—дип рөхсәт итте. Ә Лилия аны һаман да Мила Ахметовна дип йөри.

Миләүшә апага исә шул гына кирәк тә. Урысча дөрес иттереп сорасаң, ул сиңа бер көн буе дәрескә килмәскә дә рөхсәт итәр иде. Ипидер менә. Ул теләгәнчә, шартын шартка китереп, басымын нәкъ тиешле иҗеккә төшереп әйтеп буламыни аны!.. Безнең кәлҗемә ашап үскән авыздан Миләүшә апаның бөрелгән иреннәре аша саркылучы, мәтликәпле суыргандагыдай нечкә авазлар ничек чыксын! Безнең шул "пажалысты!" инде. "Юк,—ди Миләүшә апа.—Тупас әйтәсез. Алай түгел. Матур итеп, сузып, нечкә итеп әйтегез: Пожа-а-а-луйс-та!" Ничек шуңа җаның түзсен инде. Юри әйтмибез. Ә Лилия әйтә. Әллә каян еракта, Бөгелмә якларыннан килгән бу Лилия урысчаны су кебек эчә. Көнләшеп үләрсең.

Яратмыйм шул урыс теле укытучысын. Әле беркөнне безнең "мытыес" дигәннән көлеп маташты. Тәгәрәде инде. Күзлеген салып, сөртә-сөртә көлде. Тактага яза-яза, нечкә озын бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә аңлатты:

—Язганда ул менә болай—МТС дип языла, ягъни машинно-тракторная станция, ә орфоэпия кагыйдәләре буенча эмтеэс дип әйтелә. Кыскартылган сүзләрнең кагыйдәсе бик катлаулы, ятлагыз! Алфавиттагы һәрбер хәрефнең аерым-аерым әйтелештә үзенә генә хас закончалыклары бар. Язылышын орфография билгеләсә, әйтелешен орфоэпия таләп итә.

Ятлады ди менә! Әллә нинди арфаипия куша дип, Миләүшә апа яратмый дип, хәзер кайтам да әйтәм инде әнкәйгә: "Әнкәй, мина, *пожалуйста,* бидрә бир, *эмтеэска* ат бугына барам",—дим. Әйтерсең, бар! Тилергән дип куып чыгарыр.

Чыктык берзаман дәрестән. Вәрәшнекеләр бәйләнергә җай эзләп бөтерелә башлады. Беләбез инде, боларга бер сүз җитә. Юри чекрәеп өскә менәләр. Безгә исә бәйләнерлек сүз әйтмәскә, каршы торган, искитмәгән атлы булып, әкрен генә мытыеска таба чигенергә кирәк. Һәр кеше үз өендә батыр бит. Анда якынайсак, безгә үзеннән-үзе көч керә, гайрәтебез арта башлый. Көлгән булабыз, ирен чите белән генә елмайган булабыз. Үзебез чигенәбез, чигенәбез...

Шулчак түбән очның Илфаты—былтыргы бишенчедән безнең класска төшеп калган колга буйлы бер малай—Гыйльфанның букчасыннан эләктереп алмасынмы.

—Йәле, әйт әле,—диде, тәмәке төпчеге тарта-тарта саргаеп беткән тешләрен ыржайтып.

Карамалының, кара малаена
Чана карамаларга биргән идем.
Карамалады микән,
Карамаламады микән?
Карамаласа да алып кайт,
Карамаламаса да алып кайт.
Җә, алып кайтасынмы?

Гыйльфанның авырткан җиренә тиде бу. Барыбыз да катып калдык. Чуенның унҗиденче кичәседәй кара, чандыр буйлы булса да, тыгыз тәнле Гыйльфанның йодрыгы таш аның. Кинәт ул букчасын шатырдатып йолкып алды, “Үзең алып кайт, җәме!” дип, тегенең ияк астына башы белән бәрде дә мытыеска таба элдертте.

Без дә калышмадык.

Вәрәшнекеләргә житә калды. Сынын җыя алмыйча бөгелеп төшкән Илфатны ташлап, букчаларын болгый-болгый, кычкырыша-кычкырыша куа чыктылар.

Инде мытыес утарына житәргә алтмышлап кына метр калгандыр. Физкультура дәресендәге ярышмыни! Томырылабыз гына! Коткаргыч капка әнә, кул сузымында... Шулчак арттагы малайлардан кемдер чырыйлап кычкырып җибәрмәсенме! Әллә нинди ямьсез, колакларны авырттырырлык әче тавыш иде ул. Эзәрлекләнүебезне онытып, борылып карасак... Эчебезне тотып карга аудык, тәгәри-тәгәри, ауный-ауный көлдек. Вәрәш малайлары гомерләрендә ирешмәгән тизлек белән авылга таба чаба, артларыннан исә абалап зу-у-ур соры эт куып килә иде. Илфатның болай да сөрсеп, череп беткән иске сырган чалбар төбе умырылган, мытыесның ипи кибетенә бәйрәмнәрдә генә кайтартыла торган өч тәнкәлек йомры күмәч төсле, ике күт бите кызарып күренә, йөгерү тизлегенә карап алар алмаш-тилмәш сикерешә иде.

Соры эт малайларны авылга хәтле өерттереп илтте дә койрыгын болгый-болгый кире чапты. Якында гына кемдер сызгырып җибәрде.

—Сизгер! Сизгер! Кайт! Өйгә, өйгә!—дигән тавыш ишетелде.

Борылып карасак—шаклар каттык. Авыл белән мытыес арасындагы өйнең капка төбендә Лилия басып тора. Ул, куш бармагын авызына тыгып, малайларча әче итеп тагын бер сызгырды да янында сикергәләгән этне житәкләп кереп тә китте.

Әй, шәп кыз да инде ул Лилия! Һаман-һаман янында бөтерелеп маташкан малайларның берсенә дә исе китми. Ну минем кыюлык житеп бетми. Гыйльфаннан кай җирем ким инде югыйсә? Кыенмыни инде тәнәфес вакытында толымыннан тартып китү!.. Җә булмаса күбәләген йолкып сүтү. Сүтелеп төшсен иде дә, карап тор идең читтән генә шуны янадан күбәләкләп бәйләвен!.. Булмый инде булмагач. “Ачыкавыз! Мәмкә! Җебегән!” дип үземне сүгеп тә карадым, “Иртәгә барам да ишектән кергәндә юри бәрелеп китәм әле”, дип йөрәкләндем. Икенче көнне исә ул якынлаша башлауга адымнарым акрынайды, сизәм бит инде, йөзем кызарды, телем авыз куышлыгында кирәксез, артык бер нәрсә булды да калды. Йә, шуннан соң әйтеп кара инде берәр сүз. Телең агач булгач, нишлисең?!

Хәер, анысы да дөрестер. Әнкәй мине һаман-һаман: “Олы тел, телең авызыңа сыймый. Өлкәннәр белән сөйләшә белмисең”,—дип сүгә. Сүксен! Сүксә дә әйбәт кеше ул! Ничек итеп сөйләшергә инде тагы. Алар ничек сөйләшсә, мин дә шулай сөйләшәм. Алар “Гөлҗамалларга керәм”, дисә, мин дә “Гөлҗамалларга керәм”, дим, “Заһретдиннар килгән”, дисә, мин дә шулай... Юкса, белеп торам бит инде Гөлҗамалның житмештәге әби, Заһретдинның алтмыш яшьлек карт икәнен. Шул ашыгуларым харап итә дә ташлый, уйлап тормыйча әйтәм дә салам.

Мин аны үзем болай дип уйлыйм инде: минем телем буема караганда тизрәк үскән дә авызны тутырган. Үсә-үсә, алла боерса, буем да, авызым да олайгач, телем бәп-бәләкәй генә булып калыр әле. Менә күрерсез!

Әй, шул телем аркасында күргәннәрем! Берзаман чак кына кушамат ябышып калмады...

Вәрәшнең түбән очында, күпер башында гына утил-сирия, ягъни иске-москы җыючы абзый яши. Бер аягы туры, икенчесе кисәү агачы шикелле артка каерылып торганга, ул йөргәндә йә тураеп баса, йә кинәт кенә аска төшеп китә. Авыл халкы аны үзара сөйләшкәндә Бата-Калка дип йөри. Иске самавыр, йомырка (аның янасы кирәк, әлбәттә), жиз-

бакыр, тимер-томыр, сөяк-санак, чүпрәк-чапрак тапшырып анардан менә дигән кармаклар, дәфтәр, сагыз алырга була. Кармакларнын да нинди әле! Күкин белән керкә каптыра торган кылчык кармак дисенме, чучка баласы чаклы жәеннәр тотарга ярашлы ыргак хәтлесе дисенме!..

Без дә киттек Гыйльфан белән көннәрдән беркөнне анын янына. Кесәләребезгә йомырка салдык, чоланда аунап яткан борынсыз самавырны икебез ике яктан житәкләдек.

Ишегалдында Бата-Калка абзый үзе каршы алды.

—Йә, жегетләр!—диде ул безне олылагандай һәм самавырга күрсәтте.—Бу алтыныгызны нинди малга алыштырырга инде исәп, ә?

Беренче булып Гыйльфан телгә килде:

—Кармак кирәк иде...

Мин ярдәмгә ашыктым:

—Жилка да кирәк, Бата-Калка абый! Безнен күкәебез дә бар әле...

Иске-москы жыючы "ә" дә, "жә" дә димәде, безгә каш астыннан гына карап алды да мәче житезлеге белән якындагы кычытканлыкка үрелде. Аннан мондый да житезлек, мондый да астыртынлык көтмәгән без фәкыйрьләрегез авызыбызны ачарга да өлгермәдек, шәрә аякларыбызга берьюлы әллә ничә утлы энә кадалды.

Тыкрык башына житкәч кенә самавырны ташлап качканыбызны анлап алдык. Житмәсә, тотып чапмагач, йомыркаларыбыз сытылган, юка чүпрәк аша шикле булып аклы-сарылы сыекча тибеп чыккан иде.

Бакча артлатыш кына Ык буена төшеп киттек. Бу хәлдә өйгә кайтырлык түгел. Чалбарларны салып сыктык, олыларнын мәкере турында Гыйльфан белән озак зарланышып яттык әле. Без ни начарлык кылган инде бу Бата-Калкага!?

Өйгә сон гына, кояш баеганда гына кайттык. Әнкәй ачуланмады, ярты йомры кәжә сөте белән яна гына мичтән чыккан хуш исле арыш ипиенен кибән башын каршыма куйды да озак кына мина карап торды. Ни ярата торган ипием тамагымнан үтмәде, йомрыны тотып читкәрәк атлый башлаган идем, әнкәй өстәлгә ялтырап торган кармаклар, бер бәйләм жилка китереп салды.

—Гаделша абыен кертеп чыкты... Онытып калдыргансын,—диде ул нигәдер тагын бер кат мина карап.

Аркам чымырдап китте. Ачулануын, битәрләвен көттем. Иске-москы жыючынын исеме бар икән ләбаса! Гаделша абый икән ич ул!

—Борынына киртлә,—диде, ниһаять, әнкәй,—кешегә кушамат белән эндәшсән, икенче көнне үк үзенә дә шундый ук яман исем тагарлар! Йә, үзеннен дә Бата-Калка буласын киләме? Әллә сина башканы, хәтәрләгән, ямьсезрәген табыйкмы?

Телгә беткән кеше булсам да, каршы әйтергә жавап тапмадым. "Мытыеста кушамат такмыйлар",—дип әйтәсе калган икән дә бит! Хәер, әнкәй белән бәхәсләшү файдасыз. Анын үз туксаны туксан. Югыйсәм, мытыеста да кушамат тагарлык хәлләрнен булганы бар иде инде. Таксалар, инде әллә кайчан Гыйльфанга тагарлар иде. Такмадылар бит! Авылда гына ул кушамат! Әйтәм бит, мытыес ул шәһәр кебек. Мондагы халык та бит Вәрәшнеке түгел, кайсысы кайсы яктан жыелган кешеләр. Берберсен белеп тә бетермиләрдер әле алар....

Һаман шул Гыйльфаннан чыга инде. Хәйләкәр бит ул! Мытыес клубында кинолар ешаеп киткәч, гел клуб тирәсендә бөтерелә башлады бу. "Күзенә чалынып торсан, ярдәм иткәләсән, киномеханик абый бушка кертер", янәсе. Өмете акланды тагы. Анын белән мин дә бушка керүчеләрнен берсе булып киттем. Безгә рәхәт! Сәхрә!

Киномеханик абыйнын безне үз итүе, безгә ышануы шул дәрәжәгә житте ки, көннәрдән беркөнне хәтта яна кайткан кинога афиша язып элүне кушып китте. Бездә кино белдерүен, ягъни игъланны, шулай "афиша" дип кенә йөртәләр.

Кин плакат каләмен шәмәхә карага манып числоны язып куйдык.

Инде исемен генә төшерәсе. Кино тасмасы салынган зур калай банкалар янында Гыйльфан бик озак мышкылдады. Бераздан тавышы ишетелде:

—Харис, малай, син моны аңлыйсыңмы соң?—диде ул, ниһаять, гел-гел минем ярдәмгә таянуын бик үк сиздерергә яратмаса да. Үзенне аклау өчен иң әйбәте кемнедер сүгү икәнлеген генә белә ул, әнә тагын сөйләнеп маташа.—Әйтерием инде, кеше төсле иттереп, чатнатып яза да белмиләр. Хәрефләре каты җилдә уйнаклаган арыш басуымыни...

Икәүләп, хәрефләп тә, иҗекләп тә укып карадык. Әмма, калай банкаларның тышына ябыштырылган кәгазьдәге сүзләрнең мәгънәсенә безнең баш кына җитәрлек түгел иде. Алай итсәк тә, болай итсәк тә "Жизнь ирошио шишо" килә дә чыга.

—Әй, ярар сана, чит ил кешесенең исемен аңлап буламыни?!—дип кул селтәде Гыйльфан һәм авызыннан телен чыгара-чыгара, хәрефләрен матуррак итәргә тырышып, белдерүгә кинонын исемен язарга кереште.—Һинд киносы дигәч, моңа мытыеслар гына түгел, бөтен Вәрәш агылып килә инде, кереп тулалар инде. Урынны алдан алып куясы булыр...

Кичкә бөтен Вәрәш урамнарында "Жизнь Ирошио Шишо" дигән афишалар эленеп тора иде инде.

Залга кереп утырдык. Сәхнә түренә тарттырылган ак җәймәгә ут көлтәсе бөркелде һәм көндезен генә әле Гыйльфан белән без күпме баш ватып та аңламаган сүзләр балкып килеп тә чыкты: "Жизнь прошла мимо". Гыйльфанның ничек булгандыр, белмим, әмма ялкын эчендә уйнаклаган бу хәрефләрнең кызуыннан минем колакларым ут булып яна башлаган иде. Вәрәш малайларының мыскыллап көлүен, кычкыруын көттем. Беркем дә дәшмәде. Әллә инде кинонын исеменә карап та тормадылар, әллә һинд киносы дигәч дөньяларын оныткаинар иде.

Барысы да шулай шома гына, җиңел генә үтте дә китте. Юкса, әнә, Гыйльфанга менә дигән кушамат була иде. Беркем дә сизмәде, беркем дә такмады бит. Икенче көнне киномеханик абый гына Гыйльфанның кырдырып алынган такыр башыннан чәчләрен баш бармагы белән артка таба сыдырды да "Их син, Ирошио Шишо!" дип куйды. Менә шул! Кушаматны аны мытыеста такмыйлар. Ул сиңа авыл түгел. Почти шәһәр. Бездә бит колхоздагы шикелле көнгә бер таякка—хезмәт көненә эшләп йөрмиләр, вәрәшләр әйтмешли, уч тутырып акча алалар. Тутырырлар, көт! Ничек тутырганнарын беләбез инде!

Тукта, нәрсә турында сөйлим, дөресрәге ни хакында уйлана идем соң әле?!

Ә-ә... Тачка тәгәрмәче... шәмәй турында иде бит әле. Шәмәй ясау хакында.

Өйдә сыер аягы пешсә—бәйрәм. Тик сирәгрәк эләгә ул бәхет. Айга бер, күп дигәндә ике тапкыр—мытыес кәнсәсендә чут төймәсе тартып, әнкәй әйтмешли, кемнең күпме акча эшләгәнен чутлап утыручы әткәй палучкы яисә авансы алганнан соң була ул. Әткәй акчаны шулай без анламаслык сүзләр белән "палучкы" йә "авансы" дип сөйли.

—Менә, сиңа әйтәм, палучкыны алып куй әле!

Энекәшем белән мин сәндерәдән башны сузабыз. Кеше акчасын чутлап утырырлык булгач, әткәй үзенә палучкыны зурдан аладыр, акчасы күптер сыман тоела. Без шуңа өметләнәбез.

Әткәй исә түш кесәсеннән бөкләп салынган кечерәк тастымал хәтле нибары ике кәгазь чыгарды да өстәлгә салып тигезләргә кереште. И ходаем, шул ике бит кәгазьне авыз тутырып "палучкы" дип йөриләр микәнни?! Менә үсеп кенә җитим, мин аны, алла бирса, берьюлы йөзәрне... меңәрне эшләп алырмын әле, дип хыялланам. Рәхәт булып китә.

Әнкәй "тастымал"ларны алып яктыга куеп, ялган түгелме икән, дип тикшереп карады. Гадәте шундый аның. Чын акчадан, яктыга куйгач, Ленин башы килеп чыга, имеш. Чындырмы, ялгандырмы? Тотып карамагач, каян беләсең. Җылы сәндерәдән төшеп: "Бир әле, әнкәй,

акчаларны, мин дә тотып карыйм, Ленин башын күрәсем килә",—дип әрсезләнә алмыйсын бит инде. Күрсәтерләр сина Ленин башын! Каеш белән...

Чынлыгына ышанды булса кирәк, кульяулыкка төйнәп кесәсенә тыкты да авыр сулап куйды:

—Бүтән булмыймы?

—Каян булсын инде!—дип көрсенде әткәй.—Ике айлыкны йолкып калдылар бит. Әле монысын да көчкә-көчкә генә... Баш бух әйбәт кеше... Сафинны әйтүем. Анлады. Ул булмаса!.. Калганын алдагы айда тотып калырбыз, диде.

Әткәй шулай гел без анлап бетермәгән сүзләр белән сөйләшә ул. Әле менә тагын үзләренен баш хисапчылары Сафин абыйны "баш бух" диде. "Кешене бух дип әйтергә ярамый, урысча бух ул алла дигән сүз икән. Безнен Мыйлахмыйтывна шулай ди",—дип әйтәсем килә, телем кычыта башлый. Әмма әткәй белән әнкәй сөйләшкәндә безгә тыгылмаска кушылган. Түзәсен инде. Бер караганда, акча биргән кешегә, бәлки, бух дип әйтергә дә ярыйдыр. Бөтен тормышыбыз шул акчага бәйләп куйган кебек бит.

Әнкәй генә әрнүен тыя алмый, шулар теленә килә дә чыга:

—Сугыш беткәч жинеләерме әллә дигәнием... Кая ул!.. Бу займ дигәннәре чистый жилеккә үтте. Хет, ичмасам, болай кычкыртып талаганчы, бөтенләй түләмәсеннәр ие... Хәерчелектән башлары чыкмасын диләр, инде әллә...

Әткәй, әллә нишләп, дерт итеп китте. Башта ике як тәрәзәгә, аннан сон, упшыжитиядан калган гадәт буенча, ике як стенага күз салды, барып ишекне ачып карады һәм кинәт ачу белән идәнгә төкерде, көтмәгәндә үзалдына елмаеп куйды. Шуннан сон гына әнкәй янына килеп утырды да, тынычландырырга теләгәндәй, акрын гына әйтеп куйды:

—Бу яман гадәттән кабердә дә аерылып булмастыр, ахрысы, сина әйтәм... Кемдер сата, кемдер бата, дигәндәй... Стеналарнын да колагы бар. Балалар каршында алай сөйләшү ярамас иде, диюем.

—Әй, кадалыплар гына китсеннәр сәнә! Әнә бишесен биш якка жыеп алып китсеннәр... Үзләре карарлар, ичмасам.

Әнкәй сыкрап сәкегә утырды да ике кулын ике тезенә куеп уйга калды. Тамагыма төер килеп тыгылды. И жәлләдем әнкәйне шул чакта. Төшеп юатасы, жылы сүзләр әйтәсе килде. "Менә мин генә үсим... Үскәч, үскәч... күрсәтермен әле! Болай елатырлык итмәм. Белермен нишләргә".

Казанда аш кайный. Сыер аягы. И-и анын тәмле исләре! Баш әйләнә, авызга төкерек жыела. Пешеп житкәнен көтә-көтә чыдыен бетә, чыгып коры шәмәйләрне кимерер хәлгә житәсен...

Менә бервакыт аш пешеп чыга. Әнкәй сөяктән ябышып калган итне, тирене, сенерне каезлый. Сөяк—безнеке! Ботинка табанылай каты, тыгыз сенерне тешен үткән хәтле кимерәсен дә шәмәйләрне аерып аласын. Карт сыер аягы булса, сөякләрне тагын салып кайнатмыйча теләгәненә ирешермен димә! Ә мин жайлы юлын таптым. Үзебез кимергәч, тотам да сөякләрне Тигрга чыгарып бирәм. Тигр "эһ" иткәнче мина шәмәйләрне чистартып бирә дә инде. Бер генә сенер жепселе дә, йоны-фәләне дә калмас! Дөрес, вакытында кире тартып ала белергә дә кирәк. Юкса, Тигр аларны кайчагында кимереп, чәйнәп бетермичә туктый алмый, һәр нәрсәдә чама кирәк шул!

Әле тагын бер серне ачыйммы? Монысын жир йөзендә бер мин генә беләм, Тигр үзе исәпкә керми. Тынлап карагыз әле: Тигр—Сизгер... Тигр—Сизгер... Һа, вәт шул-шул! Тигр белән Сизгер гел бер төрле янгырый.

Бәләкәй генә, елтыр күзле нәни бу йомгакны мин зур булып үсәр, дошманнарына кара яшендәй ташлана торган дәү эт—овчарка булып житешер дип уйлаган идем. Хәер, бәләкәй димәгез сез аны. Һы... кирәк чакта ул Сизгердән дә уздырып жибәрә. Курку дигәннен "к" хәрефен дә

белми. Сизсен генә миңа кемнендер кырын караганын, бирим генә бер сигнал—филенә дә барып ябышачак!

Үзебез бер-беребезгә охшамаган, исемнәребез дә төрле, ә менә этләребезнең кушаматы аваздаш. Лилияне әйтүем. Миңа исә, и ходаем, бу кадәр дә ямьсез исемне каян гына таптылар икән?! Харис! Харис, дигәндә тамак төпләре хырылдый, уртасына җиткәч ырылдый, әйтеп бетергәч тә әле ысылдап кала бит: Хх-а-рр-и-сс... Лилиянекен карагыз. Ли-ли-ә! Ли-ли-ә... Үзе бер көй, үзе бер моң! Сузып җырла да җибәр инде.

Лилия, Лилия,
Лилия, гөлкәем!
Сине күргәч күтәрелә,
Нигәдер, күңелкәем.

Әллә нинди әйбәт, моңлы җыр түгел инде түгелен. Тик шунысы бар, мин аны үзем чыгардым бит! Һәм мин аны кеше алдында җырламыйм да. Эчтән генә... Болынга чыккач кына. Җырлый белмәвем дә хак инде. Үз гомеремдә бер тапкыр сәхнәгә чыкканым булды, үлә язып дулкынландым, шунда, исән калсам, кеше каршына чыгып җырламаска ант иттем. Дулкынлануның ни икәнен дә беренче мәртәбә шунда белдем инде мин.

Икенче класста укыган чак иде ул. Һаман да шул Гыйльфан инде. Ата-аналар җыелышына концерт әзерлибез дигәч, чистый бәйләнде бит.

—Әйдә, икәү чыгып җырлыйбыз,—ди. Өзми дә, куймый да.

Җитмәсә, класс җитәкчесе Шәмсия апа ишетеп калган. Ул үзе үк җыр дәресен дә алып бара, радиодан, патефон табасыннан ишеткән җырларын отып кала да килеп безгә өйрәтә.

Шәмсия апа бездән бер дә юньле нәрсә чыгар дип көтмәгән, ахрысы, Гыйльфанның “Җырлыйбыз” дигәнен ишеткәч, күзлеген маңгаена күтәреп, беренче кат күргәндәй, каш астыннан әле миңа, әле Гыйльфанга карап торды да нәкъ бәләкәй кызларча кулын чәбәкләп куйды:

—Бәй, сез булдырасыз аны! Бакчы, менә дигән дуэт чыга бит сездән!..

Ни-нәрсә чыгасын аңлап җиткермәдем. Без клоун түгел. Аңлатырга ашыктым:

—Шәмсия апа, без инде әллә нинди дуэт-муэтлар чыгарып маташмабыз. Гыйльфан җырлау турында әйтә ул,—дидем.

Класс җитәкчесенә безнең җырларга теләү ошады, ахрысы, рәхәтләнеп көлде, кулъяулыгын эзләп изаланды да, тиз генә тапмагач, чәнти бармагы белән күз читләрен сөрткәләп алды. Минем болай әйтүем ризалык шикелле ишетелде, күрәсең, кинәт ул җитдиләнде дә көлүен тыеп, ят бер тавыш белән сорады:

—Нинди җыр җырлыйсыз соң?

—“Комсомолка Гөлсара”ны,—диде теленә шайтан төкергән Гыйльфан.

Хет башта минем белән сөйләшсен, киңәшсен иде. Берәр матурракны, мәхәббәт, ярату, гашыйк ярлар, һич югы сагыну-саргаю турындагысын да җырлап була бит аның...

Шәмсия апа дәфтәренә олы хәрефләр белән язып та куйды. “Комсомолка Гөлсара”. Башкаралар икенче “а” классы укучылары Гыйльфан Идрисов һәм Харис Сәүбанов”. Бетте! Чигенер урын калмады. Кәгазьгә язып куйгач, чыгара да чыгара инде бу безне сәхнәгә. Ярамаган идеме шунда декламация сөйлим дип котылырга!? Абый-апаларның сөйләвеннән беләм, класста җырга сәләтле өч-дүрт кенә кеше була икән, концертларны гел шулар җилкәсенә өяләр икән. Менә җырларбыз да, унынчыны бетергәнче артист булып йөрергә калыр. Укырга вакыт та тимәс. Ә декламацияне аны кем дә сөйли. Аларга әйләнеп караучы да юк...

—Шулай! Башыбызны элмәккә тыктык инде,—дидем Гыйльфанга ачуым килеп.

—Нигә?—диде ул бернәрсә дә булмагандай.—Җыр дәресендә барыбер җырлыйбыз бит. Алай бик курыксан... Авызыңны ачкалап кына торырсың. Үзем генә җырлармын.

Курыкты ди менә! Һи, башлы да инде бу Гыйльфан. Белде нинди сүз әйтергә. Минем бернидән дә курыкмаганны белә ич ул! Арадагы киеренке мөнәсәбәт юлга салынды. Кул бирештек. Ике илнең дәүләт башлыкларымыни!

Концерт көне дә килеп житте. Тез башлары чыгып, бөкшәеп торган чалбарны әнкәйдән юдыртып алдым. Үзе юып бирде инде, анысы... Кеше алдына чыгасы бит. Ак күлмәк тә киеп җибәргәч, ярыйсы гына җүнле кешегә охшыйм икән тагы. Апалар—алар минем икәү—тыңлаусыз чәчләремне вазелин белән дә майлап тигезләмәкчеләр иде, кулларыннан көчкә ычкындым.

—Әй, йөрсен сана пумала баш булып, кеше сүзен тыңламагач,—дип кул селкеде аупа.

Анысы—олысы. Гәүдәсе туп шикелле йомры булганга күрә аны аупа дип йөрим. Аупа дигән сүз үзе дә менә йомры булып, түгәрәк булып тоела. Кечесе—нечкәсе, буйга тәбәнәк, миннән дә уза алмаган инде, анысы—апа гына. Бик апа дип әйтәсем килеп тормый торуын, әмма безнең өйдә гадәт шундый: үзеңнән ике генә яшькә өлкәнрәк булса да, апа, имеш. Тапканнар! Миннән дә тәбәнәк башы белән нинди апа булсын ди инде ул. Аларны калынлык билгесе белән нечкәлек билгесе дип үртим. Хәер, үпкәләмиләр тагы. Аупа гына, эләктереп алса, кулыннан ычкынырмын димә. Нишләп шул хәтле кочаклашырга ярата микән ул?! Белмәссең. Пыр тузып, аяк-кулларың белән чапаланып көчкә котыласың. Аңа нәрсә, авызын җәя дә:

—Бу да җегет кисәге ләбаса! Шул хәтле кыргый булмасаң,—дип такмаклый-такмаклый, рәхәтләнеп көлә.

И бар соң дөньяда бер кайгысыз кешеләр! Сәхнәгә чыгарып җырлатасы иде бер. Белер иде...

Ачуымны китерсә дә, бер ягы ошый аупаның: гомердә ишетмәгәнне әйтә бит, егет, ди. Үземне дастыйн буйлы, хром итекле, нишләптер үзем дә белмим, ак кәчтүм-чалбарлы сөлектәй егет итеп күз алдына китерәм дә, рәхәт булып китә. Җитмәсә, кулымда алтын сәгать тә бар, имеш!.. Җитәр микән андый вакытлар?!

Мәктәп залы шыгрым тулы иде. Әстәгыфирулла! Өч класстагы туксанлап балага шул хәтле ата-ана җыела димени! Юри, мәзәк эзләп килгәннәрдер әле. Өйләрендә эшләре юк микәнни соң боларның.

Җыелыш өлешенә безне кертмәделәр. Анда ни сөйләгәннәрдер, белмәдек. Хәер, өйгә кайткач, түкмичә-чәчмичә безгә барыбер житкерәләр аны. Житкерү генәме, мәктәп политикасын тал чыбыгы белән үткәрергә дә күп сорап тормаслар... Беләм инде мин. Күргәнем бар. Аупа хәтле аупага эләккәнне...

Үзебезнең номерны көтә-көтә җан чыга язды. Ай-һай, авыр икән бу көтүләре! Авыз ачып кына торасы булса да, йөзләгән кеше каршына чыгу шикләндерә, аяк буыннарына хәтле йомшады шикелле. "Адәм хуры булмасак ярарые!" дип эчтән генә теләкләр тели-тели вакытны көчкә үткәрдем. Гыйльфанның хәле ничектер, белмим, ә мин сәхнәгә чыгар алдыннан ярым үлек идем инде.

Шәмсия апаның безне игълан иткәне әллә каян, томан эченнән генә ишетелгәндәй тоелды. Сәхнәгә чыгып бастык. Кылт итеп аупаның өйрәтеп куйганы искә төште: берүк залга карый күрмә, ату бетәсен, тәгәрисен, дигәние. Их, сүзкәйләрен тоткан булсамчы! Залга каравым булды, күз алларым карангыланып китте. Барысы да ашардай булып безгә текәлгән. Аю кәмите күрсәтәләрмени... Шулчак әткәй белән әнкәйне күреп алдым. Икесе дә башларын аска игән. Әчем жу итеп китте. Берәр

әйберем чыгып, күренеп тора, ахрысы, минем өчен оялалар. Тиз генә шикле җирләрне капшап чыктым. Юк. Барысы да тәртиптә. Йа ходаем, ярдәменнән ташлама!

Сөйләве генә озак, болар бөтенесе бер секунд эчендә булгандыр. Башым әйләнә башлады, зал давылга эләккән көймәдәй чайкалырга кереште, күз алдындагы бар әйбер йөзеп китте кебек. Аумас өчен Гыйльфанга сөялдем. Ул да шуны гына көтеп торгандай, җилкәсе белән миңа терәлде дә бар көченә кычкырып җырлап җибәрде:

Дошман бик күп иде тирә-якта,
Туплар шартлый иде кырларда...

Кинәт тамагы карлыкты да тотлыгып туктап калды Гыйльфан. И-и бар икән күрәселәрем! Аның бу гадәтен бөтенләй онытканбыз. Җырлаганда тотлыкмый иде ич ул. Ни генә булды,ниләр генә булды соң?! Җир ярылса, җир тишегенә кереп китәр хәлгә җиттем. Адәм мәсхәрәсе, хәзер хур булабыз, бетәбез...

Бар көчемне җыйдым да, тамак төбе белән кычкырып, җырны күтәреп алдым:

Дошманнарга каршы икәү бергә киттек,
Үткен кылыч алып кулларга...

Бу мизгелләрдә мин үзебезне дошман явы каршына баскан ике батыр сугышчы итеп күз алдына китердем. Әсир төшкәнбез, имеш. Безне, кулларыбыздан каерып, баганага бәйләгәннәр, тәннәребезне утлы шомполлар белән яндыралар, кыздырып йолдыз сурәте басалар. Ә без, дошманның күзенә туп-туры карап, бу җәзаларны, бу газапларны сизмичә, тешләребезне кысып җырлыйбыз да җырлыйбыз. Безнең бүтән чара юк. Дошманны шул җыр белән генә җиңә алабыз. Менә каныбызга буылып җиргә егылырбыз, ә дошман өстендә һаман җыр яңгырар, канатларын җәйгән бөркет кебек өскә, биеккә күтәрелер...

Җыр кайгысы кинәт аска, җиргә тартып төшерде. Алдагы куплетны белмим ич. Белмим! Гыйльфан әле һаман аңына килә алмаган. Нишләргә? Нишләргә? Янабыз. Кычкырып янабыз... Авызымны ачкан көйгә каттым да калдым. Шул ук мизгелдә (менә, әбекәй әйтмешли, алланы юк диген син), Гыйльфанга тавышы әйләнеп кайтты, колак төбемдә генә чиңауга охшаш өн ишеттем.

Синең атың алмачуар иде...

Беткән баш беткән, кулымны Гыйльфанның иңнәренә салдым, ул мине кочаклап алды, бар көчемне салып, кычкырып җибәрдем:

Ә минеке тимеркүк иде...

Алга таба ничек җырлаганбыздыр, хәтерләмим, кул чабуны да, залның шау-гөр килгәнен дә ишетер хәлдә түгел идек. Урам исерекләре кебек кочаклашып, алпан-тилпән атлап чыгып киткән генә истә калган.

Менә ничек була икән ул дулкынлану! Ходаем күрсәтмәсен, бүтән кирәк түгел! Алтын бирәм, дисәләр дә, сәхнәгә бүтән чыкмыйм.

Шәмсия апа безне аркадан сөеп куйды, башыбыздан сыйпады да:
—Менә, бик матур дуэт килеп чыкты,—диде.

Дуэт дигәннәре шундый була икән! Шәп икән... Адәм көлкесе!

Мин таш күңелле кешедер, ахрысы. Шуннан бирле бүтән дулкынланганым юк. Бик теләп тә тормыйм. Китапта гына язалар бит ул, берәр нәрсә булса, "гаҗәеп дәрәҗәдә дулкынланды, хис дөньясында йөзде", дип. Беләм мин дулкынлануның ни икәнен! Кеше үз гомерендә дулкынланса, шул, бер мәртәбә дулкынланадыр да бүтән алай итмәскә тырышадыр. Минем дә шулай. Бик дулкынланасым килеп тормый әле. Эш болай да муеннан.

* * *

...Без авылның ин читендә торабыз. Быел яз гына күчендек әле. Анарчы мытыес упшыжитиясында җан асраган идек. Койма буена тезеп салынган тар, кысан бүлмәле, бер катлы озын агач баракларны шулай упшыжития дип йөриләр. Аның ин кырыйдагысы биш ишекле. Ишек саен бер дөнья, бер гаилә. Без уртада. Бер якта токарь Вафиннар, икенче якта механик Шәйхелмәрдәновлар. Үч иткәндәй, икесенең дә ими балалары бар. Чак кына шакылдарга, берәр нәрсә ясарга тотындыңмы, стена кагалар. Баланы уятасыз, имеш.

Упшыжитиядан туюыбыз шулхәтле нык иде ки, мич чыгарганны да көтеп тормадык, яз житүгә эчмәк, юрган белән мендәрләрне, сынар өстәл белән алты данә урындыкны, тутык калайлы иске сандыкны мытыес алашасына төядек тә күченеп китеп тә бардык.

И-и ул үз өендә торуның рәхәтлекләре! Хет көне буе шакылда, сикер, жырла, бие, көл—беркем дә килеп стена какмый, һәм без шакылдыйбыз да...

Әткәй каяндыр иске такталар юнәтеп кайтты да сәке корып җибәрде. Безгә бөтен түшәмне инләтеп сәндерә ясап бирде. Җылы. Рәхәт. Аяк-кулларыңны чәчеп ташлап, таралып йоклыйсың. Юрган да кирәкми. Үз дәүләтебез, үз йортыбыз. Хәер... Артык зур түгел ул. Әткәй белән абый сантиметрлап үлчәп йөрделәр. Ине дүрт, буе дүрт ярым метр. Урам якка ике, ишегалдына тагын бер тәрәзә. Шунысы әйбәт: тәрәзә аз булгач, суык аз керәсе икән. Монысы да безнең файдага.

Түбәсен Багшай күленнән урып кайткан камыш көлтәләр белән дә ябып җибәргәч, ул нәкъ әкияттәге өйләрне хәтерләтә башлады. Убырлы карчык өе дияр идең, тәпиләре генә юк. Басу ягына чыгам да сокланып карап торам. Беркемдә дә мондый яшел түбә юк. Аларныкы инде саргаеп, тузып беткән, җил тузгыткан. Ә безнеке—картинкә!

Әле хәзергә ихатада ялгыз утын сарае белән кәҗә ябарлык бәләкәй лапастан башка берни дә юк. Тавыклар да, казлар да шунда.

Әткәй булачак ихатаның почмакларына баганалар кагып чыкты. Урам якка кечкенә капка әтмәлләде. Аннан соң монсу гына көлде:

—Нәкъ ыштансыз билгә каеш буган кебек булды инде бу,—диде.— Ирексездән Хуҗа Насретдинга әйләндек менә.

Дөресен генә әйткәндә, өйнең читтә булуына баштарак эчем бик пошкан иде. Әле былтыр ук, план бирәләр дигәндә үк, эчтән генә хыяллана идем: әнә, Лилияләр янында күпме буш урын! Шуннан бирерләр дә, Лилия белән икәүләп, парлап мәктәпкә йөрербез, дәрес хәзерләргә йә мин аларга, йә ул безгә керер... Хыял чынга ашмады.

Хәер... Болай әйбәтрәк тә әле! Сагынып торасың. Су кирәргә барганда барыбер мин алар яныннан үтәм, кайтканда тагын шуннан урыйм. Көнгә бер тапкыр күрмичә калмыйм мин аны. Тик, нигәдер, эреләнде әле ул. Элегрәк, беренчеләрдә укыганда, кызлар-малайлар бөтенебез бергә җыелышып төшә идек Ык буена. Хәзер Лилияне трактор белән тарттырып та алып бара алмыйсың. Кызлар гына җыелалар да мышык-мышык көлешә-көлешә үзләре генә төшеп китәләр. Малайларны санга сукмыйлар, янәсе.

Без дә кимен куймыйбыз. Су буенда киемнәрен таба калсак, каз боты кимертмичә калмыйбыз инде. Анысы хак.

Күлмәкнең җиңен йә булмаса чалбарның балагын чиләп бәйләп куюны бездә каз боты кимертү диләр. Судан күшеккән чыккан кеше нишләсен, дер-дер калтырый-калтырый тешләре белән төенне чишәргә азаплана, ягъни каз боты кимерә. Әле тагын тозлы каз боты бар. Ык буенда тозлы суны каян аласың? Чамалыйсыздыр, шәт...

Әле беркөнне Гыйльфанга ачуым килеп үлә яздым.

—Әйдә, тозлы каз боты кимертәбез,—димәсенме. Башыма кан йөгерде, изүеннән электереп алганымны сизмичә дә калдым.

—Лилиягәме? Лилиягәме тозлы каз боты!

—Юк инде, юк! Шаярттым гына бит мин....

—Шаяртуның да чиге бар аның,—дидем кулларымны ычкындырып.— Әнә, беркөнне Илфатлар үзенә тозлыны кимертте. Тәмле булдымы соң?

Чак кына сугышмыйча калдык. Әгәр шунда башка малайлар араламаса, йодрыкка барып җитәдерие. Борылып карасам! Каһәр генә суккан нәрсә икән, аклы-каралы йолкыш кына бер бозау чирәм өстенә салып калдырган чалбарымның балагын чәйнәп маташа. Бетерә бит! Бетерә...

—Аһ, мур кыргыры!—дип чыбык тотып өстенә сикердем.

Ташлап качасы бит инде чучкага... Юк! Сыртына чыбык төшү булды, чалбарны капкан көйгә артын сикертә-сикертә чабып та китте. Куып җитеп, авызыннан йолкып чыгарганда, балакның яртысы мунчалага әйләнгән иде инде. Ярый әле чәйнәп бетермәгән! Әнә былтыр Гыйльфанныкы бөтенләй юкка чыккан иде. Төймәсе дә калмаган. Мескен Гыйльфан үзе дер-дер килә, бала йоннары кабарган, теше тешкә тия. Рәтләп сүзен дә әйтә алмый. Ярый әле майкасы озын иде. Ярый әле малайлар күп иде. Майкасын тезенә кадәр тартып төшердек тә, тыгыз бөжра ясап, аны уртага алып кайтып киттек. Үзебез көләбез, һич тыелыр хәл юк, үзебез бер-беребезгә елышып, җилкәне җилкәгә терәп атлыйбыз. Фашистларга каршы чыккан совет солдатларымыни.

Өйләренә кайтып җиткәч, баскычны бер генә сикерде Гыйльфаның.

Әле минеке ярый!..

Әнкәй бер сүз дә әйтмичә карап торды-торды да кулымнан җилтерәтеп өйгә алып керде:

—Сал,—диде.

Мыш-мыш килеп азапланган арада әллә нәрсәләр уйлап бетердем. Ул исә чалбар белән биткә унлы-суллы, унлы-суллы бәрде дә:

—Уф,—диде,—кайчаннарга хәтле җәзаларсың икән мине... Көн буе кайда йөрден? Нишләден? Бу ыштаныңны кемнән чәйнәттен? (Ыштанны кеше чәйнәмәс инде.) Каян гына җиткерим инде мин сезгә,—диде дә... кинәт битен яулык чите белән каплады.

И ходаем, тагын елый бит инде. Үзе сугыша, үзе елый...

Яна мудыны Вәрәштә, әнә шулай иттереп, мин керттем. Әллә бу кыска балаклы ыштанны матурлык өчен кия дип беләсезме?! Әнкәй елады-елады да шартлатып балакның икенчесен дә кисеп атты.

—Ничек элегрәк башыма килмәгән. Җәй өчен бигрәк тә әйбәт икән бит,—дип куйды әле җитмәсә.

Беренче көнне ишегалдында гына йөргән идем дә, икенче көнне онытылып китеп урамга ук чыкканмын... Бөтен малайның күзе миндә булды. Киноларда гына күргән җылы якларда ял итүчеләрнекенә охшаттылар. Әллә ялган, әллә чын—Гыйльфан шул ук көнне кайтып: “Харисныкы шикелле кыска ыштан тегеп бир”,—дип әнисенең теңкәсенә тигән, имеш. Үзе әйтмәде. Әмма көннәрдән беркөнне ул да балакларын кистереп чыккан иде. Район үзәге бит. Муды тиз йөри. Аупа әйтмешли, “сонгы муды” башка малайларга да күчте.

Рәхәтләнеп йөрибез. Әле җайлырак та икән. Бот араларында җил уйнап тора. Элек, болынга төшсәң, чыкка чыланып бөтен балак лыч була, ләшпердәп аякка ябышып интектерә иде. Ә яланботның ние бар?! Ничек тиз чыланса, шулай тиз кибә дә ул... Аягыңның бар икәнен дә белмисең. Болынга ат кузгалагы сыдырырга еш төшәргә туры килә мина.

* * *

Барысы да яна өйгә күчкәч башланды.

Берәр машина утын бирәләр икән, дигәнне ишеткәч, әткәй ял алып абый белән мытыеска урман кисәргә киттеләр. Такталык агач юнәтеп булмасмы!

Былтыр көз үк инде Вәрәшкә нефть эзләүчеләр килгән иде. Әрәмә

башындагы бушлыкта, төпсез күл янында буравай корып, жир тишеп яталар. Вәрәш астында жир мае булырга тиеш икән. Шуны тапсалар, Вәрәш бер көндә шәһәргә әйләнәсе, ди. Ул асфальт юллар дисенме, өчәр, дүртәр, хәтта бишәр катлы таш өйләр дисенме—берсе дә калмаячак, ди. Әнә хәзер үк инде алар авыл читендә такта щитлардан берьюлы әллә ничә барак корып яталар. Аларны финский йорт дип йөртәләр икән. Тышларын шкатурлап-буяп та жибәргәч, ул зур фин йортлары Вәрәшкә бөтенләй шәһәр төсе бирә башлады. Әнкәй шул буравайларга, шкатурларга измә изәргә ялланды. Көн саен барып, измәләрен изеп кайта.

Аупа исә бөтенләй шаккатырды. "Бу Вәрәштә ачка койрык чәнчеп ятар хәлем юк",—диде дә, барлы-юклы сынар күлмәге белән алмаш яулыгын төйнәп, үзеннән дә олы фанер чемодан күтәреп читкә чыгып китте. Ике айдан хат алдык. Бөгелмәдән ары китә алмаган. Әллә нинди "судыва" дигән жиргә урнашкан. Әткәй белеште аны, төзү оешмасы икән. "И балакай, балакай! Берәр жинелрәк эш таба алмады микәнни",—дип аһ-уһ килештеләр. Ә мин аупага ышандым. Көчле бит ул. Бирешмәс әле. Юк-бар егетләренне бәреп кенә ега ул! Тагын бер атнадан посылка килеп төште. Баш-башлары сургуч белән катырылган агач тартмадан ике данә такта чәй, бер кило башлы шикәр, бәләкәй мендәр сыман сәмихле конфет чыкты. Ак, ялтыравык кургашка төрелгән ике такта чәйне күкрәгенә куеп әнкәй тавышсыз гына елады. И әкәмәт! Сөенәсе, шатланасы урында. Үзе күпме: "Кайчаннар гына кул арасына керә башларсыз икән!"—дип уфтана иде. Керә башлагач, әнә, гомердә булмаганны...

Әле Гөлфия дигән апам бар бит. Ул да өйдә түгел. Әткәй Ык аръягындагы Шубан колхозында нининдер танышы белән сөйләшкән дә, аны шунда весовщик итеп чакырдылар. Жиде класс белеме бар. Ындыр табагына кайткан ашлыкның авырлыгын амбар кенәгәсенә язып торасы, ди. Аны гына мин дә булдыра алырыем инде. Мине чакырмадылар.

Шулай итеп, хәзер Рәшит белән икебез өйгә хужа. Тавыкларга-казларга жим болгатып бирү дә, болыннан ат кузгалагы алып кайту да, су китерү дә, кибеткә ипигә бару да—барысы да безнең, дөресрәге, минем өстә. Ипине бер кулга бер буханка гына бирәләр. Кыш көне ярый иде әле... Бер кибеткә Гөлфия, бер кибеткә аупа, бер кибеткә мин чыгып чаба идек. И бәхетлеләр! Хәзер алар бу мәшәкатьтән котылды. Дөрес, мытыес кибетеннән Рәшит тә алып кайта ала. Анда аны беләләр. Ә Вәрәш кибетендәге чиратка иртәнге биштән басмасаң, ул көнне ипи чыраен күрермен димә! Иң авыры шунысы да инде аның. Кара таң тишегеннән күзеңне ертып чыгып китәргә, ажгырып торган усал хатыннар янына чиратка басарга һәм... шунда таң аттырырга кирәк.

Менә бер заман почта янындагы багана башыннан—зур калай бидрәгә охшаган радиодан—СССР гимны янгырый башлый. Димәк, сәгать алты. Чират ух итә. Чиратның йокымсыравын кул белән алып ташлыйлармыни! Ул пружина сыман кысыла, тыгызлана, бөгәләнеп торган урыннары турая. Ишек ачылуга борынга, авыздан сулар китереп, тозлы балык исе килеп бәрелә. Ул ис өермә булып тышка ургыла да чираттагы кешеләр өстендә бөтерелә башлый. Әнә шулар, авызына су жыелган кешеләр, чират башындагы бәхетлеләрне, шешә борынына тыгызлап бөке тыккан кебек иттереп, кибеткә этеп кертеп тә жибәрәләр. Инде аягыңны атламасаң да була. Әгәр аннан кысып чыгарсалар, янадан үлсәң дә кире керә алмыйсың. Ни өчен дигәндә, ипи аз килә. Алдан керсәң—алдың, соңлап килсәң—калдың... Шуңа күрә чираттагы кешеләр усал була торганнардыр да инде. Беркемнең дә иписез каласы килми бит!

Менә тагын бераздан урам чатында арбасына зур тартма утыртылган ат күренә, кемнеңдер "Киләләр!" дигән әче тавышы янгырый. Шулчак әллә нишләп күз алдына кетердәп пешкән, хуш исле ипи килә, "Бу Чапайдан да бәхетле кеше юктыр", дип уйлый башлыйсың. Чөнки ул шушы исәпсез-хисапсыз, чутсыз-чамасыз байлыкка—тартмага шыплап тутырылган, яна гына мичтән чыккан ипигә хужа. Үзенә күпме теләсә,

шулкадәр аладыр инде ул, өйләрендә ап-ак көмәч тулып ятадыр! Үз кулында булгач... Күнних янында кукраеп утырган сатучыны—башына папахага охшаган каракүл бүрек, аягына ялтыравык галош белән бурки кигән юан апаны—Вәрәштә Чапай дип йөртәләр.

Бәхетең булса, бер буханка ипине букчаңа яшерәсең дә түбән очтагы икенче кибеткә йөгерәсең... Бәлки, анда чират азрактыр, бәлки, анда ипи калгандыр... Җәй көне чиратта кеше күп булмый... Аннан соң өйгә.

Ә өйдә сине ике киребеткәне—Мария белән Катя атлы ике кәҗәсе көтеп тора. И тынлаусызлар да инде. Чак кына күздән ычкындырсаң, өйдән йөз метрлар гына читтәге бодай басуына барып кергәннәрен көт тә тор! Ярый да бит нәфесләрен баскач чыгып китә белсәләр. Алар аны анлыймыни! Гуҗ тамаклар. Бүксәләре пух булганчы йөриләр. Куып кайтармасаң, мәңге дә кайтмаслар иде. Юкса, әнә бит инде, басу белән ике арадагы бушлыкта күпме алабута, кычыткан, песи тарысы... Шул җитмимени! Юк, бу мәлгуньнәргә колхоз бодае кирәк. Урлап ашамасалар, тамаклары туймый.

Авызыңны ачыбрак йөрсәң, плавай дигән кабих кулына баралар да эләгәләр инде, ябып куялар инде боларны. Аннан соң бар, коткарып кара син. Колхоз идарәсенә кереп, штраф түләп, андагы бирәр баш кешенең йодрык төя-төя кычкыруын тыңлап, җык булып, ач кәҗәләреңне җитәкләп көч-хәл белән кайтып егылырсың. Әле ярый бирсәләр!

Дөрес, безнең кәҗәләр алай ук башсыз түгел. Бигрәк тә Мариясы үткен. Берсе хәнҗәр шикелле туп-туры, икенчесе исә крәндилдәй түгәрәкләнеп кәкрәйгән очлы мөгезле, олы кәҗә ул. Плавайга эләгеп колхоз сараенда өч көн ач ятканы үзәгенә үткәндер бахырның, басу юлында атка атланган кеше күренсә, башын аска ия дә ишекне бәреп кенә лапаска кереп ята. Атлы күздән югалганчы чыгарырмын димә инде син аны. Катясы бераз диванарак. Яшь әле. Аңа плавай ни, син ни... Ияк астындагы сакалын селкетә-селкетә, керт-керт иттереп ура гына колхоз бодаен. Аптырыйм хәтта. Нишләп анасына охшамаган бу?! Җүнледән җүнсез туа, дигәннәре шушыдыр инде... “Эләгерсең әле бер! Өйрәнерсең әле”,—дим эчтән генә. Хәер, алай-болай эләксә, бөтен авырлыгы минә төшәсе. Аллам сакласын! Плавай Гайфине бик усал, холыксыз адәм диләр. Аның белән борчак куырып булмый.

Безнең Марияга бөтен күрше-тирә шаккатa.

—Адәм акыллары бардыр бу кәҗәдә,—дип тел шартлаталар.

Җитмәсә, сөте куе, тәмле, үзе күп. Иртән сауганда бер, кичен ике банка сөт бирә. Мин аны эчеп тә бетерә алмасыем. Карап торганыбыз шул кәҗә. Чәй эчсәң дә ул, аш салсаң да шул. Катясыннан гына уңмадык. Ни сөте, ни башкасы, дигәндәй... Үзе кысыр калган бичара. Ак борынлы, күгелҗем ефәк сыман озын, йомшак йонлы матур кәҗә бит инде, югыйсә. Ул гына җитмәгән, әле муенында ике ап-ак алкасы да бар.

Аупа кәҗәләргә багышлап әллә нинди бер такмак та көйләп йөри иде әле. Җыр-такмакка үтә дә маһир ул. Әллә үзе чыгара, әллә кайдадыр отып калганны кайтып сөйли. Аны тыңлаган кеше авызын ерып тәгәри-тәгәри көлә инде. Көлмәгәндә дә авызын ермыйча кала алмый. Ә бер башласа, аупаны туктатырмын димә.

Алла бирса, бирган булса,
Алырмын бер кәҗәкәй.
Саусаң сөте, суйсаң ите,
Налогы да бәләкәй.

Юк, түлке без кәҗәне суймыйбыз. Әйтәм ич, карап торган бердәнбер туйдыручыбыз ул.

Алар искә төшүгә сискәнеп киттем. Бауларын өзеп колхоз басуына китмәгәннәрме тагы. Тачканы да, чүкечне дә онытып, урамга йөгердем. Фу, куркыттылар, юньсезләр! Күләгәдә яталар ич.

—Түзегез, түзегез инде азга гына,—дип сөйләнә-сөйләнә чиләкләрне әзерләргә керештем.—Хәзер менә тиз генә мытыеска, ат сараена барып киләм дә сезне болынга алып чыгам... Ике чиләк алып кайтсам, әле иртәгә дә житәр...

Ат сарае мытыес ихатасының ин кырыенда. Безгә якын гына. Директор жигә торган дәү кара айгырны да, мытыес кибетенә ипи ташучы карт юаш алашаны да, башка атларны да шунда тоталар.

Мытыес атларының тизәге әйбәт, тыгыз була, ярмаланып тора. Аларга чөнки солы ашаталар. Эшкәртелеп бетмәгән солысы да шактый чыга анын. Түләүсез хәзинә инде... Шуны чиләгенә чүмәләм тутырып алып кайтасын, ат кузгалагы орлыгы белән яхшылап болгатасын. Тавык халкына менә дигән жим! Талаша-талаша ашыйлар. Кайчагында аптырап та куям, бер тапкыр эшкәртелгән азык тагын ничек ризык булсын инде. Мескен тавыкларны алдау гына бу. Мисез бит алар. Юкка гына ушсыз кешене "тавык мие эчкән нәрсә" димиләр ич. Ләкин ничек кенә булмасын, карап торганыбыз, табынып яшәгәнебез ат тизәге. Әгәр сарайга кертмәсәләр, алырга рөхсәт итмәсәләр, нишләр иден?! Жәй көне ярый әле... Ә озын-озын кышларда, пыскак көзләрдә, жәйне китермәс өчен кыр талашкандай акрын кыймылдаучы язларда нишләрсен. Тавыкбикәләр көтеп-көтеп йөрерләр иде дә тәпиләрен сузарлар иде. Аларга тагын ни ашатасын? Үзенә житмәгәнне. Әткәйнен акчасы кулга йокмый. Әнкәй әйтмешли, кереп житмәс борын бармак арасыннан шуып чыга да китә.

Ат сараеннан кайткан саен әнкәй, нечкә дә күнелле инде, такмаклап-такмаклап рәхмәт укый:

—Рәхмәт инде бу житәкчеләргә... Берәү булса, анысын да жәлләр иде әле, бирмәс иде,—ди.—Шөкер, житәкчеләр әйбәт безнен...

Әйтерсен ана ат бугын... әй, тагын ялгыштым... тизәген житәкчеләр китереп бирә.

Минем әнкәй дә гел шулай ялгыша. Искә төшкән саен төзәтәм:

—Юк, әнкәй, алай дөрес түгел. Безнен татар теле укытучысы әйтте: ул тупас сүз, әшәке сүз, диде. Культуралы кеше тизәк дияргә тиеш икән.

Әнкәй нигәдер мина карап-карап тора да, уф, дип куя.

—Барыбер инде, ике чабата бер кием,—ди.—Ничек әйткәненә карап мәгънәсе үзгәрсә икән анын. И улым, улым! Ичмасам сезгә боларны янадан күрергә язмасын иде,—ди.

Кайчагында уйлыйм-уйлыйм да, анлый алмыйча, башларым тубал була. Әллә мием сыекланган инде. Үзе мин алып кайтканга сөенә, үзе үк тагын шуны "күрергә язмасын" дип уфтана.

Сәер бу дөнья дигәнен! Хәтта мина бөтен дөньясы, кешеләрнен яшәве, сөйләшүе, нидер кылануы—барысы да әллә нинди мымырдык ялган булып тоела башлый. Адым саен бер төрле сөйләү, икенче төрле эшләү. Өлкәннәр икейөзле, чыршы бәйрәмендәгечә, йөзләренә катып калган елмаюлы яисә кайгылы битлек киеп алганнар да шул рольне уйныйлар да уйныйлар кебек. Моны мин әнкәй турында әйтмим. Ул исәпкә керми. Ул яшереп тормый, ичмасам! Йомшак жиренә чәпелдәтергә дә, кочаклап еларга да күп алмас... Ана килешә.

Әллә нишләп, тагын шул урыс теле укытучысы Миләүшә Әхмәтовна искә төште әле.

Кара такта янына басар, иннек буялган кып-кызыл иреннәрен бөрештереп сөйли башлар:

—Мин—бөек рус культурасы традицияләрендә тәрбияләнгән кеше. Миннән үрнәк алыгыз. Өйрәнегез. Шул тәрбиянен кайбер элементларын тырнак очы хәтле генә булса да сезгә дә йоктырырга телим...

Йогышлы чир турында сөйлимени?! Шунысы ачуны китерә дә инде анын. Булсын урыс теле дәресе, булсын тарих... Имеш, гел урыснықы гына әйбәт, алар гына культуралы, алар гына жинә. Безнен бер генә әйбәт әйберебез дә юк микәнни сон? Күнелемдә, бәгыремнен үзәгендә кирелеккә дә, кимсенүгә дә, үзебез өчен—әткәй белән әнкәй, апаларым

өчен, абыем һәм энекәшем өчен рәнжүгә һәм үртәлүгә дә охшаш хис, тойгы бөреләнә, шул яралгы хәлендәге үзсүзлелек укытучылар белән телләшә, тарткалаша. Урысныкы бөек булса, татарныкы биек, ди. Әле тагын да биегрәк булмаса... "Татарныкы ярамагач, аны кимсеткәч, нигә татар арасында яшисез алайсаң", дип кычкырасы килә башлый. Эчтән генә аларны үртим, үчекләшәм, шул үртәүдән тәм таба башлыйм хәтта. Дөрес, боларны кычкырып әйтергә ярамый. Ярамаганлыгын әйтмәсәләр дә, шулай икәнлеген генә чамаламый калмыйсың инде. Без дә төшеп калганнардан түгел!

Дөресен әйтим, минем болар хакында уйлаганым юк, ике ятып бер төшемә дә керми торган нәрсәләр иде. Бөтенесе дә тарих дәресләреннән башланды.

...Укытучы кызыллы-каралы уклар белән чуарланган картадан күрсәтә-күрсәтә, "Безнең куркусыз полкларыбыз", дип кабатлый-кабатлый, канатланып сөйли. Әйтерсең, үзе гаскәр башлыгы. Аның дәртләнүе безгә дә күчә. Кайсы малай сугыш турында сөйләгәндә үзен дә җиңүчеләр сафында тоймый икән?! Без дә шулай. Аның белән бергә ярсу атларга атланып чабабыз. Гаскәребезгә данлы вә шәүкәтле бөек кенәз Дмитрий Донской җитәкчелек итә икән. Кулларыбызда кылыч, башларда алтынланган шлем, күкрәктә чылбырдан үрелгән тимер күлмәк, индә корыч калкан. Бер селтәнүебез була, дистәләгән татар-монголның башы кыелып кала. Киң дала өстендә җиңүле оранybыз яңгырый. Җәнлек тиресенә төренгән кыргый татарлар безнең тыгыз сафларны күрүгә дер калтырап, кәкре кылычларын, ук-җәяләрен ташлап качалар, кайсы кая керергә тишек тапмый, имеш. Укытучы шулхәтле дәртләнеп сөйләде ки, әле дәрес беткәннән соң да колакларыбызда гайрәтле урыс гаскәренең "Ура!" кычкырган авазлары яңгырап тора иде. Барыбыз да куркак һәм хыянәтчел Мамай урдаларын сытып алга ташланырга әзер идек.

Дәрес беткәннән соң да айный алмадык. Ул көнне, хәтта, Вәрәш малайлары да безгә бәйләнеп маташмады. Барыбыз да гайрәтле, куркусыз бер үк гаскәрнең җайдаклары бит. Чыктык та, мәктәп янындагы куаклардан ботаклар сындырып алдык, алар кылыч булды. Койма буенда, канау яннарында үскән кычытканнар вәхши татар гаскәрләре. Әй кырдык инде аларны, кирәкләрен бирдек, тетмәләрен теттек.

Әле кайтып кергәндә дә кызуым сүрелеп бетмәгән, сулышым капкан, битләрем ут яна иде. Букчам—калканым бер якта, кулда булат кылыч. Кердем дә олы чүмеч белән чиләктән чумырып алып, йотлыгып салкын су эчәргә тотындым. Җинеп кайткан кешенең йөрәге кайнар була бит.

Дәрес әзерләп утырган абый гына башын күтәреп карады да бер сүзе белән мине җиргә, гап-гадәти чынбарлыкка тартып төшерде:

—Тагын кем белән сугышып кайттың?—диде.

Ачуым килеп китте. Аның бу кадәр дә салкынлыгы, битарафлыгы үртәлүемне тагын да арттырып җибәрде.

—Мамай белән сугыштым,—дидем.—Кенәз Дмитрий Донской дружинасы белән татарларны кырып йөрдек,—дидем.

Ашыгуымнан сүзләремне йота-йота әле яңа гына дәрестә ишеткәннәрне—безнекеләрнең Куликово кырындагы бөек бәрелештә татар яуларын җиңү тарихын сөйләргә тотындым.

Абый сүзсез генә тыңлап торды да акрын гына яныма килеп басты. Шул мизгелдә маңгаема тай типтемени, ул баш бармагы белән үзе генә белгәнчә шундый каты итеп чиртте, күзләремнән ут көлтәсе чәчрәп чыкты. Аның бу мәкереннән, астыртынлыгыннан телсез калдым.

—Син үзең кем соң?—диде абый усал иттереп.—Дурак! Татарны җиңгәнгә сөенеп кайттыңмы?

Мин җавап бирерлек хәлдә түгел идем.

Абыйның киерелгән бармаклары янәдән маңгаема якынлаша башлады.

—Әйт, син үзең кем?—дип кабатлады ул.—Мәктәптә нинди тел укыйсың? Әдәбият дәресләре ничек дип атала?

—Тат... тат... татар теле, татар әдәбияты,—дип җавап биргәнемне сизми дә калдым. Юкса, аның таш кебек бармаклары тагын маңгаемнан утлар чыгарачак иде.

—Соң, шулай булгач, туган телең татар булгач, син кем буласың инде?—дип сорады ул усал судья сыман.

Җавап урынына сорау биргәнем инде минем ихтыярымнан башка килеп чыкты.

—Без... без татармыни?

Абый җавап биреп тормады.

—Аңгыра!—диде дә минем шикелле надан, тимкә бер кемсә белән сөйләшеп торуны үзе өчен түбәнлек санап булса кирәк, күз кырые белән генә карап алды да дәреслекләре янына барып утырды. Аның өчен мин дөньяда юк идем инде.

Маңгайны тотып карадым. Тавык күкәе хәтле шеш чыккан. Башка вакыт булса, күземдәге яшьләрне тыя алмас идем. Әмма бу юлы түздем, тешләремне кыстым. Күңелдә әйтеп бетергесез бушлык иде. Гүяки сабый кулыннан иң кадерле нәрсәсен, кыйммәтле, ялтыравыклы уенчыгын тартып алдылар. Башымда ерып чыккысыз уйлар, җавап тапкысыз сораулар өермәсе купты. Алар миемнең һәр күзәнәгенә бәреләләр, җавап эзләп бәргәләнәләр иде. Сорауның иң беренчесе бөтенләй дә аңлаешсыз, хәтта мәгънәсез иде. Укытучыбыз үзе дә татар бит. Ул нишләп безгә кирәгенчә аңлатмады микән? Ул минем унынчыда укып йөрүче абыем белгәнне дә белми микәнни соң? Сорау өстенә сорау ятты, җавапсыз—терәксез калып, алар гүяки өстемә тау булып ишелделәр дә төштеләр. Ничек кенә эзләнсәм дә, җавап юк иде. Дүртенче генә класста укып йөргән башым белән өлкәннәр үзләре дә белмәгәнне мин кайлардан гына белеп бетерим?! Шулай да күңелгә кереп оялаган шик корты тынгы бирми иде инде. Юк-юк та уйга чумганымны сизми дә калам. Кайчагында хәтта үземне ак сакаллы карт итеп сизә башлыйм, билләһи! Без кемнәр соң? Нигә без иң изге урын дип санап йөргән йортта—мәктәптә— безне үз авызыбыз белән үзебезне үк сүгәргә өйрәтәләр? Дәресләрдә ерак бабаларыбызны хурлап, сүгеп утыргач, үскәч бездән кемнәр чыгар? Менә, мәсәлән, мин ни өчен үземнең газиз әткәемне, әнкәемне, аларны тудырып үстергән әби-бабаларымны сүгәргә тиеш ди әле?! Әйтәм аны, урыс классында укучылар үзләрен бездән өстенрәк санап йөриләр. Аларны мәктәптә шулай өйрәтәләр икән бит! Хәер, алар барысы да нәчәлство баласы. Аларның ник алай кыланганы аңлашыла инде анысы... Нәчәлство үзенең баласын татар итәргә теләми торгандыр... Шуңа күрә аларны аерып укыта торганнардыр...

Минем моңа кадәр кемнең кем икәне хакында уйланганым юк иде. Ә уйланырга, белергә кирәк икән. Үзенә дошман тиеш кешеләрне яклап йөрмәс өчен дә белергә кирәк икән аны. Әткәй белән әнкәйнең пышылдап сөйләшеп ятканын ишеткәннән соң бер тетрәнү кичергән идем, монысы икенчесе булды. Сәер икән бу дөнья дигәнең! Күбрәк белгән саен яшәү кыенрак икән, катлаулырак икән. Адым саен алдау, ялган, кемнәндер нәрсәнедер яшерергә омтылу. Кешеләрнең күп нәрсәне белмәскә тырышулары да шуннан килми микән?! Үземчә фикер йөртәм инде, ә алар белергә тиеш бит! Үзенең кем икәнен белмәгәннәрнең маңгаена, абый шикелле иттереп, күзләреннән ут чәчрәтеп, чиртеп торучылары да кирәктер. Менә шулай! Көннәр, айлар, еллар үтә. Мин үсәм. Үскән саен тормыш катлаулана гына бара.

Әйе, әгәр мөмкинлек бирсән, ул, Мыйлахмитывнаны әйтүем, гомерендә бер татарча сүз әйтмәс иде, безнең белән дә гел урысча гына сөйләшер иде. Аның хәтта ире дә урыс бит. Баштарак ул шулай итеп караган иде дә, аның әйткән һәр сүзенә җавапны татарча биреп баргач, туктады тагы. Әле беркөнне кибеттә Чапайга урысча эндәшкән, ди. Чапайның кыяфәт шәп бит инде. Башта папаха, аның астыннан бүлтәеп чыккан көдрә чәч, авызда алтын теш. Тыштан караганда, нәкъ менә

шәһәр маржасы! Теленә шайтан төкергән Чапай, сугышта йөреп шомарып кайткан хатын бит, имән бармагын наган шикелле иттереп Миләүшә апаның күкрәгенә төбәгән дә усал тавыш белән бер генә сүз әйткән: “Хенде хох! Гитлер капут! Ес лебе Сталин!”[1]—дигән. Матур киенгән, бизәнгән, яшь, чибәр укытучының телсез калуын күреп миһербаны кузгалгандыр инде, соңыннан тавышын йомшартып та өстәгән: “Апаем, син минем белән кыланмаенча гына сүләш, бу сиңа шәһәр түгел. Кирәк булса, мин нимесчә дә беләм, синең белән нимесчә сүләшеп маташмаем бит. Ни кирәген матур иттереп татарча гына әйт! Әллә үдебедчә белмәйсеңме?”—дигән. И гарьләнгәндер инде укытучы апабыз. Аны жәлләп үлә яздым. Әтәк-сәтәк сүзне пулеметтан сиптергәндәй сиптерүче Чапай белән сүз көрәштереп кара син! Им өчен күзгә кырып салырга бер урыс булмаган Вәрәштә синең белән, авызларын кыеш-мыеш китереп, урысча сөйләшеп маташмаслар шул. Әнә мытыеста Кәҗәмаслов дигән урыс токаре бар, аның авызыннан юри дә бер урыс сүзе ишетмәссен. Малайлары безнең белән укып йөри. Башларының икеледән чыкканы юк. Математикадан да, урыс теленнән дә шулай. Диктант язсалар, Мыйлахмитывна үзе үк кызыл кара белән канга батырып бирә инде аларны. Гел урыслар гына әйбәт булса, болар бит инде “бишле”гә батып ятарга, гыйлемлекнең аргы ягына чыгып, аякларын салындырып утырырга тиешләр иде.

Һаман шул Миләүшә Әхмәтовнаны уйлыйм әле. Һәр сүзе моның үлчәнгән, һәрберсе теш арасыннан сыгылып, үтә кадерле бер нәрсә шикелле, берәмләп-берәмләп кенә чыгар. Өс-баш зәһәр инде анысы. Офицер хатыны бит. Ирен военкоматта зур башлык, диләр.

“Мин бөек халыкның бөек әдәбиятын, бөек телен укытам”, дип көн саен, сәгать саен туглап тора ул. Миебезгә кадак каккан шикелле һәр көн чүкеп тора. Чүкеп кенә кермәсә, карашы белән бораулап кертер дәрәҗәгә җитә. Урыс теленең кирәк икәнлеген без үзебез дә беләбез аны. Әнә, Усть-Катавка китәсе булсаң, ансыз Бөгелмәдән ары чыга алмыйсың, ди. Шуңа өйрәнергә тырышабыз да. Ну, болай иттереп, аны гына бөек иттереп сөйләү ачуны чыгара. Чыкмыйча! Әллә без бернәрсә дә аңламыйбызмы?!

Шулай... Урыс теле укытучысы белән борчак пешми безнең. Гел безгә генә каңлашырга җай эзли дә тора. Ул сөймәгәч, без дә аның өчен егылып китәргә җыенмыйбыз әле. Дөрес, баштарак алай түгел иде түгелен. Әллә, чыннан да, без гаепле идекме, әллә ул безнең изге хисләребезне аңлап бетермәдеме. Малайларга әйткән шикелле ана “Әйдә, чыгыйк әле, аңлашыйк әле”, дип булмый бит!

Барысы да аның туган көненнән башланды.

Гыйльфан белән яз көне болынга кузгалакка төшкән идек. И рәхәтләндек инде. Язгы ташудан соң түбәнсу урыннарда җыелып калган уйдык-уйдык сулыклар янында ул яшь, сусыл кузгалак дисеңме, яңа төртеп чыккан юа дисеңме. Урдык кына. Хәтта телләребез ачыта башлады. Кесәләргә генә сыймагач, итәкләребезгә дә җыйдык әле. Өйдәгеләрне кинәндерәбез инде бүген. Ул болындагы матурлык! Әрәмәгә хәтле бөтен кинлекне язның беренче зәңгәрсу чәчәкләре каплап алган. Араларыннан иң эреләрен, иң җете төстәгеләрен сайлап, ишен-ишкә китереп ике зур букет җыйдык. Рәхәт иде!

—Әйдә, бу букетларның берсен Миләүшә апага бүләк итәбез,—диде Гыйльфан көтмәгәндә.

—Тик торгандамы?

—Нишләп тик торганда булсын?!—диде ул миңа, шуны да белмисеңмени дигәндәй, каш астыннан гына карап.—Иртәгә Миләүшә апаның туган көне бит!

—Каян белден?

Гыйльфанның борыны тагын да югарырак чөелде.

---

[1] Кулларынны күтәр! Гитлер тончыкты! Яшәсен Сталин! *(алманча).*

—Әни әйтте. Ана әллә кайлардан җидеме, сигезме телеграмма килгән, ди инде.

Гыйльфанның әнисе белә дек белә инде. Хат ташучы бит. Ул телеграммаларны үз кулы белән илтеп биргәндер әле.

—Әллә ничек унайсыз,—дидем мин бик үк ризалашасы килмичә генә. Бөтен класс алдында ул чәчәкләрне ничек бирәчәгебезне күз алдына китерә алмый идем әле.—Кызлар кебек мәктәпкә чәчәк күтәреп барыйкмыни?

—Дәрестән соң көтеп алырбыз да, кеше күрмәгәндә генә бирербез. Күрерсең, сөенеченнән башы күккә тияр. Ничек башларына килде икән дип шаккатар, бүтән "авыл гыйбадлары" дип ачуны китермәс, ичмасам! Дөнья рәтен белә торган малайлар икәнлегебезне күрсәтик әле бер.

Шулай килештек тә.

Дәрес беткәннән соң урам чатында башкалардан аерылып калдык, чәчәк бәйләмен букчадан чыгарып тигезләдек, алдан әзерләп куйган шарларны алагаема кабартып, аларны букет янына бәйләп куйдык. Мондыйны гына беләбез инде: шәһәр җирендә чәчәк бәйләменә төрле төстәге кабартылган шарлар кушып бирү бик зур дәрәҗә санала икән. Безнеке төрле төсләрдә түгел түгелен. Шулай да, зәңгәр чәчәкләр янындагы ак шарларның матур булып, серле булып күренүе икебезгә дә ошады. Аны, хәтта, зәңгәр күк йөзендә агылучы ак болытларга тиңләп куйдык. Баш бар да соң инде үзебездә!

Көтәбез.

Менә бер заман мәктәп баскычында Миләүшә апабыз күренде. Менә хәзер ул капкадан чыгачак та, төп урамнан егерме-утыз адым узгач, борылып безнен алдыбызга килеп басачак. Чаттан борылуы булды, җир астыннан үсеп чыккандай, аның каршына килеп тә бастык.

—Миләүшә Әхмәтовна!—диде Гыйльфан һәм бөтен рәвешен китереп сөйләп торган җиреннән кинәт кенә тотлыга башлады.—Сез-сез... Сез-сез-не туган көнегез белән кот-кот-котлыйбыз...

Хәзер ярты сәгатьләп тотлыгып торачак инде бу. Ярдәмгә ташланмыйча бүтән чара юк. Мин Гыйльфанның аркасына яшергән кулыннан букетны суырып алдым да Миләүшә апага таба суздым. Дөрес, шарларның берсенең тыны чыккан, ул шәлберәеп төшкән, элеккеге рәвешен ала башлаган иде инде. Аны карап торыр чакмыни! Укытучы алдында яңадан кабартып торырсыңмы әллә?! Гыйльфаннан ким каушамаган идем, шулай да ул әйтәселәрне өстәп бетердем:

—Сезгә изге эшегездә зур уңышлар һәм якты бәхет телибез,—дидем.

Шунда әллә нәрсә булды, кулымдагы букетка күз төшерүгә Миләүшә апабызның башта бите, аннары соң колаклары кызарды. Әмма иреннәре арасыннан ник бер сүз чыксын. Ул керфекләрен кысып әле миңа, әле Гыйльфанга карап алды да качып киткәндәй кызу адымнар белән китеп тә барды. Шарлы-букетлы кулым һавада асылынып калды.

—Безнең чәчәкләрне яратмады инде әллә,—дидем мин аптырап.

Гыйльфан шактый гына сүзсез торды. Миләүшә апабызның һич көтмәгәнчә мондый сәер кыланмышын аңларлык хәлдә түгел идек.

Ниһаять, дустымның зиһене әйләнеп кайтты бугай, ул үзенчә бәя чыгарды.

—Уку елы бетеп килә бит... Ул безне икеле куймасын өчен теге ни... ни диләр соң әле... взяткамы шунда, ришвәтме... Шуны бирәләр дип уйлады инде ул. Аның өчен төрмәгә утырталар ди бит. Алган кешене дә, биргәнен дә. Шуңа алмады.

Безгә шушы хөкем белән килешми мөмкин түгел кебек тоелды. Дөресрәге, тоелган иде. Юраганыбыз юш килдеме, икенче көнне минем әткәйне дә, Гыйльфанныкын да мытыестан туп-туры мәктәп директоры янына чакырып алганнар. Моны ишеткәч икебез дә шыр җибәрдек. Әгәр, чыннан да, Гыйльфан әйткәннәр дөрескә чыкса, безгә төрмә

юлыннан башка юл калмагандыр... Ләкин ни мин, ни Гыйльфан моны бер-беребезгә сиздермәскә тырыштык. Һәрхәлдә бер минут тик тора алмаган дустымның телсез-өнсез калуын башкача аңлап та, аңлатып та булмый иде. Мәктәптә ни-нәрсәләр булгандыр, безне әткәйләр ничекләр итеп йолып алгандыр, анысы миңа билгеле түгел. Тик әткәй эштән кайткач, зурлар белән сөйләшкән шикелле иттереп, мине ишегалдына чакырып чыгарды. Капка янындагы бүрәнәләргә барып утырдык. Мин хөкем көтәм, әткәй дәшми. И шул көтү дигән нәрсәнең, билгесезлекнең авырлыгы! Сүкмәде, ачуланмады әткәй. Мәктәпкә ник чакырганнарын да әйтмәде хәтта. Яңа гына күргәндәй, озаклап карап торды-торды да бөтенләй көтелмәгән сорау бирде:

—Ул шарларны кайдан алган идегез?—диде.

—Кайдан булсын... Аптиктан,—дидем мин тик торганда аның мондый гап-гади сорау бирүенә аптырап.—Бөтен малайлар шуннан ала!..

—Башкалар алсын, син алма!—Әткәйнең тавышы кырыс иде.—Кисәтүемнең беренчесе дә, соңгысы да шушы. Шарларны аптекада сатмыйлар. Ә чын шарларны мин, Казанга баргач, сиңа үзем алып кайтырмын. Аңладыңмы?

—Аңладым!

Безнең әткәй ике сөйли торган кеше түгел. Тик шунысы сәер, никадәр кырыс, усал күренергә тырышмасын, аның күзләрендә көлемсерәүгә охшаш чаткылар да абайлап калган идем мин. Өйдә бу хакта башка сүз кузгалмады. Юкса, директор хәтле директорга чакыру ул гадәти хәл генә түгел. Бездән нәрсәнедер яшерәләр иде шикелле. Әткәй белән булган сөйләшүне хәтта әнкәй дә белми калды кебек...

Икенче көнне Гыйльфан гына аркасын күрсәтеп зарланды. Анда кып-кызыл булып каеш эзләре ярылып ята иде.

—Әти каезлады гына, әттәхиятемне укытты,—диде ул.

Әбиле кеше—әбиле кеше инде, без белмәгән әллә нинди сүзләр белә ул Гыйльфан. "Р" хәрефен әйтәсе килмәсә, әнә шулай әбисенең сүз капчыгын тота да селки.

Без үзебезнең нинди гөнаһ эшләгәнебезне барыбер аңламадык. Гыйльфанның аркасыннан каеш эзләре дә эреп юкка чыкты, ә Миләүшә апага бирергә маташкан бүләгебезнең күңелдәге ярасы, эзе бик озак сакланды. Без аның сөйкемсез сөякләренә әверелдек. Тик, нигә? Ни өчен? Анысын өздереп кенә безгә әйтүче юк иде.

* * *

Илфат класста иң олы малай. Өченче ел утыра инде. Сыткылы бит, кысынкы кабаклары арасыннан елтыраган хәйләкәр күзләр, озын торык. Такта янына ул чыгып басса, Миләүшә Әхмәтовна аның кимендә ике абыйсы иләгән сырган чалбарына, мыеклары чыккан күтәртмәле иске чабатасына карый да иренен җыера, мөмкин кадәр читкәрәк басып, үзе әйтмешли, диктовать итә башлый:

—Мы—самые счастливые дети страны. Будущее страны—в наших руках. Спасибо партии за счастливое детство!

Илфат тирли, пешә. Сырган чалбарына иш куфайкасының изүен ычкындырып җибәрә. Борыныннан тамчы-тамчы тир ага. Акбурны тактага изеп кертердәй итеп яза да яза: "Мый самый частливыйы дити ыстыраны. Будучие ыстыраны ыф нашыйх руках"...

Миләүшә Әхмәтовна калтырана-калтырана ридикюленнән читчитләренә ак челтәр тотылган нәфис кулъяулык тартып чыгара, борынын каплый... Беләбез инде, тирес исен, тизәк исен яратмый. Үлә ул. Көнетөне әнисе янында, колхоз фермасындагы сыер-сарык арасында матавыкланган Илфаттан чәчәк исе килмәс шул. Ә Миләүшә Әхмәтовнаның кулъяулыгыннан класска башларны әйләндергеч хуш ис тарала. Ул, хәтта,

тирес исен, арыш ипие исен, лампаларга салганда түгелгән керосин исен дә күмеп китә. Класста бу ис чыгуга өзелеп-өзелеп җәйне сагына башлыйбыз.

Шулай да урыс теле дәресенең бер рәхәт ягы бар аның. Монда үзеңнең гадел, бәхетле, җинүчән һәм рәхәт илдә яшәвеңне аңлыйсың.

Әнә бит, Миләүшә Әхмәтовнаның тикшерткән җөмләләре генә дә нинди. Илфат белән мин, Гыйльфан, Лилия—бәхетле илнең бәхетле балалары... Бу илдә бөтенесе дә безнең өчен, безнең киләчәк өчен. Сулыш алулары кинәя.

Татар әдәбиятында исә тоташ ачлык, фәкыйрьлек, мескенлек, хәерчелек... Елыйсылар килә башлый. "Фәкыйрьлектә үткән тереклек", "Кара йөзләр", "Исемдә калганнар", "Көзге җил"... Күз яше, аһ-зар, елау, сыктау, сыкрау, сызлану.

Мин юньле кеше түгелдер, ахрысы. Үзебезнең тормышны, нигәдер, гел шулар белән чагыштырам да утырам. Бу әсәрләр безнең хакта, безнең бүгенге тормышыбыз турында язылгандыр сыман тоела башлый.

Әмма без барыбер татар теле дәресләрен, татар теле укытучысы Җәүһәрия Шакировнаны яратабыз. Иң көтеп алган укытучыбыз ул. Үзе кыланчык түгел, үзе гади, үзенең белмәгән нәрсәсе юк! Ул сөйли башласа, дөньяңны онытасың инде. Җитмәсә, шул хәтле кызык итеп сөйләр, сөйләгәннәреннән көлә башласаң, үзе дә кушылып, рәхәтләнеп көләр... Ирен өстендәге "Ю" хәрефенә охшаган миңенә хәтле яратабыз бугай без аның. "Татар теле дәресе була" дисәң, беркем дә, хәтта Илфат та дәрестән качып китми инде. Без ул дәресләрдә җөмлә тикшереп утыра дип беләсезме? Булыр... Чош! Без Җәүһәрия апа белән дөнья гизәбез. Аның сөйләмәгән нәрсәсе юк! Инглиз, француз, әмрикан язучыларының ул сөйләмәгән китаплары калмады. Жюль Верн, Герберт Уэльс, Виктор Гюго, Марк Твен, Даниель Дефо... Гулливерның лилипутлар иленә баш әйләндергеч сәяхәтләре, капитан Немо мажаралары, иксез-чиксез океан төпкелләре, марсианнар белән сугыш... Аның дәресләрендә без Том Сойер, Гекльберри Финнар белән талгын Миссисипи киңлекләрендә салда агабыз, алар белән бергә негрларны яклап сугышабыз.

Менә бераз үсә төшик әле, Гыйльфан белән без, Тигр белән Сизгерне дә алып (әле, бәлки, Лилия дә риза булыр... хәер, дингезчеләр парахутта хатын-кыз булырга тиеш түгел, дип әйтәләр, ди) колач житмәстәй бүрәнәләрдән сал ясап, Ык буенча дингезгә хәтле йөзеп төшәчәкбез әле. Ык ул сиңа Миссисипи генә түгел. Аның агымының тизлеге, аның киңлеге... Һы, уртасында олы ирләр дә басып тора алмый аның... Суырып кына алып кереп китә ул сине.

Җәүһәрия апа әле тагын "Том агай алачыгы" дигән китапны сөйли башлады. Көне-төне кукуруз басуында, яшелчә плантацияләрендә җәфа чигүче негрларны җәлләп күздән яшьләр чыкты. Ярый әле без Америкада түгел, ә совет илендә яшибез, дип сөендек. Бездә беркем дә колхозчыларны кул-аякларына богау салып эшләтми. Һәркайсы ындыр табагына да, басуга да, фермага да үзе бара. Берсен дә атка атланып куып алып бармыйлар, егылса, усал этләрдән талатмыйлар. Шул персидәтел йә бригадир өйләренә кереп сүгеп чыкса гына инде. Әле ярый без ирекле илдә яшибез.

Әй, тагын әллә кая кереп киткәнмен. Сүзем Мыйлахмыйтывна турында иде бит әле.

Менә шушы Миләүшә Әхмәтовна белән көннәрдән беркөнне кош тизәге җыярга чыгардылар. Аны мәктәптән "Путиловец" колхозына, ягъни Вәрәш колхозына шефлык буенча җитәкче итеп билгеләгәннәр иде.

Безгә ярый инде. Бу нишләр икән, дибез. Җәллибез үзен. Фәрештәдәй нәзберек, якын килергә куркырлык итеп чиста киенгән, хушбуйдан башканы белмәгән, тирес исеннән һушын югалтыр дәрәҗәгә җитә торган укытучыбыз нишләр?!

Колхоздан зур тирес чуманы куелган киң чанага ат җигеп килделәр.

Мәктәп каршына тезелдек. Миләүшә Әхмәтовна каршыбызга басып, нәкъ офицерларча, речь тотты:

—Сезгә, балалар, гаять дәрәҗәдә мактаулы бурыч йөкләнә. Колхоз-совхоз кырларында күкрәп мул уңыш үссен өчен бик күп, бик күп ашлама кирәк. Беләсез булыр...—Артык зур җаваплылык хисе тоюдан булса кирәк, кинәт аның бите алланып китте, бер генә мизгелгә туктап, сулыш алды да күтәренке тавыш белән дәвам итте.—Ы-ы... кош тизәге кыйммәтле, искиткеч файдалы... ашлама. Илебезгә гаять тә күп тизәк кирәк. Мин сезне, балалар, тавык тизәге җыю буенча ярыш оештырырга чакырам,—диде, тагын әллә нинди ялкынлы сүзләр әйтеп бетерде.

Ул шул хәтле рухланып, дәртләнеп, яратып сөйләде ки, беребезнең дә шиге калмады: Вәрәш кетәклекләрендә илнең иң кыйммәтле байлыгы ята икән. Аны, һич кичекмичә, җыеп алырга, Ватан складларына тапшырырга кирәк икән!

Звеноларга бүленеп, киттек өй борынча. Төш вакыты җиттеме-юкмы, без авылдагы һәр кетәклекне ялап чыккан идек инде. Тирес чуманы янында, бер ун метрлап читкәрәк китеп, Миләүшә Әхмәтовна үзе басып торды, кемнең ничә чиләк китергәнен санап, кызыл тышлы дәфтәрчегенә язып барды.

Авыл башына чыккач, безне тагын чүмәләм тутырылган тирес чуманы янына сафка бастырып, тантаналы тавыш белән игълан ясады:

—Илебезне чәчәк аттыруга лаеклы өлешебезне керттек, дип горурлана алабыз, балалар. Бүген без ил табынына йөз илле сигез чиләк... кыйммәтле ашлама куйдык,—диде.

Иң зур өлешне Илфат керткән булып чыкты—унөч чиләк. Ана көнләшеп карадык. Гыйльфан белән безнеке бишәр чиләк кенә. Гомеремдә беренче мәртәбә Миләүшә Әхмәтовна Илфатны саф каршына чыгарып мактады:

—Иң күп тизәк бирүче син,—диде.—Рәхмәт,—диде.—Менә кемнән үрнәк алырга кирәк!

Өч-дүрт көннән Вәрәштә чыга торган "Күмәк хуҗалык" гәҗитәсендә "Укучылар ярыша. Кем алда?" дигән сводка басылып чыкты. Кош тизәге, көл җыю сводкасы. Беренче урында Вәрәш мәктәбе иде. Безнең белән ярышучы Күбәк мәктәбе исә өченче урынга тәгәрәгән. Шулай булмый ни! Ярышып кара син район үзәгендәге мәктәп белән! Район үзәгендә кеше күп, кешесе күп булгач, тизәге дә күп. Бу хакта безгә Миләүшә Әхмәтовна горурланып сөйләде.

Гәҗитәдән кисеп алынган сводка исә бер айга якын мәктәп витринасын бизәп торды. Олы җиңү, зур куаныч иде ул мәктәп коллективына.

Менә шулай тантаналар эчендә яшибез без мәктәптә.

Ә хәзер җәй... Гап-гади, гадәти көннәр. Көтмәгәндә ялгыз башыма өелгән, тавык чүпләп бетергесез мәшәкатьләр!..

Их! Арбам—сыңар тәгәрмәчле яхшы тачкам юк. Ул булса, күпме эш җиңеләясе! Аннары... тачкага төягән—чиләккә тутырган түгел инде. Әнә, башка малайлар шуның белән күпме рәхәт чигә. Тачка—минем иң зур хыялым! Йомшак тәгәрмәчле, очкындай җинел, ныклы арбаны хәтта төшләремдә күрәм. Имеш, тизәк салырга олы әрҗәсе, чиләк асарга элмәкләренә хәтле бар. Сабында исә, нәни генә кызыл кнопка. Басуың була, үзе йөгерттереп алып китә. Этәсе дә, күтәрәсе дә юк, имеш!

Югыйсә, менә дигән саплар әзерләдем, әрҗәсен ясарга такта башларым бар. Яраклы тәгәрмәч кенә таба алмыйм.

* * *

Ат сараена барабыз. Алда мин, артта Рәшит, аның артыннан Тигр теркелди. Аның да артыннан койрык болгап барырга мәче генә җитми. Нәкъ әкияттәге кебек.

Рәшит белән Тигр тышта калдылар, чиләкләрне тотып ат сараена кереп киттем. Анда эт белән керергә ярамый. Шул йон гөнҗәләсен күргә атлар тынычсызлана, пошкыра, тибенә башлый. Директор айгыры бигрәк тә. Ә мина нәкъ аның янына керергә кирәк. Күргәнем бар, ат караучы абзый ана солының иң яхшысын, печәннең иң әйбәтен сала, башкаларга караганда күбрәк сала.

Сарайда ярымкараңгы. Аран түренә уелган кечкенә тәрәзәләр тузанга баткан, үрмәкүч пәрәвезләре белән капланган. Алардан яктылык сүрән булып, йотылып керә. Ачык калган ишектән сузылган нур тасмасы исә өч-дүрт метр узуга караңгылык томанына уралып йотыла. Күзләр ияләшкәнче ишек төбендәрәк торасың.

Сизәм, директор айгыры монда. Әнә әкрен генә пошкырып, тавыш биреп куйды. Әллә нишләп яратам мин аны. Бер-ике тапкыр шикәр алып килеп сыйлаган идем, шуны онытмадымы, мин килеп керүгә әкрен генә эндәшә сыман ул:

—Килдеңмени?—ди.

Тагын пошкыра. Монысы: "Шикәр алып килмәдеңме?"—дигәне.

Гайрәтле, кешнәп җибәрсә ярты Вәрәшне яңгырата торган айгырның мина шулай йомшак мөнәсәбәте күңелне кытыклый, әллә нишләп күзгә яшь тыгыла. Яратам да, җәллим дә мин аны. Киң болыннарда, чәчәкле тугайларда очар коштай чабып, уйнаклап йөрер чакта караңгы аранда бикләнеп ятарга мәҗбүрлеген җәллим. Мытыес директорына ялкылдап торган өр-яңа машина кайткан. Элек, ичмасам, директор белән көн саен колхозлардан бер урап кайта иде. Хәзер, әнә, мескенем, шул тузанлы, чокыр-чакырлы юлларны сагынып, саргаеп, караңгы аранда бикләнеп ята.

Айгырның борыны йомшак. Янына килүгә җилкәмә төртелә дә иреннәре белән мине капшагандай итә башлый. Тыныннан, тәнемә тиеп киткән борыныннан кытыкланам. Әмма түзәм. Ул кискен хәрәкәтне яратмый.

—Әй канатлы тулпар, ярсу аргамак! Син дә мине көтәсеңмени? Син дә иркәләгәнне яратасыңмыни?—дип сөйләнә-сөйләнә башыннан сыйпарга, ялларын бармак аша үткәреп тарарга керешәм.

Айгыр дәшми. Сөйләшә белсә, ниләр әйтер иде. "Чыгар моннан мине иреккә, җибәр мине җилләр белән ярышып көч сынашырга",— дияр иде микән?!

Тагын берничә аранга кереп чыгуга чиләкләр тула. Ат караучы абзый, рәхмәт төшкере, без киләсен белә, артык чистартып мәшәкатьләнми. Тагын берничә малай кереп чыкса, башка араннар да ялт итәчәк. Алар айгыр янына керергә курка. Моңа сөенәм дә әле. Тик, шулай да, эчем поша, нидер сизенәм, күңелне ямансу моң баса монда килсәм. Ат караучы абзыйны каравылчы булып күчә дигән сүзләр йөри. Анда эш җиңелрәк икән. Ул китсә, атлар нишләр? Директор машинага утыргач, атларга кадер беткән сыман. Кара айгыр алдындагы улакның бушлыгы да шикләндерә... Юкса, анда һәрчак нәрсә дә булса ята иде бит. Комсыз түгел ич ул. Тамакка нәзберек җан иясе. Безнең кәҗәләр шикелле агачына хәтле кимереп бетерми.

Әллә ничек монсуланып чыктым әле ат сараеннан. Кара айгырны, нишләптер, үземә охшатып куйдым. Рәшиткә ым кактым:

—Киттек!

Ул исә мытыес ихатасының түренә карап каткан иде, мине ишетмәгән дә сыман кул изәп янына чакырды:

—Кара әле, Харис, тегендә ни хәтле ватык комбайн!

—Бердән, Харис түгел, абый. Икенчедән, мытыеста ни булмас! Ватыкны җыяр өчен бит инде ул мытыес,—дидем акыл өйрәтеп.

Апаларга "апа" дип эндәшергә яратып бетермәсәм дә, үземә "абый" дигәннәре бик ошый минем. Үсеп киткән кебек буласың. Рәшитнең дә үсәсе киләдер. Рашкының аның шул инде. Бик мөстәкыйль, үзенчә

булмакчы. Беренче классны бетергән, янәсе. Син берне бетерсән, абыең бишне бетергән. Ачуым килгәндә аны шулай Рашкы гына дип җибәрәм. Ап-ак булып яуган вак бозны бездә шулай диләр. Рәшит тә рашкы гына, ягъни әле кар да, янгыр да түгел. Борын асты да кипмәгән малай-шалай гына... Шуны сиздерүем.

Шулай да ул күрсәткән якка карамыйча түзә алмадым.

Ат сараеннан ике йөз адымлап кына ераклыкта, чыннан да, берничә комбайн скелеты тора иде. Күптән торалар. Аларның басмаларында куышып, штурвалларын боргалап, уйнап, көн саен күреп безнең күзләр күгәреп беткән иде инде. Ә бүген исә аларга тагын берәү өстәлгән—кызыл төстәге зур комбайнны таратып ташлаганнар иде.

Битараф кына үтеп китәрлек яналык түгел бу. Мытыес малае бул да, яңа скелетны беренче булып тикшермичә кал, имеш! Малайлар алдында сөйләп җибәрсән, селәгәйләре агар әле...

Чиләкләрне ат сарае кырыендагы кычытканлыкка яшердек тә турыдан—сарай белән техника саклана торган җирне аерып бүленгән койманың үзебезгә генә мәгълүм ярыгыннан чыгып, скелетлар янына элдерттек. Башка малайлар сизгәнче карап чыгыйк әле!

Комбайннар өч төрле була. "Коммунар" бар, "Сталинец-6" бар. Аларны трактор тагып йөри. Иске скелетлар шуларныкы. Тагын әле самахутный дигәне күренә башлады. Анысы үзе йөри. Алгы көпчәкләре—зур резин тәгәрмәчләр сөйрәп йөртә аны. Гыйльфаннын әтисе комбайнчы, ул бик бөртекләп, мәктәптәгечә тәфсилләп анлаткан иде безгә. Тик бер ярамаган, килешсез ягы бар икән. Арткы тәгәрмәчләре бәләкәй. Аз гына янгыр яуса, безнең сазга әйләнүчән ябышкак кара туфракта баталар да рульне тыңламый башлыйлар, ди. Әнә, Ык аръягында гына Вәрәш-Баш, Иске Вәрәш авыллары. Ыкның бу ягындагы куна тактасыдай тигез җирләр юк анда. Әйтерсең, Алып бабайның коточкыч олы җилпучларын тезеп салганнар да шуның өстенә иген чәчкәннәр. Басулары бер төшә, бер менә, бер кыегая, бер турая торган тау битләрендә. Менә шушы комбайннар ул якта эшли алмый, чак кына янтаюга тау астына мәтәлли икән.

Кыскасы, комбайнчылар бик үк яратмаган аны.

Изелеп кергән ян-якларына, калҗайган әвернәсенә карап, шуларны уйлап куйдым. Ах, әрәм булган! Бу комбайн да тау астына тәгәрәгән, ахрысы. Аның эчәгеләрен чыгарып, сүтеп ташлаганнар, тирә-юньдә әллә нинди, безгә таныш түгел детальләр чәчелеп ята.

Шулчак комбайнның икенче ягында нәрсәдер шалтырады, калайга калай ышкыганда тешкә тия торган ямьсез аваз чыкты. Мытыеста кеше-кара юк. Төшке ашка киткән чаклары иде. Тавышка сәерсенсәм дә, игътибар бирмәдем. Имгәтелгән, имгәнгән гарип баһадирны, җанлы нәрсәдәй күреп, кызгануга охшаш хис уянган иде.

Рәшит исә борынын мышкылдатып шул якка чыгып китте. Тигрнын кемгәдер ярсып өргәне ишетелде.

—Кем бар анда, Рәшит?

—Әй, юк ла,—дип мыгырданды ул.—Киттеләр инде... Без килгәч тә әллә нинди малайлар коймадан сикереп чыгып чаптылар. Шуларга өрә.

Бераздан авызы колагына җиткән энекәш үзе дә күренде.

Карадым да каттым: кулында нәкъ минем арбага кирәкле, төшләремә кереп йөдәткән тәгәрмәч. Үзе аш тәлинкәсе чаклы гына, үзенең табаны кин, үзе сырлы...

—Каян алдың?—дидем баскан урынымда тыныч кына тора алмыйча. Күз алдыма ялтырап торган яңа тачка сурәте килде.—Комбайннан түгелме?

—Юк ла,—диде тагын Рәшит.—Әнә тегендә, чирәм арасында аунап ятадырые...

Кулыннан тәгәрмәчне тартып ук алдым.

—Ай, маладис, Рәшит! Ах, шәп тә булды бит әле бу!..

Имгәнгән комбайн да, өстенә менеп, штурвалын боргалап уйнау рәхәтлекләре дә онытылды, кадерле табышны ике куллап күкрәккә терәп, кочаклап, өйгә чаптык. Куанычтан, эчкә сыймыйча бәргәләнгән шатлыктан кычкырып җырлап җибәрәсе килде хәтта. “Бирәм дигән колына—чыгарып куяр юлына” дигәннәре шушыдыр инде. Бирде бит, чыгарып куйды бит!..

Дөнья түгәрәкләнде.

Әй, туймас тамак тавыклар, әй, кире беткән мөртәт кәҗәләр! Мине бимазаламагыз! Абзагыз бүген бөек конструктор, абзагыз төзүче инженер, абзагыз тиздән чокыр-чакырлы Вәрәш юлларын очып кына үтәчәк елгыр, житез, оста шоферга әйләнәчәк!..

Әнкәй кайтканда тачка әзер иде инде.

Күптән ясап, шомартып куйган сапларның башын бораулап тиштем, әткәйнең тимер-томырлары арасыннан зур гына болт табып, аны көчәр итеп тыктым. Нәкъ заводта эшләнгән шикелле килеп чыкты. Өстә—ике сапны тоташтырган аркылы тактага кызыл карандаш белән “Дизель” дип тә язып куйдым әле. Гыйльфанның әтисе сөйләгәне бар: дөньяда ин көчле двигатель дизель икән. Кәрәчин ягып кына эшли ди.

Әнкәйнең, әллә нишләп, исе китмәде. Сүрән генә елмаеп куйды да өйгә кереп китте. Бераздан тәрәзәдән башын тыкты:

—Улым... Харис, дим. Кер әле...

Керсәм, ике кулын да сөлгегә ураган, нәни бала тоткандай, аларны тибрәтә-тибрәтә йөренә.

—Ай кулым, ай кулым,—диде ул сызланып.—Кан сауды, ахрысы. Шушы чәйнекне генә дә күтәрә алмыйм. Иртәгә эшкә ничек чыгармын инде?!.

Нишләргә, ничек ярдәм итәргә белмичә ишек төбендә таптандым.

—Син, улым, кәрәчинкәгә күкәй булса да куй инде. Аннары чәй кайнатырсын...

Рәшит суга йөгерде, мин керосинканы кабызырга керештем. Әнкәйнең чирләп китүе эчне пошырды. Авырткан кулы белән ничек эшләр инде ул! Буравайларның измәләрен кем изәр?! Эчтән генә мин: “Озаклямый нефть табарлар, Вәрәш тә шулай иттереп, шәһәргә әйләнер”,—дип өметләнә идем. Бик-бик тели идем, көтә идем. Шәһәр тормышы ул сина авыл түгел инде. Анда биек-биек йортлар. Автобуслар йөреп тора. Күршеләренә дә автобуска утырып кына барасы. Адым саен кибет, ашханә... Әллә нинди ларекләр, лавкалар. Баллы су сатып торучы апалар. Инде көн саен кино күрсәтүне әйткән дә юк. Вәрәш шәһәргә әйләнсә, безнең тормышыбыз да җайланыр, рәхәткә чыгарбыз. Шәһәрдә яшәүчеләр бик-бик бәхетле, китапта язганча, рәхәтлекнең чигенә чыгып яшиләрдер кебек тоела мина. Бөтен әйбер шунда китә бит. Миләүшә Әхмәтовна, киләчәктә барыбыз да шундый иркенлеккә чыгарбыз, дип өйрәтә.

Әнкәй чыкмагач, эшләре сузыла бит инде. Аннары күнелемә икенче уй килде. “Әй, сузылса, сузылыр сана! Әнкәй генә савыксын. Ул гына чирләмәсен! Анардан башка ничек яшәрбез. Әнкәйсез шәһәрдә яшәү дә кызык булмас. Тизрәк терелә генә күрсен. Күкәйне тизрәк пешерергә, чәй кайнатырга кирәк! Ашагач, хәл кермәсме...”

Ашык-пошык капкаладык та урамга чаптык. Тачканы бер мин йөртәм, бер Рәшит йөртә. Тәгәрмәч өстенә, дизель кебек гөрелдәп йөрсен өчен, калай кадаклап куйган идем. Ана тегәрҗеп суздым. Җепне тартсан, калай күтәрелә дә, тәгәрмәч тавышсыз гына тәгәри. Җибәрүен була, бөтен урам чытырдаган тавышка күмелә. Чын дизель! Чын трактор! Бәхетнең җиденче катында йөзәбез. Бездән калышмыйча тәгәрәгән Тигрны тотып алып, юеш борынын үбеп алдым хәтта. Эчтә кайнаган шатлыкка чыдар әмәл юк иде.

Тирә-як куе караңгылыкка төренгәч кенә кайтып кердек. Әнкәй йокламый икән әле. Сәндерәгә үрмәләп маташканда, анын тавышы ишетелде:

—Кәҗә лапасын, тавыкларны яптыңмы? Харис, дим...

—Хәзер ябып керәм, әнкәй, хәзер...

—И бала, бала...

Эчем жу итеп китте. Анын тагын ни әйтерен көтеп тормадым, аска сикердем. Тачка белән матавыкланып мал-туар, кош-корт кайгысы бөтенләй исемнән чыккан лабаса!

Лапас ишеге шар ачык иде. Шырпы сыздым да эчкә уздым.

—Мария! Катя! Кать-Кать... Сез мондамы? Кайттыгызмы?

"Бэ-ә-ә" дигән ялгыз тавыш ишетүгә яман сизенүдән йөрәгем дерт итеп куйды. Мариясы гына түгелме соң! Теге җаһилы кайда?

Ишегалдын чыгып караштырдым, тавык кетәклегенә күз салдым. Яшь кәҗәбез суга төшкәндәй юкка чыккан иде. Күзләрем ачытып авырта башлады, күкрәк астында бер каты йомарлам оешып, өскә күтәрелде. Бөтен ачылыгы белән аңлап алдым: "Дошман кулына эләккән! Тамагына алданган... Штраф акчасын каян гына юнәтербез инде!"

Башым котырып эшли башлады. Ничек коткарырга моны? Явыз, усал плавай кулыннан ничек йолып алырга?! Шулай да әнкәйне борчыйсы килмәде, ничек тә жае табылыр әле. "Әнкәй, ябып кердем",—дидем дә сәндерәгә үрмәләдем. Никадәр генә үземне тынычландырырга азаплансам да, юатырга тырышсам да, котылу юлы күренми иде. Төне буе кыбырсып чыктым. Күзгә йокы кермәде. Беттем! Нишләргә? Нишләргә! Житмәсә, ялгыз калган Мария төне буе бәэлдәп жанга тиде. Әллә ялына, әллә елый, әллә мине ачулана...

Әнкәй икенче көнне эшкә бара алмады. Анын ике беләге дә кып-кызыл булып шешеп чыккан иде.

Ялган тотылды.

Анын шешкән кулыннан да ныграк кызарып, хөкем каршына бастым. Безнен әнкәй кырыс, үтә кырыс. Кирәк чакта усал була да белә икән. Сүзе бер генә булды:

—Ничек тоттыргансыз, шулай алып кайтыгыз!

Нәрсә дә булса аңлату, ялыну, ялвару файдасыз иде. Кыйналган эт кебек чыгып киттек Рәшит белән.

Тигрның эш рәхәт, ичмасам! Ул берни дә анламый. Телен салындырган, койрык сыртта. Бер артка калып, бер алга йөгереп безнең тирәдә бөтерелә. Сәйранга чыкканмыни!

Әле бит төгәл генә белмибез дә. Адашып югалганмы, әллә башка кәҗәләргә ияреп киткәнме, әллә, чыннан да, плавайга эләккәнме?! Ин куркынычы шунысы. Башта колхоз утарына сугылырга булдык.

Разведкага чыкканбыз, имеш. Мин өлкән башлык, командир. Лейтенант. Башта ялтыравык фуражка, кулда ерактан күрсәтүче бинокль. Рәшит сержант. Юк! Бусы ана күбрәктер әле. Лутчы ул ефрейтор булсын. Ә Тигр өйрәтелгән овчарка. Дошманнарын бер сикерүдә егып, хуҗасы килгәнче "эһ" тә иттермичә саклый торган акыллы эт. Чик сакчыларын кинода шулай күрсәтәләр. Алар шикелле сакланып кына колхоз утарына якынлашабыз. Безне беркем дә күрергә, нинди максат белән йөргәнебезне белергә тиеш түгел. Совет чик сакчылары җилдән житез, кылычтан үткен, юлбарыстай кыю, каздай сизгер.

Мал яба торган сарайны беләбез анысы. Ындыр табакларыннан читтә, басу юлы өстендә. Түбәсен салам белән япкан зур читән абзар ул.

Котырып үскән алабута, кычытканны аралап, кыр ягыннан читән буена шуышып килдек тә шунда аунап яткан таяк белән чыбыкларны каерырга керештек. Йодрык сыярлык тишек хасил булды. Тын алырга да куркып, эчкә текәлдем. Йа хода! Шунда бит безнен Катя, шунда. Үзе шикелле үк ач, мескен ристаннар арасында.

—Катя, Катя,—дип пышылдадым.

Әллә таныды, бахыркаем, әллә сизенде безнең килгәнне, бар сарайны янгыратып кычкырып җибәрмәсенме:

—Бә-ә-ә... Мә-ә-ә...

Ялт итеп артка ташландым. Житмәсә, Тигр өрергә кереште. Тиз генә анын башын култык астына кыстырдым, авызын томаладым. Анламый гына бит, башсызкаем, тыпырчына ук башлады.

—Житте, житте, тукта, Тигркаем! Плавай килеп чыкса, өчебезнен дә сыртны камчы белән каезлаячак!—дим.

Бәхетебез бар икән. Ни сарайда, ни анын капкасы ягында бүтән тавыш-тын ишетелмәде. Янадан колакларны авырттырырлык шомлы тынлык урнашты. Ат башы хәтле йозакка бикләнгән сарайдагы тоткыннар да коткаручы килгәнлеген анлагандай тынып калды.

Сакланып кына тагын читән янына шуыштым. Ярый әле бүрәнә яисә таш сарайга япмаганнар. Колхозда андыйлары да—элеккеге байлардан калганнары да бар. Кулны тыгып читән астын капшарга керештем. Жир йомшак, таралып тора. Таяк тыгып читәнне бераз каерсан, туфракны казый төшсән, нәкъ Катя сыярлык тишек булачак.

Алмаш-тилмәш казыйбыз. Таягыбыз сынып бетте, тырнаклар каерылды. Безнен бу эш Тигрга да ошады булса кирәк, ул да ал тәпиләре белән казыгандай итенде.

Ниһаять! Куркусыз партизан шикелле түшем белән шуышып кердем дә Катяны мөгезеннән әләктердем. Сөйрәп чыгардык моны. Инде куркудан үткән иде. Сарай артына, ирекккә чыгуга унны-сулны карамыйча элдерттек кенә.

Мина рәхәт иде, күнел жырлый иде. Колхоз кәнсәсендәге түбәнлектән, мәсхәрәләнүдән, йодрык төеп кычкырынудан котылдык. Әле бит әнә койма коясыбыз, мич чыгартасыбыз, өйалды саласыбыз, өйне алты почмаклы иттерәсебез бар! Кәжәнен үз бәһасына торырлык штрафтан котылдык.

Үземне мин дөнья көтә белүче, инде тормыш йөген жилкәсенә салып тартучы олы кеше итеп хис иттем.

* * *

Тәгәрмәч жырлый. Тегәржепне юри ычкындырып жибәрдем. Әйдә, ишетсеннәр кем килгәнне. Күрсеннәр... Мин уйнап йөрмим. Мин тормыш йөген тартам. Ат сараеннан тизәк алып кайту гына нәрсә ул! Тагын әнә берничә ел үтәр, башка малайлар шикелле Усть-Катавка ремесленныйга китәрмен, алар шикелле үк кап-кара гимнастерка-чалбар, кара шинель, аякка калын табанлы ботинка, башка аркылы-торкылы чүкеч белән ачкыч сурәте төшерелгән ак эмблемалы форменный фуражка киеп Вәрәшкә кайтып төшәрмен...

Тәгәрмәч жырлый, ана кушылып йөрәк жырлый. Әй сез, озын-озын жәйләр, чиге булмастай зәһәр кышлар!.. Сез үтәрсез дә китәрсез. Ә мин озын, дастыйн, чибәр, таза егет булып үз язларыма, якты, кояшлы язларыма атлармын. Совет илендә барысы да кеше бәхете өчен! Әллә минем бәхетем юкмы! Хакым юкмы?! Бар! Бар минем бәхетем! Мин аны табармын! Мина беркем аяк чала алмас! Беркем дә минем юлыма аркылы төшмәс!

И рәхәт икән ул үзенне бәхетле хис итү!..

Кинәт колак төбендә янгыраган тавыштан сискәнеп киттем.

—Әй син, мокыт!

Әйләнеп тә карамадым. Хыялларым шул хәтле татлы иде, алардан бер генә минутка да аерыласым килмәде. Беткәнме урамда үртәшеп йөрүчеләр.

Бер-ике адым атларга да өлгермәдем, кемнендер тупас кулы жилкәмнән әләктерде.

—Син нәрсә? Ишетмисенме әллә!

Каршымда ачудан йөзе кыйшайган милиционер басып тора иде.

—Син кем малае?—диде ул күземә кердәй булып...

—Хатыйпныкы...
—Кайсы Хатыйп? Кем ул...
—Сәүбанов... Сәүбанов Хатыйп...
—Исемең...
—Харис!

Милиционерның йөзендә бер генә сызык та үзгәрмәде. Әмма җилкәне ычкындырды. Күн итеге белән тачканың тәгәрмәченә типте.

—Каян алдың?
—Үзем ясадым...

Милиционер мин аңламый торган телдә әшәке итеп сүгенде дә, җирәнгәндәй, черт итеп теш арасыннан төкерде.

—Тәгәрмәчне каян алдың, дим, мокыт!
—Мытыестан...
—Ник алдың?

Ничек җавап бирергә белмичә иннәремне җыердым. Үзе белмимени инде.

—Менә... арбага кирәгие бит,—дип мыгырдандым шикелле.
—Салдыр!
—Нәрсәне?..
—Атаң башын... Җүләргә салынма! Давай, салдыр.

Калтыранган кулларым белән тәгәрмәчне беркеткән болтны борырга керештем. Милиционер кесәсеннән гәҗит чыгарды да тәгәрмәчне, җирәнгәндәй, кәгазь белән тотып, китәргә борылды.

Шунда гына башыма килде: көпә-көндез, яп-якты урамда мине тагын хыялымнан аералар. Нигә? Кемгә яманлык эшләдем мин? Барып кулына ябыштым.

—Милиция абый, зинһар, тимә инде! Бир инде кире. Мин аны табып алдым. Үзем таптым... Тәгәрмәчсез нишлим инде хәзер мин?

Ул теш арасыннан чыгарып тагын урысчалатып сүгенде дә күкрәккә төртеп җибәрде:

—Ах, ананны... Көчек... Милициягә ябышасыңмы әле!..

Бала башы чаклы зур, йонлы йодрык бәрелүгә бөтен буем белән лапылдап канауга барып төштем. Рәнҗүдән, ачудан тыным кысылды, күзгә яшь тыгылды.

—Милиция абый, бир инде... тимә инде...

Кинәт... безнең сөйләшүне тыныч кына күзәтеп утырган Тигр яшен тизлеге белән милиционерның өстенә сикерде, үткен тешләрен аның тәгәрмәч тоткан кулына батырды. Менә сина йон гөнҗәләсе, менә сина мәчедән чак кына зуррак ялагай эт.

—Пшол ты б...! Сука!

Тәртип сакчысы кулын селтәп җибәрде һәм эткә җан ачуы белән шартлатып типте. Тигр очып яныма килеп төште. Кулымнан килсә, аны рәнҗетүчене буып үтерергә әзер идем. Ләкин көчләр тигез түгел. Тигрны кочакладым да тыелгысыз аккан яшьләремне күрсәтмәс өчен аның йонлач гәүдәсенә капландым. Икебез дә дер-дер калтырый идек.

Тизәк төягән арбаны җирдән сөйрәп кайтып кердем. Хыялларымны, изге уйларымны челпәрәмә китерделәр. Бу минутларда минем иң усал, иң мәрхәмәтсез бандит—ата бандит буласым, кулга автомат тотып, мондый милицияләрне кырып, изеп, сытып йөрисем килә башлаган иде.

Менә тагын тәгәрмәчсез калдым. Көпчәге булмаган арба—арбамыни инде ул. Өстенә матурлап "Дизель" дип язылган тачкам тагын кирәксез бер агач өеменә әйләнде дә калды.

Әнкәйне анлый алмыйм мин. Зарымны тыңлады да күзен кысып, сәер генә карап куйды.

—Каян алган идегез ул тәгәрмәчне?—дип, нәкъ милиционер шикелле ачуланып сорады.

—Сон, каян булсын инде. Чирәм арасыннан, мытыестан тапканыек...

—Күпме әйттем, ярамаган жиргә кереп йөрмәгез, дидем. Тимәгез, дидем, кеше әйберенә. Үзегез гаепле...

—Соң бит бөтен малайларда шундый арба, бөтен малайларда тәгәрмәч... Бер мин генәмени!?. Бөтенесе шунда йөри бит...

Әнкәйнең хөкеме кыска, кырыс булды.

—Башкаларда минем эшем юк. Сез тимәгез, сез гадел булыгыз!

* * *

Көн ямьсез бүген. Хәтта әнкәйнең эшкә бармый калуы да сөендерми. Кояш кыздыра, кайдадыр кошлар чыркылдаша. Ә минем берни дә эшлисем килми. Эч поша. Ямансу. Өй каршындагы бүрәнәгә чыгып утырдым. Сөйләшәсе дә, уйныйсы да килми. Ник бөтен дөньясы чәнчелеп китми шунда...

Гыйльфанның эш рәхәт, ичмасам. Аның әтисе комбайнчы. Колхоздан умырып ашлык алып кайта. Аларның өстәлендә һәрчак бодай күмәче. Тәгәрмәчне дә ул алып кайтып биргән. Ә минеке? Гап-гади бухгалтер. Мытыеста эшлим дисә дә, башы кәгазьдән чыкмый, кулы чут төймәсеннән аерылмый аның. Кантур кешесе бит! Житмәсә, бар акчасын заемга тотып калалар. Немецларне жинеп, сугыштан күкрәк тутырып орден-медаль тагып кайткан башы белән! Их, мин булсам, үземнең хәләл тапканымны заемга бирмәсием! Чатакама талашырыем, сугышырыем, ну бирмәсием...

Безнең әткәй, гомумән дә, аз сөйләшә торган сабыр кеше. Кая ана сугышу! Сугыш турында сөйлә, ничә немец үтерден, дип тенкәсенә тигән чаклар бар. Сөйләми. Мактанчык түгел! Киноларда гына күрсәтәләр ул, совет солдаты автоматтан бер генә атып жибәрә, немецларнең унысы ун якка авып кала, үткен чалгы астындагы печән покосы диярсең. Совет солдатлары бөтенесе батыр да, матур да, кыю да, сүзгә дә оста. Безнең дә әткәйне шундый итеп күрәсе килә. Чынлап, яшермичә әйткәндә, мин сугыш турындагы киноларга шул әткәйне дә күрсәтмәсләр микән, дип йөрим дә.

Сугыш турында сүз чыкса, әткәйнең йөзе карангылана, тешләрен кысып уфтанып куя. "И балалар, балалар,—ди. Сезгә аны белергә кирәк түгел. Сезгә гомерегездә андыйны күрергә язмасын, Аллам сакласын, ди.—Сугыштан да кабәхәт, сугыштан да жирәнгеч нәрсә жир йөзендә юк",—ди. Менә шуннан соң сөйләтеп кара инде син аны! Ә киноларда бөтенләй башкача. Карарга кызык. "Их, мин дә шунда булсамые, күрсәтерием мин ул фашистларга!" дип, йодрык кысып, ярсып, йөрәкләнеп утырасың әле.

Гыйльфан кулындагы таяк белән жиргә әллә нинди сызыклар сыза. Ә мин шушыларны уйлап утырам.

—Нигә, чумып кайтмыйбызмыни инде,—диде ул бер сәгать элек үк әйткән соравын кабатлап.—Болай утырганчы... Алайсаң... мин киттем.

Ләкин, китәргә жыенып күтәрелсә дә, янадан минем янга, бүрәнәгә чүмәште. Авыл ягыннан, яңа салынган йортларны карый-карый ниндидер таныш түгел хатын менеп килә иде. Менә ул безнең янга килеп житте.

—Кара әле, апаем, Сәүбановлар кайда тора икән?

Бернәрсә дә уйлап тормыйча, мин үзебезнең ихатасыз ялгыз өйгә күрсәттем.

—Әнә! Шушы өй.

Кылт итеп башыма килде: эшеннән әнкәйне алырга килгәннәр, аны эзләп килгәннәр. Ничекләр генә итеп эшләр инде!? Кулын күтәрә дә алмый бит.

Йомышчы апаның кулында бөгәрләнгән кәгазь кисәге бар икән, ул аны ачып карады да бер Гыйльфанга, бер мина текәлеп, сорау бирде:

—Харис... Сәүбанов Харис өйдә микән? Шул иптәшне чакыра алмассызмы...

Әллә нишләп битемә кызыллык йөгерде. Гомердә булмаганча, телем тотлыкты:

—М... м... мин... Харис. Мин Сәүбанов.

Ул башка кешене күрермен дип өметләнгән булса кирәк, ышанмаган шикелле, тагын бер кат миңа карап алды да кыенсынгандай әйтте:

—Алайса, апаем, әйдә!.. Сине милициягә чакыралар.

Тораташтай каттым да калдым. Ни телем әйләнми, ни аягым атламый. Мондый алып китүләрнең дәһшәтен кычкырып сөйләмиләр, әмма анын мәгънәсен, ни белән бетәсен Вәрәштә имчәк баласы да белә. Куркуым, шигем йөземә чыккандыр, ахрысы, йомышчы апаның күзендә кызгануга охшаш нәрсә күренде.

—Курыкма, апаем, сорашырлар, сөйләшерләр дә җибәрерләр. Син... бәләкәй әле...

Шушы минутта минем, чыннан да, бәп-бәләкәй, күзгә күренмәс кечкенә бөҗәккә, бактерия яисә микробка әйләнәсем килде И-их! Ләкин бу минем ихтыярда түгел, кулымнан килми. Телемне көч-хәл белән әйләндереп әйтә алдым:

—Хәзер.. хәзер... Әнкәйгә генә әйтәм дә...

Атылып өйгә кердем дә үз-үземне белештермичә илереп кычкырып җибәрдем:

—Ән-кә-ә-әй! Мине алырга килгәннәр...

Каян килгәннәрен ул сүзсез дә аңлады ахры, йөзе кәгазь кебек агарды, ирен кырые әллә ничек кенә тартыша башлады. Бүлмә уртасында басты да калды. Кулындагы алтын йөгертелгән каймалы бердәнбер чынаяк тәлинкәбез идәнгә төшеп челпәрәмә килде.

Ник әйткәнемә үкендем. Әмма минем башка чарам, башка яклаучым, башка сыенып кешем юк иде. "Әнкәй, коткар мине, бирмә мине милиция кулына!"—дип кычкырасым, элеккечә, итәгенә капланып дөньядан онытыласым килде. Менә ул атылып урамга чыгар, йомышчы хатынны пыранлатып куып җибәрер, дип көттем.

Өйдә тып-тын. Бу тынлык колакларны кыса, миемнең һәр күзәнәгенә кереп чынлый иде.

Кинәт әнкәй уң кулы белән йөрәген тотты да ачулы, кырыс тавыш белән кистереп әйтте:

—Бар! Бар!—диде, тагын үзәгемә үтәрлек итеп, тешен кысып кабатлады.—Бар! Ничек алган булсагыз, җавабын да шулай бирегез!

Колакларыма ышанмадым. Минем әнкәйме соң бу? Ул мине шулай куып чыгарамы? Аякларым мамыкка әйләнде. Ни артка, ни алга атларлык хәлдә түгел идем. Һаман уклау йоткандай торуымны күреп, әнкәй кычкырып ук җибәрде:

—Нишләп торасың? Бар! Рәшит кайда? Рәшитне дә алып бар. Бергә урлагансыз, бергә җавап бирегез! Барыгыз!..

"Урлагансыз!" Бу сүзнең мәгънәсе хәзер генә аңыма барып иреште, чәчләрем үрә торды. Безне кот очарлык җинаятьтә гаеплиләр икән бит! Без—Рәшит белән мин—бурлар! Безне төрмә көтә. Без беткән адәмнәр икән бит...

Тышта махсус килгән, безне алырга килгән йомышчы хатын көтә. Өйдә әнкәйнең карашына, сүзенә чыдарлык түгел.

Безне төрмәгә алып китеп баралар...

Авылның нәкъ уртасында ике катлы зур йорт бар. Өсте агачтан, аскы каты колач житкесез калын, авыр ташлардан салынган. Урам яктагы тәрәзәләрендә әткәйнең баш бармагы юанлыгындагы тимердән тоташ рәшәткә. Беренче каттагы таш стена әле йорт белән генә дә чикләнеп калмый, коймага әйләнеп, бер яктан күрше ихаталарга, икенче яктан военкоматка кадәр барып житә. Анысы да ике катлы йорт. Койма өстендәге тимер казыкларга чәнечкеле тимер чыбык тарттырылган. Элек ул бер байның йорты булган диләр. Астында кибет торкан, өстендә үзе торган, имеш. Урам яктагы ишеге дә анын тимердән, олы ирләр кулы

калынлыгындагы ныклы эшермәләре дә икәү. Берсе аста, берсе өстә.

Вәрәш милициясе шунда.

Йомышчы хатын ирләр кулы шикелле көчле куллары белән дә ишекне көчкә генә тартып ачты. Керүебез булды, сиртмә белән тарттырылган икән, ишек гөрселдәп ябылды, ярымкарангы тар аралыкта калдык. Күнелем тулды, тагын күзгә әллә нәрсә булды. Шушы ишек якты дөнья белән арабызны мәңгегә аерып куйды кебек тоелды.

—Әйдәгез монда,—диде йомышчы хатын аркадан этеп һәм, соңлаган үкенүен белдергәндәй, йомшак тавыш белән өстәп куйды.—Әненне алып килмәсән дә яраган буласы икән...

Якты бүлмәгә килеп кергәндә күз алышынган иде, баштарак бернәрсә дә аермыйча басып тордым. Йомышчы чыгып китте. Өстәл артыннан таудай калкып утырган милиционер белән япа-ялгыз калдык.

Бүлмә хуҗасы безне күрмәде, ахрысы. Өстәлендәге кәгазьләрне рәтләштерде, графиннан салып су эчте һәм кремльгә охшатып ясалган язу приборыннан очына таба нечкәреп килгән саплы ручка алды. Кырмыска каләмле иде ул. Андый белән мәктәптә язарга рөхсәт итмиләр. Безгә унберенче номерлы һәм бака каләм дип йөртелгәннәрен генә тотарга ярый. Мондыйлары кулны боза икән.

Нишләптер, курку, күнелдәге шик, үрсәләнү юкка чыкты. Барысы да яхшы булыр. Әткәйнен конторындагы шикелле гап-гади бер бүлмә ич бу! Милиционернын һәр хәрәкәтен, тоткан һәр әйберен, үз гомеремдә беренче тапкыр күргәндәй, йотылып күзәтә башладым. Бу минем ихтыярымнан тыш эшләнә, түземсезләнеп анын эндәшүен көтә идем.

Ниһаять, ул башын күтәрде, салкын күз карашыннан тәнем чымырдап китте. Тигрга типкән усал милиционер иде бу. Безгә моннан рәхим-шәфкать көтәсе юк.

—Исем-фамилиян?

Әйтерсен урамдагы агачка эндәшә. Мине танымады микәнни сон?! Танымаса гына ярар иде. Юк! Юк! Танымады. Аллага шөкер, танымады. Таныган кеше болай сорар идемени.

—Харис... Сәүбанов.

—Кайсы авылдан?

—Сон... Вәрәштән инде, шушыннан...

—“Сон” да юк, “инде” дә юк. Сораганга бер сүз белән җавап бирәсе. Анлашылдымы?

—Әйе!

—“Әйе” түгел. Анлашылды.

—А-а... анлашылды.

—Кайсы урамда торасын?

—Вахитовта.

—Укыйсынмы?

—Укыйм.

—Ничәнче класста?

—Алтыда... Бишне бетердем.

—Пионермы?

—Пионер.

—Ленин—Сталин эшенә тугрылыклы булырга тантаналы вәгъдә бирденме?

—Бирдем.

—Пионерлар бары тик дөресен генә сөйли. Шулаймы? Пионерларнын бу законын беләсенме?

—Беләм.

—Дөреслек хакына, хак эш өчен хәтта туган әтисенен кынгыр эшләрен фаш иткән намуслы, батыр пионер Павлик Морозов турында ишеткәнен бармы?

Милиционернын сораулары үтә гади иде, анлаешлы иде. Әллә нәрсә сорамый ич. Тимер кыршау булып йөрәгемне кысып торган курку

хисе акрынлап тарала башлады. Хәтта бу сорауга кинрәк җавап бирүне дә мөмкин таптым:

—Бар! Безнең отряд аның исемен йөртә...

—Яхшы... Менә хәзер чын пионерларча әйт: МТС мастерскоен ничәнче тапкыр басуыгыз?—Һәм кистереп өстәде.—Җавап бер сүз белән!

Авызымны ачып каттым да калдым. Нинди мастерской? Нинди басу? Моңа инде бер сүз белән генә җавап бирү мөмкин түгел иде, ничек өстемә нахак бәла алыйм?!.

—Басканым юк! Мин бур түгел!—дидем.

Өстәлгә йонлач йодрык килеп төште.

—Кабаттан кисәтәм: җавап бер сүз белән генә... Тиз, тиз әйтергә! Көттермә! МТСка кергәнең бармы?

—Бар.

—Ничә тапкыр?

—Күп.

Телемне аркылы тешләрдәй булдым. Бу хәйләкәр, мәкерле абый үз авызым белән "Мастерскойга кердем" дип әйттерергә маташа ич. Минем анда, эткәйгә ияреп бер кергәннән соң, аяк басканым да юк лабаса! Мытыес ихатасы белән мастерскойның икесе ике нәрсә икәнен белмимени бу? Мастерскойда анда вахтер тора, безнең ишене кертәләр димени! Әмма әйтелгән хәтлесе әйтелгән иде инде. Сорауларга уйлап, ай-һай уйлап җавап бирергә кирәк икән.

—Ник кердең?

—Ат бугына.

Милицонер, шаярта дип белдеме, башын артка ташлап ихахайлап көлде һәм кинәт өстәлгә китереп сукты. Кремль белән телефон аппараты сикерешеп куйдылар. Җилкәләрем куырылып килде, тагын да кечерәеп калгандай булдым.

—Ананны... Әле син болай да сөйләшә беләсенмени!?

—Әнкәйгә тимә!—дип кычкыруымны сизми дә калдым.

Ул исә мине яңа гына күргәндәй, каш астыннан карап алды да, эре тешләрен күрсәтеп, киң итеп елмайды.

—Менә моңысын хуплыйм. Молодец! Әниеңә тел-теш тидертмисең. Дөрес эшлисең. Йә, Харис, инде, әйдә, әйбәтләп кенә сөйләшик. Килештекме?

Сүзсез генә иңнәремне җыерып куйдым.

—Йә, килештекме? Мин синең әйбәт малай икәнеңне беләм. Үпкәләшмичә генә аңлашыйк әле. Син пионер бит.

—Килештек,—дип мыгырдандым мин җинел сулап. Әллә кайчан шулай дигән булса...

—Теге тәгәрмәчне каян алдыгыз?

—Мытыеста... чирәм арасыннан табып алдык.

—Шунда, чирәм арасында башка нәрсәләр дә юк идеме соң?

—Юк иде... Мин күрмәдем. Нәрсәләр ул тагы?

—Ну... вольтметр, амперметр, монометр... Аларның ни икәнен беләсенме?

—Беләм. Белмәскә...

—Аларын кая куйдыгыз соң?

Нindидер олы җинаятьтә гаепләргә җыенуларын шунда гына аңлап алдым. Бу абзый миңа бер генә тамчы да ышанмый, керфекләрен кысып, күзләре белән үтәли тишәрдәй текәлүе дә шул хакта сөйли ич. Авызым кипте, телем аңкавыма ябышты. Ниһаять, сүз әйтерлек хәлгә килдем.

—Минем аларны алганым юк! Мин... мин бернәрсә дә белмим.

—Әле генә беләм дип әйттең ич... Ну... ышаныйк ди. Тәгәрмәчне кайчан таптыгыз, кайдан таптыгыз?

—Өченче көн иеме соң әле. Әйе, өченче көн... Самахутный комбайн янында.

—Менә шул, энекәшем. Шул ук көнне МТСтан, шул ук комбайннан

әнә теге син белгән приборлар да юкка чыккан. Йә, ни диярсен? Канатланып очтылар микәнни?

—Бернәрсә дә белмим. Мин алмадым.—Милиционерны берничек тә ышандыра алмаячагымны бөтен тирәнлеге, ачылыгы белән анладым. Янымда Рәшит тә барлыгы шунда гына искә төште. Ана төрттем.— Рәшит, син әйт инде ичмасам, бергә кердек бит. Алмадык бит!.. Тәгәрмәчтән башка бернигә дә тимәдек бит!

Милиционерның күзләре ялтырап куйды. "Кхым, кхым" дип ютәлләштергәләде һәм торып, тәрәзәсез яктагы икенче ишекнен биген шалтыратырга кереште. Ат күзе чаклы гына тишекле бу ишекне хәзер генә күреп алдым.

—Кил әле, Харис! Син монда утырып тор! Энең белән сөйләшеп карыйк,—дип ул ишеккә күрсәтте.—Бәлки, ул сина караганда акыллырактыр.

Йөрәгем каядыр аска төшеп китте. Китаплардан укып беләм: төрмә камерасынын ишеге шундый була икән.

Ишек шартлап ябылды, каранГы бүлмәдә берьялгызым калдым. Кечкенә тишектән кергән аз гына яктылыктан бернәрсәне дә күрерлек, чамаларлык түгел иде. Борыныма тынчу, сасы ис килеп бәрелде. Сидек исен дә, юынтык су исен дә хәтерләтә иде ул. Аягым сыгыла башлады. Еламас өчен йодрыгымны тешләп, стена буена чүгәләдем.

Бераздан зиһенем тупланды, ишекнен икенче ягында ни сөйләшкәннәрен ишетер хәлгә килдем.

Милиционер абзыйның тавышы йомшарган, ул тәмле итеп, юмалап сөйләнә иде.

—Машина яратам, дисең инде алайса... Әйбәт. Машина яраткан малайлардан юнь чыга алардан.

Тынлык. Дагалы итек тавышы. Тәрәзә ачылдымы, нәрсәдер шыгырдады, пыяла зынлады.

—Кил әле монда. Кара әле. Матур машинамы?

—Мату-у-ур...

—Шуна утырып йөрисең киләме? Кем әле син? Рәшит бит, әйеме!

—Әйе. Киләә, милиция абый...

—Менә, апаем, сезне шул машина белән өегезгә үк илтеп куярбыз. Бөтен малайлар шаккатар әле. Шулай бит.

—Шул-ай.

—Менә, килештек тә. Хәзер, апаем, бер генә сүз әйт тә илтеп куябыз. Әйтәсенме?

—Әйтә-ә-әм... Нигә әйтмәскә!..

—Жә... теге әйберләрне кая куйдыгыз.

—Нинди әйбер? Без бит бер әйбер дә алмадык.

Ай, рәхмәт яусын, Рәшит! Алданмады. Анын һәр сүзе өчен ут йотып, үзем әйтердәй булып ишеккә капландым.

—Юк, болай бармый, Рәшит. Син үскән малай бит. Почти егет. Син бер генә сүз әйт: алдык, диген. Кая куйганыгызны әйтмәсәң дә ярый. Абыеңны да, үзеңне дә машина белән илтеп куябыз. Әйтәм, диден бит. Килештек бит...

—Ю-у-ук! Без алай килешмәдек...

—Син курыкма, Рәшит. Сукмыйбыз, ачуланмыйбыз. Берәрсе тырнак белән генә чиртеп карасын! Миңа әйтерсен... Мин аларны... Жә, әйт. Алдык, диген. Шуннан кайтып китәсез.

—Алмадык бит, милиция абый. Тәгәрмәч алдык, бүтән әйбергә тимәдек...

Тавышыннан сиздем, Рәшит елап жибәрер хәлгә житкән иде инде. Шулчак кылт итеп анын: "Әллә нинди малайлар коймадан сикереп чыгып китте",—дигәне искә төште. Чак кына кычкырып жибәрмәдем. Ярый тыелып калдым. Әгәр әйтсәк, аларны таптырып тинтерәтәчәкләр. Әйттермичә туктамаячаклар. Бөтен Вәрәшкә әләкче, мәгънәсе буенча

коточкыч, без аны шулай дип беләбез, "стукач" дигән данybыз таралачак. Беркем сәлам дә бирмәс хәтта. Юк! Андый исем күтәргәнче, шушы камерада тончыгып үлүең мең кат яхшырак!

Ишектәге йозак шалтырады. Яныма тавышсыз гына үксеп Рәшит килеп керде.

Милиционер ишекне каерып ачты һәм ике кулын кесәсенә тыгып, бусагада басып калды, теше арасыннан чертләтеп безнең якка төкерде.

—Ил тәгәрмәченә таяк тыгучы корткычлар,—диде.—Сезнең ишеләрне балачакларыннан ук сытарга, изәргә кирәк. Төшендегезме? Ә хәзер уйлагыз. Ныклап уйлагыз. Алганыгыз искә төшкәч тә әйтерсез... Искә төшә ул. Олы абзаларыгызның да хәтере яхшыра монда кергәч.

Ишек шартлап ябылды, йозак чылтырады.

Күпме утырганбыздыр, белмим. Милиционер бүлмәсенә кемнәрдер керде, кемнәрдер чыкты, телефон шылтырады, сүгенделәр, пышылдап сөйләштеләр... Мин вакыт исәбен югалттым. Анда ни эшләнүен тынлар хәлдә түгел идек инде.

Карын ачты, тышка чыгасы килә башлады. Чыдар әмәл юк. Бер-беребезгә сыенып утырганбыз да йоклап киткәнбез. Хәер, йокы түгел, әллә нинди ангы-минге килеп онытылу, күз ачык көйгә ою иде ул, ахрысы.

Ишек артында таныш тавыш ишетелгәндә икебез дә астыбызга җибәрер хәлгә житкән идек инде. Урындыкмы, ишекме дөбердәде, кемдер каты итеп өстәлгә сукты.

Йа хода! Әнкәй бит. Әнкәй килгән бит. Рәшит белән икебез дә ишеккә капландык.

—Оятсыз, җир бит икәнсең! Оныттыңмы, сугыш вакытында балаларымның соңгы кыерчыгын бүлешеп, ачлыктан, ач үлемнән алып калган малай бит син. Инде үсеп кеше булдыңмы? Кеше таларга өйрәндеңме хәзер? Ике сабыйның канлы күз яшьләре тотмас дисеңме?! Тотар, тотар әле бер. Алла бар ул, бар!..

Әнкәй тыела алмый, кычкыра, ярсый-ярсый каргый иде. Милиционерның "Хөррия апа, Хөррия апа! Туктале... Мин бит",—дип нәрсәдер әйтергә теләгәнен колагына да элмичә ул үзенекен тезде дә тезде.

—Ярар. Ялгышып тәгәрмәч алганнар икән... Алар белән башкача сөйләшеп тә буладыр. Әтиләре өйдә юк дигәч тә. Әллә син аны кайтмас дип беләсеңме! Аның белән дә сөйләшерсең. Мин дә кимен куймам. Сугыш вакытында ир дә булдык, ат та булдык. Мин ирләрчә дә сөйләшә беләм.—Ул гомерендә әйтмәгән әллә нинди сүз әйтте, "Җаптыуашмы айт!" диде. Тагын өстәлгә суктылар.—Әйт, кая куйдың малайларымны? Башларыннан бер чәч бөртеге генә төшсә дә мин үземнең ни эшләячәгемне белмим. Минем шул балаларымнан башка югалтыр әйберем юк! Алар өчен теләсә кемнең бугазын чәйним. Бел! Гомереңдә рәхәт күрмәссең. Ул хәтле мәсхәрәләргә!..

Шулчак милиционерга гайрәте кайтты, үзенең кем икәнлеге исенә төште булса кирәк, калын, усал тавыш яңгырады:

—Хөррия апа, телеңне тый! Мин—закон сакчысы... Бер кәлҗемә бирдем, дигәч тә... Үзенне тотып ябарга да...

—Ай оятсыз, чыраена ыштыр каплаган нәрсә икәнсең... Рәхмәтең шулмы? Үз балаларымнан өзеп айлар буе тамагыңны туйдырганым бер кәлҗемә булдымы? Йә, яп мине дә! Нигә япмыйсың? Надан дигәч тә, әллә без белмибезме законны? Мин прокурорга да, Казанына да, Мәскәвенә дә юл табармын... Закон кушамы сиңа бала-чаганы төрмәгә ябарга? Әйт, кая яптың?

Минем тамак төбенә төер тыгылды, сүз әйтә алмас хәлгә килдем. Рәшит исә миңа капланды да кычкырып елап җибәрде, яшенә буылып кычкырды:

—Әнкәй! Ән-кә-ә-әй! Без монда! Монда!..

Урамга чыктык. Әнкәй икебезне ике яктан житәкләп жилтерәтеп алып китте. Иреннәре кысылган. Ни кызгану, ни әрепләү жәһәтеннән ник бер сүз әйтсен!..

Без бу минутларда әниләренен имиенә ябышкан ач көчекләрне хәтерләткәнбездер шикелле. Икебез дә тавышсыз гына үкси идек. Ә бәвел куыклары шартлар дәрәжәгә житкән.

Ярый әле янымда Рәшит бар. Ана килешә. Ниһаять, ул түзмәде, сөйрәлеп туктап калды да ботын кысып уаланырга кереште.

Анлады, хәлебезне анлады әнкәй. Кулларыбызны ычкындырды да таш коймага сыенып үскән карт, юан өянкеләргә таба ымлады.

И ходаем! Дөньяда ин рәхәт нәрсә шушы икән! Өянке төбеннән башланган агым тузанлы сукмактан урамга житте, әнкәй янына шуыша башлады. Ләкин һич кенә дә туктар әмәлебез юк иде. Бу минутларда мина тәгәрмәч тә, арба да, милиция дә, ат тизәге дә... бернәрсә дә... бернәрсә дә кирәкми иде.

Башымнан ачышка тин уй йөгереп узды. Кешене бәхетле итү өчен бик аз нәрсә кирәк икән ләбаса! Башта иреген чикләп, кыс, мәсхәрәлә дә аннары аз гына ирек бир. Ул гомере буе шатланып, сөенеп яшәр. Тормыш кануннары шундый усал, аяусыз микәнни?!

Һәр көнем газапка, әрнүле көтүгә әйләнде. Мин көтәм. Тәмамланмаган сөйләшүнен ахырын көтәм. Ишеккә кемдер килеп бәрелсә, дерт итәм. Урамда таныш түгел кеше күренсә, ераккарак, читкәрәк китәргә тырышам. Тагын мине алырга килгәннәрдер, тагын милициягә чакыралардыр сыман тоела.

Минем тизрәк, тизрәк үсәсем, бу газаплардан котыласым, Вәрәштән чыгып китәсем килә. Читтә, еракта тормыш матурдыр, яшәү рәхәттер. Шулай булмаса, жидене бетергән малайлар-кызлар читкә чыгып китмәс иде. Ана хәтле минем тагын ике ел, тоташ ике ел, озын, чиксез озын ике елым бар әле.

Ләкин милиция дә, йомышчы да кабат килмәде. Атна-ун көн үттеме-юкмы, мытыес малайлары арасында сүз йөрде: теге приборларны тапканнар. Кемнәр алган булгандыр, ул хәтлесен тәгаен белмәдем. Мине анысы кызыксындырмый да иде. Ин мөһиме—өстемнән күләгә төште, буялган кара, пычрак шиктән котылдым.

* * *

Жанымны әрнеткән бу вакыйга онытыла да башлаган иде инде. Көннәр бер төрле ага да ага...

Урам якка караган тәрәзә каршындагы өстәлдә такта кисәгеннән пропеллер ясап маташа идем. Хәзер малайлар агачтан самолет ясый. Өчәр, дүртәр, хәтта бишәр пропеллер куялар. Бомбардировщиклар...

Шулчак урамнан ниндидер күләгә үтеп киткән кебек тоелды. Пычакны куйдым да ишегалды ягындагы тәрәзәгә күз салдым.

Абау ла! Безнен коймасыз капка артына кемдер сөялгән, такта ярыгыннан мылтык—аны мәктәптә вак калибрлы винтовка дип йөртәләр—чын мылтык көпшәсе күренеп тора иде. Менә ул акрын гына өскә күтәрелә башлады, нәрсәдер эзләп йөрергә кереште. Ул төбәлгән якка каравым булды, чырыйлап кычкырып та жибәрдем. Тигр ич! Тигр! Бернәрсә сизмәгән Тигркаем сөяк кимереп ята!

Ничек атылып чыкканымны да, Тигрга гәүдәм белән капланганымны да, күтәреп өйгә сикергәнемне дә хәтерләмим. Бөтен тәнем дер-дер килә, тешләрем тешкә бәрелеп шыкылдый иде.

Шартлап ишек ачылды, усал тавыш ишетелде:

—Чыгар, мокыт, әнчегенне! Райисполкомнын карары бар: бәйсез этләрне атарга!

—Бирмим! Бирмим! Тигр бәйсез түгел. Мин аны хәзер... Хәзер

бәйләп куям. Ул безнеке. Безнеке ул! Урам эте түгел!..

Ишектә инде безгә таныш, теге усал милиционер басып тора иде.

—Давай! Хәзер минем күз алдында чыгарып бәйлә! Живо!

Калтыранган кулларым үземә буйсынмый иде. Бернәрсә аңламаган, койрык болгап сикергәләгән Тигрны кочаклап алып чыктым, кәҗә бәйли торган бауны табып, ашыга-ашыга аны лапас капкасына бәйләп куйдым.

Йөрәгем күкрәк читлеген ватып чыгардай булып бәргәләнә, кулларым һаман калтырый, тәнем кызыша иде. Милиционерның кушканын тизрәк, тизрәк үтәргә кирәк!

Бәйгә өйрәнмәгән Тигр күзләремә тутырып карады, аның көдрә йон арасыннан миңа төбәлгән зур, түгәрәк кара күзләрендә беренче тапкыр әллә нинди рәнҗү күргән кебек булдым шул чакта. Кинәт ул баудан тартылды да мылтыклы кешегә ярсып өрергә тотынды.

—Тукта, тукта, Тигр! Хәзер, хәзер бетә, җаным! Түз инде,—дип сөйләндем мин ни эшләргә белмичә.

Башыннан сыйпадым да читкә атладым, нәкъ шул мизгелдә ату тавышы яңгырады. Тигр чак кына чинап куйды, гәүдәсе калтыранып алды да тынды. Авыз кырыеннан сузылып кып-кызыл кан агып төште.

Мәкернең, кабахәтлекнең мондыен, бу кадәр астыртын әшәкесен белми идем. Җитмәсә, үз кулларым, үз кулларым белән бәйләп бирдертте бит!..

Яшьләремә, тамак төбемнән бәреп чыккан үксүгә буылып, иң кадерле, иң тугры, иң гөнаһсыз җан иясенең гәүдәсенә капландым.

Дөнья караңгылыкка чумды.

* * *

Тигрны мытыес сарайлары артындагы бушлыкка илтеп күмдек. Кабер өстенә агачтан нәни чардуган кордым, кызыл йолдызчык беркеттем.

—И газиз дустым! Сине бүтән күрмәм микәнни инде?!.

Тирә-яктагы малайлардан да оялып тормадым, сарай стенасына капландым, җилкәләрем дерелди башлады. Иптәшләрем каршында яшермичә, оялмыйча беренче һәм соңгы тапкыр елавым булгандыр ул.

Малайлар сүзсез иде. Кинәт кемнеңдер җылы кулы инсәмә кагылды. Борылмадым.

—Хари-и-ис! Мин сиңа яңа көчек бирермен, яме. Сизгернең көчекләре булырга тора бит!..

Лилия тавышы иде бу. Ярый әле җир йөзендә ул бар! Аның ягымлы, колакны иркәләүче тавышында мин үземне кызгану, кайгы уртаклашу, чын күңелдән ярдәм итәргә теләү һәм... кара төн пәрдәсен яшен камчысы кисеп уздымыни, әллә нинди, әле монарчы беркайчан да ишетмәгән бүтән бер аһән—моны тәнемнең бөтен күзәнәкләре белән тойдым—минем барлыгымны, бәгыремдәге бәргәләнүне, ятьмәгә эләккән балык шикелле чапаланучы җанымны аңлау төсмерен дә абайлап алдым. Лилия дә бу мизгелләрдә нәкъ мин кичергән хисләрне кичерә иде булса кирәк. Ярый әле җир йөзендә Лилия бар!

*1991-2000*

*Голицыно-Казан.*

# ШИГЪРИЯТ



## Шәүкәт Галиев

### СУЛАР АГА, УЙЛАР АГА

**Ник?..**

Иртән тордың моңланып,
Кичен яттың шомланып—
Замана тавышыннан
Сагаеп та тыңланып.

Ишегеңдә ничә бик,
Күңелеңдә нигә шик,
Нигә имин түгел җан—
Син туган җиреңдә бит?

Әйләнеш тә тулганыш,
Әрле-бирле болганыш,
Дуңгәләктәй тамырсыз,
Ник тотрыксыз булган эш?

Безнең гасыр тырышкан,
Вәхшәт белән тулышкан,
Ни китерер яңасы—
Ни күтәргә тормыштан?

Яшеннәр яшьнәр кебек,
Шаулап боз төшәр кебек,
Хәвефләнәсең, алда
Бер дәвер яшәр кебек...

**Яктырдым, дип...**

Таң алдыннан йокы кача—
Ул төн кошы микәнни,
Кояш белән бергә вөҗдан
Уяныр чак җиткәнме?

Йолдызларны көн күмсә дә
Төн тәмам ук югалмый:
Кара сакалың шикелле
Күләгәң арттан калмый.

Яктырдым дип, сафландым дип,
Ашыгып алданма ла—
Күрәмсең, кайчак күләгәң
Үзеңнән алда бара...

## Каралама

Өстәлемдә ап-ак кәгазь,
Каләм эзләр сала бара—
Яздым-сыздым да төзәттем,
Инде булды каралама...

Ният изге! Пычраттың дип,
Өстән генә карама ла—
Карала да, агара да,
Чынлык шулай аралана...

## Шом йөри шым гына...

Шом-мыштым—төн юлдашы,
Караңгы күләгәсе,
Ачык яткан күңелләрдән
Кемнәргә эләгәсе...

Шом йөри кара томандай,
Тотрыксызны өркетеп,
Яктыда ул үзе поса—
Өмет яши көн көтеп.

Бәлкем төннәр биреләдер
Адәмне сынар өчен,
Йомшап калган җаннардагы
Куркуны сыгар өчен?

## Сулар ага, уйлар ага...

Җил—җилбәзәк,
Су—моңсу,
Күзем алмыйм сулардан.
Сулар ага, уйлар ага
Үзе салган юллардан.

Тынгысыз җаннарны көйли,
Сулар уйдаш микәнни,
Күзләренә карап аңлый
Туган илдән киткәнне.

Тыныч елгам, сабыр суым,
Еракка барасың ла,

Югалыр көмеш тәңкәләр
Дулкыннар арасында.

Иксез-чиксез киңлекләрдә
Диңгез канат кагыныр.
Уйчанланып бер тынар да,
Кемнәрнедер сагыныр.

Җил—җилбәзәк,
Су—моңсу,
Күзем алмыйм сулардан,
Күңелем чайкалып бара
Уйлар салган юллардан...

## Балчык хәтере

Балчык—бик файдалы диләр,
Балчык—хәтерле диләр,
Тирән казыйлар галимнәр,
Ниләр генә димиләр.

Кызыл балчыкның роле зур
Минем тарихларда да,
Табигать аны күп иткән
Безнең тарафларда да.

«Нужа балчык ашата» ди,
Без дә балчык «ашадык»:
Иң әүвәле—эвәләдек,
Кызыл кирпеч ясадык.

Аннары «уфалла» белән
Ялчеккә илтә идек,
Алучылар булмаганда
Кире дә китә идек;

Барганда өмет тизләтә,
Кайтасың акрын-акрын,
Өмет ягы унбиш чакрым,
Юл уңмау—утыз чакрым...

Мондый чаклар булмаганмы,
Булган инде, түзәсең,
Ачкарынга җиңел була—
Биеп балчык изәсең.

Безнең ялан аякларга
Сеңгәндер шул файдасы.
Ачлыктан коткарып калды—
Зуррак файда кайда соң?

«Балчык хәтере» дигәне
Чын микән, ялган микән,
Кирпечләрдә янган микән,
Тауларда калган микән...

## Ак болын

Гомеремдә бу беренче
Ромашкалар туе иде,
Яшел болын күренми дә—
Аклык шундый куе иде!

Сөенечле аклык иде,
Аклык иде бертоташтан,
Биеп торган сафлык иде—
Офыклардан ташып ашкан...

Ак болында ак күбәләк—
Мәхәббәтем, син идең ул,
Саф яшьлегем кабатланган—
Канатланган мин идем ул.

Иреннәргә ирен килеп:
«Ак чәчәкләр көне» дидек,
Искә алыйк һәр ел саен,
Икебезнең сере, дидек.

Бер көн түгел, ул бер гомер,
Гомергә дә сыймас булды,
Үткәнемә, килеремә,
Шул гөнаһсыз аклык тулды.

... Бер иде дә безнең күңел,
Төрле икән күрәчәкләр:
Күзләремә яшь китерә
Һәр ел саен ак чәчәкләр...

## Егерменче гасыр азагы

*Рәссам Абрек Абзгилдинга—*
*«Язгы моң» картинасы уңаеннан.*

Яз аенда туган рәссамның
Язсыз булырмени язганы,—
Кайсы яз бу, кайсы ел дисәң,
Егерменче гасыр азагы.

Безнең гомер соңрак фасылда—
Нихәл көзләр, саумы-тазамы?
Таңмы соң син, әллә шәфәкъмы,
Егерменче гасыр азагы?

Уй-карашлар төрле тарафта,
Иҗат кына түгел газабың;
Намусыңның сират күпере—
Егерменче гасыр азагы.

Дәверләрне санар кәккүкләр,
Исән кичсә бәла-казаны.
Яңа алдашулар башлама,
Егерменче гасыр азагы.

Күп шауладык, тынып калыйк та,
Тыңлыйк әле иман авазын.
Киләчәккә карап күр безне,
Егерменче гасыр азагы!

## Мәчет манарасында

Айлы манарабыздан
Авылыма карадым:
Урам-урам тезелгән
Матур йортлар парады.

Истә, сабый чагымда
Кызыгып менгәннәрем,
Салам түбә ызбалар—
Электә күргәннәрем.

Кошлар биеклегеннән,
Догалы манарадан,

Бабамнар үткәнгә дә,
Килергә дә караган.

Күктән—өмет иткәнбез,
Җирдә—сабыр иткәнбез,
Ничек булыр моннан соң,
Шушы көнгә җиткәнбез.

Биектә рух канатлы,
Шулай да сиздe күңел—
Лаф орырга иртәрәк,
Заманы изге түгел...

Югары алып менде
Мине монда һәр адым:
Мәчет манарасыннан
Вөҗданыма карадым.

## Бу яз...

Бу язны да күрдек әле—
Мөлдерәмә кояшы.
Кемнәр бар да кемнәр юк дип,
Офтанып та куясың.

Әйтерсең лә синнән соң да
Ак чәчәкләр сибелмәс?
Сөенечләр арасында
Юклыгың да сизелмәс...

## Таң

Табигатьнең оеп торган мәле,
Әкрен генә офык ялтыра—
Күз карашым белән тартып-дәшеп,
Бүген Җиргә мин таң аттырам!

Күкләр уянуы бер могҗиза,
Күргәнем юк икән күптәннән,
Гомеренең серле бу сәгатен
Йокы-мәртт кеше үткәрә.

Җиргә Кояш туган мизгел ләса,
Аерып Җир-Күкләр арасын;
Тере ялкын, кайнар алтын чагы—
Туры төбәп карый аласың.

Җан чистарып шушы садәлектән
Хозурланып кылам тамаша.
Таң калып гел таңнан күзем алмыйм,
Җиргә карыйм мин саф таң аша.

*1999—2000.*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Аяз Гыйләҗев**

# КҮҢЕЛЕМ СЕРЛӘРЕ...

КУЕН ДӘФТӘРЛӘРЕННӘН

*1993 ел, 2 гыйнвар, көндез.*

Бүген сәфәр, Бигеш-Зәйләр аша Сарманга, аннан Иске Әлмәт дигән татар авылына кайтабыз. Нәкыя авылга кадәр мине озата бара. Юлга әзерләнеп, машинкамның хәрефләрен юдым да лентамны алыштырдым. Кул кычытып бер-ике юл язып куярга ниятләдем. Ниһаять, кышкы авылга кайтырга булдым. Әгәр һава килешсә, урын үзгәләмәсә, бик ныклап эшләргә исәп. Уйлаганны тәмамлый алсам—олы бер җиңү булыр иде.

*4 гыйнвар, Бигеш авылы, иртәнчәк.*

Аллага шөкер, икесендә үз вакытында кузгалып китеп, житез генә тәгәрәп Зәй якларына кайтып җиттек. Казанда чалт аяз иде, монда төнге җәяүле буран. Ярый әле Алмазлар машина белән көтеп торган. Тиз-тиз «Уазик»ка күчендек. Алмаз тауда куян куганда егылып, тагын дүрт кабыргасын сындырган. Былтыр ике кабыргасының ныклыгын сынап караган иде. Егыла, кабыргалары сына, үзе сизми. Берничә көн сызлаштырып йөргәч кенә, кинәт ясалган хәрәкәттән, кабыргалар сынган төштә үз урыннарыннан кубып кузгалалар. Шунда гына рентгенга бара һәм... Ятып булмый ди, йоклап булмый, гәүдәне элеккеге рәвешенә китерә алмыйча газаплана икән! Алмазның тормышы көйле, зарланмый, йорт-җирне, ихатаны караган, абзарлар житкергән, аранында кышлау бозау, «Мүкләк» исемле. Мал асрамасаң авылда ит табармын димә... Берәү дә сатмый икән...

И бу дөньяның хәлләре! Гап-гади ярты сүздән әллә ниләр белеп була. Борынгы дустым Гыйләҗетдиннең балалары Чаллыда яшәп, ел саен яңа ел тирәсендә кайтып йөриләр икән. Быел берсе дә юк, кайта алмаганнар. Өйләрен ташлап йөрергә куркалар—басалар, талыйлар...

Бигеш мәчетле авыл, мин мәчетле авылда кунакта. Мәчет балкып-ялтырап тәрәзәдән үк күренеп тора. Шунда гына хәзер энекәшемнең яңа шәп йорты мулла бабайның нигезенә менеп утырганын искәрдем. Мулладан калган йортны, каралты-кураларны хәтерлим ич мин! Өй ике

Ахыры. Башы 11 санда.

катлы иде, аскы өйдә остазбикә кызлар укыткан, үзенә күрә аскы өй мәдәният учагы булган. Ул эре-эре ташлардан житешлек белән салынган нык амбарлар, төз, биек кыеклы лапаслар, кар базы, келәтләр, алмалы-чияле янбакча... Йортның законлы төп хужалары кайларга китеп югалганнардыр да, Бигеш хәзрәтенен ак сөякләре кайсы жирләргә чәчелмәгәндер?.. Мәчет ачканда Казаннан Мансур Хәсәнов та кайткан икән. (Мансур Хәсәновның туган авылы!) «Мәчет салырга нык булышты», диде Гыйләжетдин. Мәчет ачканда әлек балкып яшәгән, сонра югалган хәзрәтләрне искә төшереп телгә алучы булдымы икән? Юктыр, без, кабатлап әйтәм, кыска хәтерле—юк халык. Мәчет авылны күккә күтәргән, мәчет Бигешне адәм балаларының бишеге—галәмгә якынайткан. Урамнан үтеп барышлый ирексездән гел шул якка каерыласын, күнел жирси, әйтер сүзләр иманга манчыла. Акча жәлләмәгәннәр бигешлеләр, матур итеп бизәп, таш мәчет салганнар. Хәзерендә унсигез карт намазга килеп-китеп йөри. Ара-тирә яшьләр дә күренеп кала икән...

Күнелнен бөтен барлыгы белән мәчетне зурлый-зурлый үтеп киттек тә зиратка бардык. Азат, мин, Алмаз, Нәкыя белән Әлфия (Азат өлкән абыйсы, Алмаз энесе, Әлфия Алмазнын кызы) әти-әни яткан изге жиргә баш орып озак кына басып тордык. Тын кыш, дөнья ап-ак, әрвахларнын жаны кунган каен ботаклары иелеп-иелеп безгә сәлам бирде. Без, тезелешеп житмешкә бара торган өч Гыйләжев, үзебезнен кайсы төбәкләрдә йокыга ятасыбызны уйлап монсуландык... Безнен балалар шулай жыелып исемнәребезне яхшы сүз белән яд итәрләрме? Әллә дөнья аларны да изеп, сытып, жаннарын тишкәләп бетерерме?.. Әти белән әни безнен өчәүләп килүебезне сизгәннәрдер, сизми калмаслар, ләхетләре жылынып вә яктырып киткәндер. Амин! Шулай булсын!

* * *

Гыйләжетдиннән сораштым... Мыек Яруллинның фамилиясе Мәхлисев булган икән. «Шактый әшәке кеше иде!» диде Гыйләжетдин. Инде Гыйләжетдин булып Гыйләжетдин, адәм балаларына бары тик яхшылык кына күрсәткән, жирдәшләренә гелән изгелек теләгән зат Мыек Яруллага шундый тамга салган икән... монда уйланырлык урын бар! Гомумән, сугыш елларында, сугыштан сон колхоз рәисе итеп әнә шундый «әшәке» бәндәләрне генә куймадылармыни?! «Усал гына түгел, әшәке!» дип кабатлады Гыйләжетдин.

Әшәкелекнен дә үз дәрәжәләре бар: усал, явыз, әшәке...

Бигеш, Бигеш... ындырларны юа-юа, ярдагы талларны берәмтекләп санап Аулаш елгасы—инеш ага. Биек тау, Кый тавы... Мыек Ярулла белән шул тау өстендә йөргән идек бит. Тырмачы малайлар янында. Горчицаны колхоз үзе чәчкән иде. Бүген иген-таруны сыпырып алып китеп бетергәннәр, ә горчица орлыгы калган. «Бөгелмәгә барырга туры килде,—дип сөйли Гыйләжетдин,—ике кило горчица орлыгы бирделәр. Атка да шул, үземә дә шул. Әнкәй әүвәл горчицаны кыздыра иде, аннан төя! Тәмле дә була торган иде инде! Сонынннан авыз эче яна!»

Бигеш үзгәргәннән үзгәрә, авылга яна төс куна. Коймалар тыгызланган, капкалар биегәйгән, йорт урыннарында таш пулатлар кукыраеп утыра, тәрәзәләр челтәрле, тимер капкалы гаражлар ишәйгән, кая карама бөтенлек, төзеклек һәм байлык күзгә кереп тора. Тик жан нигәдер монсулана, шушы бай ихаталарны, таза тормыш шаһитлары таш пулатларны бербөтен авыл итеп йомарлап торган төс юк. Баеган саен йортлар бер-берсеннән ерагайганнар төсле. Бер яктан сөенәсен, икенче яктан күнелне нидер кыра, борчый, авылнын милли төсен аерып булмый, нинди зирәк булсан да бу капка, койма артларына кереп бикләнгән адәмнәрне белә алмыйсын инде! Кунакка йөрешүләр кимегән, күршекүләнгә йомыш белән керүләр беткән, әгәр киләчәк авыллары кешеләрне шулай тарката торган булса, яшәү үтә күнелсез һәм суык булыр төсле.

* * *

ЖЗЛ сериясеннән Салтыков-Щедрин китабын карап утырам. Истә, Александр II патшаның резолюциясе истә: «И прекрасно: пусть едет служить да делает сам так, как пишет, то есть так, как желает, чтобы действительно делал хорошо».

*5 гыйнвар, Бигеш, иртәнчәк.*

Хәтер өзек-өзек чылбыр икән ул. Үткәннәрне тоташ юл-сукмак итеп һич кенә дә күз алдына китереп булмый. Вакыйгаларның урыны үзгәрә, вакытлары алмаша, үткәннәргә хәзерге мөнбәрдән торып бәя бирә башлавыңны сиземми дә каласың. Никадәрле гадел, сак булырга тырышсаң да күңел-хуҗа язмышына якты бәя бирергә тели, кылган вак-төяк гөнаһлар, адымнарыңа чүп-чар булып ияреп барган кыек-мыек эшләр читкәрәк этәрелә, ни тырышсаң да үзенә-үзең хак хөкемне чыгарып булмый. Күңелдә кат-кат тәүбәгә килсәң дә гөнаһларны тезеп салырга кул бармый, бәлки аларның кирәге дә юктыр, үз гомереңне синнән башка белеп бетергән җан иясе юк, нигә аларны дөньялыкта ук фаш итәргә, әле ходай каршысына барып баскач та тулы һәм дөрес йомгак ясыйсы бар... Анда инде гамәл дәфтәреңнең сынар сүзен дә яшереп кала алмыйсың! Адәм балалары бер-берләрен генә түгел, үз-үзләрен дә алдарга яраталар, юанып яшиләр, кешеләрнең әнә шул бәхетле юанычлары булмаса берәү дә гомереңнең язмыш билгеләгән азагына кадәр барып җитә алмас иде.

Шушы Бигеш авылы язмышымда шундый зур, мөһим урын тотар дип кем уйлаган?.. Хәбир Зәйнуллин—гомерлек акыл биреп киткән егет. Мут, наян, көр күңелле Гәрәй Гәрәев. Зәйдә эшләгәндә Сабан туена кайткан идек. Бигеш Сабан туеннан Иштирәк авылына киттек. Молотов шәһәреннән кунакка кайткан Әминә белән танышкан идем. Ак күлмәк кигән, сөйкемле кызыкай иде. Иштирәккә ат җигеп бардык, бәйрәмнән соң фатирга кайтсак, йөгәнебезне урлаганнар. Шулчак Гәрәй: «Сез бара торыгыз, мин куып җитәрмен!» диде, без атны чак-чак атлатып юлга чыктык. Элеккесеннән дә шәбрәк, җиз төймәләр белән бизәлгән каеш йөгән күтәреп Гәрәй куып та җитте. Елгыр егет иде... Бигеш, Бигеш... Шәйхулла Зиннәтуллин, мәрхүм... Ниһаять, Алмаз энем монда утыз биш ел врач булып хезмәт итте. Әти-әнине шушы авыл зиратына җирләдек... Күпме кешеләр, нинди зур вакыйгалар белән бәйләнгән мин шушы борынгы татар авылына!

*6 гыйнвар, иске Әлмәт авылы, кич.*

Күз тотып чыккан авылга бүген таңда килеп җиттек...

Кичә иртәнге чәйдән соң Зәйгә юл тоттык. Таныш дөнья, таныш юллар, күңелгә якын манзаралар, хатирәле таулар, елгалар. Бу бормалардан, шыгырдап калган күперләрдән ничә мәртәбә үттем икән дә нинди уйлар уйламадым икән? Һәр авыл исеме мине яшьлеккә алып кайта, моңсуландыра. Зәйдә озак юанмадык, Тәлгатьнең (туганнан туган энем, Зәй больницасында травмотолог) көндезге ашка кайтуын көттек тә, тамак ялгап алгач, Сарманга элдердек. Ял тәмам, кунак-кунак уйнауларны йомгакладык, урнашып, яңа урынга күнегеп эшкә тотынырга бик вакыт!.. Сарманда Әхнәф Гатауллиннарда кундык. (Әхнәф Гатауллин Нәкыянең туганнан туган сеңлесенең ире, ягъни киявебез). Озаклап сөйләштек, соң гына Сарман урамнарына чыгып, «Архангел» дип сәер исем белән аталган яңа бистә тирәләрен урап, Сарманның зураюына

гажәпсенеп, бизәлгән ятим чыршыны карап йокларга кайттык. Урамнар тын, ара-тирә машиналар уза да егет-җилән каядыр ашыгып үтеп китә. Элекке сыман авылларны бизәп, җанландырып торган уртак хәрәкәтләр юк. Һәр йорт, ихата борынгы крепостьлардай ялгыз, серле тынлыкта утыра. Сарман мин белгән почмак түгел инде, ул ят, андагы үзгәрешләрне күз элдереп, бер ноктага җыеп бетерә алмый. Соңгы елларда Сарман төбәгеннән нык ук читләштем бугай, җанга якын кешеләр картайды, аларга картлык олылыгы сеңде, мин аларны, алар мине аңлап та бетермибез шикелле... Шунамы Сарманда озак юанмадык, таң белән юлга чыктык. Тәкәй таулары өстенә менгәч, офыклар ачылды, кырлар киңәйде, сыек алсу төскә манчылып, дөнья ямьләнде.

Иске Әлмәттә безне көтәләр иде, куанып каршыладылар. Менә шушы байтак бүлмәләргә бүлгәләнгән җылы өйдә торырга кайттым мин. Урын сайлап, ары-бире караштырып йөргәч, сул яктагы нәни бүлмәчеккә кереп утырдым. Каршымда юка боз белән челтәрләнгән тәрәзә. Ятсынып мине күзәткән куакларда песнәкләр шаярып-уйнап ала, бер-берсеннән һич аерылмас әрсез чыпчыклар очып-очып куна. Мин яна тормыш башлап җибәрәм. Хәерлегә булсын!

*7 гыйнвар, Иске Әлмәт, көндез.*

Онытылганчы язып куйыйм әле...

«Юллар, юллар... Озын булса булсын, тик соңгысы гына булмасын!» Зәйдән энгер-менгердә чыгып киттек. Әле Ирнә күперен үткәнче күңел кыймылдап куйгаласа да тәмамысы уянмады. Урта юлга җитәрәк күкрәкне нидер кысты, күз төпләре дымланды. Сулда, карасу агачларын чайкап, Кашка тау шәйләнде. Без печән чапкан уйдыклар, без балык тоткан, кармак салган тугайлар, болыннар... Ятып суын эчкән чишмәләр! Ничәмә-ничә кат сез минем әсәрләремә кереп җанымны сүнмәс хатирәләр белән ураган, терелткән, җылыткан урыннар. Гомерем белән мин сезгә бурычлымын... Сезне—шушы гүзәл почмакны сездән горур биеклеккә күтәреп дөньяга таныта алмаганмын икән, нишлисең, күпме еллар пышылдап кына сөйләштек шул, күкрәк киереп, бөтен тавышка кычкырып данлап булмады... Урта Баграж зираты... Түбән оч. Машина тигез генә тәгәри, тәгәрмәчләр юлны урый, хатирәләрне сүтә. Менә Югары оч! Чуал ярларында карт өянкеләр. Баграж өянкеләре! Әти яратып утырткан агачлар! Әти вафатына унҗиде ел. Өянкеләре дә нык картайды. Алар да билләре муртаеп, ботаклары сынып, берәм-берәм эз югалталар. Кем утыртканын белгәнгә агачлар да кызганыч... Менә инеш аръягындагы тарлавык. Дөньядагы иң тыныч, иң тын урын. Тарлавыкны телеп таугa менә башласам, колакларым чыңлый, дөнья таулар иненнән минем инемә күчә. Рәхәт! Чиксез рәхәт! Үлән-чәчкәләрдән чыккан исләр куерткан татлы һава адымнарны ашыктыра, гомерне бизи, җиңеләйтә вә озайта... Җир шарында шушы тарлавыктан да кадерлерәк почмак юк мина. Өскә менәсең, унда Кызыл яр. Улларымны Кызыл ярдан таш тәгәрәтергә алып кайта идем мин. Бәхетле мизгелләр! Дөнья бәясе торырлык уртак хатирәләр. Балалар да бу тауларны хәтерлиләр, яраталар. Кызганыч, еллар үтү белән тау тәбәнәкләнә, аны ермачлаган чокырлар тирәнәяләр. Кар әз. Тау ала-кола. Беләм, хәзер анда җилләр уйный. Җилләр тарлавыкка ятып аска шуалар да Минәй чишмәсендә бөтерелеп, өскә, чуал буйлап әти утырткан өянкеләргә хәтле барып җитәләр...

Баграж... Керәшеннәр патшалыгы. Ягымлы, гади, юмарт күңелле кешеләр. Милли шикләнүләрдән азат яшәүче табигать балалары... Мин аларны шулай диеп белә идем. Янәшәдә, рәхәт итеп яшәдек монарчы. Соңгы елларда милли бәрелешләрнең хәвефле, шомлы мисаллары җанны куырып, өркетеп тота башлады. Югославия таралды, анда сыенып яшәгән халыклар бер-берсен кыралар, асалар, суялар. Хорватлар, серблар,

мәңгелеккә дошманлашырга бурыч алган кешеләрдәй, хәзер тыела алмыйлар. Бу кырылышны аларның милли лидерлары әзерләде. Тарих өчен, җир өчен, һава-сулар өчен, тагын әллә ниләр өчен үткәннәрдән канлы вакыйгаларны казып чыгардылар да халыкларны бер-берсенә каршы котырттылар. И китте суеш, и китте кырылыш. Милли чуалышлар тезгене милли лидерлар кулыннан бер ычкынса, аны авызлыклар көч юк. Алла кодрәте белән дә ул халыкларны ипкә китерә алмассың! Карабах өчен тарткалашкан әрмән-азәриләр тиз генә туганлашырлармы? Аның шаукымы йөз елларга барачак әле. Милли каршылыклар тарих төбенә салып калдырылган усал миналар алар, көне-сәгате житкәч шартлап ярылалар да, дөньяга яңа корбаннар бүләк итеп, каршылык дулкыннарын һаман көчәйтәләр. Гөрҗиләр белән абхазлар тиз генә яраларын ямарлармы?.. Осетин белән гөрҗиләр?.. Милли көрәмсезлек—куенына мең вулканны яшергән серле тау ул. Аларның берсе генә уянса да тауны нигезенә кадәр тетрәтә... Бүген юлдан ерак та түгел тын гына йокымсыраган керәшен авылларына шигәеп кенә карап барам: нигезләре тетри башламаганмы аларның?..

Китәр алдыннан нәшриятка, Фәрваз Миннуллин белән саубуллашырга кердем. Максим Глухов белән кара-каршы килештек. Зәй төбәгендә булган икән. «Керәшеннәр тормышына багышлап бер китап та язмыйсыз» дип зәйлеләр нык үпкәли,—диде ул.—Шул бушлыкны тутырырга йөргән чак. Тырыша торгач зур гына җыентык әзерләдек. Дөрес, урыс телендә. Зәйдә Вениамин Демьянович Некратов (Максим тагын ике-өч керәшен исем-фамилиясен хөрмәт белән атады) китапны нык хуплыйлар һәм матди, һәм рухи ярдәм итәләр. Бик кызыклы яңа фикерләр белән баетылган китап булачак». Аны-моны уйлап тормадым: «Минем дә Баграж керәшеннәре турында, аларга атап бер мәкалә язасым килеп кыҗрап йөрим», дидем. Максим Багражда да булган икән, «Гурий Тавлинны да, Мулла Гуриен дә беләм!» диде. Гурийнең кушаматы «Мулла Гурие» икәнен каян белүенә гаҗәпләндем. Мулла?! Бу кушаматны белә идем, онытканмын. Ни өчен һәр сүзен сергә, һәр ишарәсен тирәнлеккә манчырга тырышкан Максим Гурийны яратмый башлаган әле? Мин яңадан кабатлап: «Баграж керәшеннәренә багышлап хатирә язасым килә», дидем. Ул: «Ә син Багражның нинди мәгънә аңлатканын беләсеңме?» дип сорады. «Юк» дидем. «Сары саз» дигән сүз ул», диде Максим. «Ә бездә Сарсаз Баграж авылы бар», дидем мин, нигәдер сөенеп. «Ә син ул хатирәләреңдә кайсы якны яклыйсың? Керәшеннәр әүвәл татар булган, шуннан соң гына чукынып христиан диненә күчкән дип раслыйсыңмы?» Мин аны-моны әйтергә өлгермәдем. Югары Багражны, авыл-тыкрыкларын, кушаматларны җәһәт-җәһәт күңелдә үткәрергә тотындым. «Тугашлар тыкрыгы», «Микиләр тыкрыгы». Тугаш—борынгы татар исеме түгелмени?.. «Юк,—дип ышаныч белән дәвам итте Максим,—без бер чакта да татар булмаганбыз, без—керәшеннәр. Керәшеннәр Идел-Чулман буйларында Грозный патшага кадәр үк булган, яшәгән. Мисалга, Сөембикә патшаның җансакчылары, гвардиясе бары тик керәшен яугирләреннән генә торган. Мөселман-татарлар хыянәтчеләр, алар христиан динен сатып татарга әйләнгәннәр». Максимның үзе әйткәннәргә ышанган, бүтәннәрне дә шуңа ышандырырга тырышуы, киреләнгән ныклыгы һәр сүзеннән яңгырап тора иде. Ул миннән раслау да, кире кагу да көтми, мине дә үз ягына аударачагына, дөньядагы дөреслеккә бары тик үзе генә хуҗа икәнлеккә ышандырасына шикләнми иде. Газеталарда аның бу фикере, керәшеннәрне татарларга капма-каршы куюы, тарихтан шуңа дәлилләр табарга тырышуы күземә чалынган иде. Хәзер аның шомлы хаксызлык китерәчәк теориясе белән кыска гына танышкач, мин куркып киттем. Китап дөньяга чыгар, Зәй төбәге вәкилләре керәшеннәрнең тарихи дөреслекне яклаучы аңлы төркем икәнен авыз тутырып сөйли башларлар. Милли корт ин нык агачларны да кимерә!.. Нәтиҗәдә, татар-керәшен каршылыгы үсеп чыгар. Тарткалашу башланыр. Башкорт-татар милли кискенлеге тирәсендә татар-

керәшен каршылыгы ныгыр. Татарлар әзме-күпме жанлана, үзара аңлашып яшәргә омтыла дигәндә, тын гына оеп утырган кашка тау күкрәгеннән вулканнар ут чәчеп дошманлык тарата башлар. Аллам сакласын, авызымнан жил алсын!..

*9 гыйнвар, Иске Әлмәт.*

—Ана сөте авыз итмәгән бала—бичара.

—Бөтәү, бөтәвесе.

—Җил. Ике көн, ике төн тоташтан жил. Басуда кар әз, аны да жил тыкрыкларга, читән ышыкларына, чокыр-чакырларга ташып бетерде. Тар тыкырыктан кар кикрикләре өстеннән бата-чума барабыз. Җил эшсезлекне яратмый, ана ни булса да кучерергә, өяргә, ватарга кирәк. Басуда кар беткәч ул ужым төпләрен талап туфракны күчерә башлады, кар кикрикләре каралды, шырайды, карак жил һаман туймый, туксырмый, гуж бине гонык, һаман себерә, талый, усаллана, улый, чиный...

—Җил, жил. Кискен, мәрхәмәтсез гыйнвар жиле. Битне кисә, күзләрне яшьләндереп йомдыра, колакларны аяусыз тешли. Анда-монда ышыкта посып утырган песнәкләр, хәл жыеп-жыеп утыралар да жил уңаена ташланып бер урыннан икенчесенә күченәләр. Күз ачып-йомганчы жил-давылны иярләп икенче ышыкка барып куналар да дөп-дөп типкән йөрәкләрен сабырландырып бер-берсенә карашалар. Егет песнәкләр кыз песнәкләргә карап: «Күрдегезме, абзагызны? Җил-давылны бар дип тә белмәдем! Кистем дә үттем. Канатларыма килеп кагылган жилнең хәле бетте, көче кимеде... әнә, теге аралыкка кереп яткан кар-бураннар миннән жинелгән жилләр алар!» дип әйтәләр төсле.

—Җил, жил. Алай да кошлар жим эзләп ихата тирәсендә туктаусыз очалар, әйләнәләр, тулганалар да йорт тирәсен, бакча читләрен сарган миләш тәлгәшләре котырып атынган агач ботакларына килеп ябышалар. «Миләш ашарга каяндыр озынчарак, күгәрченнән чак кына ваграк кошлар килә. Быел урманда жим мул булды, кар озак яумады, миләш убырлары моңарчы күренмәде, әлерәк кенә яу булып безнең бакчаларга төштеләр. Бу вакытта элгәрге елларны бер чөм миләш тә калдырмыйлар иде. Быел соңардылар. Әмма хәзер миләш агачларына көн бетте: авыр гәүдәләрен көч-хәл белән күтәргән каргалар да ташлана ана, әллә кай ярыклардан очып чыгып саесканнар да аны ботарлый, «безгә калмый, безгә калмый!» дип чыпчыклар да соры болыт булып миләшкә елыша, сак вә кыюсыз песнәкләр дә шул тирәдә пыр-пыр оча, чыда гына, миләш!..» ди Рәис хужам.

* * *

Караклык монда да килеп житкән. Руша ягындагы авыл очында, иң кырый йортта яшәүче берәүнең ябык абзарына төшәләр дә дүрт сарыгын суеп, тунап, эчен-башын ташлап, итләрен алып китәләр. Атнаун көн үтүгә шул ук абзардан хужаның соңгы сарык малын—симез тәкәне йомдыралар. Эте була хужаның, бурлык алдыннан этне агулыйлар, эт исән калса да тавышы бетә, өрә алмый башлый.

Кичә телевизор аша Фәннур Сафинның вафатын хәбәр иттеләр.

Монда сәфәр чыгар алдыннан гына, нәшрияттамы, Комлев пулатындамы очрашкан идек. Очрашуыбыз мәзәк диярлек булды. Фәннур гел елмаеп, басымчак кына миңа карап торды. Мин аның учын кулымнан жибәрмичә, нигәдер тоташтан яхшы, ихлас сүзләремне әйттем. Хәзер хәтерләмим, сүзләре сенеп өлгермәгәндер ахрысы. Фәннур үзенең ялгызлыгын, хатыны ташлап китүен телгә алды. Машинага бәрелеп зиһене әз-мәз таралган бу һәйбәт, сәер шагыйрьне хатыны ташлаган иде шикелле.

Ярым гариплеген, ятимлеген уйлыйм да... үз-үзенә кул салмаганмы Фәннур дип сызланып, куркып куям. Безнең арадан ашыгып, үз ирекләре белән киткән каләмдәшләребез моңарчы да булгалады. Сөйкемле Җәгүр Уткин, тыйнак Ринат Рәхимов, моңсу Альберт Сафин... Менә хәзер Фәннур... Тик без бер чакта да аларның ни өчен дөньядан туюлары хакында уйлап карамадык, баш ватып тормадык. Ләкин һәр ирекле үлем, хөкем сөргән мохиткә, чордашларына, фикердәшләренә протест ул, көчсезлек галәмәте генә түгел, һич, һәрбер һәлакәттә җәмгыятькә әйтелмәгән ачы нәфрәт, зар ята. Мин шулай уйлыйм. Фәннур мине олы санап гел елмаеп, йомшак сүзләр белән сөйләшсә дә аның тел төбендә чиксез моң, азагы юк зар, билгесезлекне сагыну, уйларының бәргәләнүе ята иде. Кайткач, Нәкыяга да бу хакта борчылып сөйләгән идем. Бармыни ул бездә кеше кадерен белү?.. Тукай заманында да шулай булган, хәзер исә хәлебез тагын да яманрак.

Иске Әлмәттә өч кич кундык. Бүген Нәкыя Казанга кайтып китәргә әзерләнә. Ялгызым торып калам. Әлегә хәлем һәйбәт, иң мөһиме: тынычмын. Хуҗалар үтә эшчән, сабыр холыклы, кече күнелле кешеләр. Ашарга-эчәргә бик мул, һәр иртәдә яңа сауган сөт эчәм, ит ризыгы да күп, һич уйламаганда, көн туса миләш ашыйм. Әллә очар кошлар белән ярышка чыктым инде? Яратып, яскынып, рәхәтләнеп ашыйм миләшне. Салкын аның ачысын алган, аша да аша гына. Ашыйм икән—организм сорый дигән сүз. Бер-бер хаҗәте, файдасы булмаса, корсак тәпсерләмәс, кабул итмәс иде. Әле төп эшемә басылып керешә алганым юк, моңарчы вак-төяк маташтым. Инде иртәгәдән эшкә.

Бүген һава тын диярлек, җил арып-талып, руша агачлары арасына кереп бөгәрләнеп йокыга ятты. Бүген руша тирәсеннән әйләнеп тә кайттым. Алдагы көннәрдә йөрергә сукмак эзләдем. Бүген кар шулкадәр ак, акның кар булуына ышанасы да килми. Күзне кисә, күз чагыла. Дөнья безне чолгаган нәрсә-караларның төсен үзгәртеп бетерде, инде без ак чынлыкка да ышанмыйбыз.

Үзем торган хуҗаларның кызын—Фәнҗияне озата киттем. Тап-таза, озын гәүдәле, йөзе балкып торган, көче ташып торган гвардеец хатын. Балалар бакчасында эшли. Сөйкемле, игътибарлы, елмаюын артык тышка чыгармыйчарак сөйләшә. Шушы авыл очында йорт торгызып, хуҗалык корып, ире Таһир, карт әнкәсе һәм ике кызы белән яшәп ята. Сөйләшәбез: «Элек авылыбызда буш куралар ишәйгән иде, елдан-елга арта иде буп-буш ихаталар, хәзер исә бераү дә калмады. Менә безнең янәшәгә дә йорт салып куярга әзерләнәләр. Газ кергәннән бирле яшьләр авылга борылды. Су кергән, ут кергән, хәзер газ да керде. Шулар өчесе булганда авылга яшьләрне үгетләп торасы да юк, алар үзләре кайтачак. Эш кенә табылсын.»

Авыл очында, юл буенда өсте шалашлап капланган бәрәңге базлары. Әлмәтнең түбәнрәк урыннарында базга су керә башлаган. Юньле инеше дә булмаган, корылыктан интеккән Әлмәт базларында су! Каян килгәне дә мәгълүм ул нәләтнең: нефтьчеләр җир астына туктаусыз кудырган су җир асты агымнары ясап, җир асты елгалары тудырган. Хәзер шулар астан гына кыймылдыйлар да, һич көтмәгән урыннардан килеп чыгалар. Алга таба ничек булыр. Җир асты тозларын, радиоактив элементларга бай катламнарны иген кырларына ташып куймасмы ул елгалар?!

*10 гыйнвар, Иске Әлмәт, таң белән.*

Төннәр шундый озын, ә күк гөмбәзенең нәкъ түбәсендә кич балкыган тулган ай таңда офыкка да тәгәрәп төшә алмаган. Чын кыш! Ап-ак, сап-салкын, җилсез, сәламәт кыш! Кичә Нәкыяне озаттык. Нигәдер чиксез ямансу булып калды. Яңа урынга тәмам күнектем, ныклы тәртипкә кердем, яшим, эшлим дип куана идем, Нәкыя булганга икән.

Менә аннан башка ничек булыр... Ничек яшәрмен дә, ничек эшләрмен?. Бүген эшне һичшиксез дәвам итәргә кирәк...

Иртүк чәйләдек, сигез тулып китүгә мин кичә йөри башлаган сукмакларга чыктым. Дөнья ап-ак, койма-капкалар, агачлар көмеш сыкыга төренгәннәр, чыгып килгән кояш нурлары баганаларны тоташтырган чыбыкларга сарган куе сыкы бауларындагы кристаллар аша үтеп, аларга сихри төсләр биргән. Чыбыкларны төргән кар бөртекләре нурланып елтыр-ялтыр киләләр. Урамны чыгып сулга борылдым, басу юлына төштем. Каршымда әкияти дөнья булып атаклы Әлмәт рушасы калкынды. Урман кырында бәсәргән куе нарат агачлыгы. Ак чал йөгергән наратлар авызларын ачып, шаккатып, чыгып килгән кояшка текәлгәннәр. Алар артында ак нур таулары булып яшь каләшләр—каеннар стена булып басканнар. Чаларган куе яшькелт наратларнын иннәренә басып акка төренгән каен-каләшләр янына югарыга менәсе килә. Такыр юл да Әлмәтнең ындырларыннан башланып күккә инә кебек. Мин онытылган хисләр дулкынында тирбәлеп, шушы такыр юлдан, меңнәрчә күзләр елтыраган йомшак карларга басып, ыгы-зыгылы бу дөньядан мәңгегә котылып, каядыр китеп барам төсле. Мондый сихри манзараны, моның шикелле тоташ матурлыкны байтактан күргәнем юк икән. Әгәр юлны кисеп-чигеп үткән куян эзләре булмаса, бу дөньяны сихри бер төш дип уйлар идем. Куян эзләре дә күңелне күтәрә. Алар шушы тирәдә генә бәрәңге базларының өстен томалаган салам өемнәре янында уйнаклап йөргәннәр бит. Йокычы кышкы агачлар аларны күрдеме икән?..

Көн шулкадәр матур булды, иннәрем шул матурлыкны тыныч кына күтәреп тора алмады, кат-кат утырып карадым, эш үргемәде. Эш башлау—йөрергә тырышкан сабыйның беренче адымнары ул, теләк зур, көч житми, авып-авып китәсең... Әллә кыйналган тәнем белән газапланган жаным, шушы оятсызлар, гайбәтчеләр, шымчылар дөньясында яшәп матурлык белән очрашканда хәлсезләнеп каламы? Ач заманда алабута күмәченә күнеккән кебек, мин дә әшәкелекне генә кабул итеп, шуна гына түзәргә гадәтләнеп киләмме?.. Д. С. Мережковскийның I томын алып кайткан идем. Нык кызыксынып, надалыгымны, белемемнен үтә чикләнгән булуын сүгә-сүгә, бүген «Христос и Антихрист»ны укып чыктым. Император Юлиан Христос догматларыннан баш тартып, кин күңелле, ярым шук, күңелчәк Олимпия аллалары кочагына чума, халкын да шуңа чакыра, ышандырырга тырыша, иркен, шат, мул тормыш вәгъдә итә. Халыкларның иманын үзгәртү гаять авыр шул, чамасыз кыен, буталчык теләк. «Халык уянды! Татар фикри яна юлга төште! Иманын янартты!» дип сөйләнүче рухи евнухларга борылып карап, газаплы уйлар тәбәсендә тыпырчынып яттым. Император Юлианны хак юлга күндергән Максимның бер фикерен теркәп китәм: «Верить можно только в то, чего нет, но что будет». (171 нче бит) Тарихны, динне, дин тарихын, әдәбиятны яки шуның бер тармагын Мережковский кебек белсәң иде!

«Помни, художник—сила твоя в одиночестве». Сартрда бу фикер аерата анык яңгыраган иде, Мережковский бу сүзләрне Леонардо де Винчи авызыннан, дип Джованни көндәлегенә теркәп куйган.

*12 гыйнвар, Иске Әлмәт.*

Ике көн рәттән ягымлы кыш кояшының кыйгач нурларына кинәнеп басу-кырларда йөреп килдем. Мәктәп, зират яныннан уздым. Бүген Сарман-Әлмәт юлына чыгып, «Әүлияләр зираты» янына ук барып житмәкче идем. Рәис, Фәрхенур, Таһирлардан жентекләп сорасам да «Әүлияләр зираты» хакында өзеп сөйли алмадылар... Бик борынгыда әрвахлар йокыга талган жирнең шушы изге почмагы тора-бара онытылган. Таш юл салган чакта каберләрне санга сукмаганнар, юл «Әүлияләр зираты» өстеннән дә узган... Соңгы елларда зират үзенең барлыгын, үзендә әүлияләр

күмелгәнлеген сиздерә башлаган. Утын төяп кайтып килүче машина тип-тигез җирдә ауган... Йөк өстенә утырып кайтучы хатын теп-тигез урында тәгәрәп киткән. Атлар тезләнгән, арба тәгәрмәчләре нәкъ шушы урында таралган. Тагын бик күп һич көтелмәгән бәла-казалар «Әүлияләр зираты» өстендә була башлагач, адәмнәр искәргәннәр, борынгыны исләренә төшергәннәр. Зират өстендә теләсә ничек таралып яткан ташларны җыештырып, ташлардан койма кебек нәрсә ясаганнар. Ташлар теләсә кайда тәртипсез аунап ятканнар, язулары ышкылып, ашалып, юылып беткән икән. Тора-бара адәмнәр үткәннәр хакында ныграк уйлый башлаганнар һәм «Әүлияләр зираты»н тимер койма белән урап куярга керешкәннәр. Бу эш әле тәмамланмаган, койманың бер өлешен генә койганнар икән. Бу хәбәр мине чиктән тыш дулкынландырды. Казан-Чаллыяр юлында, Казаннан барганда уң якта, агач-куаклар арасында да, Иске Кирмән тирәләрендә шикелле «Әүлияләр каберлеге» саклана түгелме? «Борынгы Болгар каберләре» дигән иде аны кемдер. Мондагы зират та шул заманнардан калган истәлекме? Борынгы бабаларыбыз болгарларны халык «Әүлияләр» дип сагынып искә аламы?.. Бүген бара алмадым, кичә тып-тын торган ачык, саф һаваны җил тузгытып, юлда баралмас итте. Күк тоташ куе томан белән капланган, юк, күктә болытлар түгел, күктә тыгызланган, тарттырып куелган тирмә түбәсе шикелле. Җил булса да ул хәрәкәтсез, күк—каты һәм селкенмәс гөмбәз кебек. Гаҗәп.

—Хушландык...

—Абыстай Коръән укый һәм сүзен «Ахырзаман фетнәсеннән сакла!» дип тәмамлый. «Шул заман килде,—ди Фәрхенур,—ахырзаман фетнәләре чыкты.»

—«Раббым Алла!», «йә, рабби» дибез. Яһүдләрнең «реб, ребе»се.

—Әлмәт мәчетле авыл. Мәчет ишеге өстенә «Рәхим итегез» дип язып кадаклаганнар. Кибет ишегендә: «Көндәлек кирәк-яраклар», ямьсез өелгән, стеналарына комсомолның мәшһүр бүләкләре—алты орден сурәте сугылган бинага эре-эре хәрефләр белән «Мәдәният йорты» дип сырлаганнар. Орденнар җебеп аккан, юл-юл сузылган кинчә сары буяу эзләре коммунистларның вә комсомолларның күз яшьләре кебек. Нигә шул орденнарны юып төшермиләр инде... Хәер, Сарман газетасы һаман «Ленинчы» дип атала бит.

—Май капламычы аннан ераграк, савытны мин аңа таба этәм. Ул: «житешермен, житешермен», дип елмая. Аш тозын тикшерәбез. Ул: «мин чыгынкы булганны яратам», ди. «Биргәненә мең шөкер», аш тирәсендә гел матур сүзләр, мәгънәле гыйбарәләр.

*13 гыйнвар, иртәнчәк.*

Табигать колы шул мин, и дөнья! Кичә төшкә кадәр иләс-миләс селкенеп йөрдем, ятып аунадым, урам белән серләшеп, Әлмәт йортларына рәттән сәлам биреп, эт-көчекләренә юл сабып үттем. Кичкә таба гына күңел үз урынына утырды, ләкин күкрәктәге моң очып чыга алмады, эш үрчемәде. «Бесы»ны укыйм. Кызыксынып укысам да әле тозны төбенә сала алмыйм. Табышмакмы?..

Бүген... ходаның кодрәте кин!—вак яңгыр сибәли, ыжгырып берсе өстенә берсе менеп өелгән ак кикрикләр шиңә, басыла. Дуамал һава үзгәрешләренә дә күнел әзер икән: мин бүген тыныч, мин сабыр. Иртәнге концертны тыңладым.

—Алмагачына чыпчыклар кунган, ботакларның эресен-вагын сырып алганнар. Чыпчыксыз бер ботак та калмаган. Кинәт ишетәм: үзара сөйләшәләр, гадәтләренчә мактанышалар: «Мин утырган ботактагы алма шундый дәү иде!» дип мактана берәвесе. Икенчесе тәтелди: «Мин кунган ботактагысы кып-кызыл иде!» Өченчесе канатларын җилпи-җилпи чыркылдый: «Ә мин утырган ботактагы алма... Мин кунган ботактагысы

дәү дә, кызыл да, авыр да иде... Шап итеп җиргә төште. Аны нәни кызчык Зифа алып ашады»...

* * *

—Яңгыр атап ява ул,—ди Рәис.—Йә шифалы була, йә шифасыз. Шифалы яңгырдан соң игеннәр күтәрелеп китә, үләннәр калкына.

—Көченә күрә кыймылдыйсың инде, умырып эшләмәсәң дә.

—Суыкта чыпчыклар йоннарын кабарталар, шулай җылыналармы?

—Чыпчыклар туры сызык белән диярлек оча. Песнәк исә купшы борылышлар ясый, очуын бизи, матурайта. Килә-килә дә дугайдай эз сызып борыла. Песнәк—үтә купшы кош.

—Түбән этләр сарыга манган чаттагы юан багана йокымсыраган, көн авыр, узыша-узыша яңгыр белән кар алмашлап ява. Кыеклардан чырылдап тонык су ага. Менә сиңа Раштуа суыклары!

*16 гыйнвар 1993, Иске Әлмәт.*

Күк тоташ томаланган, җир белән күк арасында әле кара, әле ак буран, көн вә төн, бурый-бурый дымлы кар ява, баскан саен аяк батып китә. Җылы, җылы, җылы. Гыйнвар җылысы—черек гәүдәне камыр итә, мускуллар йомшара, күкрәк читлеге җеби, тәндә көч калмый. Шушы өч көнгә биш-алты бит язылды микән? Рух көчәеп, эчке тоткынлыктан ычкынып, яза гына башлыйсың, казыган коен тиз саега, өч-дүрт чиләк чупырып алуга төбе күренә башлый, суы болгана-болгана кәефне боза. Ә бүген, иртәгә алтмыш биш яшь тула дип торганда болганчык су ярамый инде, су көмештәй саф, ширбәттәй татлы, мәк чәчәге сыман йомшак булырга тиеш. Югыйсә, күрче, бүген радиода «Күтәрмен мин, иркәм күтәрмен, ялгызлыкның барын кичәрмен», дигән җыр колагыма «явызлыкның башын кисәрмен» булып ишетелде. Колак та кай ара хуҗасына буйсынмый, ул тыштан әллә ниләр яңгырап, дөбердәп торса да үзенекен итә: эчке авазларны гына оештыра, күкрәк читлеге сыймыйча тышка ыргылган дулкыннар ымын гына баш миенә җиткерә... Инде мондагы тормышның көйлелеге! Хуҗаларым кече күңелле, һәр адымымны сагалап, олылап, күңелемне күрергә дип тәяр торалар. Ни ашасаң шул бар, иртән яңа сауган җылы сөт, кичкә кырын тагын сөт. Телең йотарлык хуш исле катык. Үзләре ашатып симерткән тана ите... Фәрхенур миңа ярарга тырышып, көннәр буе газ плитәсе яныннан китми. Урыным йомшак, бүлмәләр иркен, шунысы бар: бу өч-дүрт көн өй тавыгына әйләнеп, куначадарак гомер кичәм. Яңгырлы карда, карлы яңгырда әллә кайларга барып буталасым да килми.

—Озын чокырга кәрнизләр чыгарып кар сырынтылары тезелгән.

—Рәшит Хәмәдиевне Зәйгә күчергәннәр, хуҗа итеп билгеләгәннәр. Котлап телеграмма суктым. Кулыннан эш килә торган, сөйләсә фикере булган—андый җитәкчеләр бармак белән генә санарлык бездә.

*19 гыйнвар, Иске Әлмәт авылы.*

Менә, алтмыш биш яшь тә тулды. Монда беркемгә дә бу хакта белдермәм дигән идем, Фәнҗия белән Таһир иртән үк котладылар, матур гына күлмәк бүләк иттеләр. Көндезге уннарда Ильяс (Мортамакта колхоз рәисе булып эшләүче кияүләре—кызлары Хәмдиянең ире) килеп керде. Бергәләп Таһир Җиһаншиннарга киттек. Анда мәйләп тыныч кына гәпләшеп утыра идек, Түбән Камадан Рәшит Вәлиевич Абдулхәкимов килеп төште. Кара ипи, алма, лимоннар алып

килгән, бер «Виски» дә кыстырган. Хуҗам Рәис Мөхлиевне уртага утыртып, бераз салырга, «ураза»ны бозарга туры килде...

Алтмыш биш, алтмыш биш. Әз дә түгел, Г. Бәширов, Риза Ишмораттар янында күп тә түгел. Шулай да тән әгъзаларында өзмәс үзгәреш барганын сизәм: күз начарлана, колак ишетми, кайчандыр балык сөяге кадалып интектергән тамак төбе дә кинәт-кинәт сызлаштырып ала, димәк, ул да эзсез үтмәгән. Тәнемнең кайсы почмагыннан картлык төртеп чыгар да соңгы, караңгы юлга өндәр икән дип уйлаштырам. Юк, үлемнән курыкмыйм, Нәкыямне генә җәллим. Ул картлык ялгызлыгын бер дә күз алдына китерми, коты чыгып шуннан куркып яши. Балалар, оныклар белән генә бизәлгән картлык ялгызлыктан коткара алмый, дип саный ул. Алда ни көткәнен кем анык кына белгән?.. Ходай ни язгандыр, калган гомерне Нәкыя белән тату, матур итеп үткәрәсе иде. Соңгы елларда эш белән бик нык изаланды, ял иткәне юк, һич көтмәгәндә, кинәт олыгаеп китте. Соң дәрәҗәдә борчылучан, тынгысыз җан шул. Хәзерге авылга карыйм да, шәһәр, үз тормышыбыз белән чагыштырам. Элеккеге авыл хатын-кызларга мәшәкать арты мәшәкать өстәп, аларны кол хәлендә яшәтсә дә хәзер тормыш күзгә күренеп үзгәргән, аруланган. Авылга су кергән, электр энергиясе бар, ниһаять, иске әлмәтлеләр газлы да булганнар. Газ өйне җылыта, кухняда өзлексез янып тора. Хуҗаларым икесе дә шактый мул пенсия алалар. Рәис Ватан сугышы инвалиды, икенче группа. Мал асрыйлар, мал ризыкларын табу да азмы-күпме җайга салынган. Бәлки, бөтен йортларда, барлык хуҗалыкларда алай ук түгелдер, минем хуҗаларның тормышы көйләнгән, түгәрәк тормыш. Бүгенге тормыш шартларын без белгән тарихтагы авыл тормышы белән янәшә куеп чагыштырырлык түгел! Иң мөһиме: авыл халкы шәһәрнекеләргә караганда күп мәртәбәләр тыныч яши ала. Нәкыя кибетнең берсеннән икенчесенә чаба, һәр җирдә чират, халык, ызгыш-талаш, тегесе юк, бусы кайтып җитмәгән. Барасың, син алырга теләгән нәрсәләр беткән, кайчан буласы да мәгълүм түгел. Кибетләргә һәр сәяхәтеннән гасабиланып, борчылып, йөрәгенне урталай телеп, эчтән сүгенеп, тыштан зарланып кайтасың. Һәр таң нервларны ашый, һәр көн саулыкны урлый, һәр кич сине хәлсез, өнсез, көчсез хайван хәлендә калдыра. Авылда хәзер мал асрамаган кеше юк, быел Рәис балалары һәммәсе сугым суйган, бүтән елларны итне ата йортыннан да алып китә торган булганнар. Быел һәркаюсының үз сугымы, ит запасы бар. Дөрес, Рәис белән Фәрхенурның балалары хәлле кешеләр, кызлары унган, сакчыл һәм йорт тота белерлек кызлар.

Авылның тышкы кыяфәте дә нык үзгәргән. Бигештә абзар-кура өсләренә киң-киң такта сарайлар утыртып куеп, печәнлекләрне, салам лапасларын киң-киң җәеп, аңа «аэродром» дигән исем бирсәләр, монда шундый типтагы корылышларны «КамАЗ» дип атап йөртәләр. Яңа өйләрне киң, иркен итеп, күбесенчә кирпечтән салганнар, йорт тирәсенә иркен верандалар чыгарганнар, авыл урамы буйлап очтан-очка барасың, тоташ коймалар, һәммәсе буялган, капкалар бизәкле: татар яраткан кояш сурәте күпчелек, сирәк кенә чәчкәләр, үлән яфраклары күренеп кала. Этләр явызланмый, өрми диярлек, үткән-сүткән әдәмнәргә ырлап ташланмый—димәк, тамаклары тук дигән сүз.

Элек бу якларда ике кабилә булып яшәгәннәр, башкортлар һәм типтәрләр. Башкорт булып языланнар җирне күбрәк биләгәннәр, таза тормышлырак булганнар. Сарман да, Дими Тарлау да, Иске Әлмәт тә бүленеп яшәгәннәр. Рангазарда исә өч төркем: татарлар да килеп кушылган, аларны «Казан татарлары» дип атап йөрткәннәр.

Иске Әлмәт урам баганаларында көндез дә рәхәтләнеп утлар яна. Хак сүз: «көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр».

—Нигә сезнең әтәч кычкырмый?—дип сорадым Рәистән. Ул уйлап-уйлап торды да: «Тавыклар күкәй салудан туктагач, кычкырырга ояла бугай», диде.

*20 гыйнвар, Иске Әлмәт*

Кичә урта мәктәптә очрашу булды. Укытучылар (сөйкемле генә яшь төркем!), өлкән класс укучылары, аксакаллар, китап сөючеләр килгән иде. Авыл мулласы башлап җибәрде, коръән укыды. Җырлар, биюләр булды, сораулар яуды. Бүген үкенеп уяндым: сүземне «сөймәсәгез дә татарны татар булганы өчен яратыгыз!» дип башлап киттем дә, фикердәшләремә, чордаш әдипләргә мәдхия укыганнан соң, әдәбият яңалыклары турында сөйләштек.

Минем китапларны тезеп куйганнар. Арада шактый таушалган, тузганнары да бар. Терлекче, гади бер ханым чыгыш ясады: «Ирем белән икебез дә сез язганнарны бик яратып укыйбыз, гыйбрәт алабыз», диде. Хәзрәтнең әтисен утызынчы еллар азагында юк иткәннәр, чибәр генә ир, ә хатыны Казан кызы икән—затлы, чибәр хатын. Укытучы. «Балалар ярата!» дип куана директор. Бу хәбәргә мин дә куандым. Мәчетле, иманлы татар авылында да татар үрчемәсә, без кая барабыз?!

Соныннан, чәйләп алгач, читтәрәк басып торган ике кыз янына килдем. Кызыксынып: «Син кайсы урамда яшисен?... Ә син?» дип сорадым. Беренчесе, «Мин кибет тирәсендә», дигәч тә иптәш кызына карады. Анысы бераз читенсенеп: «Ә мин типтәр очында», дип җавап бирде. «Әле типтәр-башкортка бүленү бармыни? Онытмадыгызмени сез аны?» дип кызыксындым. Күз карашлары түбән тәгәрәде: «Юк», диделәр кызлар икесе бер авыздан... Милли хис, милли аң, милләт аерымлыклары бәгырь түренә мәңгелеккә кереп оялаган, нәни генә бер вакыйга яралса да ул Этна вулканы булып уяна, йокымсыраган лава ташкыны ике арага килеп керә. Кышын йоклаган аюны уятсан—ярсуын басармын димә! Милләтара каршылыклар бер чакта да бетә алмас, мәгәр аны саксыз уятудан куркырга кирәк.

—Мәсгут Гарифович Ибәтуллин—36-94-71, «Ленинград блокадасы» оешмасының җитәкчесе. Романга тотынгач кирәге чыгу ихтимал.

*21 гыйнвар, Иске Әлмәт*

Көн озынлыгы—8 сәгать! Шөкер Тәңремә, кояш миңа ярдәмгә ашыга, иртәнге концерт мәлләрендә мин тәрәзәнең салкын, җансыз пыяласына терәлеп, көннән-көн яктыра барган ягымлы офыкка текәләм. Күземнең начар күрүен, укып-язып хәлдән таюын бик яхшы аңлаган чиксез кодрәтле кояш мине кызгана, яз ясарга кабалана, иртәнге шәфәкъ ал чәчәкләр булып уйный, күзне камаштыра, көннәрдә кояш моңарчы яктылыкны каплап торган лапас өстендәге салам кибәне өстенә үк үрмәли. Кояш нурлары һәр таңда өмет төяп килгән кебек. Ә җан яраткан җырчылар бүгенге тургай-сандугачларны алыштыралар. Җанга күпме дәрт, күңелгә кайнарлык өстәүләрен белә микән җырчылар? Татар күген иңләгән моннарны тотып ала белгән композиторлар аңлыйлармы?.. Бүген аларның иссме дә кояш белән бергә уяна да нур булып татар илендә тарала... «Әй, Идел-йорт, Идел-йорт! Әй, Идел-йорт, Имин йорт!» Без татар дөньясының гимны өчен текст эзләп изаланабыз, нинди сүзләр генә тәкъдим итмәде үз байлыгын барлый алмаган татар балалары! «Идегәй»дә ята безнең гимн тексты, «Идегәй»дә! Дөрес, минем күңелем тәкъдим иткән шигъри юлларга көй язылган, ләкин ул юаш, басынкы көй янәшәсендә татарның гаярь җайдаклары, аргамакларының тояк астыннан чәчрәп чыккан очкыннар, сыгылып, сыпылып калган кылганнар дулкыны, урман авызларында яңгыраган болгар-татарларның ур-ра! тавышлары, киндер тукмаганда моңланган кызларның күкрәк аһәннәре дә, монгол, урыс кылычларыннан киселгән башларның соңгы хушлашуы авазлары да ишетелергә, татарның мең еллык инрәүләре, тантанасы да яңгырарга тиеш.

*22 гыйнвар, 1993*

Ике көнне кышка бирдек! Гыйнвар рәхәтләнә! Купшы агачлар бизәнер нәрсәләр тапты—агачлар чигеш төсле, җир-күк ак томанда тавышсыз гына чыңлый. Салкын һава, сыкылы дөнья мине иннәремнән тотып күтәрә, әкияти дөньяның сихри манзарасына уралып, телсез калган хәлдә әүвәл баштан тыгыз кар кешеләре каплаган тыкрыктан урамга менәм, тыкрык башында йөнтәс курчак хәтле генә эт каршылый, суыктан иреннәре ябышып катканмы, өрми... Авылны чыгып шундый ук бай бизәлгән урманга таба барам. Юлны кисеп сикергәләгән кыска койрыкларның эзләренә елмаеп баш иям, төнлә аларның шушы киң тынлыкта бер-берсен куышып уйнаганнарын күз алдыма китерәм. Рәхәт, рәхәт! Гаҗәеп тын, мондый рәхәт, тирән тынлыкны татырмын дип күз алдыма да китермәгән идем. Еракта, еракта самолет мырлый, ул да бу биек, тын гөмбәз астына адашып, ялгышып кына килеп кергән кош төсле. Серле ак диварлар арасына, текә ак кирмәннәргә пар-пар чаңгы эзләре сузылган, минем дә шул юллардан, яшьләр эзеннән ак әкият арасына кереп югаласым, сихри гүзәллек чоңгылында онытылып басып торасым килә. Дөнья гүзәл, гүзәл... Кычыткан куралары да көмеш зәр булып үрелгән, юл читендәге һәр таучык мисыр пирамидалары кебек серле, бай... И дөнья, әле синең шундый сихерле белә торган көннәрең дә бар икән! Артыма борылып карыйм, Иске Әлмәт авылы өстенә. Өстән караганда йортлар йөзтүбән ятканнардыр кебек тоела, йөзтүбән ятканнар да өсләренә тау-тау кар япканнар, төсле төшләр күрә-күрә йоклыйлар... Умарталык тирәсенә таба тирән-тирән бәллүр эзләр—чана эзләре ашыккан. Чана эзләре офыкларны бер-берсенә ялгаганнардыр кебек, бүгенге әкият сәгатьләрендә эзләр дә гади түгелдер, чананы чаптар атлар, канатлы аргамаклар тартып үткәндер кебек. Ирексездән шул ялтыравык эзләргә төшәм дә ак, куе томан кәфенгә төренеп, әзгә генә булса да бу ыгы-зыгылы дөньядан китеп торган урманга карап барам. Баш очымнан каргалармы, кара җилпәзәкләр очып үтә, «мондый көндә нигә алар агармаган соң?» дип гаҗәпләнеп калам. Шулчак кинәт урман авызы җанлана, шыбырдап сыкы сәйләннәр коела. Тынлык томалаган колагыма абалап өргән явыз эт тавышлары кереп тула. Умарталыкта явыз этләр бар, бәйдә торалар, вакыт-вакыт аларны ычкындыралар, андый чакта алар кемгә барып ябышырга белмиләр, дигән иде Рәис. Этләрдән болай да куркам, үзем генә кинәнеп барган әкияти юлларда, көмеш җәймәгә төрелгән ялгызлыгыма этләрнең ниндиен дә, юашын да, явызын да кертәсем килми, мине чакырып ишарәләп торган урманга тагын бер карап баш орам да чана юлының бөтенлеген, төгәллеген, тигезлеген бозмаска тырышып кире борылам. Рәхмәт явыз этләргә, алар күземә күренмәделәр, тавышлары еракта гына яңгырады. Тындылар. Бәсәргән агачларны, ак наратларга бүген тәмам гашыйк булган ак каеннарны кызгандылар бугай. Этләр дә матурлыкның кадерен белми, дип кем әйтә ала?

*23 гыйнвар, иске Әлмәт*

Ах, җилнең бүген төнката мине кысып кочкан җылы ятакка үтеп керәсе килде! Мең бармаклы житез кулы белән ул төн буе стеналарны капшады, сыйпады, сызгырып, ялварды. Стена һәм төнге җил хакында том-том әсәрләр язылган, адәм җаннарына тынычлык түгел, борчулар китергән бу табигать омтылышы бүген мине тынгысызламады. Җил тавышына уяндыммы, бишләрдә калкындым да мендәремне тәрәзәгә табарак тартып тыңлап яттым, җилдән качасым килмәде бүген, киресенчә, кул биреп күрешәсем, аңлашасым килде. Ә җил аның саен

көчәйде, чак кына тынып хәл алды да тагын тәрәзәгә ташланды, стеналарны ялап чыкты, тишек таба алмагач, ак карны дулкынландырып-тузгытып, ындыр аша әллә кайларга йөгерде.

Бүген «Петр Скороходов» бүлеген яздым. Кызыклы шәхес иде! Сергей Сергеевич Козлов-Куманский аша мина Пастернак, Мандельштамм килеп керде. Скороходов Есенинның моңлы, ак каенлы дөньясына өндәде. Ростислав Иванович Илечко мина көнбатыш дөньясы хакында гыйбрәтләр аша белем бирде. Әле Мерзленков Александр бар. Бөек, якты шәхес! Аның татарларга мөнәсәбәте нәкъ Худяковча иде. Ул власть иярәренен— Сталинның, Ленинның кемлеген ачу өчен урыс тарихынын түрендә киерелеп утырган Петр патша мисалына мөрәҗәгать итте. Аның табынган, яраткан әдибе Мережковский иде. Мин, монда килгәч, Мережковский сайланмаларынын ике томын ермачлап чыктым. Икенче томдагы «Антихрист»—«Петр һәм Алексей» романы мине—Гариф Ахуновча әйтсәк, «таң калдырды». Без Петр I гә—Пушкин ясаган иконага ышанып йөргән бер катлы бәндәләр икән... Власть бозмый кешеләрне, властька явыз, кансыз бәндәләр генә килә ала, дигән хакыйкатьне мина шул елларда ук Мерзленков сөйләп, кат-кат аңлаткан икән. Мин—әзерлексез, системалы төпле белемсез авыл гыйбады—тиешле көннәрендә аңлап бетермәгәнмен. Ләкин мин Александр Васильевич Мерзленковка мең бурычлы. Мең!

Ниндидер бер дәрәҗәдә мин югарыда исемнәре саналган олпат ирләрнең шәкерте. Үзләренә лаек хатирәләр яза алырмынмы? Мәсьәлә шунда. Тагын яһүдләр турында бер бүләк булырмы... Наум Песин, шапшак, түше ашка каткан, серле күзле Рафаэль Шапиро... «Мост Ватерлоо» фильмын караганнан соң Вивьен Ли хакында тирән лекция укыган, җәя кебек бөкрәйгән, урак кебек бөгелгән тынмас җан Берсеневич карт. Япь-яшь булса да хәйләгә оста, култык таякларына таянып, атлар-атламас йөрүче Луи... Мең анекдот белгән одессалы Мирошниченко... Фамилиясе украин булса да үзе яһүд иде. Бер кулының бармаклары юк, көрәшче, украин егетен күтәреп алып чөйгән иде... Французча көрәшкән егет.

Аннан: татарлар. Алардан соң «лагерь сугышлары»... Казанга кайту...

*25 гыйнвар, Иске Әлмәт*

Февраль башларында әллә кайтып китсәмме дип юрап йөри идем, шимбәдә Сарманга барып, Әхнәфләрдә кунак булып, Нәкыяга шалтыраттым. «Эш кым-кырыч, Рәшатның квартирасын ясыйбыз, төзәтәбез, буйыйбыз... әллә тагын әзрәк торасыңмы? Син кайтсаң эш өзелә, сине генә карап торасы була», диде ул. Башны кашып уйга калдым әле. Хуҗалар әлегә киң күңелле, кунакчыл, игътибарлы, юмарт, мин димәгән сулышлары юк... Ә тора-бара... ялыксалар, туйсалар? Дөрес, әдәпле, тәрбияле кеше буларак аны-моны сиздермәсләр, ә үзем... Нәкыяне кызганам. Яшьләр уралып йөридер шунда арада, эшнең бөтен авырлыгы аның тынгысыз холкына, сынык кулларына төшәдер. Бу юлы минем аны уйламаган, аны сагынмаган сәгатем юк шикелле. Бәләкәй кызларны да бик сагынам, Зифаның башын аскарак иеп, янтаеп: «бабай» дип өзелеп торган чаклары күз алдыма килә дә... китми! Мина карап тора Зифа...

Бер кич Сарманда кунып, кичә төшкә кадәр нык кунак булып— Риф, Флераларга бардык, Рәшит белән Гәүһәрләрдә кунак булдык, әбәдтән соң Рәшит мине янадан монда китереп китте.

Кыш. Кар. Буран. Иртән Рәис ишегалдын себерә. Сорадым: «Җил карны кырдан урлап ташып куйганмы, әллә яшь кар яуганмы?» Рәис көлә: «Кыр кары каты бөртекле ком шикелле була, ә бу ефәк кар, йомшак. Әле җир белән катыланып өлгермәгән», дип куана.

—«Эт кешенең куркак икәнен әллә каян сизеп тора, чөнки адәм баласының куркаклыгы баш түбәсеннән сөрем булып күтәрелә», диде Фәрхенур.

Гыйнварның соңгы атнасына кердек, көн иртә уяна, иртә яктыра. Хәзер ашыга-ашыга яз ясалыр, аны кире куып җибәрер хәлең юк...

Китапханәдән Әхсән Баянның «Язмыштан узмыш» китабын бүләк иттеләр. Алтмыш еллыгына чыккан бу җыентыгын күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде. Дүрт повестын тезеп салган. Баксаң, үз тормышын вә язмышын Әнис Бадыйгинга ышанып тапшырган икән егет. Гомереңнең һәр фасылында шул кеше аның тулы хокуклы вәкаләтле илчесе булып татар укучысы каршысына чыгып баскан. Һәр әсәрен җентекләп, кызыксынып укып чыктым... Иске Әлмәттә Ф. Достоевский, М. Е. Салтыков-Щедрин, Д. Мережковский, Григорий Кановичның «Козленок за два гроша» әсәрләрен укып чыктым. Ремарк, Хемингуэй әсәрләрен карап чыктым.

Бу әсәрләрдәге уй-фикерләрнең тирәнлегенә, хисләренең байлыгына, тел осталыгына гашыйк булып, туймыйча сокланып укып, укыган саен образларының яңа, бөек якларын ачып, китап белән аралашуның, туганлашуның бәхетен татысам да кабат-кабат Канович әсәрләренә әйләнеп кайтам. Эссе көндә, челләдә печән өстендә тау асты чишмәсеннән эчкәндәй туеп булмый Канович әсәрләреннән. Достоевскийның «Бесы» романының мең чуар кузәнәкләренә әле кереп бетә алганым юк, дөньяның рухи хәрәкәтенә зур йогынты ясаган әсәрнең бөтен серле төпкелләренә кереп житә алмыйм һаман, җинелрәк җил капкаларны ача барам, ә алда зур, биек, нык урыс капкасы, әлегә ул бикле, ачкычны таба алганым юк дияргә ярый, әсәрнең бөеклегенә бүтәннәр, белгечләр фикере аша гына ышанырга мәҗбүрмен. Тарихны, роман язылган дәверне, бөек адәми зат Достоевскийның җанын кыйнаган мәсьәләләрне белер-белмәс кенә баргангамы, әсәрне бер бөтен итеп кабул итмәдем әлегә. Чор да, кешеләре дә, аларның бергә ялганган гамәлләре дә мине көймәгә утыртып, бу ярлардан аерып яңа дөньяга алып керә алганнары юк...

Мережковскийга әйләнәм дә кайтам, «Христос и Антихристос» трилогиясеннән «Петр и Алексей» романын яңа уйларга төреп, яңа таләпләр иләге аша үткәреп, урыс язып калдырган урыс дөньясының безгә монарчы бик үк ачылып бетмәгән сәхифәләрен кабул итеп, сендереп, дөньяның бүгенге агыш серләрен дә анларга тырышам. Һич туеп булмый Мережковский белән серләшеп. Салтыков-Щедринның II томында һәммәбез өчен гыйбрәтле тормыш вакыйгалары бар. «Помпадур һәм помпадурша»ны моңарчы укыган булсам, Р. Мөхәммәдиевнең «Кенәри— читлек кошы» әсәренә анализ ясаганда, мөгаен генә, бу мәгълүм әсәргә таянмый калмас идем. Бик кызыклы параллельләр табарга була!

Үземнең һәм үзебезнең файдабызга булмаса да күңелсез һәм үтә катгый йомгак ясарга була: татар прозасы XX гасырда дөнья тирәнлегенең катламнарын ача алмаган әле. Нинди беркатлылык, бер чордарак иҗат ителгән повестьларда уртак сыйфатлар, бигрәк тә рухи сайлык бар. Безнең геройларда рухи бөтенләй юк!

Райком-горком хуҗалары берчакта да ачылып бетми торган затлар иде. Җүләрләр җүләрлекләрен, акыллылар акылларын ачып бирмәслек дәрәҗәдә хәйләгә өйрәтелгән, хәйлә белән кочаклашып яшәргә күнеккәннәр иде. Коммунистик режимга бары тик стандарт фикер йөртә алучы таш курчаклар гына зарур иде. Әле кичә Рәис сөйләп тора. «Сирәк кенә мине дә райком бюросына ияртеп баралар иде, малчылыкта эшли идем бит... Байтак колхозлардан житәкчеләр килгән була, берәм-берәм аларны чакырып алалар да пешекләп чыгаралар. Безнең үтә хәйләкәр рәисебез бар иде... Күпне күргән, сансыз-исәпсез бюроларда мунча кергән адәм... Шуның бер сүзе хәтердә. Кан калтырап бюро көтеп утырган бәндәләргә кинәш бирә иде: «карышмагыз», ни әйтсәләр дә «үтибез, үтибез без аны!» дип тәкрарлап тик торыгыз, шул чагында бөтен хаталарыгызга хөкем кичектерелер!» Совет хакимияте ничә еллар дәвамында әнә шундый бушбугаз попугайларга күз тотып, шуларның бушкуык вәгъдәләренә ышанып яшәде. Горком-райком секретарьлары... Күпләрне күрдек, ләкин алар арасыннан берәү дә мине үз тормышы бакчасына

чакырып кертмәде, икәүдән икәү калган мизгелләрдә дә аларның күңеле йомык, теле бикле иде...

Элгәрәк, әллә ватандашлар, милләттәшләр белән кин аралашуга сүрән генә булса да өмет яшәгәнгә, мин коммунистлар партиясендә югары урыннар биләгән иптәшләрдән ачылу, мине әсәрләндерерлек серләр, без белә алмаган караңгы катламнар легендаларын ишетермен дип көтә идем. Еллар үтеп бара, коммунистик хакимият серләре яңа вакыйгалар юшкыны астында калып югала торалар, ә кулларында хакимият тоткан таныш-белешләр ачылырга ашыкмыйлар. «Дуслар» дип әйтергә базмыйм мин аларны, ата коммунистлардан дусларым булмады, юк иде. Дөньялар болганды, югарыдагы иптәшләрнең эш, дәрәҗә урыннары үзгәрде, мәгәр Казанга килгәч, берсе дә мине юксынмады, телефоннан шалтыратып: «Әйдә очрашыйк әле бер, эчләр бушаганчы гәпләшик!»—димәде.

*28 гыйнвар, Иске Әлмәт авылы, иртәнчәк.*

Авылда туып, гомернең иң сизгер көннәрен шунда үткәреп, кышның кодрәтле рәссам, буйсынмас хикмәт иясе икәнен белмәгәнмен икән. Өченче көн, ягъни 26 сында җир өстенә ак томаннар явы төшеп туктаган иде. Нигә синең төньяк котыпларын, боз дингезен яргалап калкынган торос-тауларын, Әлмәт басу-кырларында бүген барысы да бар иде. О ул өченче көн, өченче көн! Өйдә чакта ук рухи җинеллек, рәхәт тугарылу тоеп, машинкам белән нык кына серләштем... Инде өй кысасын ертып урамга, урман ягасына, иркенлеккә чыгып киткәч, андагы тамашаны, җанны сыйпый торган тыныч манзараны... сөйләп бирергә тел җитмәс!.. Мондый чакта җырлап җибәрергә генә кирәк, җанны аңлатырлык бүтән әмәл юк...

Өске урамнан иплән кенә Түбән очка төшеп барам. Ишегалларында җан ияләре күренеп-күренеп кала, тавышлар килә, кеше шәүләләре төсмерләнә. Озаклап туктап тормыйм, мондый сихри матурлыкка гади кешеләрне катыштырасы килми, мондый көн арасында бары тик бөек шәхесләр, әкияти язмыш ияләре генә сыя торгандыр дип, ниндидер могҗизалар эзләп, туры атларга тырышып барам. Матурлык бүген исертә, кайгыларны оныттыра. Мережковскийда укып уздым: «Глаз дает человеку более совершенное знание природы, чем ухо». Леонардо де Винчи сүзләре. Татарның «Йөз тапкыр ишеткәнче бер күрүең артыграк» дигәнеме бу?

Барам, барам, мәктәпне үтәм. Унда зиярат, аннан ары Сарманга юл үргә менеп китә. Шундый тын, җир шарының иплe генә әйләнгәне ишетелә. Тоташ кар, зират тирәләрендә нәни көмеш таучыклар тезелгән. Төнге буран, төнге кар җәймәләре әтрафны танымаслык итеп үзгәрткән. Мин кырга, кыр миңа ятсынып карашып торабыз. Озын Чокырга сыенган сырынтылар яңа, аучы түгелләрнең дә йөрәген җилкетә торган ашыгыч куян эзләре дә яңа, күпер култыксасына кунаклаган кар калачлар да яңа... Мин «Әүлияләр зираты»на таба менеп барам. Инде ничәнче кат мин бу серле сәяхәтемне башладым?

Беркавым атлагач та нигә тыелып тукталам мин? Күпер аша чыгуга күкрәгемә сак кына ага башлаган авыр сагыш, тыгызланып, тынымны бүләме?.. Бу бөек атама, тиңдәшсез олы исем—«Әүлияләр зираты» тирәягыма, шул серле каберләрне мәңгегә сүзсез кочагына алган үргә мөнәсәбәтем һәркөн үзгәргән саен үземнең дә үзгәрә баруымны тоям. И дөнья! Без бичара татарларның җан алгысыган мәлләрдә барып баш ора торган урыннары бармыни?.. Иң изге җиребез Яңа бистәдәге татар зираты да ташландык бер чүплек башы ләбаса... Зират—җан югарылыгының билгесе, милләт югарылыгының бәясен билгеләүче нокта да ул. Мин кинәт шушы кырда бер үзем калам, мине чолгаган ак дөнья югала, күз

алдымда Әүлияләр зираты да көмештән коелган кышкы юл гына. Әнә генә ул зират, Әүлияләр сагына әлерәк кенә, күздән генә баскан баганалар... Нигә чабып кына үтә алмыйм мин шушы юлдан? Нигә зиратка якынайган саен адымнарым читенләшә дә атлар-атламас калам... Сизенәм, минем Әүлияләргә эндәшер хәлем юк, сүзләрем, арадашлык җепләрем өзелгән. Әүлияләрнең Бөек рухына багышлап дога укыр идем, белмим... Менә кайчан кирәк ул тиңдәшсез Олы сүзләр! Җаннарны уртаклый торган, Әүлияләрне һәм мине бергә Күккә күтәрә торган догаларны мин белмим. Нинди кызганыч вә мескен минем хәлем! Мин озак кына дөнья тынлыгына күз яше аша текәлеп карап торам. Ни көтәм мин, Бөек бер Могҗизамы?.. Мине шушы төбәккә тартып торган, ычкындырмаган көч әле сыекланган канымда калгандыр лабаса! Күнелгә килгән якты уйлар нигә сүзләргә, хөрмәткә, сокланута әверелеп телгә килмиләр икән?.. Минем күз алдымнан бүгенге кыр кебек ап-ак сакаллы бабаларымның шәүләләре тезелешеп үтә. Йөз яшь аларга, ике йөз... Мең яшь! Минем күз алдымнан илемне-җиремне саклаган батыр атлылар чабып уза... Мин белмәгән, мин белмәсәм дә тарихта булган, барлыгын сеңдереп калдырган яугирләр ат тояклары белән йокымсыраган татар илен уятырга теләп чабышалар... Кемнәрнең изге сөякләре шушы үрдә ятып, һаман-һаман тынгы табалмый икән? Нинди җаннар?..

Татарстанның—Татар иленең чынкый картасы әле төзелмәгән, дога көтеп, җылы хөрмәт көтеп яткан җаннарның кайдалыгын без әле билгеләмәдек. Татарстанны моңарчы таларга җайлы булган урыннарын күрсәтеп кенә бүтәннәргә тәкъдим иттек. Ханнарыбызның каберләре юк. Идел йортны саклаган гаскәр башлыкларыннан берәүне дә юньләп белмибез, акыл ияләре Ил агаларыбыз кадерсезләнеп күмелгән чокыр-чакырларда таралып яталар. Менә ул чиксез кадерле җиребезнең берсе—Әүлияләр зираты. Мин шушы Изге почмак хакына әллә ниләр эшләргә әзер, әрвахларның җаны җылынырлык итеп, Изге китап аятьләре белән ныгытып, сагыну хисләре белән бизәп гаҗәеп бер таш куясы иде монда!.. Юк шул, без хәтерсез вә хәерсез халык шул. И кызыл авызлар шапырынган булалар, и мактаналар, Сара Садыйковага да һәйкәл торгызмакчылар, Бакый Урманчега да, хәзер Нәкый агага һәйкәл кирәк дип үзара, корып-коргаксыган камышлар сымак шаулашалар... Бөегебез Салих Сәйдәшкә дә һәйкәл куя алмавыбызны, моңарчы җыелган маянын да әрәм-шәрәм юкка чыгуын белмисезме сез әллә? Татар кулыннан андый эш килми ул, без ярлы халык, мескен-бичара гавам, нигездә, матурлыкның кадерен белмәгән авыл гыйбадлары. Казанның ямаулы, җылымса канлы мокытлары корырмы ул һәйкәлләрне?.. Бирмәде Ходай муллыкны, һәр адымы мең чакрым булган Әүлияләр зиратына ак мәрмәрдән зур бер таш куяр идем!.. Сарман зиратыннан әрвахларның сөякләрен җыеп та тормаганнар, әллә нинди биналар корып, тарихыбызга, үткәннәргә лач итеп төкергәннәр, мәсхәрәләгәннәр... Аңлыйм, хәзер генә боларны аңлау дәрәҗәсенә (житештем) ирештем: минем кадерле әбием Гыйлембаянның сөякләре дә шунда уалып ята бит... Җаны йә карлыгач булып июнь кичләрендә, җылы, тымызык һавада шушы тирә күген кисеп очадыр... Йә сандугач булып, шушы як агач ботакларына кунып, зарый-зарый җылыйдыр. Монда күмелеп, һәркөн лап-лоп янгыраган аяк тавышларын ишетеп, ләхетләрендә борылып-борылып интегүче әрвахлар! Сездән гафу сорап, бәхиллегегезне өметләнеп, бу олы татар зиратының аулаграк почмагын табып, мәрмәр таш куясы иде!

Әүлияләр янына бүген дә барып җитә алмадым. Күкрәгемә моң, сагыш, әче күз яшьләре төяп, бөтен бер дәвернең язмыкларын аягыма тагып, ава-түнә, әкрен генә Рәисләргә кайттым...

Егерме җиденче гыйнварда көн аша буран котырды... Капкадан үземне түгел, борынымны гына күрсәттем...

—Күз түгел, күзлек пыяласы елтырый торган вакытлар житте.

—Һи, аны әйтәсең икән! Мәнүк ич ул. (Бер катлы, исәр.)

—Үзенә дигәндә мәнүк түгел! Итәрсен аны мәнүк!

*29 гыйнвар, Иске Әлмәт.*

Беркөн килеп килешенеп киткәннәр иде. Кичә күрше Рангазар авылына, мәктәпкә очрашуга бардым. Яшь-яшь укытучылар, укучылар күтә иде. Унынчы класста биш егет, барлыгы 40 бала. Ә авылда 150 йорт. Мәчет. «Рангазарда дин гомергә көчле булды», диләр хуҗаларым. Монда типтәр-мазар дигән бүленеш юк. Әле читтән кайтып урнашкан качаклар да юк. «Күрше авылга... тажиклар кайтты», диде мәктәп директоры Мәҗит. Иске Әлмәттә укыту, мәктәп традицияләре юк, гомер-гомергә дүрт класс булган. Рангазарда бүтәнчәрәк, мәктәпне тәмамлаган яшьләр күбесе ВУЗларга китә, укымышлы кешеләр шактый. Коридор стенасында герой-пионерларның рәсемнәре, пионер оешмасына багышланган плакатлар. «Пионер оешмасын алыштырырлык нәрсә юк ич әле!» диде директор. Егетләр дә, кызлар да биеделәр. Таза, сәламәт егетләр, үтә сылу кызлар. Биргән сорауларында да мәгънә бар. «Йөртә безне язмышлар»ны укыганнар. «Язмышка ышанасызмы, намаз укыйсызмы, ураза тотасызмы?» дип сорадылар. Ахырга таба мондый сорау да булды: «Сез ... иң зур язучыларның берсе. Нигә сез мәктәп программаларында юк? Булган очракта да обзорный урыннарда гына...» Минем бу хакта ныклап уйлаганым юк та иде. Быел Бигештә Алмазларда «Мәгариф» журналының былтыргы саннарын актарып, күзгә чалынган программаларны карагач, мин мәктәпләрдә әле берни дә үзгәрмәгән дигән фикергә килдем. Иконалар... Коммунистик әхлак белән агуланган тар маңгайлы программистлар, әле һаман шул ленинизм идеяләрен тормышка ашырып яталар. Стандарт калыпка рәхәтләнеп сыя торган язучыларның иҗатын тырышып-тырышып мәктәпләргә тәкъдим итәләр. Кичә, берара шикланып, болай диярге дә җыендым: «Программа төзүчеләр шул тиклем түбәндә калганнар ки, алар утырган эт биеклеге таулар түбәсенә генә үрмәләп менә алалар. Шуннан торып дөнья фәлсәфәсен, дөньяны, әдәбият кануннарын аңлаталар. Ә өстә Аяз Гыйләҗевләр барын, Гаяз Исхакый кебек гигантлар иҗаты әлегәчә сер булып сакланганын алар белми дә, белә дә алмый...» Тыелдым, дәшмәдем, сорауны уен-көлке белән үткәреп җибәрдем. Рангазар укытучылары арасында дөньяны аңларлык дәрәҗәгә күтәрелгән укытучылар да бар икән дигән фикер белән кайттым. Арык кына чәй өстәле әзерләгәннәр, табын тирәсендә сүзсез диярлек утырдылар. Нигә икән? Аңламадым.

Гигант «КамАЗ» белән барып алдылар, чак-чак мендем, бик биектән сикереп диярлек төштем. Әле дә аякларым сызлап, гүләп тора.

Кичә-бүген «Бригада» бүлеген яздым. Әле эшнең очы-кырые күренми. Тагын атна торсам, эшне шактый алга илтер идем дип уйлыйм... Көннәр җылак, инде генә суыта дип торасың, шалт, Мөхәммәтҗан! Мәскәүдә җибеп ага да безгә килеп җитә. Аптыраш.

Бүген Мансурга утыз ике яшь... Әз түгел, валлаһи!

*1 февраль, Иске Әлмәт авылы.*

Иртән радиода Мидхәт Миңшин. Акыллы гына егет ләбаса! Татарстанны яклап ару гына сүзләр дә әйтә ала. Юкны лыкылдаган хәсрәт депутатларга калала да белә! Нигә без татарлар шундый икән, уң кул белән эшләгәнен сулы белән изеп ташлыйбыз!.. Бүген Мидхәт очына-очына бер татар гаиләсен мактый. Бер авылда (авылын ишетмәдем!) берәүләрнең җиде улы бар икән! Өлкәне дуңгыз бага, икенчесе фермада силос ташый, өченчесе тагын кемдер. Җиденче малай әле мәктәптә. Укый. Мидхәт сорый тегенәрдән: «Укып бетергәч, абыйларың кебек авылда каласыңдыр инде?» Малай яклана-яклана: «Калам! Әйе! Авылда!» ди... Бичара татар гаиләсе. Бичара татарлар, тезелешеп, сыер

коерыгын борырга, дуңгызның маңкасын сөртергә калалар. Һәм шуны, дөньяның алдын-артын белүче Мидхәт Миншин мактап ята!.. Шуннан соң ук берәү сөйли. Украинада туган, милләте поляк. Идел аша күпер сугучы коллективны житәкләгән, Әгерҗедә тимер юл развязкасын ул башкарган. Хәзер Зөя елгасы аша күпер сугуны тәмамлаган да... Сорочие Горыда Чулман аша күпер сугарга керешкән. «Шушы күперне дә тәмамлый алсам...» дип хыялын да яшереп тормый. Әлләкем... Францевич... Хи-хи-хи! Чулман аша күпер сугарга керешәләр икән, бусы искиткеч шәп нәрсә! Күпер сугылып, су астында калган болыннарны әз-мәз дамбалар төзеп халыкка кайтара алсалар... Күпер башына: «Бу күперне фәлән пан, мөхтәрәм поляк житәкләгән мәшһүр коллектив сукты», дип язып куячаклар. Кремль янындагы онкология диспансерына әлерәк кенә Мойше Зельманович Сигалга багышлап истәлек тактасы куйдылар. Диспансерга Сигал исемен бирү хәл ителгән... Курашов исемендәге институт... Сигал дигән больница... Мин бу могътәбәр затларның данын киметергә жыенмыйм. Ләкин, нигә алай? Әхмәтжанов Фоат дигән иптәш тә эшләде вә эшли ул онкология больницасында. Ул да өч меңнән артык операция ясаган һәм әйтүләренә караганда уңышлы ясаган. Фәнни хезмәтләре дә, шәкертләре дә бар... Ник Сигалны тәүге адымыннан башлап телдән төшермибез дә, нигә Әхмәтжанов дигән татарны түргә уздырмыйбыз?! Нигә без жиде баласын да пычрак арасына керткән татарны мактап, бүтәннәрне дә шул түбәнлектән чыкмаска котыртабыз? Менә ай буе авылда яшим, урамнарда жәяүле кешеләрне күрмим диярлек, бүген, туксан өчтә колхозчы машинага утырган. Иске Әлмәттә унбиш трактор бар. Арлы-бирле узып бульдозерлар йөри. «К-700» тракторлары гөрс-мәрс үтеп тора. Дәү-дәү «КамАЗ» лар, «быел гына өч «КамАЗ» алдык», ди председатель Нәжип. Димәк, алдагы елларда да шулай булачак, адәмиләр машиналарга менеп утырачак. Фермаларда, кырларда бик әз кеше кирәк булачак. Урыс шәһәргә күченеп беткән, нәни-нәни урыс учаклары сүнгән. Нигә татарны югарыга өндәмибез без? Ник әзерләмибез? Торам-торам да хатынның колагын борам дигәндәй, тегe жиде малайның һичьюгы бер-икесе укып, колхозга экономист, инженер булып кайтса?.. Акыл, белем, тапкырлык гаиләдән килә ләбаса! Бу ап-ачык нәрсә. «Оясында ни күрсә—очканында шуны күрә», ди. Татарстанның ничә гасырлык зыялылары, асылда мулла балалары булганнар. Татар укымышлылары нык, укымышлы гаиләләрдә туганнар. Әгәр без татарны һаман арзанлы араннарда авызлыклап тотабыз икән, алдагы көндә татар иле, татар жире, татар акылы белән идарә итәрлек кадрларны каян алырбыз?.. Казанда жиде РОНОның жидесендә дә мөдир булып урыс агай-энесе утыра дип зарлану ансат ул... Ә куярлык татарың бармы соң? Жиде буыннан бирле тоташ сыер койрыгын борган адәмнәрнең балалары каян килеп эчке милли хисләргә байый алсыннар?..

—И, урам як пәрдәләрен бер чакта да тартмыйлар, балалары жылак була инде!

—Чикте—отказался.

Иртән Ильяс кереп чыкты, «Казанга үзем илтеп куям», ди. Минем бер дә аннан илттерәсем килми... Аның артыннан ук администрация башлыгының урынбасары Разия Кәримова дигән хатын белән Дамир Гарифуллин кереп чыкты. Кәримовадан машина сорадым. «Уңысында илтеп куярбыз», дип сөендерде. Әле ничек-ничек китәрмен дип борчылып та куя идем. Димәк, уңысында юлга.

*2 февраль, Иске Әлмәт.*

Асылда кеше һәр таңда яңа кеше булып көнгә керә. Гомернең бер көне дә үзгәрешсез узмый, кемнедер очратасың—уйларыңны уртаклашасың, йә син байыйсың, йә югалтасың—димәк, үзгәрәсең. Дөнья хәлләре алмашына, үзгәрә, алар да сиңа тәэсир итми калмый.

Бүген февраль бәяләрен күтәрделәр... Мин өйдән чыгып киткәндә генә доллар 420 сумнар торса, бүген ул 580 сум!.. Болай барса мен сумга менеп житәчәк тә болай да соңгы сулышында тилмереп яткан Рәчәй икътисадына аклы-каралы кәфен кигертәчәк. Шундый һәм шуна охшаш меннәрчә вакыйгалар адәм жанына тәэсир итми буламы?.. Үзгәрәсен, алмашынасын. Син һәр иртәдә бер көнгә олырак булып туасын... Бәяләр, көнкүреш мөмкинлекләре тарая. Кичә Бунич белән Отто Лацис ил икътисады, яшәү-эш шартлары турында ике яклап сафсата сатып, ил язмышын, безнең башларны бутап утырдылар. Черномырдин да телевизорда күренеп китте. Өзеп кенә бер сүз дә әйтә алмыйлар. Сай суда чупырдашкан сабыйлар кебек шаулыйлар үзләре, кумәк авазлардан юньле бер мәгънә алырмын димә. Александр Васильевич Мерзленков сүзләре кабат-кабат искә төшә: «Россиядә ил башына менеп утырырлык затлар туа да, үсә дә алмый» дигән иде... Ленинны сызып ташларбыз, тәгълиматын чүплеккә чыгарып чөярбез. Сталинның гәүдәсен әллә нишләтә алмасак та исемен кат-кат капларбыз да... тормыш туры юлын табар, дип ышанып киллдем. Тормышнын туры да, кыек та юлы юк икән. Тормыш, төп асылында, бер урында таптану вә бер-беренне изү-таптаудан гыйбарәт икән. Нигә? Таптану да хәрәкәт бит! Кемдер әз-мәз кыймылдаганда да, «алга барабыз, хәрәкәтләнәбез!» дип, үзе дә юанадыр, тирә-яклап үзен камаган матдәләрне дә ышандыра аладыр. Йөз миллионлаган адәм бөртекләре арасында шушы боткадан аерылып чыгарлык көчле, гайрәтле берәү булмасын инде! Академик Бунич та, йорт хужам Рәис тә нәкъ бер үк сүзне сөйлиләр: «Очына барып чыга торган түгел әле бу!»

Бүген иртәдән бирле кар ява. Кыш лапас өсләренә дәү-дәү кибәннәр куйды, койма ышыкларына биек-биек эскертләр сузды, бакчада утырып калган ялгыз умарта өстенә чүмәлә өйде. Тәрәзәгә мангаемны тидерә язып, ишегалдына карап торам. Әй бөтереләләр кар бөртекләре, канчыклыйлар, кынжырланалар, биииләр, чәлмәшәләр... Нәкъ минем уйларым төсле. Йа рабби, чуалсыннар уйлар, кар бөртекләре сыман биесеннәр, чәлмәшсеннәр, тик кар бөртекләре сыман ак вә пакь калсыннар...

Борчуларны, кайгы-хәсрәтләрне читкә куеп торыр урын юк, алар яңа чыккан чебиләр сыман, жылыда, күңел куенында гына сакланалар. Әжәлетдин абзый гына тән белән бергә аларны да күтәреп китә...

Ялгыз, ялгызлык дип «мактансам»да, чынлап үлчәсәң ялгыз да кала алмыйсың икән! Төннәрен сөйкемле нурларын тәрәзәгә жибәреп ай мина сәламнәр күндерә. Яна туган ай урагын күргән мәлдә жаным рәхәт дулкынлана, сыкрый, Яна ай урагы мина әллә ниләр сөйли. Куанганым: бер мина гына түгел, бүтәннәргә, әллә кемнәргә, дөньяның дүрт ягындагы бик күпләргә сихри серләрен чишә. Ай югында, күкне аклы-каралы канатлар таккан болыт каплаганда, төнге армас жил тынган, йокымсыраган тәрәзәмне капшый, тикшерә: «Мондамы син?» Аның тынмас тавышын ишетеп мин әйләнгәләп ятам, караваг йокы аралаш шыгырдый, ул жилне үзенә эндәшә дип белә, шатлана, куана... Мендәр үз яңагын минем яңагыма куя, йомшара, мендәр эчендәге каз мамыклары ак болыт булып түшәмгә күтәреләләр, ак чәчкәләр булып баш түбәмдә йөзәләр. «Элек егермешәр каз үстерә идем» дип куана Фәрхенур. Кул бармаклары аша берәмтекләп үткәреп каз мамыгын мендәргә тутырганда нинди уйларын да сыйдырмагандыр ул мендәр сүрүенә, нинди йомшак өметләрен мамыкка кушмагандыр. Бер-бер артлы дүрт кызын кияүгә озаткан ана... «Һәммәсен әзерләп житеш итеп озаттым», дип сөенә ул. Әни кешенең шуннан да олы шатлыгы бармыни?.. Кызына мендәр әзерли, сүрүләрен тыгызлап кага-кага йомшартып тегә... Бу догалы мендәрдә аның кызы, йөрәк пәрәсе язмышы билгеләгән бүләкне—егетне кабул итәчәк. Шушы мендәргә башын куеп ул егеткә Ир дигән югары дәрәжә тапшырачак. Шушы мендәр аның кайгыларының, шатлыкларының сердәше булачак... О! Мин бөек рәссам булсам, кызына бирнә әзерләгән ананың мендәр сүрүен типчеп, мендәр тышы тегүен язып, сокландыргыч

рәсем иҗат итәр идем... Нинди бөек хисләр сыяр иде мамык мендәрләргә!.. Күпме аналар күз яше түгеп теккән мендәрләрдә ничаклы җайсыз вакыйгалар булып үтмәгәндер... мендәр почмагын тешли-тешли күпме яшь хатыннар газап кичермәгәндер... Ходаем, кызларыбыз—Галиягә, Миләүшәгә, бәби кызым Зифага бәхетле тормыш әзерлә, аларга ышанычлы егетләрне юлдаш ит... Тәрәзәмдә капшанган җил мине дә, уйларымны да очыртып алып китә, элегрәк мин уйларым белән янәшә оча ала идем, хәзер юк, каз мамыгы тутырган йомшак мендәрне сал итеп күнелем ясаган тын буада гына йөзәм, уйларымны кыр казларын озаткан кебек кул болгап, яулык селкеп озатып калам. Уйларым-канатларым! Өскә күтәрелегез, таңремә якынрак килегез!..

Көндез һич ялгыз кала алмыйсың! Тәрәзә каршымдагы кураларга песнәк дус килеп куна, йомры мәрҗән күзләрен текәп мине тикшерә: ял итә алганмы? Кәефе ничек? Машинкасы артына утырырмы?.. Ишегалдына чыксам, яшь юкә ботакларында рәхәтләнеп тирбәлгән чыпчыклар очкарак үрлиләр, чыркылдашып та алалар. Юк, сәламләмиләр, үзара минем хакта сөйләшәләр. Сөенәләрме?.. Мин аларның ара-тирә агач бөреләрен кабуларын күзәтеп сөенәм. Юкә бөреләрен малай чакта без дә бик еш ашый торган идек. Сугыш елларында, сугыштан соң юкә бөреләрен, чикләвек алкаларын бик яратып ашый идек без. Минем шушы чыпчыкларның аркасыннан сөясем килә. «Нихәл, дуслар, асылда мин песнәкләрне яратсам да бүген сез дә миңа бик сөйкемле күренәсез!» Ул арада качып-посып, мунча кыегына ышыкланып, мине подзор торбаларсыз да бик яхшы күреп, үтәли күзәтеп торган саесканнар, без белмәгән телләрдә кычкырып-акырышып, пыр-пыр очалар. Бар, саескан күзеннән качып торып кара. Алар туктаусыз позицияләрен алыштыралар, якын-тирәдәге кошларга гына түгел, әллә кайларда, авыл очында, Түбән очта яналыкларга зарыккан кардәшләренә дә хәбәр җиткереп торалар. Ни диярләр икән? «Бүген арган Аяз», диләрме? Песнәкләрнең: «Бүген Аяз бабай шактый озак эшләде!» дигән шатлык гимннарын кабул итәләрме саесканнар?.. Бүген аларның теш шыгырдатулары да ямьсез ишетелми, ә коерыкларын тирбәтүләре сөендерә хәтта. Бәлки, аларның да коерыклары аралашу чарасыдыр? Тавышлары җитмәгән араларга коерык флагларын селкеп моряклар төсле хәбәр салалармы?.. Ап-ак, бизәнгән агачлардан, акшарланган тупыллардан кара чүпрәк ертыклары булып, иләмсез канатларын киереп каргалар егылып төшә. Юк, егылабыз дип куркыталар гына алар. Адәмнәрнең каргаларны яратмавын, аларның гыйшкы бүтән кошларда икәнен беләләр, егылган булып алар җәлләтергә генә уйлыйлар. Кара күләгә булып тоташ энҗе-мәрҗәннәр сибелгән, бизәнгән җиргә төшеп җитәм дигәндә кинәт күтәреләләр, и җилпенәләр, җилпенәләр дә күз ачып йомганчы тупылның җил-давыл сындырган очына ук менеп җитәләр. Каргаларны күзәтеп, «Ах, харап булдылар!» дип ухылдашкан саесканнар әй куана шуннан соң, чыркылдык базар ясыйлар, «Син дә күрдеңме, әй, карт пистон!» дип коерыкларын селкиләр.

Әлмәт этләре дә мине күздән ычкындырмый. Тыкрык белән урам кисешкән юлда өчәре-дүртәре җыела, әүмәкләшкән булалар, янәсе, бу тирәгә болай гына, адашып кына килеп чыкканнар! Мин капкадан күренүгә колакларын торгызалар, кайсы сырт йонын кабарта, кечерәкләре сәламләп коерык болгый, дәүрәкләре ырлап та ала. Тыкрыкка керсәм—ияреләр, руша ягына китсәм—каршымда куян эзен иснәгән булып сагалыйлар. Янәсе, адашып Кәүҗияккә китмәсен бу тагын!

—Кошлар усалланды,—ди Рәис.—Юаш чыпчыкларга тиң азынды, язын авыр юлдан алҗып килгән сыерчыкларга тынгы бирмиләр. Оя тибеп утыра гына башлый бичара сыерчык, Югары оч чыпчыклары болыт булып очып киләләр дә, оясыннан буранлатып куып чыгаралар тегене... Инде ничә ел сыерчыклар бала чыгара алмый...

Кара син, сыерчыкларга һөҗүм бөтен фронт буенча башланган икән. Займищеда мин элек өч оя куя торган идем, өч улымнан сыерчыкларга яз

бүләге. Өч ояда мәж киләләр иде тырыш кошлар!.. Тора-бара оям бергә калды. Анысында да хәзер бүтән хуҗалар... Сыерчык очып килә, сайрап мен рәхәтен безгә житкерә, туган иленә кайтуына чиксез куана... Инде бала чыгарыр көннәре житә дигәндә генә, кара канатлары белән ал таннарны кисеп керәшәләр оча башлый. Әүвәл пычак-канатларынын очы белән һавада зәһәр тавыш чыгарып жил-жил очалар, аннан соң ояга һөжүм ясый башлыйлар, гәүдәләре белән килеп бәреләләр, кошнын котын алалар. Аннары тәмам акылдан шашып, оя тишегенә ядрә сыман атылып кереп, якты өметләренә куәт биреп күкәйләре өстендә утырган бичара ананы куып ук чыгаралар... Тәки кертмиләр! Керәшәләр жылы күкәйләрне тышка чыгарып ыргыталар... Явызлар! Үз балалары чыккач керәшәләр бу тирәгә тагын яу булып төшәләр, буш ояга кереп-чыгып, балаларына явыз үгет бирәләр: «Менә... Аларны оялар ясап, хөрмәтләп көтеп торалар!.. Бәйрәм ясап каршылыйлар... Ә без?.. Оя тибеп күпме көч түгәбез... газап белән типкән ояларыбызны малайлар жимерә, тыелмас яңгыр сулары юа!.. Бик кинәнмәсеннәр әле сыерчыклар!»

Саесканнар артты. Каргалар ишәйде. Хәзер тургай тавышы да берән-сәрән генә ишетелә, сандугачлар тынды...

Кошлар усалланмый нишләсен?! Алар мең еллардан бирле кеше белән янәшә яшиләр, адәм балаларынын гореф-гадәтләрен күзәтәләр, адәмнәрне ялгыз калдырмыйлар... Ни өйрәнә алар адәмнәрнең гыйбрәтләреннән?.. Ни акыл ала?.. Күрегез дә торыгыз, ун-унбиш елдан соң чыпчык өерләре явызланып бала-чаганың күзен чокып чыгарачак, песиләр ЧОН отрядына берләшеп, кешеләрнең колагын чәйнәргә тотыначак... болай гына булачакмы әле?..

Кошлар, кошкайлар, рәхәтләнеп күзәтегез мине! Карлы юлларнын матурлыгына куанып бетә алмыйча сукмак-юлларда йөргәндә мина ияреп янәшәмдә йөрегез, очыгыз. Песнәк-чыпчыклар! Карга-саесканнар!... Күнелемдә инә очы хәтле дә явызлык юк... Әүлияләр мәңгегә йокыга талган изге төбәктә күңелемә гел ак уйлар гына инә!..

Өскә төкерсәң, мыекка элгә,
Аска төкерсәң, сакалга элгә.

*3 февраль, көндезен.*

Нишлисен, нишләмәк кирәк, дөнья халыкларынын байтагысына коммунистик аң сөреме сенеп калган. Россия коммунистлары съездга әзерләнә, Румыниядә властька коммунистлар килү ихтималы бар... Тагын, тагын... әйе, халыкның власть түмен татып бозылырга, азынырга өлгергән төзәлмәс өлеше үзгәреш чорына яратып кигән битлеген бүген сала. Салырга әзер. Ә түбәндә ятып калган, тамагыннан бүтәнне кайгырта белмәгән күпчелеге каты кулны юксына. Хужа кирәк аларга! «Эт үзенә ничек итеп хужа эзләгән» дигән тунгус халык әкияте бар иде без яшь чакта. Хәзер заман, замана балалары үзләренә хужа эзли. Мин әллә дин борылыш ясарга булышырмы дигән идем, коммунистик астыртын көчләр дингә капка ачып тормыйлар әлегә. Мөфти хәзрәтне салып таптау да, асылда, кара көчләрнең касәфәте. Урыс чиркәвенен үз яшерен оешмалары—КГБсы, МВДсы, Хәрби разведкасы юк дип кем әйтә ала?! Алай ук бер катлы булмыйк инде! Чиркәү—илдәге иң куәтле көчләрнең берсе... Бу—шиксез! Халаекларнын коммунистик ожмахка омтылуларын көннән-көн, атнадан-атнага көчәюен күреп хурланам. Күпчелек тагын коллыкны сайлый. Шакмакларга бүленгән, чәйнәп каптырылган деспотизм идеялары халыкка аңлаешлы вә якын икән. Тарихны кабул итә алырлык аннар бездә юк икән әле. Ничә кеше чыкты икән явызлар партиясеннән? Бармак белән санарлыктыр, мөгаен... Һәммәсе «туктатып кына торалар».

*5 февраль, Иске Әлмәт*

Язны агач бөреләре һәм кызлар әүвәл башлап сизә дип язганым бар. Белеп бетермәгәнмен, монда торганда гына искәрдем: язны «Римны саклап калган» сизгер казлар сизенә икән. Моңарчы, февральгә кергәнче, ишегалларында казлар барын белмичәрәк йөри идем. Хә-ә-әзер!.. Аннан да моннан да, ерак ихаталардан ук ата казларның гайрәтле, егетләрчә аваз салганы ишетелә. Һәм бу язгы мәхәббәт авазлары торган саен көчлерәк яңгырый. Авыл тирәсендәге бөтен гадәти авазларны, тавышларны уздырып кычкыра казлар. Үзара сөйләшәләрме, җәй көне танышып, бергә-бергә инеш ярларында чирәм капкалап, сакчы күрмәгәндә яшькелт ужым кыяклары белән сыйланып йөргән ахирәтләренә дәшәләрме, белмим. Иллә мәгәр, алар әлегә ябылуда, араннарда, лапас асларында. Хәзер мин дә аларга сәлам биреп йөрим, авылда танышлар артты. «Саумы сез, казлар!» Ата казга сәлам бирмичә йөрсәң, муеныңа кыярак чыга, диләр татарлар.

«Буран» дибез, юри генә зарланабыз да, ә илләрдә әллә ниләр бар. Кола ярымутравында штормнар, һәлакәт, шәһәр-авыллар утсыз-сусыз калды, атомэлектростанциясен туктатырга мәҗбүр булдылар. Кабарда-Балкарда һәлакәт арты һәлакәт. Таулардан кар ташкыны төшә, автобуслар, машиналар кар асты төрмәләрендә калалар, кешеләр үлә. Тарлавыклардагы кар катламнарын күрсәтәләр... Ай-һай, анда миллион сумнар давылларга оча, монда миллионнар кар астында кала. Кичә Заирда биш миллион сумлык купюрларны күрсәттеләр. Ул җәһәттән бездән алда илләр бар икән! Әллә Рәчәй рекордчы буламы дип йөри идем. Безгә дә килеп җитмәсме ул биш миллионлык кәгазьләр?.

Утырам—уйлыйм, ятам—уйлыйм. Уем берәүгә дә кирәк түгел, уйларымнан берәүгә дә юаныч яки куаныч юк, уйларым белән бер башым, үзем генә юанам. Кәгазьләремнең язган кадәресен кайтып укырга куркам, әллә чүп язам, әллә... Кемгә кирәк алтмыш биш яшьлек картның казынулары? Гомумән, татар әдәбиятына мохтаҗлык калдымыни?.. Менә бүген Сарман урта мәктәбендә очрашу булачак. Машина килгәнне көтеп торам. Сарман мәктәбендә татар әдәбиятының тәэсире калганмы?.. Ай-һай... Дөрес, мондый шикчел уйларга баш бирергә ярамый... Алар башны ук алып китсә, ничек яшәмәк кирәк? Ничек?

*6 февраль, иске Әлмәт*

Әлмәттә Мулли исемле туксан яшьлек карчык яши. Хас исеме Мөгаллимә. Гомере буе ялгыз, кызлыгын саклаган хәлдә гел ир-ат арасында уралды. Сарык асрады—көтүгә кумады, сарыклар үзләре чыгып, үзләре кайтып йөрде. Сарыгын суйдырмады, быел чыккан каз бәбкәләре икенче елга да кала килде. Нык эчте, аракыны стаканга салгач, «айнымасын» өчен стаканның авызын учы белән каплады. Тост әйтергә яратты. Хәтере шәп, әле искене, Коръән аятьләрен дә белә, шаулатып укый.

—Зиһеннең ныклыгы юк, әнә, догаларны гәҗит-журналларда гел чыгарып торалар, бикләп кенә булмый. (Бикләп—ятлапның нинди матур формасы!) Без сәвит карчыклары шул инде, күп нәрсәдән мәхрүм ителгән.

*8 февраль, Иске Әлмәт*

Фәнҗияләр «Ватаным Татарстан» гәҗитен алдыралар. Ул январь номерларын җыеп төшерде, куана-куана алып калган идем... Юк, валлаһи дип әйтәм, газеталар мине ырлаталар гына! Күпләрнең җүләрлеген, ахмаклыгын күреп, тешемне кысып, утны тышка чыгармыйча

яшәргә тырышам... ә гәҗитләр ахмакларның фикерләрен хуплап, һичбер анлатмаларсыз халык арасына тараталар... Юк бит шуларга сендереп каршы төшүче акыл иясе дисәм, 22 гыйнварда Әмирхан Еникинен зур мәкаләсе басылган икән. Колак салучылар, уйланучылар табылырмы, мәгәр «Кем хаклы?» дигән мәкаләсендә Әмирхан ага тарих менгергән югарылыгыннан тагын бер тапкыр татар халкына эндәшеп карый. Сүзләре хак, хафалары урынлы, ул татарларны канлы бәрелешләрдән аралап алып калырга тырыша. Әлбәттә, бер генә дәүләт тә, Россия белән арасын бозу бәрабәренә Татарстанның суверенлыгын тану юлына кермәячәк. Әлбәттә, хәзер һәм алда да без Россия белән татулык шартларында гына яши алачакбыз. Мона Татарстанның географик урыны да, җөмһүрияттән читтә яшәүче биш миллион татарның урыс дәүләтендә тозакта, биктә яшәве дә мәҗбүр итә. Нишлисен, татарның иле булса да, күпчелек халкы үз тирәлекләреннән читтә яши... Бер генә нәрсәне әйтми Әмирхан ага: бүгенге көнгә җиде миллион татар—миф, Татарстанда, Казанда чын татарлар калмаганда, мәркәзебез татарлары бүгенге шартларда «ямаулы татарга» әйләнгәндә, ерактагылар никадәр житез кыланган булып маташсалар да кардәшләребез татарны татар иткән сыйфатларын күптән югалтканнар, телләрен онытканнар. Әйе, өметне суытмыйк, бәлки татар канындагы татарлык геннары уянып, хәрәкәтләнеп, кемнәрдер анга килер, әмма бүген аларга йөз тоту, татар язмышын алар кулына тапшыру—балачагалык, беркатлы ахмаклык.

Бу көннәр бушка үтте. Романдагы «Татарлар» дигән мөһим бүлек язылмады. Аны бетереп кайтырмын дигән идем. Әле Әхмәтзыянның хатын архив папкаларыннан эзләп табасы бар. Ул бик мөһим, минем үткәннәремә төс бирә алырлык кадерле хат. Исән-аман кайтып егылсам, беренче эшем.

3 февраль санында Газим абый Салиховның мәкаләсе басылган. Безнен өчебезне телгә алган... Фроловны язып китүе гыйбрәтле. Чахотка белән авырган икән, бичара. Монысын белми идем... Мина да бу фактны искә алып китү кирәктер...

Кич якынлаша. Иске Әлмәттә соңгы кич. Актыккы көннәрдә кәеф бозылып авылда татыган рәхәтлекләр тоныкланды. Акыл: авылда артык озак юанырга ярамый.

—Бурсыган ит, сасыган ук түгел, мәгәр ябык савытта торып бурсыган.

*9 февраль, Иске Әлмәт*

Монда соңгы көн, соңгы иртә. Салкын! Кичә колхоз рәисе Нәҗиптән: «Авылда ин фәкыйрь кеше кемнәр һәм нигә алар фәкыйрь?»—дип сорадым. Җавап: «Бикмәттән берәү шактый вакыт зимагурлыкта йөри... Ахыр чик, урыс маржасына өйләнеп, үз авылына түгел, Әлмәткә кайтып төпләнә. Бәләкәй генә өе бар, сыеры, хатыны... Хатын димәссен, безнең басуларда чөгендерләр дә аннан дәүрәк була хәзер. Ике баласы бар... Хәлләрен белешергә дип кердем. Отчет якынлаша. Сорау бирүләре ихтимал. Бер баласы яшь ярымлык, икенчесе яна туган... сөт шешәсеннән чак кына олырак... шушы арада гына иренә карабодай ярмасы, егерме кило шикәр яздырып биргән идем. Сорыйм: «Шикәрегез бармы?» «Юк», ди... Ире егерме кило шикәрне исерек баштан бер яртыга биреп җибәргән. «Ни ашыйсыз соң сез?» дим... «Менә ярма бар», ди... Чын ярлылар, мөгаен, шулар калган..»

*11 март 1993 ел, Түбән Кама*

Һич истә-оста югында Кама ярына килеп утырдым бит, әй! Күптәнге дустым Рәшит Вәлиевич Абдулхакимов: «Ял итәргә, эшләргә безнең якларга кил, урнаштырам!» дип кыстап йөри иде, тәвәккәлләдем!..

Кичә иртәнге автобус белән сәфәр чыктым, көн матур, юл һәйбәт, очабыз гына! Рәшит Вәлиевич каршылады, выжлатып кына санаторий-профилакторийга китереп житкерде. Авыл хуҗалыгы эшчәннәре-крестьяннар өчен нәкъ крестьянча ашык-пошык салынган өч катлы йорт икән. Ишек ярыкларыннан үтә-сүтә пәри малайлары шуып кереп йөрерлек, идәннәре шикле пычрак, бәдрәф идәнендә башмак табаннары ябыша, кай почмакка карасаң да котсызлык, хуҗасызлык. Кат-кат басып, туктаусыз йодрык белән төйгәч кенә ут кабына, розеткалар эшләми, чәй кайнатыр өчен бүлмәдән-бүлмәгә чабып йөрисе, иң хәтәре—сап-салкын. Калын юрган астында йоклаганда әлләни сизелмәгән суык, урыннан калкынуга, кочып кына алды! Бр-р! Калтырата, каһәр! Өстәмә җылыткыч куя алсак ярар да... көндез һәйбәт кенә ашатканнар иде, кич манный боткасы белән сап-салкын омлет бирделәр. Җирле баш врач Илбәк Садыйкович Мөхәммәтҗанов дигән урта яшьләрдәге ир икән, Урта Азия тумасы, татарны белми диярлек. «Язучы» дигәч, шүрәле күргәндәй булды, әллә инде татар әдәбиятының барлыгын ишеткәне дә булмаганмы? «Массаж бездә һәйбәт!» дип сөендерде. Тоташтан сызлаган кулларыма әз-мәз шифа, савыгу таба алсам ни куаныч булыр иде дә...

*13 март 1993 ел.*

Шактый салкын бүлмәдә калын мамык юрганга җылы тәнемне тапшырып, монда өч төн үткәрдем. Алданучан тәүге тәэсирләр онытылып, мондагы тормыш чынлыгына кереп киткәч, «Яшәргә була» дигән фикергә килергә тырышып карадым. Иң мөһиме: диабетны нык кына «иркәлиләр», аерып ашаталар, диетаны эчкерсез рәвештә сакларга булышалар. Аннан да мөһиме: бу татар дөньясы икән. Кайсы бүлмәчеккә кагылсаң да татар врачлары, татар шәфкать туташлары, татар хезмәтче хадимнәре каршылый. Татар теле белән генә түгел, татар кунакчыллыгы, гадилеге, эчкерсезлеге белән каршылыйлар да рыясыз, чын күңелдән олылау, изге теләк белән озатып та калалар. Ял итүчеләрнең иң зур күпчелеге татар, Зәй, Актаныш, Әлмәт якларыннан килгән крестьяннар. Яшеренеп, шыпырт кына йөрим дисәң, Зәйдән шактый халык җыелган икән, танышып, сәлам алышып йөри башладык. Үзара мөнәсәбәтләр гади, садә, мөлаем, санаторий хадимнәре миһербанлы, игътибарлы. Монда татар авылларында гына була торган борынгы мөнәсәбәтләр шәйләнә, Олы—монда олы, ярлы да, бай да тигез. Врач Сабиржанова, кабул итеп, зар-моңнарымны тыңлаганнан соң, мине ияртеп кабинетлар күрсәтеп, массажда-парафинда хезмәт күрсәтүче туташ-ханымнар белән таныштырып йөргәч, әллә минем язучы икәнемне белеп шулай кыланамы дисәм, врачның һәркемгә (һәркемгә!) шәфкатьле мөнәсәбәтен, бик фәкыйрь киенгән, өшәнгән, бичара урысны да нәкъ шулай озатып, урнаштырып йөрүенә шаһит булгач, гаҗәпләнүем соң дәрәҗәгә житте. Бу санаторий татар гореф-гадәтләрен саклап торучы резервация булып тоела. Кичә баянчы килгән иде, бар халык җыелып «кичке уен» үткәрделәр. «Өчле, «Бишле» биеделәр, «Чүпләмле» уйнадылар, азакка кадәр утырмадым, миннән соң да ярты төнгә кадәр диярлек икенче каттан күңелле шау-шу безнең катка да менеп житә торды. Карт-коры, тешсез әби-сәбиләр, билләрен сылатып, парафин белән җылытып ах-ух килеп йөргән карт-коры и җилкенде, и куанды! Татарча уеннарны онытмаган буын монда, милли хисләрен саклау турында уйламыйча яши алган, мәгәр нәкъ кирәк чагында гына чын татарлыкны күрсәтә алган буын вәкилләре икән минем тирә-ягымда... Арада шактый өлкән яшьтәге, җыерчыклы битле, яшенә караганда килешеп тә бетмәгән кара ефәк күлмәк кигән бер марҗаның очынып-очып татар көйләренә бөтерелүен, аулак өй уеннарында рәхәтлек дингезендә йөзеп бәхет татуын сүз белән генә аңлатып бетерә дә торган түгел.

Кичә дәваланырга керештем, парафин, массаж алдым. Һаман шыр тиле инде үзем, житмешкә атлап акыл кермәде. Парафин кызарткан, массаж изгән жилкәмә юка курткамны салып бер сәгать чамасы урман юлларында йөреп кайттым. Төнлә тамак төбе кымыржый, әллә кай чокырга кереп оялаган ютәл бугаз төерен әрле-бирле йөртә, чирләп ятырга язмасын!!! Әле эш тә тота алган юк, гомумән, ныклап дәваланырга керешкәч, эш белән очрашырга жай чыгар микән? Үтә нәзберек хезмәт бит ул язу эше! Эш—иркәләгәнне, бары тик үзенә генә тугры булганны ярата, ул хужасын читкә жибәрми, бөтен барлыгыңны, тәнең вә жаныңны суырып ала, якана бер ябышса—ычкындырмый!..

Телевидениедән Хәйдәр шалтыратты, Зәй егете, якташ.

—«Язучы фикере» дигән рубриканы дәвам итәбез, яшәтәбез, Аяз абый. Хәзерге катлаулы заманда сезнең фикерне ишетәсе килә...

Чак егылып китмәдем: нинди фикер? Кемгә кирәк бүген язучы фикере? Кемнәр мохтаж аңа? Хәзер һәр адәм заманча философ, заманны узып алга китә алган акыл иясе... Жәмгыятьнең иң мескен, иң фәкыйрь, өлешсез вә киләчәксез калган төркеме әдипләр, сәнгать әһелләре. Шушы факт кына да аларның бүгенге көрәш сызыгыннан читкә тибәрелгән төркем икәнен күрсәтә. Күпчелек фикри адашулар арасында бутала... Дөнья буталган, асты өскә, өсте аска килгән. Бер авыздан да өметле, ышанычлы сүзләр, якты фаразлар чыга алмый, дөнья авызларны пичәтләгән, аннан бары тик зар-моң авазлары, бөтен Рәчәй милләтләрен берләштергән сүгенү сүзләре генә чыга ала...

Туктадым да бер ноктага карап онытылып торам. Ни булды? Аңламыйм. Ә-ә, тыкрык башындагы йорт ишегалдында балалар татарча сөйләшеп уйныйлар икән! Йа, ходаа, мондый гүзәл манзаралар да бар икән әле дөньяда. Быел Муллиле авылына кайткан идек. Матур халык яши анда, кунакчыл, игътибарлы, кече күңелле... Ишегалларында балалар... бөтенесе урысча сөйләшәләр. Ил шәһәрләреннән ял итәргә кайткан татар балалары... татар дип... Дамир Гарифуллин сөйләгән иде. Бер бала каладан кайткан ди, теттереп урысча да, татарча да сөйләшә икән. Авыл малае өенә кайткач, шаккатып, әтисенә сөйли икән: «Әти, әти, урысча белгән башы белән ничек оялмыйча татарча сөйләшә икән ул?»...

*7 октябрь 1993 ел.*

Йа, Ходай! Күктә Кояш та бар икән әле! Булгандыр, алтмыш алтынчы ел яшәп мондый мәрхәмәтсез көзләрне дә күргән бардыр... Аерма шунда гына: элгәрге ямьсез көзләр, авыр дымлы һавалар, суга туксырган авыр жилләр мин яшьрәк чакта килеп киткәннәрдер. Хәзер исә гәүдә талкынган, аяклар авыр, тез буыннары сызлый—диабет сиздерә. Йокыдан торасың, әллә ял иткәнсең, әллә юк—йокыда чакта да шайтан сине йөк ташыткан, таш ваклаткан, балчык төяткән кебек. Рәхәтләнеп киерелеп тә булмый! Йөрисең шунда танавыңны тартып...

Ниһаять, өч ел дәвамында мине хатирәләр белән тыгызлап тоткан, зиһенне тәмам биләгән, акылны яулап алган хатирәләр романы—«Йөгез, бер дога!» тәмам. Бишесендә мин аның соңгы сәхифәләрен журналга илтеп бирдем. Алдагы бүлекләре журналның унынчы санында басылып та ята. «Куанырмын, очып-очып йөрермен!» дип, әсәрнең очын өзелеп көтсәм дә... юк, күңелгә ниндидер ят авырлык ишелеп төште. Өч ел! Ничәмә-ничә тапкыр мин әсәр бүлекләрен юлда йөргәннәрдә күңелем тирәнлегендә суздым, онытылган өлешләрне ялгадым, төн ката аерым-аерым вакыйгаларны хәтеремнән уятып, иртән сикереп торып яза башладым. Төн урталарында сердәшем машинкага ялварып, сәхифәләрне теркәп-теркәп куйдым. Атналар буе кулымнан эш төшеп китеп газапландым. Хәтта, язын, апрель аенда, һич истә-оста югында, романны

ташлап торып, «Уналты яшь» дигән хикәя дә язып алдым...

Өч ел! Шушы еллардагы авыр газапларымның нәтиҗәсе—романым. Мин монда җанымның властьларга, системага, күргән нужаларыма бирешмәгән, сау калуын бәян иттем. Китапта телгә алынган бер вакыйга да, күңелемнең давыллы дингезләрендә һаман-һаман саклана торган бер генә кеше дә уйлап чыгарылмаган. Дөрес, адәм балаларының мәсләген, иманын ача торган фактларга дәлилләрне мин китаплардан, гәҗит-журналлардан да эзләп алдым. Чөнки юлдашларымның төп фикер юнәлеше хәтеремдә булса да аларны укучыма җиткерү өчен байтак казынырга, эзләнергә туры килде.

Җанымны җылыткан, җанымны баеткан, ныгып җитмәгән иманыма тугры калырга булышкан тоткын-зекларга үтә рәхмәтлемен! Сезнең затлы исемнәрегезне татар әдәбиятында булса да беркетеп калуыма сөенәм. Өч ел! Өч ел мин ал-ял күрмәдем. Быел хәтта Идел буйларына барып ял да итә алмадым. Ике тапкыр гына су кердем. Шуның нәтиҗәсеме, аякларым сызлый, баскычтан менгәндә уфылдыйм, баскычтан төшкәндә култыксаларга яки дусларымның иңенә ябышам. Ял кирәк, хәрәкәт кирәк. Ничәмә-ничә битләр басып, аларны ыргытып бәреп, яңадан эшкә керешмәдем мин!..

Январь-февральдә Иске Әлмәттә бәрәкәтле, эшле, җимешле көннәрем үтте. Юмарт хуҗаларым Рәис белән Фәрхенур минем һәр ишарәмне сагалап, ни ашыйсым килсә, шуны пешереп, кырык көнгә якын мине баладай карадылар. Романның зур өлешен мин шунда күчереп эшләдем. Ничәнче кат?! Февраль башында өйгә кайтып, әз-мәз уралдым да Түбән Камага юл алдым. Түбән Кама—«Зәңгәр күл»... Анда каты чирли башлап, кайтып, аяктан егылдым. «Чыраең зәп-зәңгәр иде», диде, коты чыгып, Нәкыя... Шуннан китте, китте чир белән тарткалашу! Шикәр күтәрелде, басым уйный, йөрәк кага!...

Җәйгә чыккач кына ипкә килдем, тоташтан басып эшләргә керештем. 515 бит текст! Кат-кат басып, тегеләй күчереп, болай йөртеп маташа торгач, соңгы ноктаны куйдым. Иңемнән тау төште, ике иңемә менеп баскан хатирә-албасты әкренләп җиңелде. Дөньялык алдында бурычым үтәлде. Әҗәтем калмады. Бу олы хезмәтемне исән-аман тәмамлый алуым белән бәхетлемен. Язу дәвамында зиһенең таралып аяктан егылсаң, ни кылыр идең? Болай ил алдында йөзем ак, җаным тыныч. Күңелдә тәгәрәп йөргән башка уйлар, бүтән әсәрләр үткән төндә үк зиһенне кымтырыклый башлады. Литвин белән бергә уйланылган әйбер бар иде, тизрәк аны ерып чыгарга кирәк...

*14 октябрь, 1993 ел.*

Бүген сәфәр чыгам—Переделкинога. Былтыр да нәкъ шушы көннәрдә китеп, ике срок торып кайткан идем. Бер ел эчендә шактый зур аерма: көчем әз, кул-аяклар сызлый, хәтер саеккан, бүтән якларда да җәрәхәтләр, яралар сизелә, ел эчендә адәм баласы үзгәрсә дә үзгәрә икән! Бер куанычым бар: роман-хатирәне язып тәмамлап, журналга тапшырдым. Унынчы санда басылып чыгып та килә. Өч еллык газаплы хезмәтне артта калдырып барам бу юлы иҗат йортына. Инде сау-сәламәт йөреп кайтырга язсын. Юл мәшәкатьләре болай да каушатып тора. Барсаң вай да, бармасаң вай!

*17 октябрь 1993 ел, Переделкино*

Унбишендә килеп төштем. 107 нче бүлмәгә җайлы гына урнаштым. Иртән, яктырганчы ук, әз-мәз эшне кузгатып карадым. Ашыкмый, теркелди. Литвин белән уйланылган повестька тотындым. Өйдә чакта исәп биреп бетермәгәнмен: тагын төрмә темасына ябышканмын

икән! Хәерле булсын: Литвин тынгы бирми, көчләп яздырачак. Эшсез, мазасыз бер көн дә тора алмый, бичара.

Гәҗитләр кыю, Яна Октябрь вакыйгаларына капма-каршы бәяләр биреп, дөреслекне йон йомгак эченә яшерәләр. Йомгакнын жеп очын эзләп таба алсаң да, кайчан сүтеп бетерерсен әле аны!.. Станислав Говорухиннын сугышчан отрядлар жыйнап, ашыгыч рәвештә Ельцин тарафдарларына каршы барырга өндәвен бер яклырак кабул итеп анлаган идем. Элек тә коммунистик режимга ачыктан-ачык каршы төшкән, шул какшамас якты иманнары өчен мин яратып өлгергән, югары күтәреп йөргән кайбер шәхесләр дә бу чуалыш сәгатьләрендә Ельциннын гамәлләрен гафу ителмәслек явызлык дип бәяләгәннәр икән!

Станислав Говорухин исә бу дәһшәтле көннәрне «Россияне атып үтерү» дип бәяли. «Россиядә каһәрле көннәр башланды», дип тәмамлый ул «Известия» газетасындагы мәкаләсен.

Әйе, без—Сталин чоры балалары, Руцкой-Хасбулатовларны «атып үтереп кенә илне коткарып була!» дип санаган, аларга әҗәл-үлем теләп, кесәдәге йодырыкларны йомарлаганда... кешеләр тирәннәнрәк тә уйлаганнар икән! Синявский, Максимовлар да бер сүздә булып Ельцин гамәлләрен «ирекне буу», дип бәяләделәр. Бу очракта мин тагын беркатлылык күрсәтәмме? Кабат ялгыштыммы?.. Ельцин кай ягы белән «алдырды» соң?.. Беренче нәүбәттә ул коммунистлар партиясеннән чыкты. Икенчедән, ул жаһилләр партиясен таратты. Дөрес, таратуы азакка кадәр үк барып житмәде, алай да, үз вакытында бу карар, тарату нияте мина рух өстәгән иде.

Дөрес, гәжитләрдә бара торган тартышлар, ызгышлар, телдән телгә жинел күчеп йөргән уйдырмалар уемнан какшата алмадылар, мәгәр Мәскәү мохитенә барып кереп, йөк-йөк хәбәрләр төягән гәжитләрне күзәткәннән соң, жанымда нидер кителде. Адәм жаннарын кыймыйча гына фашистик оппозициядән арынып булмас идемени?.. Безнең аннар да шулай итеп канга сусаган булып чыктымы?.. Әллә ленинизм идеяләренең йогышыннан кан кою белән генә котылып буламы?

Быелгы 3-4 октябрьдән соң кемнәрдер тагын үзгәрәләр, көнгә-сәгатькә кулай битлекләр киеп алалар, андыйларнын запас битлекләре бер чакта да үзләреннән калмый, әзер тора, мәгәр бер нәрсә ап-ачык: акыллы адәмнәрнең байтагы Ельциннан һич канәгать түгел! Мондый шик-шөбһәләр көннән-көн арта икән... ил башына Зюганов, Сажи Умалатова, Аман Тулеев менеп атланмасмы? Әйе, әйе, акыл дилбегәсен кулдан ычкындырырга да, жебеп калырга да ярамый. Руслан Хасбулатов булдымы Ил башы? Ничә айлар безнең өскә салкын сүзләр койган буш бугаз! Брежнев комсызга атап салынган 500 кв. метрлы зиннәтле әкияти сарайга бәгрәеп кереп утырды. Туксан проценты илне имеп, күзләрен кан баскан коммунистлардан укмашкан парламентны тәмам котыртып житкерде!

Болар хакында инде уйламам, чәнчелсен депутатлары, үз йөгем карт иннәремә житеп ашкан дип үземне-үзем әрләсәм дә читтә калып булмый икән...

Мин тагын монда. Былтыр «Йәгез, бер дога!» белән женләнеп ята идем. 1991 нче елда бүтән эшләремне читкә куеп, «дога» укырга керештем. «Коръән» белән генә ярты ел утырдым!.. Тәнремә рәхмәт, ниһаять, быел ул эштән котылдым. Монын кадәр дә газапланганым, бәргәләнгәнем, жан талатканым, шушы чаклы интектергән, жан талаган әсәрем юк иде шикелле. Авыр язылды, инде аллагы бүлекләр тәмам дип исәпләгәндә дә романнын азакккы өлеше юк иде әле. Азак хәзер дә канәгатьләндерми, ни эзләнеп, ни төпченеп, казынып, ахыргы фикерләремне югары, көчле тавыш белән күк күкрәтеп әйтеп бирә алмадым. Мондый рәвештәге китап, доньяны сискәндереп бетәргә тиеш иде дә, әлләни көчем житмәде, фикерләр көпшәкләнде, сүзләр, рәткә тезеп утырткан домино шакмакларыдай авып таралдылар. Китап итеп әзерләгәндә актыкккы күләмне янадан ермачламый ярамас.

Булды шундый авыр мизгелләр, барысын чәчеп ташлап, ыргытып, туку станоклары кергәч, котырынып машиналарны җимереп бетергән инглиз эшчеләре кебек дулап, кулъязмаларымны ут төртеп яндырып, җәһәннәмгә җәяү чыгып чабасы килгән чаклар булды. Тик бу романны язып өлгертергә кирәк иде мина! Өлгертергә, дөньяга чыгарырга...

Передилкинога чыгып китәрлек ихтыяр көчем калмады, Нәкыя кыстап, үгетләп юлга чыгарып җибәрмәсә, быел кузгалмаска да иде исәп. Өненнән көнгә чыгарга өнәмәгән карт аю хәлендә, караватта аунап ятасы идем. Юлга чыгар алдыннан җентекләп карыйм: мүкләнә башлаганмын, валлаһи! Моңарчы яшәешемдә гел бер тәртип булды: өзгәләнеп-хурланып Казанда яшим-яшим дә, дөнья божрасы тынымны кысып буа башлагач, чыгып таям, дөньяның шушы бәрәкәтле, юмарт почмагына килеп җитеп егылам. Октябрь айларында гел монда булам диярлек.

Переделкино яфракларының коелганын яратам мин!

Гайрәт белән агачларны аралап килеп җиткән көзге җилләрен сагынып киләм мин бу төбәкнен! Тәрәз пыялаларының рәхәт салкынлыгына пеләшләнә башлаган кайнар мангаемны терәп, өермә булып тузгыган сары буран ташкынына озак-озак карап торам. Көнне камаган давыл күкрәктәге ярсу хисләр бер-берсен эзләп табалар да мине өерләп-җинеләйтеп күккә ашыралар. Кайный-кайный яфрак бураннар тузгыта көзге урман!

Быел соңгарак калганмын, урманнар тоташ шәрәләнгән, сукмакларга калын-калын быелгы юрганнар түшәлгән. Яфраксыз калган шыр урман тавышларны төрле якларга тигез тарата. Быел, октябрь орышларыннан соң, тирә-яктагы тавышлар да үзгә, бүтәнчә янгырый. Ике-өч кеше гөр-гөр килеп ашханә верандасының түбәсен ямыйлар—кеше тавышлары пулемет тырылдагандай була. Берәвесе төчкерсә—янда гына мина ярылгандай янгырый. Борын сөнгерсәләр—бомба төштеме әллә, дип куркып торасың. Дөнья алмашынганда тавышлар тиз-тиз үзгәрә.

Кичә, бүген ихата эчендәге борма сукмаклардан җил-җил йөрим, тынычлыкка зарыккан күңел киңәя, куана, инде ниятләп килгән эшне дә беркадәр алга җибәрә алсам...

«Казан утлары»ның 10 нчы саны укучы кулына барып кергәндер. Йөзләрчә күзләрнең нуры роман-хатирәм юлларына түгелгәндер. Миннән башка моны беркем дә сизмәде, сизә алмады, мин «Балта кем кулында?» романын язып, бертөрлелеккә, беркатлы фикерләргә күнеккән стандарт татар укучысын үземнән читләштердем. Барлы-юклы әдәби хәрәкәт, укучыдан чак кына алдарак барырга тиешле әдәби тәнкыйть үз вазифасын—әдәбият белән укучы арасын яктыртуны үтәмәде. Роман тәнкыйтьчеләр йөзгән быкырдык инештән югарырак иде шул. «Балта...», «Яра» повесте белән бер тышлыкта басылды. «Яра» повесте турында һаман сүз өзелми, әмма уй-фикер «Балта...»га барып җитә алмый. Солженицынның «Один день Ивана Денисовича» «Новый мир» да басылып илгә таралгач, Ил Саттаров аны күтәреп алды, нигезле, әтрафлы, дәлилле гыйльми мәкалә язып, Мәскәүгә җибәрде. Ул арада Александр Исаевичны чукый башладылар, язганы югары дәрәҗәдә булса да дөнья күрмәде. Илнең гадәти булмаган фикерләү рәвеше, автор күңеленең чонгылларына төшә алуы мине нык сокландырган иде. Яшерен өметләр белән мин аңа «Балта...»ны тәкъдим итеп карадым. Үз бәямне яшермәдем: «Бүгенге көнге татар прозасында мондый югары дәрәҗәдәге әсәр юк», дидем. Озак укыды ул романны, ярты еллар үткәч бер очрашып, сүрән генә гәпләшеп тә алдык. Солженицынны аны вә җаны белән яраткан егет минем әсәрне кабул итмәде шикелле. Инде ул да йөз чөергәч, үземнең мөнәсәбәтем дә үзгәрде... «Китабым хак бәя ала алмады!» дип кыйналмыйм. Инде «Йәгез, бер дога!» да укучы күңеленә юл сала алмаса... Ни уйлармын?.. «Халкым белән бер арбага җигелеп бара алмадым, уф алла!» дип, өметсезлеккә бирелүем бик ихтимал. «Балта кем кулында?»ны урысча

чыгарып булмады. Урысның зыялылары арасыннан әсәрне якын итәрлек адәмнәр табылыр да иде. «Кызлар хатлары» урысча басылып чыккач, мәктәп балаларыннан ниндиен хатлар алмадым мин! Урыс ишле халык шул, балалары арасында әдәбиятны зәвык белән кабул итүчеләре бар, әзерлеклеләр күп. Безнең ни, һаман шул инде, авыл балалары укыштыра да, сирәк-мирәк кенә авыл укытучылары китап актаргалый. Татардан китеп бетмәгән, урыска барып житмәгән йон төргәкләренә порнография белән детективтан башка берни дә кирәкми шул!

Переделкинога китәремә атна калгач, карчыклар чуагының матур, йомшак бер көнендә Литвин белән Фәрваз янына кагылдык. Алексей Львовичның үз йомышлары, минем дә нәни генә белешәсе эшем бар, бер очтан саубуллашырга да кирәк. Кердек, утырдык, сүз ялганмый интектерде. Була бит, өчебезнең дә тел очында сүзләр туып сүнә, берәү дә ачыктан-ачык уртадагы суык учакка ботак ташларга ашыкмый. Фәрваз элек тә зарлангалый торган иде, ниһаять, өстәлгә түше белән ятып, янтаеп зарланырга тотынды. «Авырта... Теге дару сызлауларны баса торган иде элек. Хәзер дару юк. Казанда да юк икән! Польшада бар диләр, кабы йөз мең сум! Ул кадәр акчаны мин кайдан алыйм! Һич түзәр әмәл калмады». Эссе көн, бөркү бүлмә, дәүләт оешмаларында ремонт гасырлар буе туктамый. Коридордан буяу исе саркыла, тынны кыса. Фәрваз тәрәзәгә монсу гына карап алды да: «Әллә иртәгә, бер жай табып, табигатькә чыгып керәбезме?» дип сорады. Без, Литвин белән, алмаш-тилмәш аның бу фикерен хупларга тотындык.

Килешенгәнчә, көндезге өчтә машина белән алар килеп житте, мин чыгып утырдым, яна диярлек «Волга» машинасы алга элдерде. Литвин белән Фәрваз арткы урыннарда, Фәрваз аякларын кая куярга белмәгәндәй, ярым ятып, кыймшанып, әйләнгәләп бара. Литвин үз дачасына барырга өнди, мин: «Кая алай еракка? Ике сәгатьтән караңгы төшә, якты күздә кайтып элгәшергә иде!» дип, кирегә сукалыйм. Чуар-чобар киемнәргә төренеп каршылаган урман эчләп беравык бардык, машинага юл еракмыни, «Аккош күле»нә якынлаштык. «Аккош күле»ндә туктыйбыз!» диде Фәрваз. Без риза, жил ягыннан гына торабыз. Фәрвазга каршы сынар уебыз да юк. Унга борылдык, язучылар дачасына таба юл алдык. Бу сукмак-юлларда байтактан булганым юк иде, онытылган, ятсынып як-ягыма каранып барам. Урман эчләп әллә нинди коттеджлар, йорт-куралар салып бетергәннәр. Юан-юан аркандай коерыкларын селкеп олы, авыр авазлы этләр шигәеп озатып кала. Барып життек. Әдипләрнең тарихи, мәшһүр мәйданын унда калдырып алгарак үттек, канатлары салынган капка белән жирне тырнап ачып дачаның эченә үк барып кердек. Жирдә башлары көйгән, муртайган өч-дүрт бүрәнә ауный, уртада агач төбе. Яндагы йортка ишарәләп Фәрваз: «Монда Равил Фәйзуллин тора», диде дә, «теге башында Мансур Вәлиев», дип өстәде. Литвин букчасыннан коньяк чыгарды, мин вак-төяк ризык хәстәрләгән идем, коньяктан соң кабарга су да ачтык. Фәрваз эчәрме-юкмы дип караган идем, кулы белән ишарәләп, «Салыгыз мина да!» дигәч, каршы килмәдек. Коньяктан соң тел ачыла, Литвин килештереп кенә бер-ике анекдот сөйләп алды. Гадәтенчә, яһүдләр турында яһүдләр чыгарганнарын сөйли. «Урам якка такта калаклаганнар һәм кайчы сурәте ясаганнар. Үтеп баручы ашыгып кына керә дә: «Чәчтарашмы монда?» дип сораган. «Юк,—дигән хужа карт яһүд,—монда сөннәткә утырту!» «Нигә алайса кайчы сурәте ясап эллегез соң?» Хужаның кашы өскә сикергән: «Ә нинди сурәт ясарга боерасыз?» Бу анекдотны Литвин ярата, очрашып салган саен тәмләп, матур итеп сөйли. Ихтыярсыз көләсең. Мин Литвинга, Фәрваз мина ияреп көлде... Тәки коньякның башына життек, тәвәккәлләп Фәрваз да капкалады. Ризык чемченеп, шара-бара сөйләшеп тордык та, баягы капканы йокысыннан уятып, шыгырдатып ачып урман якка чыктык. Тәмле-татлы исләр таратып яткан урман юлы белән атлыйбыз, аякларыбыз, балачактагы кебек рәхәтлеккә чумып, кызгылт-сары яфракларны көрәп юл ачалар. Кинәт Фәрваз сүзсез генә

алга ыргылды, бер җир буе барды, тукталды, иелеп җирдән нидер алды. Тын гына, каккан казыктай шунда хәтсез вакыт басып торды. Литвин белән без бер-беребезгә караштык һәм икебезгә дә бер уй, шомлы һәм аяусыз уй инде: «Урман белән саубуллаша бит бу егет!» Борылып килгәч, без аны сүзсез каршыладык, ул да аны-моны әйтмәде. Машина янына кайттык, төялдек һәм кайтыр юлга чыктык. Күл янына житкәч, Фәрваз машинаны уң кул якка борды. «Волга»быз күлгә терәлеп диярлек туктады. Машинадан төшкәч Фәрваз баягы житезлек белән яр буйлап теге башка китте, тукталды, озак итеп күлнең жансыз, шыксыз суына текәлеп-текәлеп карап торды, башы очына шәрә ботакларын сузган таныш агачларга каранды. Ул монда яшәгән ләбаса! Без баягы шомлы фикерне кабатладык: «Күл белән саубуллашуы егетнең!» дидек. Бу юлы ул иплэп, адымнарын санап, як-ягына жете каранып килде-килде дә шоферга багажнигын ачарга кушты. Шофер аракы чыгарды, ике чәркәгә яртышардан койды, Фәрваз үзе эчмәде, безне нык итеп таләпчән тавыш белән кыстады. Нишлисең, тотарга туры килде. Ярлар котсыз, чүп-чар баскан, суы кимегән жансыз күл ягасында без озак тормадык, күз бәйләнә башлаган иде, ямьсез адәмнәр төялгән бер-ике машина да килеп туктады, эчтән кызлар чыркылдашканы да ишетелде. Шофер алар ягына карап, яратмыйча гына: «Ишәләр... ярларны!» дип куйды.

Ирләр үлемнәрен сизәме әллә? Мәрхүм Газиз Мөхәммәтшин, үләре алдыннан «Хатынны аерам!» дип йөреп мәж килде. Икенче бер Газиз мәрхүм Кашапов та «Аерылабыз!» дип дөньяга өн салды. Фәрваз исә сөйләп кенә калмады, аерылды да... Шул житәме аның башына?..

Фәрваз белән «Аккош күле» урманына сәяхәткә чыгуыбыз мина кире вә кискен тәэсир ясады... Шунамы, яна әсәргә ныклап тотынырдан элек, шушы хатирәләрне язып калдырырга булдым. Гомере озын булсын дустымның... Тәгәрәп үсеп килгән ике кызы бар! Аларны әзме-күпме аякка бастырасы, кеше итәсе бар лэбаса! Асия Минһажева күкләр телендә сөйләшә белсә дә жир-дөнья мәшәкатьләренә ул кадәрле үк яраклашкан жан түгел дип беләм! Фәрвазыннан башка ул ничек яшәр?.. Татар әдәбияты һәм без ничек көн күрербез?..

*20 октябрь 1993 ел, Переделкино*

Ниһаять, тормышның табигый үсеш кануннарын гарипләндереп бозган, адәм асылын үз файдасына үзгәртергә маташкан явыз Ленинның иң актыккы утенече тормышка ашачак: жәсәден әнкәсе янындагы тын урынга күчерәчәкләр. Беләм, әле монын белән генә Жир шары Ленин афәтеннән котыла алмас, әле ул һәм аның тәгълиматы төртеп-күмеп калдырган миналар тоташ чылбыр булып бер өзлексез шартлап ярылып торачак. Ә-ә-ле! Казанда, үз тирә-ягымдагыларны санасам да бөтенесе ленинизм чумасы белән чирләгән жаннар. Ленинизм—«возвратный тифның» иң авыр, жаннан һич китмәс формасы. Кайчан исә бер ил башына яна диктатор калкып чыга икән, ул, әлбәттә, Ленин-Сталин алымнарына борылып кайтачак. Әле жир чак-чак күтәреп торган бу авыр йөк вак-төяк кисәкләргә таркалып уалганчы йөз, йөз илле ел үтәчәк. Рәсәйдә каршылыклар бер чакта да бетәчәк түгел, каршылыклар яшәү кырын ундырышлы итеп ашлап торачак һәм нәкъ әнә шул кырда диктаторлар шытып чыгачак та инде. Бөекләрнең мәетләренә дә тынгылык юк! Христофор Колумбның гәүдәсен кайлардан кайларга күчереп йөртмәгәннәр. Сталин бу юлы да Лениннан калмый. Аны кая куярлар икән? Гөржиләр алып китәрме? Шулай булыр, мөгаен. Югыйсә, Мәскәү зиратларында аңа тынлыктан өлеш чыкмас. Ельцинның көр тавышы янгырый башлады. Кая кадәр барып житәр. Әлегә күнелем белән мин ана ышанам. Кылган гамәлләрен аклыйм. Бөтен тирә-ягым, танышларым,

очраклы юлдашларым ана ләгънәт укый. «Рәсәй Американың кисәкчәсенә әйләнде, хәзер илдә бара торган барлык үзгәрешләрнең житәкчесе Америка!» дип кабатлыйлар. «Ельцин—диктатор!» дип куркыталар. Монарчы йомшаграк булды шул диктатор дигәнебез! Әгәр ул көчен сиздерсә, дилбегәне кулыннан ычкындырмаса, мәми авыз булмыйча коммунистлар өеренең котырынуына чик куйса, илдәге буталыш бу дәрәҗәгә килеп житә алмас иде. Коммунистлар Икенче Бөек Октябрь фетнәсе аша властька килеп житә яздылар бит, ходаем... Телевизор тынды, радио сүнде, Мәскәүдә мәхшәр!

Тагынниләр күрсәтәсең бар икән, и дөнья!

Төнәген кичке чәйдән соң йортыбызның ишегалды сукмакларына йөрергә чыктым. Ике ел инде үз тирәбездә генә уралам, ихатадан ары чыгарга аяк тартмый. Этләрдән куркам—усалландылар, машиналардан шүрлим—күбәйделәр, адәмнәрдән сагаям—күпчелеге ятлар—һичберсен аңлап, кабул итеп булмый. Чит ил машиналары шау-шусыз шым гына шуып киләләр дә кычкырып, саңгырау колакны да яралар.

Кичә радио-телевизорлар: «Фәлән вакыттан капитализмда яши башлыйбыз», дип тантаналы тавышлар белән илгә яна игълан тараттылар. Шуны күздә тотып социализмда келпеп утырган багана башы лампочкаларын чепи күзле, мунча оялдыларында гына яраган утларны яндырдылар. Кара, тар сукмаклар куе караңгылыкта эрегәннәр. Сагаеп кына атлыйм югыйсә, алай да абындым. Ничек чәчрәп барып төшмәдем дә, ничек күзлегемне ватмадым! Булыр иде бер кәмит! Иелеп карыйм, капшап табам: шактый юан каен шартлап сынып сукмакка аркылы төшеп яткан. Мин узасы юлга женнәр чыгарганмы? Җил, җил, җил... Урманның кара шавы колакка сыймый, выжлый, куркыта... Әз генә тынган арада күктән самолетлар шавы коела, сизәм—самолетлар да канатларына төяп тавыш ташыйлар.

Илне аркылы-торкылы бүлгәли торган, бүленгән кисәкләрне берберенә каршы котырта торган яман аяклы хәбәрләр колакны киле сабы белән төя, күкрәк читлегенә күгәргән тимердән кыршаулар суга. Җил, жилкәй житез аяк! Нигә андый уйларымны алып китеп башымны жиңеләйтмисең? Кай тарафлардан иссәң дә син мина дәһшәтле шикшөбһәләр, тышауланган уй-гамь иядтеп киләсең! Тыңлачы, күрче, таныш агачлар арасыннан кысыла-кысыла чыккан кара жилнең бусы нәкъ Казан тирәсеннән исеп килде бугай?! Мине уртада калдырып бөтерчектәй бөтерде, зыр-зыр әйләндерде. Аллакайгынам, очыртып алып та китте! Очам, очам! Себеркегә атланган убырлы карчыкмыни! Карыйм, түбәндә татарның бишеге Казан! Әнә, татарның сәяхәтен йомгаклый торган утрау—Яңа Бистә зираты. Шәһәрнең кара шәмнәрен учына җыйган Бишбалта. Төзелеп бетмәскә нигез салынган ваемсызлык һәйкәлләре—кунакханәләр. Зәһәр исе китмәскә сеңгән мәшһүр ертык Болак. Җир белән Күкне ялгап масайган тәкәббер жил мин чалны тузан өермәседәй бөтереп болгый...

Сабый чакта өлкәннәр, әби-бабайлар безне ни-нәрсәгә өйрәткән? Тормыш сабакларын ни дип авызландырган? Беренче нәүбәттә тыйнаклыкбасынкылык сеңдергәннәр. Көн туса: «Иелгән башны кылыч кисми!» дип тәкрарлаганнар. Янәсе, безләргә юашлык кына килешә, татарны шул гына бизи, дигәннәр. Бер без генә, сугыш алды балалары гына түгел, гасыр буена шул кагыйдә татарга ябышып яткан. Без, мәсәлән, идарә итү фәне барлыгын, арадан сайлап алып зирәкләрне шул мөһим фәнгә өйрәтергә, шул рәвешчә дөнья күтәргә кирәклеген уйлап та карамадык. Икътисад кануннарын бик яшьтән танып белергә кирәк, дип безгә берәү дә әйтмәде. Беркатлылык—татар гадәте, бул юаш, хәйләсез. Бүген син—ишәк, иртәгә—йөк аты. Тормыш безгә нык сеңдергән төп фән шул иде. Җитәкчеләр, югарылар кайдадыр чит кырларда үсә дә... аларны безнең түргә кылыч тактырып китереп утырталар. Күргәнебез шул, инанганыбыз да шул булды.

Тормыш шартлары, нужа бабай, хәерчелек тә шушы, кеше жанын

какшата торган кануннарны татарга өстәп, сендереп килгәннәр. Бер мисал: мин урта мәктәпне сугыш беткән елны, кырык биштә тәмамладым. Унҗиде яшьлек егет! Характерның бөреләнеп чәчкә аткан чагы! Унынчыга, ата-бабамнар яшәгән төбәккә—Сарманга ике ел көтү көткәннән соң килдем. Төннәр айсыз, көннәр дөм карангы булса да яшьлек үзенекен ала, Минзәлә елгасы ягасында атауда кичке уеннар булгалый. Мин дә атауга төшәм, читтән-читтән гөр килеп биеп-җырлап йөргән кызлар көтүенә карап торам. Уенга кермим, биюгә катнашырга базмыйм. Аягында сүсәргән мыеклы чабата, ... сидрәп беткән тезе ямаулы чалбар, өстә агарып-юкарып беткән иске солдат гимнастеркасы... Ничекләр кыеп уен уртасына—янып торган кыз-кыркын арасына керәсең? Кызлар бөтен барлыгымны, шигъри күңелемне йотып алсалар да мин, серле кыяфәт алып, читтәрәк булырга тырышам: аккан су, ай урагы, яр буе бизәкләре-таллар белән серләшкән булам. Серләшәм дә! Мескенлек гасырлардан бик авырлык белән, озак еллар дәвамында китә торган сыйфат ул. Бу сыйфат татарның үзәгенә үткән, бәгыренә төшкән. Син шул әшәке йогынтыдан арынып, бер арата гына өскәрәк менәм дисәң... тормыш барыбер изүеннән эләктереп ала. Әтиеңне кимсетәләр, мәсхәрәлиләр... Анаң бичара кара язмыш тәгәрмәчләре астында кала. Авылдашларыңның, кардәш-ыруларының зар-моңнары туктаусыз сиңа агылып тора. Кай якка карама—хәерчелек, юклык, бөлгенлек. Күңелеңне өзмәс авыр моң баса!..

Һәммәсе алдында да син көчсез, син—чарасыз. Җан тартыша, күңел үсми.

Шулай яшәлде, мин бик озакларга кадәр әнә шул җәрәхәтләрдән арына алмадым. Әле хәзер дә начальниклар ишеген кыяр-кыймас кына кагам. Йомышым ни тәҗел булганда да алар катына барып баш иярга базмыйм. Улларымда да шул сыйфатлар бар! Бигрәк тә олы улым Искәндәр басынкы. Нәбәрә-оныкларым да шулай булмас дип кем әйтә ала?!

Каһәр суккыры, балаларга бүтәнчә тәрбия биреп тә булмый бит! Тәрбия—ата-ана теләгенә буйсынып кына нәселдән-нәселгә күчә торган гамәли сыйфат түгел, нишлисең: башны ташка орасыңмыни!.. Хәлбуки, балалар, татар сабыйлары, идарә итү фәне белән бик иртә кызыксына башларга, нидер белергә, туктаусыз өйрәнергә кирәклеген аңларга бурычлылар. Урыс «Простота—хуже воровства!» дип тиккә генә үз балаларына тукып киләме?.. Оялчанлыкны, басынкылыкны, буйсынуны безнең канга буыннан-буынга сеңдергәннәр. Берзаман тарих әзрәк кенә үзгәреп, татарның да күзе-колагы, теле вә теше барлыгы билгеле булгач, милләт хадимнәренә ихтыяҗ туды. Буш урыннарга беренче чиратта әрсезләр, ачарбаклар, тәмле тамаклар менеп утырды. Коммунистик мәктәптә сабак алган, аякланган кадрлар иде болар. Бүтәнчә тәрбия мәктәпләре булмагач, шул явызлык мәктәбе шәкертләре Татарстан белән идарә итә башладылар. Башта җыйнаулашып Мәскәүнең күнегелгән җырын җырладык, әле безнең тавышларны күмәк җырда гына ишетергә мөмкин иде. Тора-бара тормыш күмәклек арасыннан солистларны таләп итте. Табигать үзенекен итә, милләт түренә омтылган кичәге коммунистлар да сагаеп кына, як-якларына каранып булса да үз тавышлары яралганын сиздерәләр. Һәм шушы ике-өч ел дәвамында ил-көн каршысында абруй да казанып өлгерделәр. Мин Минтимер Шәймиевне күз алдында тотам. Аның Мәскәү кубызына биергә бик үк теләмәгәнен шуннан әйтәм, Мәскәүнең карагруһ шовинистлары шактый нык талкый башлады егетне! Үз этләребез дә күздән ычкындырмадылар, нәни генә чатагы сизелсә дә арттан да алдан да типкәләделәр. Тәүге хөрмәтне Минтимер сабырлыгы белән казанды. Төрле яктан ябырылган әнчекләргә сәлам бирмәде, Мәскәү белән арадашлыкны уңай дәрәҗәдә саклады, федераль шартнамәгә имзасын салмады, иплән кенә җөмһүриятнең хокукларын, бәйсезлеген саклады. ГКЧП көннәрендә ул беренче тапкыр абынды. Үзе соныннан ни уйлагандыр, яраннары белән ниләр сөйләшеп, нинди нәтиҗәгә килгәннәрдер, белмим, колагыма чалынмады...

1992 нче елда Татарстан кырларыннан алынган көтелмәгән уңыш Шәймиевкә нур өстәде. ГКЧП онытылды, яисә онытылып торды, татарларның рәсми лидерларына кыюлык килде. Идарә итү сабаклары эзсез үтмәде: авылда туып, шунда үскән, авылча тәрбияләнгән Шәймиев сүзгә остарды, аңа олысымаклык, ышанычлы егетлек килде! Үз-үзен тотышына, кыяфәтенә, тавышына, без монарчы татарда күрмәгән олпатлык килде. Күңелемнән мин аны «Ил агасы булып житешә бит бу малай!» дип атарга әзер идем. Ныклы тәрбия дип мин нәрсәне атыйм? Сина яшьтән сеңгән иман берниндп шартларда да какшарга, алмашынырга тиеш түгел! Син һәрчакта да үзең булып кала бел! Юк шул, юк! Безнең каннарга андый алмашынмас тәрбия ныклыгы сеңмәгән, көтелмәгән тормыш алмашларында без аптырап, хәтта тиз-тиз югалып калабыз, тәртәләрне бик ашыгып артка борабыз. Алда упкын диләр, моны бел, мәгәр иманың ныклыгы өчен барыр юлыңнан тайпылма!..

Менә тагын октябрьдә коммунистларның чираттагы фетнәсе күтәрелде. Рәсәй язмышы кыл өстендә калды. Татарстан—илләр арасында Рәсәй белән иң тыгыз бәйләнергә мәжбүр булган ил. Татарстан өчен Казанда кемнең, кайсы төркем вәкиленең хужа булып утыруына караганда Мәскәүдән нинди жилләр исүе мөһимрәк! Тормыш шундый кысан шартлар тудырып ныгыткан ки, Мәскәүне кемнәр үз кулында тотуы безнең киләчәкне дә билгели. Әгәр 3-4 октябрь көннәрендә Руцкой-Хасбулатов-Макашов ише коммунистлар жингән булса, Татарстанның үзбилгеләнү хокукы, милли үсеш тирәсендәге хыяллар, жөмһүриятнең бәйсезлеге иртәнге томан сыман тарала да бетә иде! Кайсы якка борылып баксаң да Татарстан язмышы Мәскәүдә нинди хөкүмәт утыруга тыгыз бәйләнгән. Хуш, Мәскәү фетнәсе!

*25 октябрь, иртәнчәк.*

Кичә кышның чыны булды, көне буе кар яуды. Бүген эшкә кайтырга вакыт житкәндер. Байтак симерттем ялкауны! Казанда Литвин ыжгырып көтеп торадыр! Менә эшлекле кеше! Совет заманасында туып, совет чорында яшәсә дә еврейлыгы һич китмәгән Литвинның! Мәсьәлә кайсы чорда яшәвеңдә генә түгел, кемнең тамырларында нинди геннар төягән кан агуында! Татарның генофонды бозылып беткән шул. Менә нәрсәдә хикмәт! Мина да, мин бичарага да, Бикчура ханнан ук килә торган нәсел жепләренә терәк булган геннарны уятырга бик вакыт! (Әгәр сонармаган булсам!)

Менә өч көн—нык кына, нәтижәле язам. Повесть героеның үзенчәлекләре ачыла бара, характеры табыла. Әле беркемнең дә исеме ачыкланмаган. Жәлладның татар булуы эчне тырный тырнавын, ул чынбарлыктан да тәмам качып, котылып булмас шул. Исемнәр әдәби әсәрдәге кешенең асылына ярашып, берегеп торырга тиеш. Әсәрнең герое исеме аның хәрәкәтенә, ритмына ярашмаса, атлаган саен телне көрмәкләндерә. Ә палачка нинди исем кушарга?..

Ямиль «Наш современник» журналының 2, 3 саннарын калдырып киткән иде. Үткән төндә Борис Можаевның «Изгой» исемле романын укыдым. Журналның тенденциясе куркыныч, ул урыс күңелендә ватанпәрвәрлек уятырга тырыша. Урыс үз тарихын, үткәнен вә бүгенгесен, сугышларда жиңүләрен, батыр солдатларын телгә кертә икән, шунда ук аның теленә «татар» сүзе эленә. Нинди сүзләр белән генә каһәрләми журнал татарны! Шигырьләрендә исемнәре атап әйтелмәсә дә туксан процент татарлар каһәрләнә. Ай-һай, журнал үгетләре белән генә, урысның кара төркем булып тупланган әдипләре сүзе белән генә иманын югалткан урыс милләте яңарыш чорына барып керә алырмы?.. Мин Югары курсларда укыганда, семинарларның берсендә: «Һәр милләтнең үсеш юлы бар, туа

ул, үсә, тамырлана, чәчәк ата һәм һәлак була!» «XIX гасырда үзенең иң биек ноктасына менгән урыс милләте бу гасырда һәлак булачак», дип чыгыш ясаган идем. Партбюрога дәшеп алып сабагымны укытмакчылар иде, партиясез икәнемне белгәч куып чыгардылар. Можаев чын әдип, алган темасын белеп, тирәнтен актарынып, югары сәхнәгә менгереп яза...

Эрнст Сафонов Югославиядән бер повесть язган. И яратмый инде мөселманнарны! Мөселман кыргый да, вәхши дә, сасы исле шакшы да. Татар-башкорт арасында яшьли яшәгән бу кешечек элгәре татарлар, мөселманнар хакында яхшы нияттән хөкем чыгара торган иде, хәзер үзгәргән. Чыны кайчан иде: элекме, хәзерме? Адәмнәр ашыгып-ашыгып битлекләрен алыштыра торган чак!

Һава таза, әле салкын патша тәхетенә менеп житә алмады. Алама тунын сөйрәп тәхет аягы тирәсендә мыштырдап йөри. Кичә алдан һич уйламыйча «Кар ява, кар!» исемле хикәя яза башладым. Бәхетсез, бичара, гарип Петрович белән очрашып сөйләшү миңа нык тәэсир итте. Менә ул арып, хәлдән таеп, иске себеркесен кочып йортыбыз баганасына сөялеп тора. Болдырга чыгып баскан тук, симез, иркә Мәскәү маржалары этләренең танавын үбәләр, мәчеләрне сыйпый-сыйпый ашханәдән алып чыккан кәтлитләр белән сыйлыйлар. Ә сиксән яшьлек бичараның күз яшьләрен бирәү дә күрми. Үзем дә моңарчы күрмәгәнмен, белмәгәнмен. Картлыкта адәмнең күзе бәхетсезлекләрне жетерәк, ачыграк күрә башлый.

Милли аң үсеше хак сүзләр, тарихи дөреслек белән беркетелмәгән совет әдәбиятына иртәгә мөнәсәбәт ничек булыр?.. Әле яшәү мәйданыннан китеп бетмәгән, көймәнең коерыгын кулларыннан ычкындырырга уйлап та карамаган, бүген битлекләрен оста гына алыштырып яшәп килгән татар большевиклары, үткән чорның зарарлы, ярлы әдәбиятыннан да нәкъ үзләренә файдалы, киләчәкләрен тәэмин итә торган гыйбрәтләр табып алып, шуны чәйнәмәсләрме?.. Иман алыштыру, кабатлап әйтәм, берчакта да ансат булмаган, әмма яңа заманга безнең кебек жимерелеп, ватылып килеп кергән халык тарихта булдымы икән?.. Иман алыштыруны жинелгә санап, бүгеннән: «Халкыбыз уянды, ул бүтән!» дип сөрән салучылар нык хаталаналар. Һәм ул хаталарның кая илтеп житкерәсен уйлап карау юк. Кинәт уяту өчен чамасыз олы көч, жир тетрәтерлек вакыйгалар кирәк. Булырмы алда андый вакыйгалар, табылырмы андый биниһая үлчәүсез көч?..

Рәсәй яңа конституция кабул итәргә әзерләнә, аның төрле вариантлары жаваплы кешеләрнең миен черетә. Әлегәчә мәгълүм булган проектларда «самостоятельная республика Татарстан» дигән мәгънә юк. Ярый ла Президентыбыз Шәймиев ипле генә басып торып, егылмыйча Татарстанны яклый алса! Ярый ла Ельцин жәнапләре безне анларга омтылып караса; Чаллыярдагы инде коралланган, инде тешләрен кайрап үткерләгән башсыз житәкчеләр яшьләребезне котыртып утка алып кермәсә! Татарстан мисалында Рәсәй империясенең тагын бер кат, инде бик озакка таралып китүе бар! Свердловск «Урал республикасы» дип үзен игълан итте. Тарихта булган ич, кенәзлекләр булган, тагын шул чор әйләнеп кайтмасмы?.. Чөнки шушы кадәр зур, иләмсез, котсыз дәүләт үз санын үзе күтәреп тора алмый шикелле.

Бездә ул кадәр сизелми иде, Мәскәү чынлап торып, күмәк рәвештә капитализмга кереп бара икән! Төрле катлауларның, бер-берсенә һич охшамаган төркемнәрнең юлы нык аерыла, моны күрү өчен әлләни вакыт та кирәкми. Берәүләр—хап та хоп халык авызыннан миллионнарны тартып ала. Капитализмга, аның жылы түренә үтә алганнар кыйммәтле чит ил машиналарында жилдерәләр.

Машиналарның тизлеге арткан, әкрен кыймылдасаң, хәзер изеп, таптап китәчәкләр. Иң кызыгы шунда ки, тиз барып, куелган кагыйдәләрне бозсаң да куркыныч янамый. ГАИ егетләре дә долларның, марканың, фунтларның бәясен нык үзләштергәннәр. Тәртип бозасың икән—долларга

атланып сират күперен теләгән кадәрле үтеп чыгасын... Капитализмга беренчеләрдән булып коммунистлар партиясенен өлгер вәкилләре барып керде. Алар әзерлекле, идарә итү, урлау тәҗрибәләре житәрлек, ин мөһиме—алар бердәм, хужалыкнын кайсы тармагына борылсалар да элеккеге әшнәләрен табалар... Илдәге мал—элеккеге партия тарафдарлары кулында...

Аларга кызыгып карап, көнләшеп, жае килгәндә бу күчеш чоры каракларынын жанын кыюдан да чирканмаган иkенче төркем бүтән сукмактан уза. Мәскәүлеләрнең чиреге, килгән кунакларнын яртысы бәләкәй арбаларга күчкән. Арбалар, арбалар, арбалар... Безнен күз «уфалла» арбаларына авыл юлларында күнеккән. Гадәттә, ул чак арбаларында утын, печән, бер-ике капчык бәрәнге була иде. Ә капитализмнын бүгенге көн шома сукмакларындагы арбаларда ниләр барын, жир йөзендә кылынган гөнаһларны санап барырга көчләре житкән фәрештәләр дә санап, хисаплап бетерә алмас иде. Алыпсатарлар, маклерлар, мал юллаучылар, кыстаучылар, алдаучылар, теләсә кемне сугып егып өскә калкырга тырышкан бөкеләр, ирләр, хатыннар, беләтләр, угрылар, тәнсатарлар—һәммәсе дә бар бу бәләкәй арбалар салган яна заманнын тар сукмакларында. Мал арбаларга гына сыймаган, шытып килгән капитализмнын куллары буш түгел, унына-сулына дәү-дәү буаз букчалар эленгән, ин өсләре дә буш түгел, биленә дә уннарча капчык-янчыклар асылган, бау белән биленә тагылган арбасын сөйрәп чаба Рәсәй балалары. Хәзер шәһәрләрдә йөкле хатыннар бөтенләй күренми диярлек. Хатыннар шикле, өйрәнелмәгән капитализм дөньясына яна гражданнарны катнаштырып жибәрергә ашыкмыйлар, котәләр...

Хәзер халкыбыз ике төркемгә бүленәчәк: байлар вә ярлылар катлавы барлыкка киләчәк. Киләчәктә бу аерма тагын да тирәнәячәк һәм аерымлык мәнгелек канунга әвереләчәк. Байлар тагын да баеп ярлылардан күпкә өскә менәчәк. Бу жәмгыятьнен какшамас үсеш законы. Байлар татар булып калырмы, аллә алар үзләренә файдалы бүтән юл сайларлармы? Кайсы төркемгә хажәт булачак татар әдәбияты? Кем укыр татар телендә?.. Житмеш еллык сыналган әдәбиятыбыз хәзинәләрен тоташтан яндырырга, көл итәргә туры килерме?.. Большевизм чорында өстен саналган темалардан берзаман мыскыллау, көлү башланачак...

*13 декабрь 1993 ел, иртәнчәк.*

Менә сайлауларга катнашмадык...
Бүген мин татарлар авызыннан сүз көтәм, йомгак сүзләренә мохтаж минем күнелем. «Жиндекме?», «Жинелдекме?» Ни әйтерләр безнең хөкүмәт әһелләре? Оттыкмы? Оттырдыкмы?

Бүгеннән Рәсәй язмышында олы борылыш ясала. Кыяр-кыймас көйрәп яткан яна рух—шовинизм кичәге бәрәкәтле сайлаулардан сон үзенең ал битлеген салып ыргытачак бит! Жириновский ышереп тә тормады, сайлауларга ай кала элек үк: «Әле мин һәммәсен дә ачып бетермим, менә сайлаулар үтсен, без үзебез теләгәннәрнең һәрбарчасын ачып салырбыз!» дип янамадымыни?!

«Сайлаулардан соң Рәсәй күкрәгенә таралган татарларнын язмыш шартлары» хакында миннән башка берәр кеше әрнеп уйлыймы бүген?! Нигә мин ашыгыч эшемне ташлап кәгазь-машинкам белән генә серләшәм? Эндәшер кешем калмадымы?

Эшемне ташлап, дидем дә... авырткан кулымны сызлаган маңгаема терәп уйга баттым. Эшләрем муеннан, эшләрем тезелеп тора. Алар кулында чыбыркы, каулыйлар алар мине, тышаулыйлар да яралар. Зәнкиевнын 20 табаклы романын беренче майга өлгертергә кирәк. Нур Гайсиннын 16 табаклы жыентыгыннан нидер рәтләргә, сипләргә вакыт. Литвин белән

язарга тотынган повесть бер атлый да, ике адым артка чигә. Мин кызыгып, янып уйлыйм: бу эшләр өстемә таш булып яумаса, мин бүген үземне ничегрәк хис итәр идем икән?! Җинел яшәр идемме?.. Белмим, сизәм, акча өчен бөтенләй юк эшләр белән маташам. Беләм, язганнарым беркемгә дә кирәк түгел. Безнең язучылар «халкым өчен», «халкыма!» дигән купшы шома сүзне үлеп яраталар. Ә мин?! Бармы минем халкым?! Мохтаҗмы ул минем сүземә?! Ай-һай! Гомумән, бармы ул татар халкы?! «Юк ул!» дияргә базмыйм... Әнә ич, сайлауларны кире кагарга дигәндә шактый нык бердәмлек күрсәттек. Ләкин мин бу адымнын (кабатлап әйтәм!) җинүме, түгелме икәнен өзеп кенә әйтә алмыйм. Бер нәрсәне беләм: без шактый катлаулы, дәһшәтле юлдан бара башлыйбыз. Бүген милләтнең сынала торган көне!..

Уйлар сынык-санык... Уйлар ышкы йомычкасы сыман вак. Уйларыма үзем хуҗа түгел. Офыкта Жириновский... Җинүче—ул.

*25 декабрь 1993 ел, Казан.*

Таннан торып Нәкыя абыстай белән ярминкәгә чыгып киттек. Муллык, муллык! Шөкер! Ит-ашлар эскерт булып өелгән, бәрәнге төягән дию пәриедәй машиналар мәйданга тыгызланып тулган. Яшелчәләргә карап күзләр камаша. Буа, Кукмара районнары килгән. Казан халкы акчаны санап тормый, ризыкларны батманы белән алалар. Мин бер читтә, кап-кара куштан машина чыгарган әче төтенне иснәп Нәкыянең бәрәнге алып чыгуын көтәм. Тышы вә эче кара машинага кәттә-кәттә киенгән ике кеше кереп утырдылар. М. Гафуриның алтын базларын һәм аның хуҗаларын тасвирлаган күренеш исемә төште. Болар Рәмиевләр янында!.. Нинди ерак безнең аралар, арада упкын, болар—татар булсалар да бер чакта да мине анлар түгелләр. Якын араларда мина «халык язучысы» дигән исем ябыштырырга ниятлиләр, диләр. Имеш, указга култамга да салынган инде. Ә мин, алтмыш алты яшен тутырып килгән аксакал, күрә карау күзләрем белән урамнан карлы сукмак эзләп, чана тартып ит-бәрәнге, бавыр алып кайтам... Район хуҗаларынын нинди иркенлектә яшәп, байлык диңгезләрендә коенуларын уйлыйм...

Алдарак язасы сүзләргә кайтыйм әле! Бу арада күнел гел сынык, гел төшенке булды. «Ел азагын хәтереннән чыгарма!» дипме, 24 ендә, көндезге 11 дә кан басымым күтәрелде. Сул яктан мангай чатнап-чатнап китә. Элегрәк басым уйнаганда мин сәбәбен эзләп таба торган идем, бу юлы һич очына чыга алмыйм, очына чыга алмаганда күнелгә курку катыш каушау керә... Кан басымым 180/110. Мәктәптән Нәкыяне чакырып кайтардым. Ул кайткач тынычлана төштем. Идарә утырышы билгеләнгән иде, бармадым, бара алмадым. Соңыннан бармавыма сөендем: күп кешеле, ыгы-зыгылы утырыш булган!.. Сонра, гадәттәгечә, төрле почмакларга чәчелгәннәр дә башлары күпереп тубал булганчы салганнар...

Сайлаулар узды, демократ дип ат алган төркем: «Ни булды? Сайлауларда ник җинелдек? Нихәл итеп фашист Жириновский алга чыкты?» дип үзара мыштым гына талашалар, гәҗит-журналларны, телевидениене сүгәләр. «Халык Жириновскийны яклап түгел, хөкүмәт әгъзаларын кабул итмичә тавыш бирде. Бу бик очраклы хәл!» дип, тагын бер тапкыр халык күзенә ком сибеп маташалар. Сайлау нәтиҗәләренен сәбәпләрен ачыклау өчен комиссияләр төзегән булып кыланалар. Беркем дә: «Әйе, урыс халкының күнелендәген, ниһаять, Жириновский азагынача ачып салды. Бу ачыш кирәк иде. Бу мәсьәлә монарчы битараф урысларны да уятачак һәм үзәккә тартачак!» дип әйтми. Ә Жириновский, үзе сайлаган вә үзен җинүгә китергән куркыныч юлыннан бер карыш та тайпылмыйча Австриядә «частный кунакта» ята, шәраб эчә, мунча керә (телевидениедән анысын да күрсәттеләр!) һәм дөньяны атом бомбалары белән коендырырга,

ул гына житмәсә әле эшләнеп бетеп кенә килүче яна коралны да кулланырга вәгъдә биреп, бөтен кешелеккә кыю рәвештә яный, өркетә. «Әгәр буйсынмасагыз... әгәр мин билгеләгән юлдан бармасагыз... бер милләткә дә, бер илгә дә рәхим-шәфкать юк!» дип секунд саен кабатлый...

Безнен сайлауларда катнашмавыбыз жинү дип игълан ителде.

Жинү булуы да бик ихтимал. Татарстан урыслары да бу юлы татарлар белән бер сафка баскандай иттеләр. Яналыкмы бу, әллә уен гынамы? Урысның кайсы тармагы безгә тартылды? Авылллармы? Алай дисән, авылда урыс калды микән? Нигә авылда чиләнсен ул, урыс Рәсәй кинлеге калаларына тартылды һәм барган бер жирендә жирле халыкны кол итеп эш башына менеп утырды. Хәзер менә Урта Азиядән, Кавказдан, бүтән төбәкләрдән күпме урыс куылып кайта. Бу олы сүзне истә тотыйк: куылып! Монарчы урыс куып йөртә иде, теләсә иле-иле белән халыкларны өерләп куа иде, бүген урысны куалар. Һәм, нигездә, яшәгән урыннарында баш булып торган урыс куылып кайта. Явызлана белгән, изәргә оста, тәмлетамак урыс кайта. Алар хупламыймы Жириновскийны! Татар-башкортны Монголиягә куам ди икән, бары тик үз кәефенә яраштырып кына кумый ич безләрне ул, әнә шул жайлашкан төбәкләреннән кузгатылган дүнгәләкләр өчен дә тырыша ләбаса! Гасырлар дәвамында куып күнеккән, канына өстенлек, әрсезлек сенгән урыс-улак берәр заман шушы куылышларга риза булып тора алырмы?.. Ай-һай!..

Яши-яши гыйбрәтләр арта... Әле кайчан гына Ельцин ягына авышканын сиздермәгән, Кырымда октябрь фетнәсе көннәрендә арка жылытып ятканы өчен Президентыбызга әллә нинди гаепләр тагарга әзер идем... бу хакта язып-теркәп китмәдемме икән, көндәлек бик өзек-өзек, торымнан-торымга гына языла, язганнар истә калмый, буталчык дөньяда зиһеннең бөтенлеген саклап тотып булмый. Хәзер Шәймиевнең зирәклегенә сокланам. Парламент явызлары Хасбулатовларны тереп аттырып, кичәге үз адәмнәрен үтертеп, кан коеп, Ельцин дөньяга үзенең күләгәсен ачып күрсәтте. Шактый явыз, кансыз икән ләбаса ул!.. Аның шушы атыш адымнарын хуплап үзем дә үземә бүтән төрлерәк итеп карадым. Хасбулатовның кемлеген әллә кайчан белә идек ләбаса!.. Аның властька үрләве хакында бер генә сөйләшмәдек, хатларымда ошбу фикерем чагылыш тапкандыр! Шул чакларда Хасбулатовны, аның иярченнәрен авызлыклау, тәхеттән кагып төшерү берни тормый иде. Ике ел тынып-куркып яшәде дә корал телгә килгәч кенә Ельцин дә гайрәтләнде. Сизгәнме боларны Шәймиев, юкмы, иллә мәгәр бүген аның йөзе ак, ул канлы бәрелешкә кулын тыкмады. Илбашына сабырлык килешә ул!..

Декабрьнең ин зур вакыйгаларыннан: Рөстәм Яхин вафат булды. Татарның без белгән, без кабул иткән, без яшәгән чор татарының соңгы композиторы. Яшь ягыннан Рөстәм белән Әнвәр Бакиров тиң булсалар да халыкның аның, моңын, кайнар жанын бер дәрәҗәдә кабул итә алмадылар. Рөстәм үз чоры татарларының жанын бөтен тарафтан аңлап, табигать көчләрен заманча эшкә жигеп, татар күңел дөньясының бердәнбер хуҗасы булды. Уфалы Рим Хәсәнов вакыт-вакыт аның бәрәкәтле дулкыннарында тибрәлеп, татар күңеленә китмәс жылылык өстәп торгалады... Әмма Рөстәм Яхин соңгы ун, егерме елда бердәнбер бөек милли композиторыбыз иде. Рөстәм татарның жан сакчысы, күңел биеклегенең төгәл үлчәү берәмлеге иде. Глинка әйткән: «Без музыканы тудырмыйбыз, аны халык тудыра, без аранжировать кына итәбез», дигән. Соңгы чирек гасырда татар милләте шулкадәр жимерелде ки, аны татар дип атау да кыен, аның милли төп сыйфатлары уңды, югалды, алмашынды. Рөстәмнән соң килә торган композиторларга үпкә дә юк сыман, алар үз чорының жимешләре. Рөстәм Яхин белән татарларның йөз еллык, мен еллык нурлы тормышы, жылы жанлы татар моңнары китте. Сәйдәш-Яхин, алар арасындагы мәйданны хаклы рәвештә биләгән Мансур Мозаффаров, Заһит Хәбибуллин, Жәүдәт Фәйзи, Александр Ключаревлар китте. Рөстәм яшәгәндә, аның моңы шушы буын дулкыннарында өстенлек иткәндә,

ошбу мәшһүр затлар да татар күңеленең тоткасы булып торалар иде. Рөстәм Яхиннын вафатына багышлап, атап Марсель Галиев искиткеч тирән мәгънәле мәкалә язды, татар дөньясында Рөстәмнең нинди урын тотуына хак бәя бирде.

Кичә, ягъни егерме дүртендә, Тинчурин театрында Исламия Мәхмүтованың юбилеен үткәрдек, илле яшь тулган икән. Бөтен Казан купты, моңарчы бер генә татар артисткасының юбилее да болай зур күләмдә, халыкның ихлас мәхәббәтен кузгатып узганы булмады шикелле. Ярата икән татар Исламияне! «Оештырган, оештырганнар!» дисәләр дә чынлык бүтәндә: милләт сөйкемле, ягымлы балаларына үтә мохтаҗ икән!

Һичнинди арттырусыз әйтелгән мактау сүзләре, ихлас котлаулар Исламиянең бүгенге татар сәхнәсендә беренче дәрәҗәдә торган артистка икәнлеген раслады. Алсу бар, Рузия бар, Наилә Гәрәева дә күз уңыннан төшмәгән... Исламияне халык зурлады! Һич бүтән уйларга бирелмичә рәхәтләнеп, сафланып, Исламия тудырган рәхәт һавада кинәнеп утырдым. Сәхнәгә дүртәү мендек: мин, Туфан, Илдар вә яшь драматург Данил Салихов. Җылы сүз дә әйтергә тырыштык. Татарстан, Казан, бөтен районнар тузгыган иде, Исламияне чәчкәләр белән күмделәр, олы-олы бүләкләр тапшырдылар. Кара болыт булып урамда кеше калды, театрда урыннар житмәде. Без Туфан белән янәшә мыек астыннан гына көлеп утырдык. Хәер, мыек Туфанда гына иде. Яшә, Исламия!

*15 октябрь 1993 ел*

Хәтер көне уңае белән...

Хәтер—үлчәүләргә сыймас искиткеч зур көч ул. Без әнә шул байлыкка—үз хәтеребезгә озак еллар хуҗа була алмадык. Димәк, милләт тагын бер тарафтан имгәтелеп, көчсезлеккә дучар ителеп килде. Олыгая төшкәч, дөньяның уңын-сулын аңлагач, инде төп фикерләргә йомгак ясар вакыт җиткәч, Хәтер турында кайта-кайта өзмәс уйланыла икән. Хәтер хакында сүзгә керешердән элек бер мәсьәләне ачыклыйсы килә... Хәтер—хисләр йомгагы түгелмени? Әйе, хисләр күп төрле, ләкин аларның иң нечкәсе, нәзеге—милли хис. Милли хис булганда гына милләт бөтен хәлендә яши ала. Күзгә бәрелеп тә тормый ул хис, милли хисләр хакында һәр таңда чәчелеп тормыйбыз кебек, асылда исә ул мең төрле сизелмәс җепләр аша балаларыбызга, якыннарыбызга, тирә-юнебездәге милләттәшләргә күчә тора, синнән аларга, алардан сиңа. Милли хис теге яки бу дәрәҗәдә һәр җан иясендә дә бар. Җанның терелеген саклый торган хис ул. Хәтер көне җәһәтеннән уйланганда татарда милли хиснең үлмәвен, барлыгын, терелеген тоясың. Хәтер көне безгә әнә шуны да искә төшерде! Туган җирне, туган телне, милләтне ярату сыйфатлары да сыя ул олы хискә. Милли хис хакында авыз ачып сүз әйтү үтә җаваплы миссия, ул сак эш иткәнне таләп итә. Татарда булган кебек чуашта да бар ул назик хис, башкортта да аның югалганы юк, урыста да шактый көчле ул. Бу юнәлештә бер уем белән уртаклашам, кайвакытта теге яки бу милләт вәкилләре, милли хисләргә көч-энергия өстәргә теләп, саксыз сүзләр ычкындыралар. Милләтләр бер чакта да тар сандыкка бикләнеп яшәмиләр, милли хисләр бер-берсенең кадерен, олылыгын раслап килгәндә генә милләтара тынычлык, татулык урнаша.

Мөхтәрәм әдибебез Әмирхан ага Еники иманына табынам. Ул һәр җәһәттән сак булган кебек, милләтара мөнәсәбәтләргә дә житди, төптән уйлап карый. Үткән еллардагы Хәтер көне безнең барыбызга да, урыска-татарга, милләтебезнең исәнлеген, барлыгын, кайчандыр шанлы-шәүкәтле дәүләте булганын, аның тарихтагы данлы урыны барлыгын искә төшерде дә, киләчәккә өмет белән карарга нигез салды.

Менә без Хәтер көнендә Сөембикә манарасы янына җыелабыз.

Халык бу тантанага нык әзерләнә, тәнен пакьли, чиста киемнәрен кия, ап-ак яулыкларын бөркәнә. Тәкбир әйтеп, саф-саф тезелеп Казан урамнарын инләп-тутырып аккан татарларны күргәч, күңел бөтәя, үз-үзенә вә халкына ышаныч арта. Чынлап та милли рух сүнеп-сүрелеп бетмәгән икән әле! Милли рух күп нәрсәләргә мохтаж, аны тарих агышының һәр җаваплы мизгелендә тукландырып торырга да кирәк! Милләтнең тирән тамырларын, мәшһүр улларын—мәгърифәтчеләрен, батырларын, ил агаларын, олы язмышлы улларын да барларга кирәк. Мәңгегә татар күңеленнән китми торган ул-кызларыбызны шушы Хәтер көнендә барламасак, кайчанрак барлый алабыз без аларны?! Тарих үткәннәрдән үзе сайлап алып милләтнең бөек балаларын киләчәккә, ягъни мәңгелеккә тапшыра. Сөембикә-ханбикә әнә шундыйларның иң бөеге, иң сөеклесе. Юкка гына Сөембикә янына җыелмыйбыз без!

—Хәтер бик чәрексезгә дә әйләнә ала! Хәтерне онытып җибәрү дә, аның көпә-көндез буталу ихтималы да бар. Хәтер явызлар кулына төшкән мәлләр дә бар! Хәтер өзмәс, тоташ бер агым булып яшәргә тиеш. Һәм менә шушы гасырлар буена сузылган күперне милләтнең асыл затлары иңнәрендә күтәреп торырга тиеш. Иң элек милләтне милләт иткән асыл затларыбызның исемнәрен татарның үзенә, томанлы вә тоньк бүгенгесенә кайтарырга кирәк. Ансыз ярамый. Милләтләрнең дөнья йөзеннән йә бик тиз, йә яшертен-акрын гына югалу мисаллары юкмы әллә? Хәтер янарту, асылда, үзебезнең тарихи шәхесләргә борылып кайта да ул! Монарчы тел төбебездәрәк яшәгән бөек асылзат Сөембикә-ханбикә хакында бүген авыз тутырып, горурланып сөйли алабыз икән, бу милләт яшәешенең янарышы дигән сүз. Урыслар язган, татарга көчләп тагылган тарихта татар хатын-кызлары изелгән, ташкурчак хәлендә, чүпрәк-чапрак арасында кысылып яшәгән дигән ялганга ышанып килдек. Бар икән алар, бөек шәхесләр—Сөембикә, Нурсолтаннар яшәгән икән! Без үткәндәге тарихыбызны әле генә яза башладык, шуның өчен аяк терәп: «Тарихыбыз Хәтеребезгә кайтты!» дип раслый алмыйм. Мәгәр бүген бер нәрсә ачык: гүзәл илебез булган, гүзәл кешеләребез яшәгән. Тарих—бормалы юл ул, гасырларны кичеп үткән чакта аның кемдер кабул итмәгән, кемгәдер ошамаган яклары да булгандыр, ләкин ана карап татарның бөтенлеге вакланмаган, сакланган.

—Тарих безгә татарның яңа дәүләтчелеген төзү мөмкинлеген бирә. Алай да, Татарстанның якын киләчәген өзеп кенә әйтү минем хәлдән килми. Без элеккеге гасырларда дәүләт булып яшәгәндә тарихи шартлар бөтенләй үзгә булган. Европа, Азия илләренең системасы бүтәнчә булган. Хәзер шушы үтә болганчык чорда, илләр-җирләр үзара сугышып, кан елгалары агызып ятканда, Россия дәүләтенең фундаменты дер-дер калтыраганда, «Татарстан шулай булыр, болай булыр!» дип күрәзәлек кыла алмыйм. Раслау, өзеп әйтү—яки алдау, яисә беркатлылык булыр иде. Мин бүген бер нәрсәгә ышанам: Европаның төп илләре үзара дәүләт чикләрен бетереп, якынаеп, бер акча системасы—экюга күчеп, уртак парламент сайлап яшәгәндә, бүтән дәүләтләр дә бер-береннән ерагая алмастыр дип беләм. Әлегә без мөстәкыйльлекне аерылу, читләшү диебрәк кабул итәбез, әмма алда мөстәкыйльлекнең яңа формалары туачак. Аның бөтен шартларын бүгеннән билгеләргә минем акылым җитеп бетми бетүен... Бер нәрсәгә—татарның киләчәгенә, аның яшәячәгенә, милләт буларак шушы дөнья тарихына—үз урынына кайтачагына ышанам. Тик шушы бөек юлда сабырлык, акыл белән яшәсәк иде!

—Туганнарым, адәм баласының аңы мөкәммәл булсын өчен, чикләнгән бүгенге көн белән генә яши алмый ул. Тарих та тере булырга, үзеннән соң килгән буыннарга тере хәлдә хезмәт итәргә тиеш. Бүгенге Хәтер көнендә иманыбыз бер вә нык булсын! Күңелләргә аклык, милләтебезгә хөрмәт инсен, күршеләр белән ике арада татулык чатнамасын! Ходай безгә бердәмлек һәм ныклык насыйп әйләсен!

# ШИГЪРИЯТ



## Нур Әхмәдиев

### СӨЮЕБЕЗ КҮПТӘН КҮККӘ АШТЫ

* * *

И нигез,
Кичеп елларны,
Керәм мин бусагадан.
Кайсыбыз күрәзәче соң,
Язмышын белә алдан?

Ул чакта сары томшык без,
Ашкындык офыкларга.
Бер көнлек рәхәтлекләргә,
Минутлык кызыкларга.

Бишек тирбәткән нигезгә
Оныттык хат язарга...
Кышларда йөреп ваемсыз,
Тирләп кердек язларга.

Бәхетнең зуры һаман да
Алдадыр кебек иде.
Өзгән җимешләр барсы да
Алмадыр кебек иде.

Яшәешнең чын асылын
Беләсең икән соңлап...
Утырам ялгыз нигездә
Тынлыкны ялгыз тыңлап.

Кабердәге тынлыкмыни—
Чикерткәләр дә качкан.
... Күз алдымда черек алма
Өзелде алмагачтан.

## Палатада

*...Үзем сүнеп ятам,*
*Үзем көлеп ятам,*
*Кеше бәхете өчен сөенеп.*

Гамил Афзал

Авыртуга түзү җиңел түгел,
Чәнчи моннан, чәнчи тегеннән.
Рәхмәт, табип, бер кодрәт илә
Алып калгансың бит үлемнән.

Исән калганыма мең-мең шөкер,
Якыннарым килсен янәма!
Кайберәүләр әнә наркоздан соң
Китеп бара, килми аңына...

Беркем белми шушы палатада
Кемнең калган күпме гомере,
Сүнәм-сүнәм диеп көйрәп ята
Гомер учагының күмере.

Сызлый тәнем, наркоз авыр чыга,
Ятам уттай янып, сызланып...—
Сызланып һәм минекеннән күпкә
Хәле авырларны кызганып.

* * *

Ходай миңа миһербанлы булды:
Күп күрсәтте—исән калдырды.
Кайберәүләр юлдан язган чакта,
Йоклатмады—Шигырь яздырды.

Күзгә җилләр шашып шаулаганда,
Киек казлар моңын ишеттем,
Тик каядыр артык иртә бардым,
Ашыксам да, кайчак кичектем.

Аллаһудан иңгән вәхиләрне
Йөрәк аша азмы үткәргән!
Хагы булса әйтеп калыгызчы,
Нахак сүзне ләкин күтәрмәм.

Пәйгамбәрлек, бәлки, канда бардыр,
Бер гөнаһлы бәндә үзем мин.
Шайтан кебек гаять сабырсыз мин,
Фәрештәләр кебек түзем мин.

## Күк капусы ачылганны көтеп

Карыйм, карыйм—карап күзем талмый,
Сулыйм, сулыйм—сулап туялмыйм.
Өнем икән—бәхетем ун кешелек,
Төшем икән—тизрәк уяныйм.

Уяныйм да барсын уртаклашыйм,
Бәхетсезләр күп бит болай да.
Язмышыма мең-мең рәхмәт әйтеп,
Дога кылыйм әле Ходайга.

Һәр чәчәген үбеп чыгар идем,
Сыйпар идем һәрбер бөҗәген.
Таңнан торып бүген, и кешеләр,
Ак бәхетләр сезгә теләдем.

Сабыйдай саф, садә, керсез чагым,
Мунчадан соң кебек җаным да.
... Күк капусы ачылганны көтәм,
Алданасын белеп тагын да.

## Алып батыр һәм Геракл

Чагыштырып карыйм кайчагында
Бер бизмәнгә салып:
Кайсы көчле: грек Гераклмы,
Әллә безнең Алып?

Икесен дә иҗат иткән ласа
Хыялга бай халык.
Бәлки әле якын туганнардыр
Геракл һәм Алып?

## Кеше

Нигә сызлый бу тән,
Нигә сызлый бу җан:
Әллә инде тәннән
Аерыла Вөҗдан?..
Вөҗдансызлар белән
Инде дөнья тулган...
Мин Вөҗдансыз калсам,
Язам акылымнан.
Юлдан яздырулар—
Бусы шайтан эше.
Шайтанга сер бирсәм,
Булырмынмы—Кеше!?

* * *

Ап-ак томаннарда ак сагышым,
Чыклы үләннәрдә эзләрең.
Исеңдәме, иркәм, җәйге кичтә
Ап-ак кашкарыйлар өзгәнең?

Тәкыяләр үрдек, кашкарыйның,
Бәхет юрап, өздек чукларын.
Кашкарыйлар безне бергә диде,
Кая илтте синең сукмагың?

Ак томаннар җиргә сузылып яткан,
Кашкарыйлар сөттә коена.
Ап-ак сагышларым, томан булып,
Кочагыма килеп сыена.

Томаннарда әллә адаштыңмы,
Синең өчен җилләр чәч тарый.
Исемеңне әйтсәм, ник сискәнә
Ак чәчәккә чумган кашкарый?

## Венерага

Еллар узган саен якынрак син,
Арта бара һаман кадерең.
Син соң әллә аеруча нечкә
Бер кылымы моңлы бәгырьнең?

Син кыл булсаң, аны уйнатырга,
Көйләр чыгарырга мин кирәк.
Шатлык белән тулы көн кирәк,
Сөю-назга тулы төн кирәк.

Без үлгәч тә, яшьләр кабатласын,
Саф Мәхәббәт, Сөю бар диеп.
Яшәделәр, яшьнәп яшәделәр
Бер-берсенә лаек пар диеп.

* * *

Нидер булды, бер дә туялмадык
Күзебезне күзгә карашып.
Төн буена күктән йолдыз яуды,
Сандугачлар йөрде адашып.

Йолдызларны әлдем керфегеңә,
Мәрҗән итеп тездем түшеңә,
Өнемме бу?
Татлы саташумы,
Керүеңме бары төшемә?

Җавап эзләп гомер уздырмадык,
Ә кемгә соң кирәк җавабы?
Йөрәкләрне кавыштырган өчен,
Фәрештәләр, сезгә савабы!

Җиһан уртасында тик икебез,
Чыклы үләннәрдә эзебез,
Сөюебез күптән күккә ашты,—
Ничек җирдә калдык үзебез?..

*2000. Әлмәт.*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



### Әхсән Баян

# УЙЛАР ДӘРЬЯСЫНДА

ХӘТЕР ДӘФТӘРЕННӘН

*Иделемне кичәр идем*
*Талдан саллар тезеп тә.*
*Төштем уйлар дәръясына,*
*Чыга алмыйм йөзеп тә.*

**Сездән көтәм...**

*Бәлки, түземлегем җитмәгәнгә күрәдер, мин үз гомеремдә көндәлек алып бара алмадым. Аннан, көнкүрештә кабатлана торган хәлләр минем өчен вак нәрсә һәм соңыннан да кызыксыз тоелыр, онытылса да зыянсыз югалту булыр, дип уйлый идем. Тойгыларга кагылмаганнары чынлап та онытыла баргандыр. Әмма кайберләре, онытылмау гына түгел, хәтта онытылуларын бик теләгәндә дә, кабат-кабат искә төшеп, интектерә килде. Күбесе, бөтенләй маза бирмичә, әсәрләргә килеп керә һәм шуннан соң гына күңел бушап, җиңеләеп кала иде.*

*Андый хәлләрнең күпчелеге шигырьләрдә, поэмаларда, повестьларда һәм кайберләре хәтта романнарда урын алдылар.*

*Болардан тыш, тәгаен автобиографик язмалар («Минем кечкенә дөньям», «Хыялда туган калам», «Су өсләрендә пароход») дөнья күрде. Аларда шул онытып булмый торган истәлекләр үзләреннән-үзләре, минем ихтыярга буйсынмыйча диярлек, ирекккә чыктылар.*

*Хәзер инде кәгазьгә теркәлгән истәлекләргә чират җитте. Илленче еллардан— студент елларыннан башланган блокнотларны күздән кичердем. Болары әсәрләргә кергәннәреннән шактый нык аерыла. Вакыйгалар, тормыш фактлары булудан бигрәк, фикерләүләрдән гыйбарәт булып, күңел эшенә кайтып кала һәм барыбер рухи яшәеш эволюциясен барлыкка китерә. Алар турыдан-туры иҗади максат белән, әсәрләр язганда кирәк булу, шулай ук онытылу ихтималын күздә тотып, хәтер төеннәре рәвешендә теркәп барылганнар. Кайберләре, чынлап та теге яки бу әсәрдә файдаланылган, шигырьгә әйләнгән. Әмма әсәрләргә кушылмый калганнары да байтак җыйналган булып чыкты.*

*Аерым фикерләр һәм фрагментлар беренче башлап теркәлгән хәлләрендә кала. Шулай да, хронологик тәртиптә җыйналгач, алар уртак мәгънәгә ия була башлый икән.*

*Вакыт агышына бәйле рәвештә, фикри истәлекләр, шәхси эчтәлек белән чикләнмичә, тарихи вакыйгаларга, мәгълүм чордагы идеологик шаукымнарга реакция буларак барлыкка килгәннәр. Рухи яшәеш көндәлекләре төсен алып, алар биографиянең*

*эчке сыйфатларын чамаларга һәм тулыландырырга ярдәм итәрләр кебек. Тәгаенрәк әйткәндә, минем бу тупланманы да истәлекләр китабының бер өлеше итеп күрәсем килә.*

*Шул ук вакытта икенче бер моментны искә алу фарыздыр. Тупланмада шәхси фикерләр белән, минем үз тәҗрибәләрем белән беррәттән, башка кешеләрдән ишеткән сүзләр, эпизодлар да теркәлгән. Ягъни монда замандашларның уй-фикерләре дә чагылыш таба, билгеле микъдарда аларның да рухи халәте тасвирлана дияргә җөрьәт итмәк булам.*

*Күптөрле фикерләр һәм тойгылар чиратлашкан калейдоскоп гомуми кәеф халәтенә, аерым кисәкчәләр мозаик сурәткә әйләнә ала бит? Минем моңа уңай җавап бирәсем килә.*

*Нәтиҗәдә ничек килеп чыккандыр, җавапны мин, мөхтәрәм укучыларым, сездән көтәм.*

АВТОР.

## Киңәшле сөйләшүләр

(1953—1958)

Алтын гасыр булган, борын заманнарда кешеләр рәхәт яшәгән, имеш. Мәгәр фән белән икәүләп, без моны кире кагабыз.

Алтын гасыр—алда. Адәм баласын ул һаман киләчәктә көтә.

• • •

Дөньяда бөтен нәрсәнен туйдыруы, хәтта ин кайнар йөрәкләрне дә өшетә башлавы ихтимал. Мондый хәвефле мизгелләрне тормыш барышында тик көчле, кин күнелле кешеләр генә мөнәсәбәтләргә зыян китермичә кичерә ала.

• • •

«Каләм юнсан, озын юнгыл ботыны, Хатын алсан, элек алгыл котыны»,—дигән шигырьне көлешеп кабатлый идек. Ә ул көләрлек кенә түгел, кайчакларда еларлык та була ала икән. Монысын кайберәүләр картаймыш көннәрендә генә анлаячаклар.

• • •

Бүген шундый көн—кешеләр баралар-баралар да, күккә чалкан ятып карыйлар.

• • •

Ак тәхетләр безгә кирәк түгел,
Ак бәхетләр булса, шул җитә.

• • •

Бүлмәгә кереп, озак кына сөйләшкәннән сон, бер адәм «Исәнмесез!»—дип чыгып китте.

• • •

Яна йортка күчкәндә, җиһазлар чыгарыла барган саен, фатир эче белән бергә, яшәлгән гомернен дә бушап калганы сизелә торды.

• • •

Бер егет клумбадагы бүтәннәр үстергән чәчәкне өзеп биргән иде, кыз алмагач, анын хәтере калды.

• • •

Бу чорда житәкче абзыйлар индивидуальләштерелгән сәнгать образлары түгел, ә персональләштерелгән әхлак кагыйдәләре таләп иттеләр.

Төп игътибар психологиягә һәм анда да психологиянең үзе хакына түгел, ә тормыш фәлсәфәсе хакына юнәлтелергә тиешлеген алар башларына да китермиләр иде.

* * *

Тормыш һәм андагы конфликтлар авырлыгын үз иңнәреннән төшерергә, дуслар җилкәсенә күчерергә, анлы рәвештә кызгандырырга тырышкан кеше—көчсез.

* * *

Сөйгәненә яратуыңны адым саен кабатлама. Аның синнән туюын теләмәсәң, аның да сине яратуын теләсәң, күбрәк тынларга өйрән. Сөйгән кешенә әрсез күзләрдән, купшы мәгънәсезлекләрдән сакланырга булыш.

* * *

«Эшләр майлана, күзләр җайлана»,—дидегез.
Әллә киресенчәме?

* * *

Шактый дорфа агай белән шактый чәүчәләк ханымны бер бүлеккә куйдылар. Эшләре пешмәгәч, мөхәррирнең урынбасары болай диде:
—Скрипка белән барабаннан рәтле көй чыкмас диган идем аны.

* * *

Ялгыз карчык, үзе ярыйсы гына яшәп, туганнарына да ярдәм итә. Балалары юк. Бик тә җитди сөйләшкән арада, елмаеп куя:
—Кияүгә чыгарга, балалар табарга вакыт тимәде. Өч җирдә берьюлы эшләдем. Активистка идем.

## Чакматаш бул

(1964—1969)

Син таш кебек салкын, диделәр. Ә син ышанасыңмы шул сүзләргә? Ышансаң, сынап кара. Син чакматаш булсаң, салкын урынына дөньяны дөрләтерлек ялкын бөркелмәсме? Чакматаш була алсаң, минем нинди таш икәнлегемне тоя да, күрә дә алырсың.
Чакматаш бул.

* * *

«Синдәге авыскаллык (таркау күнеллелек) унбиш профессорга җитәрлек»,—диде чибәр.—Нишләп син профессор түгел?»

* * *

Кайберәүләр этне мыскыллыйлар, «эт!»—дип тиргиләр. Кешеләрне дә шулай атап мәсхәрәлиләр. Ә үзләре эттән түбән. Ә бит эттән дә рәтле, эттән дә тугры җан ияләре юк дәрәҗәсендә. Ә ник этләр көлми бәгъзе бәндәләрдән?
Көләдер дә бәлки, әмма тел белмиләр. Ходай бәгъзеләргә биргән җайны.

* * *

Таш су өстенә калыккач, таштан үлән шытып чыккач, үлән өстендә чәчәкләр үскәч, карьеристларда вөҗдан уяначак. Бүре сарыкка әйләнсә, аю бакчачы булса, дуңгыз яшелчә үстерсә, закон үтәлешендә тигезлек урнашыр.

...

Хатынын ташлап, ир-егет яшь хатынга өйләнә. Аннары яшь хатын икенче яшь иргә чыга. Икенче яшь ир—тагы бер яшь хатынга.

Тәгәрмәч көйле генә әйләнә.

...

—Мине әни тапкан,—ди кыз бала.

—Әллә әтиме?—дип шикләнә ир бала.

—Әни, әни тапкан. Әти тапса, мин мыеклы булыр идем.

...

Җир галәмнең йөрәгедер кебек. Карангыда, ялгызым гына тыңлап торганда, мин ул йөрәкнең тибешен тоям, ишетәм дә төсле.

...

Мылтык күләгәсе, ракеталар шәүләсе Җир өстенә төшә таңнарда. Ярый әле, Кояш чыга. Җирдә саф болыт һәм агач күләгәләре генә кала.

...

Музыкаль әсәр куйган вакытта, драма театры режиссеры опера җырчысына:

—Авызыңны ачып җырлама!—дип күрсәтмә бирде.

...

Утыз җиде яшь тулды. Күпме яшәлде, ә күпме генә эшләнгән? Күпме гомер әрәм узган. Уйласаң, тән чымырдап куя.

Инде шулай яшәргә кирәк: бер ел ике елга торырлык булсын. Ерак төньякта яшәгән кешеләргә, ә үзебезнең якта интернатларда эшләгән тәрбияче педагогларга бер ел урынына ике еллык стаж исәпләнә бит.

...

Ресторанга керсәң, бөтен халык көн-төн ашый, эчәдер, больницада—гел авырыйдыр, гел үләдер кебек. Бакчаларда, танцы залларында гел бии дә җырлый, гел мәхәббәт белән мавыгадыр сыман.

...

«Син, безнең кебек, колхозга ат биреп кермәдең»,—дип, авылдашлары кимсетә башлагач, зимагурлыкта йөреп кайткан бер кеше, җыеп кайткан бөтен акчасына ат алып, колхозга тапшырган ди.

Ихтирам дигән нәрсәнең ни икәнен белгән кеше булгандыр инде. Ыштыр битле булса, мыегы да селкенмәс иде.

...

Елның 21 декабрендә көн кыскаруы тәмамлана. Аннары берничә көн кыскармый да, озынаймый да. Җир бушка әйләнәдер, диясе килә. Гел шулай торса, мәңгелек кыш булыр иде. Нинди куркыныч!

...

Плутон—караңгылык патшасы. Кояштан иң ерак торган планета. Мәңгелек караңгылык. Исеме дә шуны аңлата. Кояш аннан бездәге ай төсле булып күренә.

Мәхәббәттә алданган бәхетсез көннәремдә мин үземне шул планетада аерылып калгандай хис итәм. Кояшым Айга әверелә.

...

Кояшка күзләрне нәрсә беләндер каплап, яки нәрсәдер киеп карамасаң, ул күзне яндыра. Мисаллары да бар.

Кояш белән һәм Мәхәббәт белән шаяру куркыныч.

* * *

Борынгы Рим рәссамнары 650 мең төсле буяу кулланганнар. Шулай да төсләр азлыгыннан зарланганнар. Ә без күп булса бер дистә төс белән канәгатьләнәбез. Хәтта бер кызыл төс җиткән вакытлар бар иде.

Үзебез кешелек үсә бара дип тәкърарлыйбыз.

* * *

Кешелек белән идарә итү өчен кемгә дә булса бер тәүлек вакыт биреп, җаның ни тели, шуны эшлә, дисәләр, ул нишләр иде икән? Кем дә булса, бөтен тарих буе җыйналган кыйммәтләрне кыйратып ташламас идеме?

* * *

Бөркет, тулы көченә очып барганда, самолетка бәрелә. Самолет та, бөркет үзе дә һәлак була. Таран. Менә уйла инде шуннан соң: металл катыракмы, әллә тере тәнме?

* * *

Мин, карандаш белән язылган сорауларны бетереп, әсәр төзәтеп утырганда, тугыз яшьлек Розалия:

—Ә сезгә пычраткан өчен начар отметка куяламы?—дип сорады.

* * *

Дөньяда өч төрле бәхетсезлек бeләм: кышын ягылмаган өйдә йоклау, җәен кысан аяк киеме кию, бала елаган өйдә йоклау. Ә шуннан да яманрагы—җаның сөймәгән, яки сиңа хыянәт иткән кеше белән бер түбә астында яшәү.

* * *

Көн очып бара—урман-кырлар, болын-дәрьялар белән бергә, бал кортлары һәм еланнар белән бергә, дуслар-дошманнар белән, синен белән, минем белән бергә. Күзгә күренми торган мәңгелек упкынга таба.

* * *

Йокларга ятсам, мендәр астыннан көйләр ишетелә. Тынлыкта тагын ишетәм: чүкеч белән нәрсәгәдер сугалар. Гаҗәеп тигез, дөрес ритм. Кайберәүләр: шулай бәхет чүкече суга диләр.

Ышанасы килә, әлбәттә.

* * *

Иблис уттан яралган. Фәрештәләр—нурдан, пәриләр—төтеннән. Адәм—балчыктан. Шуңа күрә, Җир өстендә ул хуҗа. Ләкин Иблис тә, Ходай каршында сәҗдә кылмаганга күрә, күктән сөрелгән. Адәм балаларын адаштыра-саташтыра, ул да Җирдә көн күрә. Күп очракта—кешеләр, хәтта чибәр кызлар рәвешендә.

* * *

Райкомның пропаганда бүлеге мөдиренә: «Эшең күренми»,—дип бәйләнәләр. Ә ул исә:

—Пропаганда—ул печән түгел, аны кибән итеп өеп булмый,—дип җавап бирә.—Күрмәскә тырышсаң, юкка да чыга.

* * *

Сугыштан кайткан танкист—Җәмәки авылының Хатип исемле кешесе—шундый вакыйга сөйләде.

Танк яна башлагач, ул аннан чыга һәм әсирлеккә эләгә. Көннәрдән бер көнне аны кырга алып чыгалар. Анда кабер казылган. Өчме, дүртме

кеше кабер эчендә утыра. Танкистка һәм аның ике иптәшенә шуларны тере килеш күмәргә кушалар. Болар күмә алмый. Шуннан соң, фашистлар кабердәге кешеләрне чыгарып, танкистларны төшерәләр дә, инде бая кабердән чыккан кешеләргә боларны күмәргә кушалар. Күмә башлый болар. Фашистлар, аларны туктатып, танкистка һәм аның иптәшләренә: «Күрдегезме инде боларның нәрсәгә сәләтле икәнен?»—дип сорыйлар.

Шуннан соң, танкистлар хыянәтчеләрне таптый-таптый күмәләр.

Хатип абзый, соныннан качып, үзебезнен якка чыга. Хәзер дә исән. Орденнары күп. Ләкин нык уфтанып, шушы вакыйганы шактый еш кабатлап сөйли.

• • •

Ижтимагый куркаклык дигәнне ишеткәнегез бармы? Булмаса, ишетегез. Менә болай ул.

Ленинның абыйсы кулга алынгач, аның әнисен судка озата баручы табылмый. Шәхес культы чорында кулга алынган кешенең балалары белән уйнамыйлар. Уйнамаска әниләре боера.

Шундый чакта да мәрхәмәтле, затлы кешеләр очраштыргалый. Язучыбыз Н. Исәнбәт кыерсытылган вакытларда, мәсәлән, шагыйрь Ә. Фәйзи, ишекне төбенә кадәр ачып, хәл белергә килә торган була.

• • •

Әшмәндә безнең күрше абзыйның олы кызы, әтисе Уфага чабата кигән хәлдә баргач, кеше арасында күрмәгәнгә, танымаганга салышып, тиз генә узып китә. Әтисе ана ул чакта да ачуланмаган. Хәзер дә сагынып көтә, шатланып каршы ала, рәхәтләнеп кунак итә.

• • •

Бер күренеш күнелдә һич онытылмаслык булып, уелып калды.

Безнең өй кыегында күгәрченнәр оясы бар иде. Күгәрченнәр анда күкәй сала, бала чыгара, гөрли-гөрли яшиләр иде. Әти үлгәч, башта гөрләми башладылар, ә соңынтын бизделәр.

Ә ул чакта мина—жиде яшь. Алар минем иң якын дусларым, сердәшләрем иде. Әлбәттә, нык юксындым, моңайдым.

• • •

Тегермән буасы алдына терекөмеш салалар. Тамчы гына булган терекөмеш, әкертен-әкертен буаны тишә дә, су, язгы ташкын шикелле, буаны эссе жәйдә агызып китә. Көндәш тегермәнчеләр берсенә-берсе шундый этлек кылалар. Халык тегермәнсез кала. Әллә кая, ерак тегермәннәргә йөреп интегә. Ә хөсетлеләрдә кеше кайгысы юк. Тик үч кенә кайтсын...

Ни кызганыч, ни оят, югарыга үрли барган карьерист чиновникларның да күпчелеге шул дәрәжәдә бит.

• • •

Икмәк сатып алу өчен гомер-бакый кешеләр шәһәрдән авылга килә, яки авылдан шәһәргә илтеп саталар иде. Хрущев вакытында хәл үзгәрде. Авыл кешеләре шәһәргә килеп капчык-капчык ипи ташыдылар. Магазинга керсәләр, күп аласың дип, бирми дә азаплыйлар. Үзе үстергән икмәкне ул ялынып сорый. Сатсалар, рәхмәт әйтә. Аркага капчык аскан килеш юлда газап чигүен әйткән дә юк.

Соңрак шәһәр кибетләрендә шар тәгәрәтеп уйнарлык бушлык җәйрәде. Ипигә иртәнге алтыда торып чиратка басалар. Менә эш чыкты әбиләргә. Алар ала иде чиратны.

Дөньяны болай оятсыз рәвештә кирегә әйләндерү өчен даһи булырга кирәккәндер... Нормаль кешенең моңа башы җитмәс иделер...

* * *

Ил буйлата сәяхәтендә Хрущев Казанга да килде. Өч көн буе завод-фабрикалар, оешмалар эшләмәде. Бөтен халыкны урамга чыгардылар, аны каршыларга. Кичә генә ач-ялангач интеккән урамнарда бөтен нәрсә пәйда булган—искиткеч матур киосклар торып баскан, күчмә буфетлар. Аларда жимешнең ниндие генә юк—алма, апельсин, мандарин...

Без Аны гаилә белән Красная Позиция урамы почмагында көттек. Аяклар сызлый башлаганчы көткәннән соң, бермәлне халык гөжли башлады. Ул! Ул күренде! Ачык машинада бөтен буена баскан—менә мин нинди, карап калыгыз, күреп калыгыз, бу—сезнең онытылмас бәхетле көнегез!

Үзен күрсәтәсе килмәсә, җинел машинада шулай басып йөримени кеше?!

Узып китте.

Без кайтыр якка борылдык.

Искитмәле хәл: без борылып караганчы, киосклар, буфетлар кай арада диген, юкка да чыккан. Тротуарларда, урам кинлегендә апельсин һәм мандарин кабыклары гына аунап ята. Без шуларны таптый-таптый, өйгә кайтабыз. Күнелләрдә дә бушлык, алдану хисе...

Шушы хакта поэма яздым. Билгеле ки, басмадылар.

* * *

Ачлык, салкынлык һәм шуларга бәйле бүтән газаплар рәнжетәләр, әлбәттә. Илла болардан да ачырагы, аянычрагы—ул гаделсезлек. Бит син шушы хәерчелектә яшә дә, кемнәрдер, симертергә куелган мал рәвешле, рәхәт чиксен, муллык дингезендә йөзсен. Һәм син фикерли бир:

—Фәкыйрьлек—безнең ташламас юлдашыбыз!

* * *

Иң гади дигән кешеләр яшәешендә дә дипломатия атлы нәрсә бар бит ул. Социаль психика. Оятсызлылык, затсызлык, икейөзлелек, хыянәтчелек, кабахәтлек...

Җанны кыйнаган, рәнжеткән сыйфатлар.

* * *

Ванна бүлмәсендә юынам. Краннан чылтырап су ага. Күзләремне йомсам, ул чишмәгә әверелә. Бу чакта инде мин еракта, бала чагымда. Туган як чишмәсе суы белән иреннәремне чылатам.

* * *

Хыянәтнең зурысы-кечкенәсе юк. Бик бәләкәй дигәне дә, барыбер, куркыныч, чөнки ул кешеләргә ышанмаска өйрәтә. Ә ышанычсыз нинди тотрыклылык, дуслык, мәхәббәт инде ул?

* * *

Дөнья—иҗат остаханәсе, ачышлар ясала торган лаборатория. Йолдызлар безгә якыная бара. Без шул дөньяда—бөтен галәмне күз алдында тотып яшәргә хаклы, ә бәйләнгән хәлдә, муенчак кигән хәлдә түгел. Шәхси файда дип исемләнгән тар чоланда һәм морҗа кырыендагы карангы кәбәркәдә түгел.

Хәлбуки, хәлбуки...

* * *

Галәмгә без иң зур биеклектән егылып төшәр өчен түгел, ә күбрәк күрер өчен, дөньябыз кинәйсен өчен генә омтылырга тиеш.

* * *

Һәркемнең үз төсе, үз йөзе, үз холкы. Күпме гасырлар, меңьеллыклар

узган, ә беркем дә беркемне кабатламый. Табигатьнең (әллә Ходайнынмы?)—даһилыгы!

Әдәбиятта исә, бер-берсен кабатлаган образлар тулып ята. Бер матур фикер, сурәтле гыйбарә тудымы, аны элкеп алып, селкеп кенә салалар. Төс тә, чырай да, холык та, фикерле образ да таптала, изелә, юкка чыга.

* * *

Юлда ярдәмчел кешене «Аның юллыгы әйбәт» дип мактыйлар. Өч кенә сүз. Мәгәр кемнең кем икәнен әйтә дә бирә. Характеристикалар язасы юк.

* * *

Ярлы кеше үзенең фәкыйрьлеген яшерергә тырыша. Авылда безнең күршеләр шундый иде. Бер умачлык оннары калса, хәтта ач торсалар да, зарланмыйлар. Байлар исә, ярлы булып кылана, шулай күренергә тырыша...

* * *

Горькийның язучылар йортындагы бюстын җыештыручы ханым көн саен сөртеп тора. Андагы тузанны сөрткәндә: «Элек кемнәр сыйпады икән синең башкаеңны!»—дип сөйләнә. «—Хәзер инде менә миннән башка сыйпаучы юк.»

* * *

Медицина техникумы тәмамлаган кызлар сөйләшә.

—Авылга киткәч, андагы бар трактористлар, комбайнерлар безнеке була инде,—ди берсе.

—Һәм башка житәкчеләр,—дип өсти икенчесе.

* * *

Мәскәү Кремлендәге Патша кыңгырау, чамасыз зур булганлыктан, артык авыр булуы аркасында, егылып төшә. Тавышы барлык кыңгырауларны җинсен дип уйлаганнардыр. Әмма ул бер генә тапкыр чыңлый язган. Бердәнбер мәртәбә яңгыраган мәгънәсе шундый булган:

—Кешеләр, артык зурдан купмагыз! Патша туп та әнә бер тапкыр да ата алмый калды!

Ә кечкенә кыңгыраулар ничәмә гасырлар буе чыңлый бирә.

* * *

Тормыш мәшәкатьләре—җилкәгә салынган ташлар кебек. Ләкин алардан котылу да, котылырга тырышу да юк. Алар минем өчен—сәгать герләре. Шулар йөртә сәгатьне һәм... кешене. Алар булмаса, йөрүдән—яшәүдән—туктар идек.

* * *

Кыз, биткә сипкел чыга дип, язгы кояштан битләрен яулыгы белән каплый. Җилдә, кояшта чыныкса, битләре әлегедән дә матуррак төскә кермәс иде микәнни?

* * *

Бер райком секретаре үз эше хакында шундый кызык нәрсә сөйләп куйды.

—Обкомның беренче секретаре Игнатьев бер райком секретарен тиргәде-тиргәде дә, җыелыштан чыгып китәргә кушты. Аннары, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кинәт туктатты.

—Чалбар төбең каешланып беткән, ялтырап тора,—диде.—Чалбар төбе белән эшлисең икән. Басып тор, тыңла. Кай төш белән эшләргә кирәген белеп кал.

Җыелыштан чыккан чакта, башка иптәшләр дә кинәшмәдән соң алга карап түгел, кырын-кырын гына чыгарга тырыштылар.

* * *

Шул ук секретарь дәвам итте:

—План үтәү—иң җаваплы эш. Әгәр аны үти алмасаң, партбилетны пычраталар. Ә мин моны теләмим. Үземнекенә хәтле башкаларныкын пычратып өлгерәм. Чара күрелде!

* * *

Бер-берсенә иң ярдәмчел кешеләр—шоферлардыр. Бер машина ватылса йә батса, аны төзәтмичә, чыгармыйча узып китмиләр... Тормышта гел шулай гына булсачы!

* * *

Кеше елан түгел, аның теле агусыз, диләр. Ләкин ничек кенә агулы әле! Бер сүз белән кешене аяктан егарга мөмкин. Икенче төрле сүз белән терелтергә була. Телдә—агу, телдә—дару.

Син дә мине чагасың да, дәвалыйсың да.

* * *

Җиде яшьлек Эльбрус:

—Ревальнең әнисе Африкада эшли,—дип хәбәр итте.

—Әйе шул, фабрикада эшли,—дип җөпләде аны әнисе.

* * *

Кайберәүләр: «җирле патриотизм булмый, бөтен илне яратырга кирәк!»—диләр. Ничек инде? Туган авылыңны, туган калаңны яратмасаң, зур илдә нәрсәне генә яратырга мөмкин?

* * *

Утызынчы елларда хөкем ителгән кешеләрнең барысы да төрмәгә гаепсез утыртылган дип сөйлиләр. Ләкин аларның күбесе хәзер: «Мин Совет властена каршы идем!»—дип мактанырга ярата. Кайберләре хәтта төгаен гамәлләрен дә телгә ала.

Шулай булгач? Кем каршында кем гаепле дә, кем гаепсез?

* * *

Композитор Ә. Бакиров сөйләгәнчә, Салих Сәйдәшев кемгәдер: «Көзгегә карап, үзенә «Сез» дип эндәшә торган адәм ул!»—дип бәя бирә икән.

* * *

Әгерже районында, әдәбият көннәрендә, безне бер яшь шофер йөртте. Автомобиль йөртүдән башка, тагын бер вазифасы бар икән. Үзенә дип кызлар белән таныша да, аларны начальнигына «бүләк итә.»

—Иң авыры начальникка кызлар табып бирү,—ди егет.—Тагын да кыенрагы, шуны кешеләргә сиздермәү. Коры җирдә балык булып яшәп яту менә.

* * *

—Алкоголикларнын бөтенсоюз корылтае җыела икән.

—Ялгыш ишеткәнсеңдер.

—Юк, мин ул чаклы исерек түгел идем.

* * *

Бервакыт бабай безгә «сез» дип эндәшә башлады.

—Безнен бабай бигрәк культурный,—мин әйтәм.

—Ак күлмәк кигәч, шулай культурныйга әйләнә ул,—дип анлатты кызы.

• • •

Карт йоклап ята. Иртән абзарга чыккан карчыгы куркып өйгә керә дә:

—Атыбыз үлгән!—дип кычкыра.

Карт уяна.

—И-и, җүләр, шунын өчен мине уятасынмы? Мин аны кичкене үк күргән идем инде,—ди.

• • •

Гел машинада йөреп күнеккән түрә урамда йөри белми икән. Берничә мәртәбә машина астында кала язды инде.

• • •

Эррозия ашый йөрәкне. Җил-янгыр түгел, гөрләвекләр, ташкыннар да түгел. Алардан котылып була. Ә вакыттан, шикләнү-икеләнүләрдән, хыянәт-ялалардан ничек котылырга? Ничек аларны туктатырга?

• • •

Әби улын калага озата.

—Бар, улым, Кунакханәдә урын тапмасан, бажана булса да кереп йокларсын.

• • •

—Иптәш Белинский әйткән, хатыннар ирләре өстеннән жалу белән парткомга да, профкомга да барып йөрмәсеннәр, дигән.

• • •

Урман. Көз. Кем өчендер валюта сурәтләре оча. Жыеп кына өлгер. Кемдер язгы, жәйге яшел көннәрен эзли.

• • •

Замандаш шагыйребез Берлин шәһәренә Муса Җәлил юбилеенә китте. Муса чыгарды аны дөнья киңлегенә.

• • •

Төш күрдем.

Бүрәнә араларына яшеренеп, тәрәзә аша өйгә елан үрмәләп керергә азаплана. Тәрәзә янында гына колга бар икән. Шунын белән сугам. Ләкин бүрәнә ярыгына керә елан, бирешми. Шуннан сон колга белән эләктереп, жиргә ташладым. Ерак түгел уйнап йөргән малайлар, аны күреп, таяклар белән кыйнап үтерделәр.

«Явызлыкны качып йөргән жиреннән шулай яктыга, кешеләр арасына чыгарырга кирәк!»—дип уйланып ятам, имеш.

• • •

—Мөфтинен сәркатибы булып эшкә керәм әле,—диде бер таныш.

Хезмәт хакы әйбәт. Өстәвенә сәдака жыясын. Баегач, гомерлекне жыйгач, эштән китәсен дә, мәгълүм ишан улы кебек, диннен икейөзлелеге турында чыгышлар ясыйсын, яза башлыйсын.

• • •

Эльбруска—жиде яшь. Пальма кушаматлы эт белән идәндә утыра. Иртәгә, кышкы каникулдан сон, мәктәпкә барырга кирәк. Барасы килми.

—И-их, кайчан пенсиягә чыгармын инде!—ди.

* * *

Авылдагы күршебез тракторчы Тимерзаһит бичәсе сөйләде.

Бер көнне аның күз төбе күгәргән. Икенче көнне кабыргасы авырта. Ире төнлә төшендә трактор йөртә икән. Рычаглар тартам дип, терсәге белән хатынына төртә, күгәрмәгән җирен калдырмый.

Кыйнаганы юк. Тик барыбер кыйный бугай дип шикләнә авыл халкы.

* * *

Карангылык күз күремен ала. Әмма мин төнлә күбрәк күрәм. Дөнья киңәя, зурая. Мин бөтен Галәм белән берләшәм.

* * *

Әгәр ир артык кешелекле булса, хатын ятларга карый. Болары кырыслыклары белән төрлечә интектереп, сәнгатькә, романтик китапларга тартым яналык китерә, имеш.

* * *

Ирнең алгы тешләре—протез. Кичен ул аны салып куя. Хыянәт итүе ихтимал дип уйласа, хатын протез тешләрне яшереп куя.

* * *

Әгәр бөтен көченне куеп, ачуланышып, тиргәшеп, бөтен әшнәләренне, агайларыңны файдаланып, үзенне расларга, уңышларына ышандырырга тырышасың икән, әгәр дә хәтта теләгенә ирешәсең икән, син үзеннең сәләтенә ышанып бетмисең, дөресрәге, сәләтеннең урта кул икәнлеген нык беләсең, дигән сүз.

* * *

Традицияләр бер төрле генә түгел. Аларның тискәреләре дә житәрлек. Традициягә әйләнсә, кемнәрнедер гадәт буенча мактыйлар, эше әллә ни булмаса да. Кемнәрнедер гадәт буенча тәнкыйтьлиләр, эше мактарлык булса да. Гадәт буенча сөйләнә торган сүзләрдә, дәрестән бигрәк, ялган күбрәк була.

* * *

Кеше, танылмаган чагында, әйбәтрәк чыгышлар ясый иде. Мәгәр аны бигүк ышанмыйча тыңладылар. Ә хәзер аны публика таныды, ул зур гына чин алуга иреште. Шактый койты чыгышлар ясый, фикерләре шаблон, һәркемгә мәгълүм нәрсәләр. Әмма хәзер аны ышанып тыңлыйлар.

Авторитет көче—гипнозлы.

* * *

Тиздән зәңгәр океанга—күккә чумачак нәни кошлар әле йоклый йомыркалар эчендә. Ә син аларны, бер минут эчендә юкка чыгардың, жиргә бәрдең.

* * *

«Жинүчеләрне хөкем итмиләр!»,—дип килде Тарих карт. Ләкин шагыйрь әйткәндәй: «Есть высший суд!».

Яңа буыннарга сабак өчен генә дә барыбер хөкем карары чыгарылачак.

* * *

Хатын-кызга: «Акылсыз»—дисән, ул сина ачуланмаска мөмкин. Ләкин: «Ямьсез»,—дисән, ул сине ахыр көненәчә гафу итмәячәк.

* * *

Табигатьтә төп төсләр—зәңгәр, яшел, кызыл. Калганнары шулар

пропорциясеннән килеп чыга. Адәм баласы, нинди даһи бит—ул шушы өч төстән меңгә якын төс һәм төсмер иҗат иткән!

* * *

«Давыл җыеп алганнан» соң, кешеләр минем янга утырырга ашыкмыйлар иде. «Иҗтимагый куркаклык»,—дигәнне телгә алган идек бит. Шул закон буенча. Шулай бер җыелышта ялгыз утырам. Янымa бер агай килеп утырды, бюрода мина шелтә биргәннәрнең берсе.

—Башлап үзем утырдым менә. Ашамассың әле.

—Мин куркырга тиеш моннан,—дим.

—Минем тешләрем бетте инде, чәйни алмыйм.

Башка ике төрле җавап килде. Беренчесе: «Ай-һай, шулаймы икән?» Икенчесе: «Ходай кушсын».

Әдәп саклап, икенең берсен дә әйтә алмадым.

Әдәп! Алар саклаган идеме соң аны?

Шулай да, абзыйның килеп утыруында мәгънә бар иде.

* * *

Мәскәүдә Казан поездына утыргач, купеда чебен безелдәде. Кулыма кундырып уйнадым. Кая ул үтерәсе килү! Якташ белән очрашкан кебек тоелып, күңел җинеләеп китте.

Ни әйтсәң дә шулай бит, бердәнбер якташ...

* * *

Кечкенә бер эт комлыкта шөпшәгә охшаш босоножка алып китеп бара.

—Ах, негодник, кая чабасың?! Аның хуҗасы сынар босоножка белән кая бара алсын! Ташла!—диләр күрүчеләр.

Эт босоножканы җиргә куйды. Кешеләр бөтенләйгә куйды дип тынычлана язган иде инде. Илла шул вакыт босоножканың хуҗасы—Анабыз Һәүвага тартым бер чибәр—босоножкасын алырга дип килә башлаган иде, эт босоножканы әйбәтләп капты да, янадан торды да чапты.

—Негодник, карак, карак!—дип кычкырды кыз да.

Эт булып эт, мин әйтәм, кем белән шаярырга икәнен белә бит ә? Безгә ни сан!

* * *

—Әфәндем, сезгә шовинизм дигән прививка ясалган. Шул сәбәп илә, үзегез дә анламыйча, бер үк сүзләрне такылдыйсыз. Сез—гап-гади попугай.

* * *

Туксан ике яшьлек тимерче карт үлемнән курыкмый. Әмма күңеле тыныч түгел.

—Һөнәрем җәл кала,—ди.—Өйрәтерлек кеше калмады. Олыраклар үлеп бетте, яшьрәкләре кайсы кая таралыштылар.

* * *

Борынгы акыл иясе шулай әйткән:

—Шәрапның беренче касәсе—сусауны басар өчен. Икенчесе—күңелне ачар өчен. Өченчесе—ләззәтләнү өчен. Дүртенчесе—акылдан язар өчен.

Ләззәтләнү белән акылсызлык янәшә торалар.

* * *

Үлгәч, бер кешедән сораганнар:

—Нинди хәлләр күрдең? Нинди кызыклы нәрсәләр бар дөньяда?

—Туганда бик бәләкәй идем, берни белмәдем. Үлгән чакта исерек идем, берни күрмәдем.

* * *

Кызгану кешене кимсетә, дигән сүз белән һич тә килешәсе килми. Бу хис кешенең кешелеклелеге турында сөйли бит. Кызгандырырга тырышу белән бутамаска кирәк аны. Кешенең хәленә керү табигый хис, матур сыйфат лабаса.

* * *

Иң бәхетсез кеше—егерме тугызынчы февральдә туган кешедер. Туган көнен ул дүрт елга бер генә тапкыр уздыра ала. Ләкин аның гомеренә дүрт елга бер көн өстәмә итеп бирелә.

* * *

Университетта укучы бер студент кыз, бәхәсләшкән вакытта малайлар аны «ак сөяк», «аристократка» дип мыскыллагач, санаторийга җыештыручы булып урнашкан.

Хезмәт хакың күпме дигәч, җавап бирә алмый. Белми. Әтисе зур галим икән.

* * *

Кеше гомер азагында ачыш ясады: «Ромео белән Джульетта мәхәббәтен тыйган кебек, минем дә мәхәббәтне тыйган булсалар, мин әле дә сөюдән суынмаган булыр идем. Мин мәхәббәттә диабет чире кичердем. Ризыкның тәме-шифасы калмады.»

* * *

Минем «Яшьлегемне эзлим» повестена карата КПСС өлкә комитетының өченче секретаре: «Не всякий прыжок хорош, если он даже быстр»—диде.—Кемнәрнедер тыеп торырга да туры килә».

Китап чыгуын тыйдылар, берничә елга «акрынайттылар». Ләкин язуны тыя алдылар дия алмыйм.

* * *

Трамвайда бер әби ак япмага төрелгән песине бала тоткан кебек тотып бара иде. Минем гаҗәпләнгәнемне сизеп, сөйләшә башлады.

—Авырый. Күршеләр агу биргән. Профессорга күрсәттем. Пеницилин уколы ясады. Хәле бик авыр ди. Температурасы утыз тугыз.

—Анысын ничек беләсез?—дип сорыйм.

—Шуннан ким булса, ятмый. Яткач үлчәсән, шулай булып чыга.

Өйдә егерме биш мәчесе бар икән. Күршеләр аларны рәнҗетсә, әби үзе рәнҗи. Ире сугышта үлгән. Ялгыз яши.

* * *

Армиягә алынганчы кырда эшләп йөргән егет, солдаттан кайткач, бригадирның кыр эшенә чакыруына хәтере калып:

—Что син, Әхмәтша, сержант башым белән нишләп мин сабан сөреп йөрергә тиеш!—дип баш тарта.

* * *

Үзем өчен ят тормышның тәрәзәсеннән карагач, чирканып читкә борылдым. Менә ничек яшиләр икән шәһәр читендә! Яктылыктан, рухияттән читтә! Гайбәт—әнгәмәләрнең төп кызыгы. Эчкечелек—дуслык бәйрәме. Авыл тормышын кимсетергә өйрәнгәннәр, кала мәдәниятенә тоташа алмаганнар.

Ходай ярдәм бирсен.

* * *

Кич сөйләшеп утырганда, Ишкар авылы егете Хәнифҗанның көрәк шикелле кулларына игътибар иттем. Ул, моны сизеп, шундый аңлатма бирде:

—Мин солдатта чакта, старшина булдым. Лейтенантыбыз институт бетергән, каты эш итә белми. Аның өчен солдатларны мин кулда тотадырыем. Тәртип боза башласалар, йодрыкны гына күрсәтәм. Шым булалар. Исключительни порядкы. Политический кул бу!

* * *

Йоклый алмый ятам.
Караңгыда ефәк күлмәк кыштырдый.
Кызның сулышы тигез түгел.
«Юк, бу өндә түгел, төштә генә шулай!»—дип, үземне тынычландырам.

* * *

Бер көнне кичен Базы елгасы кара елгага әйләнде. Икенче көнне нефтьчеләр, елганы бульдозер белән буып, жыелган нефтькә ут төрттеләр. Төтен күкнең түбәсенә хәтле күтәрелде. Кап-кара төтен. Елга янганда, үзем дә сизмәстән:

—Балык шулпасы пешә!—дип куйган идем, икенче көнне балалар шул сүзне кабатлап йөрделәр.

Ничек ишеткәннәр диген!

—Елгада уха пеште, кунакка килегез!—дип кычкыралар.

Шаяру белән фажига чынлап та янәшә йөриләр шул.

* * *

Арыш басуы аша тар гына сукмак салынган. Шул сукмактан Мәчет саклавы аша Базы буена төштек. Арыш—кеше буе. Керәсең дә чумасың. Менә бит ничек уңган!

Басу тирәсендәге чаукалыклардан Эльбруска керпе эзләдек. Урманда да, болында да без актармаган бер генә куак төбе дә калмагандыр. Юк, керпе күрсәтеп булмады малайга. Бер генә керпе дә табылмады.

Болай кырны гына агулаганнар ләбаса!

Аның каравы, арыш—дингез кебек... Шулай да икебезнең дә кәеф кырылды...

* * *

Элекке елларда басуга тарма (киндер) чәчәләр иде. Аннары чәчелмәгән елларда да иген арасында үзләреннән-үзләре үсеп чыга иде. Боларын кем тели шул жыя. Зур капчыкларга тутырып кайтабыз. Орлыгыннан күмәч пешерәләр. Шул кадәр тәмле һәм туклыклы, кем әйткәндәй, итең бер якта торсын.

Быел кайткач, шуларның берсен сыдырып, кулга алып иснәдем. Ерак еллар хуш исе төсле тоелды. Бар иде бит чиста, гөнаһсыз заманнар! Хәзер исә тарманың яманаты чыкты. Имештер, ул—наркотик. Әйтерсең, үсемлек гаепле...

* * *

Хатын чит ир белән йөри. Шуны белгән Авыл Советы рәисе:

—Үзеңнеке жәл булмаса, кеше гаиләсен бозма, ичмасам,—дип кисәтә.—Аның хатыны бик көнчел, сизсә, жир тишегенә керерлек итәр,—ди.

Бу сүзләр иргә килеп ишетелә. Шунда ул:

—Ник минем хатынны усал дип даның сатасың?—дип, рәискә бәйләнә.

Һәм кыйнап та ташлый.

Шул рәвешле, хатынының намусын «яклап», төрмәдә утыра. Әнә бит нинди рыцарьлар бар безнең арада!

* * *

Безнең әнкәй җәй көне туган нигездә үзе генә яшәсә дә, кышларын, дөнья көтү кыенлашкач, балаларына күчә. Кыш буе: «Ихатамда әтәч кычкыртып яшәсәм иде әле»,—дип теләк тели. Ә җәй житкәч:

—Теләгем кабул булды, Ходайга шөкер,—дип, кошларга җим сала.

Әтәч күтәрмә култыксасына ук басып кычкыра. Югары дәрәҗәдә почетлы, кая барса шунда ул хуҗа. Курку дигән нәрсәне бөтенләй белми.

* * *

Илләр гизден, спорт ярышларында сан-исәпсез призлар яуладың, сувенирлар алып кайттың. Ә иң яхшысы—матур хатирәләрдер. Призларның авыры да, җиңеле дә булуы ихтимал. Ә менә дан дигәне, һичкайчан да җиңел була алмый. Ул һәрвакыт авыр...

* * *

«Айсбергларга ерактан карап кына сокланырга ярый»,—диләр диңгезчеләр.

Караңгы төннәрдә, томанлы көннәрдә аның коры җирдә дә күренүе ихтимал. Монда ул бигрәк тә куркыныч.

* * *

Күрше йорт балконында каз кычкыра. «Инешләрем, күл буйларым, чирәмле урамнарым ишетсен»,—ди микән? Шушы зур калага, диварлар арасына ник мине җибәрдегез?»—дип өзгәләнәме?

«Сөйгән апам, көлә-көлә сатты да җибәрде!»—дип каргана, ахрысы.—Саткансыз икән, туган җирләремне, инешләремне, күлләремне дә өстәп җибәрегез!»—дип ялвара бугай.

Зур кала шавын җиңеп, балконда каз кычкыра.

* * *

Чәчәк бәйләме өчен (икебана өчен) төз ботаклар бик сирәк кулланыла икән. Һәр бөгелешниндидер хәрәкәт төсмере бирә, кәеф халәте һәм сыйфат билгеләренә ишарәли.

Шуңа күрәдер, төзләргә урын җитми, аларга дөнья кысан, яшәү кыен.

* * *

Бөек кешеләр үзләреннән үзләре генә бөек булганнармыни? Юк, кайбер кешеләр югары рухи биеклеккә күтәрелә, үз шәхесләрен шул дәрәҗәдә үстерә, гаять зур эчке байлыкларга ирешә алган икән, тиешле шартлар булганда, ул югарылыкка күп кешеләр күтәрелә ала, дигән сүз. Гәрчә моның өчен кайбер очракларда берничә буын алмашынуы таләп ителсә дә.

Эволюция тарихи вакыйгаларга бәйле. Шунда, әлбәттә, «Язмыш» дигән төшенчә дә катнаша. Ләкин барыбер, шартлар, сәбәпләр хәл итә.

* * *

—Нишләп шулай икән?—дип сорады Эльбрус.—Кышны «красавица зима» дип каршылыйлар да, яз житкәч, ул убырлы карчыкка, ведьмага әйләнә. Үзен куып җибәргәндәй озаталар.

* * *

Оялчанлык чынлыкта булган сәләтләрне күрсәтергә комачау итә. Чынлыкта кешенең кем, нинди икәнлеге беленми, кеше бүтән төсле булып күренә. Димәк, оялчанлык тискәре ягына әйләнгән икейөзлелек булып чыга...

* * *

Кара жиләк (черника) куагы өч йөз ел яши икән. Җиләк җыйсак, ул куаклардан безнең ерак бабаларыбыз, әбиләребез дә җыйган булып чыга.

* * *

Берзаман лозунглар, плакатлар чуарланып тора. Өй кыекларына, коймаларга, диварларга заман сурәтләр, портретлар элә. Ә икенче заман, аларны кубарып, йолкып, чүплекләргә, подвалларга, иң яхшы очракта—архивларга ыргыта.

Өченче заман, шуларны эзләп табып, юа, чистарта, кояш яктысына чыгара.

Галимнәре, ачышлар ясап, биеккә күтәрелә.

* * *

Бала чакта явызлар, залимнар юк. Рәнҗетүләр, рәнҗетелгәннәр булмый. Абый-апаларның барчасы шәп, барчасы чибәр, юаш. Бүреләр дә, кәҗәләр дә бер җирдә йөри, бер күлдән су эчә.

* * *

«Бигрәк ихлас йоклый иден, уятырга базмадым»,—диде бичә иргә.

«Бер грамм димәс идем, ну, бер йөз грамм гына йоклап алдым»,—диде абзый моңа җавабында.

* * *

Мәҗлес вакытында патшаның сакалына ашамлык валчыгы кунганны күреп, вәзире:

—Падишаһым-солтаным, гөлгә кош кунган!—ди.

Патша аңлап сакалын сөртә.

Икенче бер патша, вәзире белән туалетка чыккач:

—Әнә бит кешеләрнең вәзирләре нинди тәмле телле. Икенче юлы син дә шулай матур итеп әйтергә тырыш,—ди.

Мәҗлес дәвамында икенче патшаның сакалына ашамлык валчыгы ябышканын күргәч, аның вәзире, әүвәлге хатасын төзәтергә чамалап:

—Падишаһым-солтаным, бая бәдрәфтә сөйләшкән әйберебез булды!—дип ярдәмгә килә.

* * *

Пятигорск базары. Җиргә рәт-рәт товарлар тезеп җәелгән.

Бер урында чәч толымнары ята. Сатучы апа аваз сала:

—Чәч сатам, чәч! Толымнар! Искиткеч шәп толымнар!

Ә баш үзе кайда? Ә матурлык? Чибәрлек? Сафлык? Алары күпме тора?

Ишетсәң дә, аңлыйсы килми.

* * *

Кавказда Лермонтов һәлак булган урынга куелган истәлек кыясына кемнәрдер үз исемнәрен акбур белән язып калдырган: «Алик, Боря, Вася. Мы здесь были».

Печоринның дуэльдән соң әйткән: «Финита ля комедия!»—дигән тәгъбире искә төште.

Ләкин тормышта—бүтенчә. Мәхәббәт һәм мәкер, фаҗига һәм комедия, шөһрәт сөю һәм ахмаклык дәвам итә. Алар—үлемсез.

* * *

Тын торуның нәрсә икәнен белмәгән пиратлар, Цезарь йоклаганда, шауламый торганнар. Уянгач, Цезарь аларга: «Минем йокымны бүлдермәгән өчен менә сезгә тагын мең ассы (фәлән мең сум буладыр инде) дип, акча бирә.

Тынлык антик дөнья заманында ук шулай кыйммәт торган, димәк. Хәзерге заманда исә, бигрәк тә шулай булырга тиеш. Ләкин... ләкин кая инде безгә аның кадерен белү!

* * *

Сабыйлар ихлас сөенә белә. Алар үзләренә бүләк ителгән дөнья өчен шатланалар, күрәсең.

* * *

Юлий Цезарьга Луций Сестий Гавий дигән философ: «Без икмәккә һәм тамашаларга гына мохтаҗ дип уйлау кабул ителгән. Әмма безгә тарих та кирәк. Улларыбыз һәм оныкларыбыз безнең хаталардан сабак алсын»,—дигән.

Хәзер менә: «Тарихка безнең дә хокукыбыз бар!»—дип өстисе килә. Хаталар төзәтү өчен генә түгел, үзебезнең Ходай тарафыннан яратылган хокукыбызныраслау өчен.

## Табигать-әнкә—зирәк

(1970—1980)

Локаторлар әйләнә дә әйләнә. Дөньяның һәр ягыннан алар сигнал көтәләр. Сугыш сигналы...

Көтүләре бушка була күрсен.

* * *

Шагыйрә әсәрләр укый. Шигърият сөючеләрне үз бүлмәсенә чакырган. Бер хатын кояшлы җылы көндә калын мохер шарфын җилкәсенә салган. Шарфның этикеткасын иң күренеп торган җиренә туры китергән. Өзеп ташламаган. Чит ил товары икәнен күрсәтергә, ирләрне кызыктырырга кирәк бит. Иң шәп, мактанырлык, башкалардан сине өстен итә торган әйбер—ул чит илнеке.

Шигырь сөяме хатын, әллә башка нәрсәнеме, шунысы да ап-ачык күренеп тора иде.

* * *

Елмаю—яхшы күңеллелек билгесеме?

Әйе, күп очракта шулай.

Ләкин кайбер очракларда шундый елмаюлар була, тәннәр чымырдап куя.

* * *

Матди кыйммәтләр беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия булган чакта, байлык шул кыйммәтләр микъдары белән үлчәнә. Гомум хезмәт культурасы белән, кешеләрнең белем дәрәҗәләре белән, аларның иҗади канәгатьләнә алулары белән түгел. Матди муллык тәэмин ителгәнгә кадәр шулай гына була ала. Ә муллыкның чиге бармы? Адәм баласының нәфесе: «Инде житте!»—дия аламы?

Нәфес, канәгатьсезлек—узып була алмаслык барьер. Кешелек аны сикереп тә, җимереп тә уза, чыга алмый.

Без җирдә көн күрер өчен матди әйберләр җитештерәбез. Вакытның төп өлеше шуңа сарыф ителә. Ә кайчакларда—бөтен гомер. Син шул шартларда үзеңнең рухи дөньяңны баетырга тырышмакчы, иҗади сәләтеңне камилләштермәкче. Ләкин андый шартлар бөтен җәмгыять өчен тигез түгел икән, синең андый камиллеккә хакың юк. Чөнки ул гаделсезлек булып чыга. Тулаем гаделлек мөмкин түгел булып чыга...

* * *

Табигатьнен бүгенге көне—ул шулай ук безнен киләчәгебез. Ул—фән предметы һәм эстетика кыйммәте. Аңа кимчелек китереп, без киләчәк җәмгыять каршында жинаять ясыйбыз һәм үзебезне дә эстетик кичерешләрдән мәхрүм итәбез. Кешелекнен хужалык эшчәнлеге планетар характер алды. Жир язмышы хакында кайгырту да шул масштабта булырга тиеш. Ләкин адәм баласы ул хакта кайгыртыр дәрәҗәгә житә алмаган шул әле.

* * *

Биогеносферада каты, сыек һәм газ хәлендә булган бөтен нәрсә—берләшкән хәлдә. Ул—кешелекнен анасы, кешене ул барлыкка китергән. Һәм аны аналардай күреп ихтирам итәргә, яратырга кирәк. Эксплуатацияләргә түгел. Икенче бер затны һәм табигатьне эксплуатацияләгән кеше азат та, әхлаклы да була алмый.

* * *

Һөҗүм итүче жанвар башта психологик атака ясый—ырлый, мырлый, күзләреннән ут чәчә. Үзенең гәүдәсен булганнан зуррак итеп күрсәтергә тырыша. Йоннары тырпая, калак сөякләре өскә калка. Кошларнын канатлары җәелә, бакалар һава йотып кабаралар.

* * *

Ана кошлар, партнер сайлаганда, гәүдәләрен кечерәйтеп, бөкшәеп йөриләр. Үзләренен яшьләрен киметеп күрсәтергә тырышулары икән бу. Әле генә канат чыгарган бала кош тавышы чыгарып, томшыкларын ашыйсы килгән төсле итеп ачалар. Кайбер ата кошлар шактый олыгайган бу затларны чынлап та ашата башлый. Алар китергән сый ир-атнын хатын-кызга алып килгән шоколад кабына туры киләдер.

Ана кош, ихтимал, ата кошнын көчле икәнен күрсәтү нияте белән шулай ялагайланадыр.

Гүзәл затларга хас изге икейөзлелек безнен беркатлы ир-атка бик тә, бик тә ошый бит!

* * *

Дөньяда бөтен нәрсәдән өстен күреп кадерләрлек мәхәббәт юк. Без үзебезнен мәгъшукаларыбыз белән рухи тугрылыкка исәп тотып яшәмибез, ләкин яшибез. Бу исә—табигый мәжбүрият.

Кем дә булса бүтән фикердә тора икән, мин аны гаепләмим. Ләкин мәжбүр итеп куелган тугрылык кешенен тормыш иптәшенә канәгатьлек китерми, ә киресенчә, үртәлдерә генә.

Рухи хыянәттән физик хыянәткә—бер генә адым. Ике, өч диясегез киләме? Анысы кешенен холык-фигыленә һәм форсатка бәйле.

Күзәтүләр, тәжрибәләр шундый нәтижәгә китерсәләр дә, мин мона гомер буе ышана алмыйча яшәдем һәм үземне зәһәрле үкенүләргә, югалтуларга дучар иттем...

Яшәеш—каршылыклар төене. Алардан котылмак юк. Үлемнән башка, дип өстик. Анысына инде беркайчан да сон түгел. Барыбер киләчәк, синнән башка да...

Мәхәббәттә тугрылык юк. Сина тугрылыклы хатын (яки ир) үзе өчен сөйкемле тоелган күп ирләр (яки хатын-кызлар) белән очраша. Алар анын хәтерендә нинди дә булса эз—мөһер калдыра. Һәм ул синен белән бер түшәктә булганда (сине яратканда) да тегеләр хакында уйлый. Син үзен дә кем турында булса да уйлыйсын. Кешене гомер буе бары тик бер генә кеше хакында уйларга мәжбүр итү мөмкин нәрсә түгел. Бу—кешене күзсез яки тагын бүтән нәрсәсез калдыруга бәрабәр.

* * *

Дөньяда жылылык җитми башлагач, аны кеше үзе жылытырга тиеш булачак. Кояшны кеше алыштыра, дигән сүз. Кеше—үзе Кояш, үзе—Алла... Шул рәвешле, монын дингә әверелүе ихтимал түгелме соң?

Матди һәм рухи стихияләр белән идарә итү—кешелекнең иң беренче миссиясе. Киләчәктә кеше дөньяны үзе иҗат итүче көчкә әверелергә тиеш була.

* * *

Антик дөнья традициясе Аллаларны табигать көчләреннән курку аркасында барлыкка килгән дип исәпли. Әгәр мәхәббәт тарафыннан иҗат ителсә?

Гаҗәпләнмәскә мөмкиндер кебек.

Әгәр Алласыз яшәү мөмкин түгел дип уйланылса, ул тулаем табигатьнең, материянең үзе булып чыга. Һәм бу дин беркайчан да искәрмәс иде. Бу хәл борын заманнарда мөмкин булган булса, төрле пот-санамнәргә табынунын хаҗәте калмаган булыр иде.

Мин дөньяда бер генә культны—табигатькә табынуны гына кабул итә алыр идем. Хәер, уйлана төшсәң, ул бар да бит. Табигать, ә кинәйтеп әйткәндә—материя шул Алла төшенчәсенә туры килә. Анабыз Табигатькә булган мәхәббәтнең изгегә әйләнүе һич тә анлашылмас нәрсә түгел.

* * *

Мещаннар өчен идеал һәм яшәү максаты—буш сүзләр. Аларның бөтен омтылышы—ашау-эчү, матур кием, тән рәхәте. Безнең телгә күчерсәк, әлбәттә, монысы да—идеал. Гомум кешелек асылда шушы принцип белән яши. Димәк, аны да мещанин диярга була. Ләкин дөньяда индивидиум дигән төшенчә бар. Индивидиумның мещанлыктан чыгу мөмкинлеге бар—башкалар мәнфәгате өчен, җәмгыятьтә өлешсез калган мәзлумнар өчен көрәшкә чыгу юлы. Бу очракта ул мещанлык дигән түгәрәк чылбырны өзә ала.

* * *

Күпләр өчен Табигать—хуҗасыз байлык. Аның хакында кайгыртунын нәрсә икәнен белмәгән промышленниклар җирне, суны, һаваны гына түгел, ә бәлки җаннарны да пычраталар.

* * *

Кешенең хайваннар дөньясыннан бүленеп чыгуы—ул тормышның катлаулана баруына, яшәү шартларының начарлана баруына карата булган реакциясе, ярашуы.

Димәк, бер-беребезгә: «Кыенлыклардан курыкмагыз!»,—дия алабыз.

* * *

Галлюцинацияләр вакытында кешеләр еш кына моңарчы үзләре күрмәгән нәрсәләрне дә күрә икән. Ул күренешләрне аларның ерак бабалары күргән булуы ихтимал. Мин моны нәсел хәтере дип атадым.

* * *

Кошларга һәм җәнлекләргә без үзебезнең психологияне көчләп тагабыз. Имештер, без ничек уйласак, алар—шундый. Енотлар—карак. Йомраннар, әрләннәр дә—караклар, чөнки кырда ашлык ашый, ашлык җыялар.

Арыслан—җәнлекләр патшасы. Библия традициясе буенча, еланнар—явызлык чыганагы. Төлке—хәйләкәр, куян—куркак.

Шулай санауны дәвам итәргә мөмкин.

...

Ир-ат иягеп сыйпый, хатын-кыз чәчен рәтли... Мондый хәрәкәтләр—тәнне чистарту инстинктына бәйледер. Шулай ук киеренкелекне киметә төшү, игътибарны читкә юнәлтү ысулы булуы да ихтимал.

...

Табигать еланнарга балаларын саклау инстинкты бирмәгән. Алайса, жир йөзендә еланнар чамадан тыш күп булыр иде.

Кабатламый хәлебез юк, Табигать-әнкәбез—зирәк.

...

Галимнәр раславынча, анасыз маймыллар женси аралашу теләге туарлык хәлгә житә алмыйлар икән.

...

Улыбыз Эльбруска, унике яшь тулгач, яңа кышкы пальто алган идек. Шуны киеп, урамда йөреп кергәч, сөенечен уртаклашып:

—И-и, әйбәт тә икән бу пальто,—диде.—Главное—жылы!

—Главное—матур!—дип төзәтмә кертте кызыбыз Розалия.

...

Тауларга көнләшеп карыйм. Ерак-еракларга күренеп торганнары өчен генә түгел. Алар чыгып килгән кояшны иң беренче булып күрә, баеп барган кояшны иң соңгы чиратта озатып калалар.

Болытларга да шундый хисләр белән карыйм.

Дөнья караңгыга чумган. Ә күктә болытлар сап-сары, кып-кызыл... Алар кояшлы шатлык кичерәләр.

Иртәнге, кичке шәфәкъ—кызыктыргыч, тылсымлы һәм... дөньяның мәңгелек серләренә таба агалардыр кебек.

...

Кыңгыравыннан аерылган чың, көеннән аерылган сүз, синсез калган мин, барыбыз да бер иш. Афродита түтәй безгә шундый язмыш билгеләгән.

...

Үпкәсенә салкын тиеп авырган Эльбрус саташып ята:

—Стена ава... Шулай бит... чынлап ава... стена.

...

Диңгез буендагы комга: «Антон + Герта»—дип язылган. Кыз, елый-елый, аяклары белән шул язуны сөртә.

...

«Нәрсә белән бетәр икән бу мәхәббәт?»—дип сорама. Минутларның кадерен бел. Мәхәббәтнең һәм гомернең ничек бетәсе билгеле.

...

Көндез кояш балкып торган чакта, шул ук күктә ай моная.

Бер сәнгатькәр күккә карап:

—Декораторлар айны алып куярга онытканнар,—дип искәрмә ясый.

...

Электромагнитлы дулкыннарның билгеле диапозонда тибрәлешеннән яктылык хасил була. Ә икеләнүчән кеше фикерләре диапозонынннан ничек икән?

Кабатланучы тибрәлеш дулкын дип атала. Бер кешедән икенче

кеше күнеленә күчә торган дулкыннар яшәешне яктырта да, карангылата да ала, диясе килә.

Иҗади яктылыкның да чыганагы шундый ук дулкыннардыр.

* * *

Лазер нурланышы ике көзге арасындагы тибрәнешләрдән хасил була, диләр. Хактыр. Чибәрүшкәләребезнең көзге янында озак булышуын бүтәнчә ничек анлатасың?

* * *

Цирк артисты хәнҗәр йота, җәрәхәтсез кала да, рәхәтләнеп көлә. Ә мин, рәнҗешемне йоткач, яшьсез үксим.

* * *

Бала аз фикерли, әмма күп күрә. Зурая төшкәч, күргәннәре барыбер фикергә әйләнә. Олы кеше күп фикерли, ләкин аз күрә.

* * *

Мин сине чын күнелдән яратканда, без еш кычкырыша идек. Мәхәббәт сүрелгәч, кычкырышмый башладык.

* * *

Син—элекке, бер җирен дә үзгәрмәгән. Мин сыйпый торган дулкынлы чәчләр, битләр, чигәләр—шул ук. Хәтта иреннәр дә элеккечә матур. Ләкин инде мин сиңа кул суза алмыйм. Иреннәр хакында әйткән дә юк.

Арада—чит еллар, ят уйлар һәм... ят куллар.

* * *

Мәхәббәттән күз яшьләре түккән чаклар... Кайда алар? Ул чактагы көчсезлегемнән хәзер оялам. Инде тынычмын. Ләкин элекке белән чагыштырганда, бәхетлерәкме мин?

* * *

Балыкларның ис сизү сәләте бик көчле икән. Җим салу белән килеп житәләр. Һәм... кармакка эләгәләр.

Кемнәргәдер:

—Борыныгыз бик сизгер булмаса да ярыйсы икән,—диясе килә.

* * *

Фрейд фикеренчә, безнең бөтен рухи яшәешебез беркайчан да туктамый, азагына җитми торган, аңлы һәм аннан аргы ихтыярлар көрәше рәвешендә, кылган гамәлләребез өчен җаваплылык һәм инстинктларыбызның җавапсызлыгы арасындагы кайнар бәхәс рәвешендә бара. Бер төрле уйлыйсың, карарга киләсең, ләкин еш кына икенче төрле эшлисең. Күнелдә гүя—ике «мин». Кайчакларда бу хисләр белән Ходай үзе идарә итәдер төсле тоела. Бигрәк тә—язган чакларда.

Коръән иҗат иткәндә пәйгамбәребез Мөхәммәт тә шундый халәт кичергәндер, мөгаен.

* * *

Ялгыш ычкынган сүзләрдә кешенең әйтергә тиеш тапмаган, әмма чынлыкта уйлаган фикерләре әйтелә.

Кешеләр онытылырга тиеш дип табылган нәрсәләрне оныта һәм югалтырга тырышкан әйберләрен югалталар да.

* * *

Күк гөмбәзе җимерелеп төшмәсен өчен кешеләр аңа терәүләр куя—

жир өстендә манаралар, һәйкәлләр калка. Табигать үзе дә кайгырта— өянкеләр, мең яшәр имәннәр күтәреп тора күк гөмбәзен...

* * *

АКШта, үзенә тун тектерү өчен заказ биреп биш леопард үтерткән өчен, бер кино йолдызын судта хөкем иткәннәр. Бездә мона игътибар итәрләр иде микән? Иткән очракта да хатын-кызлар мона кызыгып кына игътибар иткән булырлар иде. Биш ерткычны түгел, биш милләтне юк иткәндә дә каршы сүз әйтелмәгән илдән бүтән ни көтәсен.

* * *

Мәскәүдәге «Просвещение» нәшриятында басылган «История средних веков» дигән хрестоматиядә Болгариядә әсирлектә булган бер чех кешесенен истәлеге китерелә. Анда: «Болгар дигән халык турында анын Волга исемле скифлар елгасы буеннан килгәнлеген искә алалар... Һәм шул елга исеме белән алар болгарлар, ягъни волгарьлар дип атала икән»,—дигән сүзләр бар.

* * *

Ир белән хатын язылышмыйча яшиләр. Кеше арасында ир: «Мин өйләнмәгән әле»,—дип, ә хатын: «Мин иргә чыктым, әйбәт кенә торабыз»,—дип сөйли икән.

* * *

Борын заманда падишаһ каршында жинаятьчеләргә хөкем бара. Вәзирләр тәкъдим кертәләр. Беренче вәзир:

—Тереләтә утка салырга!—ди икән.

Икенчесе:

—Балта белән туракларга!—ди.

Өченчесе әйтә:

—Тереләтә суга батырырга кирәк!

Читтәрәк утырган бер кеше патша ишетерлек итеп кенә:

—Һәр нәрсә үз асылына тартыр,—дип сөйләнә.

—Анысы ничек була?—дип сорый аннан падишаһ.

—Вәзирләрнен беренчесе элек янгынчы, икенчесе—терлек сугымчысы, өченчесе тегермәнче булган.

—Ә син үзен кем буласын?

—Беркем дә түгел, мин—Хозыр Ильяс кына.

* * *

Радио, телевидение, газеталар, төрле журналлар хөкүмәт башындагы кешеләрнен ниятен безнен башларга, лепкәгә кадак төсле итеп кагалар. Чүкечләр каты, авыр. Ә сакланырга безнен кулда бернинди корал да юк. Йолкып булмый кагылган кадакларны. Йолка башласан, авыртуга чыдап булмый, күнегеп булмый.

* * *

Тау ягы алиһәсе уйнарга килгән жирдә чәчүргеченме, билбавынмы онытып калдырган. Җәйге төндә, түбәндә шул инеш төсле бормаланып, ялтырап ята.

* * *

Терлекче егет кибеткә керә.

—Коньяк бармы?

—Юк иде шул.

—Нәрсә, кешесенә күрә дә юкмыни?

Кешеләр көлешә. Егетнен үз дәрәжәсен нindirәк дип санавын анламыйлар бугай.

* * *

Яңгыр ява. Яфрак клавишларга тамчылар тама. Тамчылар тамган саен яфраклардан бию көе тәсле тере аһәң сирпелә. Тигез һәм шатлыклы көй тарала. Яшәүнең чиксезлеге, рәхәтлеге турында сөйли торган яшел моң тарала дөньяга.

Яңгыр ява.

* * *

Урамда күлдәвекләр җыелды.

Яңгыр тукталгач, күк аязгач, күлдәвеккә яшь ай төште.

Кешеләр, күлдәвек аша атлап, айны таптады, изделәр. Әмма алар узгач, яңадан тынычлык урнашып, яшь ай яңадан бөтен яктылыгы белән балкып китте. Ул һаман якты, чиста, саф иде.

Көн яктыргач кына, күктән ай-әнкәсе аны үз янына күтәреп алды. Анда инде аңа беркемнең дә аягы баса алмаячак. Хәтта кулы да җитмәячәк.

* * *

Төннең кара чаршавын җил тартып төшергәч, кояш чыккан чакта, гүзәл бер Алиһә су буена килде. Көн яктысын, күк зәңгәрен чиләкләренә мөлдерәмә итеп алды да, сукмактан атлап китте.

Ул безнең күрше кызына тартым иде.

* * *

Әрсезлектән берзаман оялыр чак җитәр әле, дип уйлый идем. Юк, җитмәде андый вакыт. Оялырга тиешле бәндәләр инде зур дәрәҗәле, мәһабәт абзыйларга әверелделәр. Бик тә симпатичныйлар...

* * *

Гүзәл идеяләрне, аренадан киткән җитәкчеләренең сурәтләрен бәндә һичбер икеләнүсез, илтифатсыз гына таптап узды. Каядыр ашыга иде.

* * *

Финнарда шундый әйтем бар икән.

«Әгәр кешегә мәңгелеккә кыя бирсәң, ул аны чәчәк атып торган бакчага әверелдерә. Әгәр дә ун гына елга чәчәкләр атып утырган бакча бирсәң, ул аны чүлгә әйләндерер иде.»

* * *

Галимнәр: «Безнең сөякләрдә кургаш, автомобильләргә хәтле чор белән чагыштырганда, 180—200 тапкыр күбрәк»,—диләр.

Генофондны саклау өчен табигатьтә—һәм җәмгыятьтә дә!—тыюлыклар оештырырга туры килмәгәе.

* * *

Ялгышлык аркасында килгән кайгы—иң ачы хәсрәт, фаҗига.

Иртән яп-якты көндә, кеше автомобиль белән эт таптатты. Көне юкка чыкты. Көне генә дә түгел. Юри эшләнгән эш түгел бит, югыйсә. Үзе гаепле булса, бәлки җиңелрәк кичерер иде.

* * *

Кичереш—хәрәкәт рәвеше. Аның мантыйгын ачыклау кыен. Җенси мөнәсәбәтләр, хис, дәрт—шулай ук кичереш. Иктисад һәм хуҗалык эшләре барышында аның арткы планга күчеп торуы ихтимал. Ләкин күчми. Мөһимлек ягыннан караганда, алай булырга тиеш түгел кебек, югыйсә.

* * *

Төштә туган фикер.

Халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне бозар өчен гади интриган

булу житә. Ә дуслаштыру, берләштерү өчен бөек акыл иясе булырга кирәк.

...

Синен яратуын авырлыгын күтәреп йөрү авыр иде. Ә яратмавын авырлыгын күтәрү тагын да авыррак.

...

Куян урман буйлап чабып йөргәндә күрә: агач башларында ике карга көлешә-көлешә утыра.

—Ник шушы хәтле шатланасыз?—дип сорый куян.

Бер карга:

—АББА дискосы таптым!—ди.

Икенчесе:

—Ярты литр аракы таптым!—ди.

Ерак та түгел, өченче карга елап утыра.

—Ә син ник елыйсын шушы хәтле ихлас итеп?

—Берни дә тапмадым.

Куян ары чаба. Береаздан кабат каргалар янына килсә, бөтенләй икенче хәл. Ике карга елап утыра, ә бая гына елаган өченче карга рәхәтләнеп җырлый. Куян үзгәрешнен сәбәбен сорый. Беренче карга дискосын югалткан. Икенчесе ярты литрдан колак каккан. Өченчесе көлүен белә. Ник көлгәнен сорагач, баягыдан күнеллерәк итеп җыр суза:

—Мони, мони, мони! Ыһ-һык!

Очкылык тота өченче карганы.

...

Янгыр ява. Чиләкләп коя дию дә житмәс, дингез убылып төшә диярлек. Дөнья үзе дәрьяга әверелә. Бөтен жирдә су, су, су.

Тик бермәлне күк күкри, яшен яшьни. Шундый яшен, әйтерсен, дингезгә әверелгән күкне ут каплый. Яшен хәбәр сала:

—Онытмагыз, жирдә ут та бар, ут та бар!

Күктән утлы янгыр ява.

...

Тышкы як тәрәзә төбендә күгәрченнәр кояшта кызына. Февраль кояшында. Алар өчен Кара дингез комлыгы шушыдыр инде.

...

Сугыш вакытында тургайлар шулкадәр күп, шулкадәр ихлас һәм кыю сайрыйлар иде, гүяки жирдә гел шатлыклар гына тантана итә. Гүяки дөнья матур да, тыныч та.

Хәзер исә, тыныч заманда, алар сирәк күренә һәм курка-курка гына сайрыйлар...

## Хезмәт–намус һәм вөҗдан эше

(1983—1989)

Суер (урман тавыгы) балдак кидерүне кабул итә алмый икән. Стресстан йөрәге ярылып үлә. Балдак алар өчен безнен богаулардан яманрак, күрәсен. Күпчелек кошлар, адәм балалары төсле үк, түзә.

...

Тын бакчаны гел тыныч була дисезме?

Әнә бит, ала каргалар зәһәрләнеп ябалакка ташлана. Ә ябалак, кышкы кояшнын саран нурлары астында, зирәк философларча, тынычлык һәм үзенә ышаныч белән йокымсырап утыра бирә. Ябалактан бер генә

бөртек каурый да, мамык та төшмәячәк, бер генә карга да ана ныклап кагыла, чукый алмаячак. Чөнки каргалар, бердәм тоелсалар да, чынлыкта җитми аларга бердәмлек тә, тәвәккәллек тә. Мәгәр һәркайсы үзеннән канәгать. Туйганчы каркылдап, көнчелек һәм үч сусыны басылгач, батырлык кылган кыяфәттә таралышалар.

Безнең язучылар җыелышларындагыча. Батырлар күп, зирәкләр дә юк түгел.

* * *

Кеше күзлек кигән. Күрә карау. Мангай тирәсендә җөйләр шактый ачык күренә. Характеры белән киредер, бәйләнчектер. Бәләкәйдән үк эләгә килгән булса кирәк.

* * *

Һәркем игътибарга лаеклы. Шуна күрә, ул, игътибар сизмәгәндә, бигүк урынлы булмаган рәвешләрдә үзенә игътибар җәлеп итәргә тырыша. Минем дә андый хәлләр булгалады. Кайберләренен зыяны гомерлеккә киткән чир булып калды.

* * *

Бәхет сүзгә мохтаҗ түгел, дибез. Кайчакта бәхеткә, рәхәткә түзә алмыйча, кычкырып җибәрәсе килә. Ымлыкларга сыеп бетә ала ул. Әмма күпме җырлар, көйләр, сүзле һәм сүзсез моннар, таштан һәм бүтән төрле әйберләрдән ясалган сурәтләр!

Бәхетне, мәхәббәтне ымлыклар түгел, сүзләр, авазлар, сурәтләр дә аңлатып бетерә алмый. Мәхәббәт тә, бәхет тә аларны үзләре иҗат итә. Ә иҗатның чиге юк.

* * *

Күпме генә качып йөгерсән дә, күләгәннән котыла алмыйсың. Карангыга кереп югалсаң гына ул юкка чыгар. Ләкин монысы җайлы ысул түгел. Иң җайлысы—күз йому, көнгә, яктылыкка, дөньяга, оятка...

Таплы хатирәләрдән шулай гына котылып буладыр.

* * *

Менә бит нинди парадокс: культура үскән саен, варварлык көчәя бара. Ул культураны, цивилизацияне юкка чыгару белән яный. Кешеләрнең тарихта күрелмәгән санда үтерелә баруын әйтәсе дә калмый...

* * *

Астрономнар йолдызларнын утыз проценты игезәкләр дип саный. Йолдызлар бер-берсен каплый булып чыга. Ләкин спектрда барыбер күренәләр, чынлыкта алар барыбер—мөстәкыйль. Кара булмасалар...

* * *

Авылда елның һәр фасылы бәйрәм булып килә.

Җирне аклык белән күмгән беренче карлар, өметләргә яктылык өстәгән беренче тамчылар, кошлар кайтуы, язгы күкрәү һәм гөрелтеләр, беренче яфраклар, чәчәкләр—бөек тантаналар.

Печәнгә төшү—бәйрәм.

Уракка төшү—бәйрәм.

Ә көзге төсләр, уңыш бәйрәмнәре?!

Алар бетсә, авыл бетә.

* * *

Анна Павлова—атаклы балерина—сәхнәдән китмәс өчен ана булу бәхетеннән баш тарта.

Бу нәрсә? Эгоистлыкмы, җәмгыятькә хезмәт итү хакына китерелгән корбанмы?

Безгә: «Ике бәхет бергә туры килми»,—диясе кала.

* * *

Сугыш алдыннан кешеләрнең эшкә карашы да, техниканың кадере дә хәзергечә түгел иде. Менә шуның бер мисалы.

Язгы ташкын, буаны ерып, тегермән турбинасын агыза башлагач, тегермәнче аның артыннан суга сикерде һәм шуның белән бергә үзе дә агып китте.

* * *

Тормыш факты, кешеләр теленә күчкәч, ул инде саф факт кына түгел, ул инде—тойгылар төсе йоккан, күпмедер дәрәҗәдә сәнгатьле факт. Язмага күчкәч—бигрәк тә. Тарихи фактлар белән дә эшләр шулай тора.

* * *

Тарихи фактлар авторның шәхси мөнәсәбәте, директив оешмалар мәнфәгате һәм җәмәгатьчелек фикере тәэсирен кичерә. Шул сәбәпләр аркасында, алар алдагы дәверләргә реаль хәлләреннән ераклашкан рәвешләрдә килеп җитәләр.

* * *

Факт кызыклыгына кайтып калган әсәрләр, вакытлы хөкүмәт шикелле, үзенең властен—тәэсир итү көчен—озак саклый алмый. Икенче вакытта аның кызыклыгы үзгәргән, кирәклеге беткән булырга мөмкин.

* * *

Фактларны, образларны сайлау һәм бер-берсенә бәйләү рәвеше—материалны тасвирлау формасы—авторның сурәтләү манерасын, стилен барлыкка китерә.

* * *

Үзләренең карьеристик максатларын җәмгыять мәнфәгатьләреннән өстен күрүче буын барлыкка килде. Дөньяның, тормышның үзенә юкка чыгу куркынычы янап торса да, алар шул куркынычны да үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга тырышалар. Иртәгә дөнья бетсен, дөнья бозга әйләнеп катсын, тик менә хәзер, тик менә әлеге мизгел аның өчен отышлы булсын. Бары тик ана гына һәм хәзер. Бүген!

* * *

Илдә:

—Тыйнаклык кешене бизи!—дигән сүзләргә ышанган чаклар бар иде.

Хәзер тыйнаклык—ахмаклык билгесе. Хәзер ул үзенең кимчелеңне тою (комплекс неполноценности) сыйфатында кабул ителә.

* * *

Бәләкәй чакларда, ашлык сукканда, ат куа идек. Барабан әйләндерү өчен. Көннәр буе атлыйбыз, ә беркая да китә алмыйбыз.

Хәзер генә башка килде: бу да—тормышыбыз рәвеше булган икән. Безнең алга барышыбыз...

* * *

Мәктәптә укыганда, узган дәрестә үтелгәнне кабатлый торган идек. Яши торгач, сабакларны күп алдык. Ләкин үткәннәрне кабатлап булмый...

* * *

Үткәннәрне, тарихны фаш итү—безнең гомерләрнең зая узуын тану дигән сүз. Табигать биргән вакыт яшәлмәгән, диярга туры килә. Аны ничек кайтарырга? Бушлыкны ничек тутырырга? Ә табигать бушлыкны белми...

Минем монарчы яшәлгән алтмыш елым—тарихи хаталарга сыеп бетә. Шушындый да югалтуны ничек кичерергә? Ничек килешергә? Ничек?!

Шуңа күрә, хаталарны юк диясе, җинаятьләрне дә аклыйсы килә. Кичерегез.

* * *

Агач башларыннан, күктән зәп-зәңгәр, нәп-нәзек аваз төшә:
—Фью, фью! Түтекәй! Түтекәй!
Песнәкләр сөенече.
Язның, мәхәббәтнең, яшәүнең тыелгысыз авазы.
Кояшлы кар ява. Ак карга да зәңгәр, күк төсе сеңгән.

* * *

Яшел уҗым киңлегендә, рәхәтлеккә түзә алмыйча, куян чаба.
Җәйгә таба, яңа өметләргә, бәхетләргә таба!

* * *

Ниһаять, шундый кызык заман кичерәбез. Бөлгенлек, ачлык һәм өметсезлек заманы. «Үзгәртеп кору» дип аталган җимерүләр заманы. Отышлар һәм канга батып сугышу, үтерешләр заманы. Оятлы җиңүләр һәм бөек югалтулар заманы. Икмәк бәясен күтәртмәс өчен ил башлыгы рельскә, поезд алдына яткан, исән калган заман.

Бөтен халык биюе... Сарабанда диләрме?—башланып, кызганнан кыза барган заман.

Читтәрәк торган кыз бала:
—Мине дә чакырыгыз биергә, мине дә чакырыгыз!—дип көй суза.
Шундый кызык, җылыйсылар килә.
Ләкин түзәбез.
Шундый заман.

## Тугансың икән, яшә

(1990—1999)

Урманда тавышы таныш булмаган, моңарчы ишетелмәгән кош сайрый. Сулыш алудан туктап, тын калабыз. Таң калабыз.

Яңа талант—тансык.

* * *

Безнең күрше агайларның берсе, кешеләр юлга чыкканда; «Морҗаң күренмәгән җирдә марҗа хәләл»,—дип озата торган иде.

* * *

Синең төсеңдә, табигатеңдә төзәтергә кирәк булган бернинди кимчелек тә юк. Синнән мең гаеп табу өчен менә шул сәбәп тә инде. Гүзәллек—гайбәт чыганагы. Син гүзәл яки талантлы икән, гайбәткә һәм нәфрәткә дучар. Сафлык белән, хаклык белән туктатырмын димә аларны. Хөсет көчне генә таный.

Гайбәт һәм яла—мактауның яшерен төрләре. Аңласаң да, шулай макталсаң да, барыбер җиңел түгел шул. Түзәргә, түзәргә генә кала.

Гафу ит, чибәр, ихластан әйттем.

* * *

Чәчәкләр үз төсләрендә генә була ала. Үзләре булып чәчәк ата,

үзләре булып яши һәм үзләре булып сула. Исемнәренә, төсләренә, исләренә хыянәтсез кала.

Кешеләр кебек меңгә төрләнмиләр чәчәкләр.

* * *

Маңгай күзем синең кимчелекләреңне, килешеп бетмәгән җирләреңне күрә. Ләкин күңел күзе моның белән ризалашмый. Күңел күзе белән маңгай күзе бәхәсләшә. Күңел күзе җинә бара.

* * *

Директор яңа ел алдыннан башкарылган эшләр хакында хисап бирә. Унай эшләр арасында шунысын да билгеләп үтә:

—Быелгысы елда җитди үлемнәр булмады...

* * *

Татар хатыннары һәм кызлары чит илләргә китсә, аларның уллары шул илнең солдатлары була.

Үз иленә ата...

* * *

Быел алмалар агачларның эчке ботакларында күбрәк булды. Читтән караганда, алма бик тә аз, сирәк кебек. Кәүсәнең янына ук килеп, астан карасаң, тәлгәш-тәлгәш алмалар.

—Моның бөтен байлыгы эчендә, күңелендә, ә тыштан үзе нинди тыйнак!—диде беребез.

—Байлыгын яшергән, астыртын икән,—диде икенчебез.

Менә син объективлыкка исәп тот!

* * *

Ходай үзенең балаларына иң кыйммәтле байлыгын шулкадәр мул өләшкән, җирдә бер генә адәм дә үзен акылсыз дип исәпләми, зарланмый. Ә менә бәхетне кешесенә күрә генә, сайлап кына биргән. Бәхет җитмәгәннән зарланмаган кеше юк диярлек.

* * *

Эссе көнне яр буенда утырган адәмнән: «Нишлисең?»—дип сорадылар. «Су киптерәм!»—дип җавап бирде ял итүче.

* * *

Элек тимер пәрдә ил чигендә генә иде. Хәзер исә, илдәге һәр йорт тәрәзәләрен тимер челтәрләр һәм ишекләрен корыч плитәләр белән капладылар. Ил киңлеге белән фатир киңлеген чагыштырсаң, яшәү мәйданыбызның киңлек дәрәҗәсен чамалау кыен түгел булса кирәк. Металлга ничек экономия ясалуын да әйтәсе калмый, шаять.

* * *

«Салкын тиюдән саклан, эссе кабудан саклан, яман сүзләрдән саклан, яман күзләрдән саклан, дуслардан, дошманнардан саклан!»—диделәр. Әмма гел сакланып кына торсаң, кайчан яшәргә?

Сәламәтлек өчен мәхәббәт тә, хәтта яшәү үзе дә зарарлы бит. Нишләргә соң?

Бүтән юл юк: тугансың икән, яшә!

# ШИГЪРИЯТ



## Гәрәй Рәхим

### Татар мадонналары

*Күренекле татар рәссамы Илдар Зарипов иҗатында татар хатыннары, татар кызлары образлары үзенчәлекле урын алып тора.*

**Киндереңдә туган яклар,
Туган кыр, болыннары...
Моңлы ханым... Әнә аны
Иркәли колыннары.**

**Киндереңдә Ил һәм Тарих,
Көмеш чулпы чыңнары.
Монда көйнең ялганы юк,
Монда көйнең чыннары.**

**Киндереңдә хатыннарның
Таза, көр, ялгызлары...
Безне йөгәнләгәннәре,
Безне аздырганнары...**

**Киндереңдә Ат һәм Хатын—
Илне сөйрәп баралар.
Алар элек тә булганнар,
Һәм бүген дә бар алар!**

**Киндереңдә татарымның
Кайгы, шатлык, моңнары.
Күзләремә карап тора
Илдар мадонналары,
Татар мадонналары.**

## Җәкәү дәдәй

*Атаклы керәшен шагыйре Яков Емельяновның туууына 150 ел тулу уңаеннан.*

Җәкәү дәдәй, сине сагынам мин
Йөз илле ел гомер үткәч тә.
Бу тарихның күпме патшалыгын,
Тәхетләрен җыеп сүткәч тә.

Җәкәү дәдәй, күпме әләк күрдең
Керәшеннән, татар, урыстан.
Ә чынында, әхлак дөньясында
Син түгел бит, алар[1] ырыстан.

Җәкәү дәдәй, син тырыштың һаман
Җирдә булсын бары хаклык дип.
Саклыйк әле туган халкыбызның
Җырын, көен, телен саклыйк дип.

Бүген сине халкың ярата да,
Исемеңне илгә тарата.
Җәкәү дәдәй, Яков Емельянов,
Син бит безгә рухи бер ата...

Сине бүген халкың ярата!

## Яңгыр тавышы

Усал кыш үтте,
Ярлыкады Тәңре—
Ниһаять, көннәр язга авышты.
«Быелга әле яшәтәм сезне»—дип
Түбәләрдән дәште яңгыр тавышы.

Күңелләр сөенде, бәдәннәр яшәрде,
«Плюс»лар, «Минус»лар үзара кавышты.
Өмет, дәрт, үрчемгә чакырды
Борынгыдан килгән яңгыр тавышы.

Без дә тиз кузгалдык, хәрәкәткә килдек—
Сөрдек, сукаладык, чәчтек, тырмадык.
Ызаннарга ятып мәхәббәт кылдык—
Шөкер, язык булыр дип тормадык.

Табигыйдер ки, тудык без буразнада,
Үстек түтәлләрдә, җиргә ябышып.
Иркәләде безне моңсу симфония—
Сыңар бер тактлы яңгыр тавышы...

...Без күп кыландык, булгандыр инде
Кемнеңдер рәхмәте, кемнең каргышы...
«...Шыбыр... Шыбыр...»—дип,
«Сабыр... Сабыр...»—дип,
Ярлыкый Тәңре—яңгыр тавышы...

---

[1] Ырыстан—ристан.

## Җилтотар

Бу җилне кул белән тотып була—
Шундый назлы хәтта күзләрен.
Бу җил белән мин битемне юам—
Яшәреп үк китә йөзләрем.

Кулга тыгыз, биткә иркә җил ул
Җылы, нәфис, татлы, җилле җил.
Чәчләремнән килеп сөеп китә
Такташ әйткән «нечкә билле җил».

Мин бу җилне җыям зур тубалга,
Учлап-учлап сибәм дөньяга.
Дөнья йөзе чистарынып кала—
Мине сөеп яңа көн бага.

Дөньядагы бөтен байракларны
Иркә җилдә чайкап юамын.
Президентлар, парламентлар, илләр
Сафлана барыр дип, куанып.

Җил куучы бер җилкуар түгел,
Бер җилтотар булдым мин бүген.
Җилдәй җитез зиһен, хыял белән
Җилгәрергә исәп ил күген.

## Кеше башлы гыйфрит

*Гыйфрит—Зур гәүдәле, көчле, куркыныч, диюнең бер төре дип уйланылган җан иясе дип санала; Артык усал, явыз, рәхимсез кешеләргә карата әйтелә.*

*Дию—Бик зур, ямьсез, куркыныч гәүдәле, бер яки күп башлы, төрле кыяфәткә керә ала торган, мәкерле, кеше ашаучы итеп тасвирлана торган мифик зат.*

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1 том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977 ел, 281 һәм 309 битләр.

Балык башлы халык...
Урыс башлы татар...
«Мин—Дию!»—дип йөргән башсызлар—
Болар инде бездә бар да бар...

... Мин күзеңә карап чынын әйтәм,
Егерменче гасыр, гафу ит—
Синдә генә, синдә пәйда булды
Кеше башлы гыйфрит.

Ул яшереп тормый кыяфәтен,
Ул ояла белми үзеннән.
Ул гәүдәгә безгә бик охшаган,
Безне алдый безнең сүз белән.

Аның йөзе бөтен тәүлек буе
Телевизор экраннарында.
Ә куллары безгә тама торган
Изге бюджет краннарында.

Милләтче һәм галим булып китә.
Кайда җыен, шунда тартыла,
Ул—журналист.
Конкурска чыга—
Ул бит кыйбатрак сатыла.

Мәчетләрдә, чиркәүләрдә йөри,
Мулла була, була атакай.
Чын диндарлар акча гына бирсен—
Уңда тәресе бар, сулда—ай.

Безнең балаларны өйрәтә ул
Наркопокупатель булырга.
Шуның белән бизнес-җай чыгара
Кесәсенә доллар тулырга.

Ашаганы шул «яшел кәбестә»,
Ул бит банкирларның башлыгы.
Аңа шәраб—безнең күз яшьләре.
Йөрәк итебездән шашлыгы.

Сәясәтне уңга-сулга борып
Без үзебез аны булдырдык.
Аның ата-аналары без бит,
Аны без үзебез тудырдык.

Үз кулыбыз белән рәсемнәрен
Мәйданнарда йөрдек күтәреп.
Трибуналарга алып мендек
(Аһ, ташлыйсы булган түнтәреп!)...

Безнең үзебезгә бик охшаган—
Бер үк камырдан без,
тәндә бер ит.
Арабызда йөри—чор тудырган
Кеше башлы гыйфрит...

## Идел-Каспий

«Мәхәббәтең кышкы Идел»,—дисең.
Ә үзеңә тыңлисең син Каспий көчен.
Әнә Идел язны көтеп ята
Каспиена торып чабар өчен.

* * *

*«Кара юрга» җырын тыңлагач*

Сиңа барыр өчен ак юллар юк,
Чыктым кара юлга.
Тез тиңентен кара балчык ерып
Бара кара юрга.

*1999—2000.*
*Казан—Саралан*

*Хәсән Туфанның 100 еллыгына*

# ЗУР ТАЛАНТ, ЯКТЫ ШӘХЕС ИДЕ...

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ӘДИПЛӘРЕБЕЗ

**Илдар Юзеев:**

Егерменче гасырның илаhи талантлы ике шагыйре үзеннән алдагы традицион шигырьне инкарь итеп, юкны табарга дип аваз сала. Үзенең Тукай шигыреннән килеп чыгуын оныткан яшь Такташ шулай. Туфан да, бунтарьларча, йөрәкне инкарь итеп килә. Кушаматында ук—өермә, давыл, җимерү... Ике бунтарь: Туфан һәм Такташ, искене җимереп, яңа пролетар поэзиясе тудыру өчен көрәш башлыйлар. Егерме алты яшьлек Туфан, табигый лирик җанына ирек бирмичә, бунтарь Хабулны иҗат итә. Шагыйрь өчен шигырьдә иң элек—акыл, образ-сурәт. Чор шундый геройларны таләп итә. Ритм—ватык, ирекле, авыр, Хабулның үзе шикелле дуамал. Аннан соң эшче Минап, Чапый, Гыймай... Шагыйрь-рәссам кулы белән сурәтләнгән типлар, образ-сурәтләр шул килеш тә поэзиядә кабатланмас бер чор булып калалар. Утызынчы елларда Туфанда—борылыш. 1933 елда язылган «Аккаен» шигыреннән башлап ул «йөрәк кебек жылы уй»га күчә башлый. Ритм төзекләнә, фикер хистән, эмоциядән туа. Белмим, бәлки, аны якын дусты Такташның үлеме тетрәткәндер. Ә бәлки Такташтагы ирекле шигырьнең, новаторлыкның миллионнар күңеленә барып тоташканын үзе тоеп торган Туфан—йөрәгенең табигый агышына ирек биргәндер. Бәлки, Такташның аның турында: «Соңгы вакытта Туфан үзенең шигырьләре эчендәге сирәк, ләкин яшь, яңа хисләре, күп вакытта гакыллы тирән хисләре белән җанга жылылык кертә башлады» дип язып калдырган сүзләре уйга калдыргандыр... Кем белә, бәлки, аны Сәйдәш музыкаль ритмнарының халык күңеленә нәкъ Такташча табигый агышы тарткандыр...



*Хәсән Туфан, Илдар Юзеев, Абдулла Әхмәт Мәскәүгә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына барганда— юлда. 1957 ел.*

Ничек кенә булмасын, Туфан үзенең эволюциясендә иҗатының иң олы биеклегенә—Гүзәл Гамьгә бара һәм илленче елларда «Агыла да болыт агыла», «Киек казлар», «Кайсыгызның кулы җылы» кебек шедеврларны тудыра.

Шулай итеп, Туфан Гамьне, уйны-фикерне гүзәл итеп бирүнең югары дәрәҗәсенә ирешә һәм поэзиябезне Гүзәл Гамь дигән яна үргә күтәрде.

**Ләбибә Ихсанова:**

1958 елның җәендә язучыларның Аккош күле буендагы дачасында Хәсән ага Туфан белән бер йортта яшәгән идек. Кояш чыгышына караган зур бүлмә аныкы, калган ике кечерәк бүлмә безнең гаиләнеке иде.

Шулай бер кичне кухнядан чәйнек тотып чыгышыма Хәсән ага Туфан очрады. Кайдандыр кайтып килеше иде ахыры, кулында ромашка чәчәкләре.

—Рәхмәт, Хәсән абый,—дидем.—Чәй эчәргә керегез.

Шагыйрьнең яраткан чәчәкләрен сулы банкага куеп, өстәл әзерли башладым. Бераздан Шәрәф аны чәйгә чакырып алды. Туфанның кулында яшел кара белән язылган бер бит кәгазь иде. Аның бүлмәсендә үк бу кулъязма турында сүз булган күрәсең, Шәрәф шуны дәвам итеп:



*Хәй Вахит, Хәсән Туфан, Зәки Нури, Ләбибә Ихсанова һәм Мирсәй Әмир СССР Язучыларының 1966 елда булып узган IV съездында*

—Тагын бер укыгыз әле, Хәсән абый, Ләбибә дә тыңласын,—дигәч, шагыйрь сөекле хатыны, татар халкының яраткан артисткасы Луиза Салигаскәровага багышлаган шигырен укыды. Күпләрнең күңеленнән китми торган, моңлы җырга әйләнгән «Әйткән идең...» дигән шигырь иде ул. Бу кичтә мин аны Хәсән ага үзе укыганда тыңладым. Ул аны тәмамлап кына куйган әле, акка да күчермәгән, уйларына, хисләренә ирек бирергә теләп, урманга чыгып киткән... Соң гына, караңгы төшкәч кенә, тынычланып кайтып килеше булгандыр инде аның, миңа чәчәкләр биргән вакыты...

**Мәсгуд Гайнетдин:**

Туфанны язмышы, иҗат эшенә, зур шагыйрь булырга махсус әзерли кебек. Ул һәрчак аерым игътибар үзәгенә юлыккан һәм бу аның характерын, шәхесен формалаштыруда хәлиткеч роль уйнаган. Сабый чакларыннан шулай. Әнисенең соңгы улы, иркәтае. Читләр, җәмәгатьчелек—авылларында бөтен халык тырышлыгы

белән оештырылган беренче стандарт мәктәпнең рәсми мөгаллиме—укытучысы аерым игътибар биргән укучы. Сабый чакларындагы әнкә назын һәм беренче укытучысы игътибарын ул «Бәлки шагыйрь булмас та идем» дигән мәкаләсендә сокланып искә ала.

«Яңа мөселман» («отпавший»лардан) булганы белән, «Галия» мәдрәсәсендә дә ул укытучыларының һәм сабакташ шәкертләрнең аеруча ягымлы-кайгыртучан игътибар үзәгендә була. Бу нәрсә Бабич белән якынаюда, Бабич җитәкчелегендә җитди рәвештә шигырь теориясе курсын үтүдә дә күпмедер роль уйнаган. Стенографиягә өйрәнүе аны татар милли-азатлык хәрәкәтенең иң алгы сафына, Уфа Милләт мәҗлесенең президиумына китереп кертә. Милләт мәҗлесе утырышлары стенографиясен тәртипкә китерү һәм саклауда күрсәткән фидакарьлеге, хезмәт юлын башлау елларында, аны милли хәрәкәтнең күренекле җитәкчеләре дәрәҗәсенә куя. Бу нәрсә аны бик иртә тормыш ваклыкларыннан өстә торган олы хәрәкәткә юллый. Шул күтәрү-күтәрелүләр аны, һәрчак, ничек кенә булса да, шигърияттнен, әдәбиятның да югарырак планкасына күтәрелергә мәҗбүр итәләр. Әдәби иҗат юлына баскач та бу «аерым игътибар» аның кешелек язмышы булып кала. 20 еллар әдәбиятында ул— «әдәбиятка индустриаль Урал биргән» иң күренекле «пролетар шагыйре»; 30 елларда— ялгыз, бер үзе генә, Такташка алмаш булып калган шагыйрь; 50 еллар уртасыннан иҗади гомеренең азагына кадәр, яңа этаптагы яңарту хәрәкәтенең алмашсыз юлбашчысы.

Әдәбиятыбыз тарихында мисалы булмаган бу «аерым игътибар», асылда, халкының шагыйрьгә карата һәрчак искәрткән аерым бер кайгыртучан мәхәббәте, Туфанның иҗади язмышында хәлиткеч диярлек роль уйнаган. Аны халкының шул сөю хисе шагыйрь иткән, зур шагыйрь иткән. Туфан—халык мәхәббәте шагыйре.

**Шәүкәт Галиев:**

Сәяхәттә Туфан, сәяхәттә,
Яшь чакта бер китеп югалган—
Кайнар комнар, таулар илләренә
Тынгысыз җан җәяү юл алган.

Сәяхәттә Туфан, сәяхәттә—
Кырыгынчы еллар, илләләр...
Тимер рәшәткәле «иркен» Себер,
Ядрә искән каһәр җилләләр...

Сәяхәттә Туфан, сәяхәттә,
Әле дә бит дөнья буйлатып,
Гамьсезләрне йөри ул уятып,
Гамьлеләрне йөри уйлатып.

Сәяхәттә Туфан, сәяхәттә,
И татарым, диеп яна ул—
Гасырына сыймас әрнүләрен
Киләчәккә алып бара ул.

Туфанның бөтен гомер юлы сәяхәттән тора. Маҗаралы да, фаҗигале дә— яшәгән гасыры кебек. Соңгы дәвер—Казанда үткән чирек гасырда да сәфәрләре күп булды аның. Болары инде, исеме Тукай, Такташ белән янәшә торган, халкы яраткан олуг шагыйрьнең очрашулары иде. Фотоларда теркәлеп калган кайберләрен күздән кичерәм, күңелдән үткәрәм. Классик шагыйребезнең 100 еллыгы уңае белән журналыбыз укучылары да күрсен иде, дим.

*Мәскәү, 1957 ел.* 1957 елның маенда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы булды. Тәмам хәзерләнеп җиткәч, аны 1941 елда сугыш бүлгән иде. Шул ике дата арасында Хәсән Туфан тоткында, сөргендә булды, декадага баруы да рәсми түгел иде. Ә рәсми башкала кистереп әйтте—гостиницага кертмәделәр. «Тегеннән» кайткач алган паспорты тамгалы икән. Яшь язучылар да аерым бүлмәләрдә урнашканда, Хәсән абый уртак бүлмәләрдә кунып йөрде. Алай да хәлен сиздерми, кушылып шаярткан да итә, әмма кинәт йөзенә күләгә төшә...

Бу халәтен шактый еллардан соң, фотолар караганда, янә күреп алдым. Колонналы залда Мәскәү татарлары белән очрашкан кичәбез. Бари Рәхмәтнең шаян шигырь сөйләп торган чагы. Рәхәтләнеп көлеп утырабыз. Берәү генә уйчан, монсу, ул—Туфан. Вәйран бәйрәм иде аның өчен. Кыяфәтендә—читләштергәнне тою, ятсыну, шушы дөньяга кушарга теләмәгәннәрә өчен әрнү.

Шигъри җанын керсез саклаган гаҗәеп шәхес иде ул. Нарасыйларча, изгеләрчә ихласлыгы рухи имгәнүләрдән аралап калгандыр. Йөрәге суынмаган, иманы

какшамаган иде аның. Бер елдан соң, Аккош күлендә яшәгәндә, шагыйрь инде бөтенләй бүтән—иркен күккә ияләшкән очар коштай иде! Сагынып көткән дусларының, үзе күрмәгән яңа буын язучыларның олылап, яратып, тере классик итеп каршылавы үзгәрткәндер: яктырып елмайган монсу—көләч Туфанга әверелде ул.

*Уфа, 1958.* Уфа Туфанга кайнар мәхәббәтен сиздерә алды, легендар шагыйрь итеп каршылады. Дуслары, укучылары белән үзе дә сагынып-яратып күрешә иде. 1958 елның язында элек «Галия» мәдрәсәсе урнашкан 15 нче мәктәптә очрашуда катнашырга туры килде. Атаклы мәдрәсәнең элекке шәкертләре—Хәсән Туфан белән Нәкый Исәнбәт, икесе дә, Галимҗан Ибраһимовны, Шәехзадә Бабичны юксынып искә алдылар. Бик җылы очрашу иде бу.

Уфа—шагыйрьнең яшьлек шәһәре. Тагын егерме елдан соң да: «Мин асылда синдә тудым, Уфа...»—дип язуы да очраклы түгел. Дуслык җепләрен киләчәктә дә туганнарча саклау, бердәм яшәү—Туфанның безгә үз үрнәге, иҗаты белән безгә калдырган васыяте.

*Әстерхан, 1966.* 1966 елның көзендә Әстерхан өлкәсендә әдәбият көннәренә бардык: Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, яшь шагыйрь Рәдиф Гатауллин. Ул чакта «Гаташ» түгел әле. Әмма беренче китабы «Гөлләр су сорый» белән танылып өлгергән иде. Хәсән абый аны үз улыдай якын итеп, игътибарлы булды. Әстерханга бик теләп бардык, милләттәшләр яшәгән тарихи төбәк, бик кетәләр дә икән. Тукай, Җәлилләрдән соң анда кем генә булды микән? Менә, Хәсән Туфан бара.

Алтын көз, пароход әллә Иделдә йөзә, әллә Вакыт дингезендә. Тыныч, рәхәт сәфәр. Г. Минский музыкаль салонда рояльдә уйный, Хәсән абый кушылып көйли, аннары үзе дә уйный. Алтынчы октябрьдә Казаннан китеп, 11 ендә иртән Әстерханда булдык. Су өстендә 112 сәгать, кайтканда һавада 2 сәгать, дип шаярттык.

Әстерханның үзендә, авылларында нәкъ бер атна йөрдек. Туган телне тансыклап, сагынып-сусап торган милләттәшләр сөенеп каршыладылар. Нәшриятта чыккан китапларыбыз йөзләп кенә түгел, меңләп таралды. Нәшриятның баш редакторы Хәбиб Гобәйдуллин да безнең белән, бу күренеш күңеленә бик хуш килде.



*Хәсән Туфан, Шәукәт Галиев Идел буенда. 1963 ел.*

—Бездә калыгыз әле: Хезмәт хакы түләп торыр идек,—дип халык исеменнән кодалап калдылар. Хәсән абый Әстерханны, истәлекле урыннарын, бабаларыбыз эзен, тарих китабын ачкандай, бик дулкынланып карады. Туган тел язмышы, читтәге кардәшләрнең аерылган, онытылган булуы борчыды аны. «Әстерхан Кремлендә», «Гүзәл гамь» шигырьләрен язып, очрашуда укып йөрде.

Китәр көн житте.

—Әйдәгез, Тукайга чәчәкләр алып кайтабыз!—диде Хәсән абый, үз тәкъдименә үзе дә, без дә сөендек. Казанга кайткач та Тукай һәйкәленә салдык ул чәчәкләрне—Тукай, Җәлил булган жирнен, милләттәшләрнең мәхәббәт билгесе итеп. «Чәчәкләр китерегез Тукайга» шигыре дә шул елда язылган.

*Балтыйк диңгезе, 1975.* Латвия, Ригадан ерак түгел язучыларнын «Дубулты» ижат йорты. Хәсән Туфан тәрәзәсеннән дингез күренә, наратлар якын гына.

—Агачлар бик якын, матур күренә икән,—дим.

—Беләсенме нәрсә—пәрдәне корып куйдым мин—уют булсын дип. Игътибарны тартмасын дип...

—Өйрәткәннәр кешене томалап тотып...—дим, шаяртып. Үзем уңайсызланып та куям—хәтере калмасмы? Мәзәкне бик яхшы аңлый ул—елмайды гына.

1975 елның көзе иде бу. 30 сентябрьдә автобус белән Курляндиягә сәяхәт иттек: Юрмала—Тукумс—Кандава—Сабиле—Талсыларны әйләнеп кайттык. Кичен бергәләп, бик иркенләп сөйләшеп утырдык. Бусы үткәннәргә сәяхәт булып чыкты. Өлкәннәрнең бергә үткән гомерләре, уртак танышлары—каләмдәшләре күп шул.

Ижат йортыннан китәр алдыннан фотога төштек. Шаярышып-көлешеп сөйләшкәндә туктап калган ул мизгел караган саен җанлана да китә...

### Гасырым маяклары

Егерменче гасыр—язмышыбыз...
Хафалан, тик өмет өзмә, туган:
Халкым рухы маяклары булып
Бер башында яна—сүнмәс Тукай,
Бер башында яна—сынмас Туфан!

**Ренат Харис:**

«Гажәеп фотогеничный кеше инде Хәсән Туфан!»... Бу сүзләр Бакый ага Урманченыкы. Дистәләгән персонажлы фотосурәттә Хәсән ага булса, күз карашы иң әүвәл аңа барып төртелә. Анын ач яңаклы озынча йөзендә, чекрәеп елтыраган күзләрендә, йә буранны, йә язгы ташкынны хәтерләткән чал чәчләрендәниндидер тылсым бар. Бу тылсымны мин шигърият дип атар идем. Әгәр дә шул ук фотосурәттә бер шагыйрь дә бар дисәләр, минем уемча, һәркем Хәсән Туфанны күрсәтер иде... Бик күп күренекле танышларымның төс-битләре күземнән хәтерендә инде тоныклана башлады, ә Хәсән аганың портретына вакыт янгырлары тимәгән...

Мин гомер буе күнелемнән Хәсән ага Туфан белән бәхәсләшеп яшәдем. Житмешенче еллар башында булса кирәк «Татарстан яшьләре» газетасында анын «Юкны эзләмәскә, барны үстерергә» дигән мәкаләсе басылып чыкты. Бу мәкаләсендә Хәсән ага алтмышынчы елларда татар әдәбиятына килгән шагыйрьләрнең ижаты турында сүз алып бара һәм мәкаләнең исеменә әверелгән нәтиҗә ясый. Ә без ул вакытта татар шигъриятенең сугыштан соңгы хәлен, яшьләргә хас булганча, кистереп шактый түбән бәяли идек. Ул елларда рус шигъриятендә Евтушенко, Вознесенский, Рождественский, Белла Ахмадуллиннар исеме белән бәйле гажәеп көчле күтәрелеш бара иде. Рус поэзиясе эстрадаларга, стадионнарга ташып чыкты, анын сәяси жегәре Маяковскийлардан мирас булып калган традицияләргә барып тоташты һәм ижтимагый-эстетик көчкә әверелде. Шигъри форманын төрлелеге, интонацияләр байлыгы, публицистика белән шигърилек симбиозыннан туган заманчалык, әлбәттә, һәрвакыт яналыкка омтылган татар шагыйрьләренең күнелләрен бик тиз яулап алды. Рус поэзиясе белән чагыштырып караганда безнекенең «житешсезлекләре» бик күп булып күренде.

Нәкъ шул елларда ул вакытта Мәскәүнең М. Горький исемендәге әдәбият институтында укытучы шагыйрь Шамил Анак Казанга кайтып йөри башлады. Анын белән бергә татар шигъриятенә Европа верлибры (ирекле шигырь) һәм әдәбият, татар шигыре хакында укымышлы бәхәсләр кайтты. Кайберләребез бу алымны татарча «жигә» башлады һәм матур-матур уңышларга да иреште. Бигрәк тә Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтжанов һәм Рәдиф Гатауллин.

1970 елның 4 декабрендә Татарстан Язучылар союзы идарәсендә шигырь секциясенен утырышы булды. Ул вакытта Язучылар союзы Бауман урамындагы матбугат йортында иде, ә секция житәкчесе—Марс Шабай. Утырышны да ул алып барды. Әле күптән түгел генә Рәдифнен «Кунел ташлары» дигән китабы чыккан иде һәм без, яшьләр, аны куанып каршы алдык. Күзен арыш кырларыннан аерып, йолдызлар арасына, яна дөньяларга, яна рухи биеклеккә омтылган замандашның хисләре безнен күнелләргә хуш килгән иде. Ә Хәсән агага Рәдифнен яна китабы ошамаган икән. Дөрес, сүзне үзенә хас салмаклык белән Сибгат ага Хәким башлап жибәрде.

—Рәдифнең беренче китабын укып, мин шагыйрь килә дип, куанган идем. Матур образларга, төгәл детальләргә бай иде ул китап. «Кунел ташлары» ... бераз ... абстрактрак булып тоелды... Яшьләрнен һәр яна китабы турында секцияләрдә сөйләшергә кирәк...

Хәсән ага сүз алды. Һәрвакыттагыча дулкынланып, үз сулышыннан йотлыга-йотлыга, турыдан ярды:

—Рәдифне коткарырга кирәк... Китап шигырьләре язу—Рәдифнен шагыйрь буларак үлеме ул... Башына сугып, якасыннан алып, бик нык бер селкеп, егетне акылына утыртырга кирәк...

Дипломатия саклауны Хәсән ага бу юлы да кирәк дип санамады. Бу юлы да дип шуна әйтәм—мин берничә мәртәбә Язучылар союзы китапханәсендә Хәсән Туфанның Шамил Анак белән сөйләшкән-бәхәсләшкәнен тынлап тордым. Хәсән ага шигырь теориясе белән житди һәм ныклап шөгыльләнә иде булса кирәк, ә Анак аны тирәнтен белә. Безнен буын шагыйрьләре дә бу мәсьәләдә төшеп калганнардан түгелләр иде.

—Син, Шамилкай энем, модачы, экспериментчы... Сезнең буын, гомумән, ялгыш юлдан, формализм юлыннан бара... Без үттек инде аны, Маяковскийларга ияреп. Менә мин янадан гасырлар буе чарланган классикага кайттым. Син дә кайтачаксын... Иртәме, сонмы... Ташла бүген үк татар теленә ят, килешмәгән бу экспериментларынны—бозып йөрмә яшьләрне... Мондый минутларда Хәсән аганың бит очларына алсулык йөгерә, күзләре очкынлана, тынгысыз алгы чәчләре жыерчыклы маңгаена ишелеп төшә, мишәр акценты тагы да көчәя... Ул тагы да матураеп китә. Бакый ага Урманченың югарыда китерелгән сүзләре, мөгаен, шагыйрьнен нәкъ менә шундый чагын күргәч туган сүзләрдер. Рәссамның әйтүенчә, Хәсән Туфан аның белән дә бәхәсле сөйләшүләр алып барырга яраткан, ләкин мина, ни кызганыч, андый очра-шуларның шаһиты булырга туры килмәде.


*Бертөркем язучылар Тукай-Кырлайдагы шигырь бәйрәмендә. 1975 ел.*

Шигырь секциясендә Рәдифкә дип әйткән сүзләр, әлбәттә, бер Рәдифкә генә юнәлтелмәгәннәр иде. Әлбәттә, алар татар шигъриятен кайгыртып, татар әдәбиятын модага бирелүдән саклап калырга тырышып әйтелгән сүзләр. Ләкин мода гына булды микән сон безнен ул еллардагы эшчәнлегебез? Бу сорауга җентекле җавапны әдәбият белгечләре, галимнәр бирделәр инде. Шул елларның матур эзе татар шигъриятен яна формалар белән генә түгел, яна интонацияләр, сурәтләү чаралары, яна темалар белән дә баетты. Татар шигыренә урбанизм дулкыны бәреп керде һәм шигъриятебезнен башка хасиятләрен кысрыкламыйча, үзенен, әйтерсен лә алдан

әзерләп куйган, урынын алды. Ә иң мөһиме—шагыйрь җаныннан кайбер идеологик тышаулар алып ташланды, шагыйрь үзен ирекләрәк тоя, иркенрәк тота башлады...

Ә күренекле шагыйрь Рәдиф Гатауллинга карата ул чакларда әйтелгән киңәшләре ни дәрәҗәдә актуаль һәм урынлы булган? Бу сорауларга җавапны әдәбият белгечләреннән ишетү кызыклы булыр иде, чөнки бик күп вакытлар узды, шагыйрьнең яңа китаплары чыкты, яңа иҗади мавыгулары ачыкланды...

Хәсән ага Туфан иртә яздан кара көзгә чаклы язучыларның «Аккош күле» дигән иҗат йортында, дөресрәге—иҗат бакчасында, яши иде. Соңгы елларындагы күп әсәрләре аның Кече тирән күл буендагы шушы бакчада язылды. Бакча уртасындагы беседкада көзләрен «авыл хуҗалыгы күргәзмәләре» булып, анда һәр язучы гаиләсе түтәлендә үстергән яшелчәсе белән катнаша. Кемнәрдер кабак, кишер, чөгендер, кәбестә куя, ә Хәсән ага күргәзмәләрдә фәкать чәчәкләре белән генә катнаша һәм барыбызны да сокландыра иде. Бакчаларыбыз күрше булганга, минем өлешемә аның белән очрашып сөйләшүләр бәхете дә төшкәләп торды. Күп очракта сөйләшүләр хәл-әхвәл белешүдән узмый иде. Кайбер вакытта гына татар театрларының репертуары белән кызыксына. Мин җитмешенче елларда культура министры урынбасары булып эшләдем һәм ел тәүлегендә 50-60 яңа спектакль кабул итүдә катнаша идем. Мин, әлбәттә, үзем белгәнне сөйли идем, ләкин Хәсән аганың ни дәрәҗәдә театрал булуын әйтә алмыйм.

Чыбык очы туганым очучы (ул хәзер язучы да) Рәшит абый Ибраһим Сочи якларыннан иң беренче черешняларны алып кайта иде һәм безнең гаиләне сыйлый иде. Һәм без һәр елны шул черешнядан Хәсән агага да өлеш чыгара идек. Шундый көннәрнең берсендә хатыным Лилия бер кәнди черешня алып Хәсән ага өенә кереп китте дә, йөзе агарынып, әйләнеп тә чыкты. Күчтәнәче кулында.

—Ренат, Хәсән агайга анда нидер булган, ахры...

Аны-моны уйлап тормастан мин Хәсән ага янына йөгереп кереп киттем. Тәрәзә пәрдәләре ачылмаган бүлмә. Хәсән ага караватка чалкан яткан. Күкрәгендә «Спидола» радиоприемнигы. Ниндидер шомлы музыка яңгырый. Хәсән аганың уң кулы күкрәгендә, ә сул кулы идәнгә асылынып төшкән. Йөрәгем жу итеп китте. Мөнҗия апаның, күрәсең, шәһәргә азык-төлек алырга киткән чагы булгандыр. Мин куркып кына Хәсән аганың идәнгә асылынып төшкән кулын күтәрә башладым. Йа, Ходаа, кулы җылы... Ул арада, черешнялы кәндиен тотып, Лилия дә кереп җиткән... «Ни булган?.. Кем анда?» дип шагыйрь уянып китте... Мин аңа күчтәнәчне суздым.

—О! Черешня! Быел да!..—дип Хәсән ага торып утырды.—Лилия сеңел онытмый инде мине, онытмый...

Мин әле дә кызыклы агач ботакларыннан кул таяклары ясарга яратам. Шул елларда бер алмагач ботагыннан матур гына таяк ясаган идем. Тоткасы—бөркеткә ошаган кош, ә кәүсәсендә «Шигырьчылар бер көтү, көт, шигырь бөркете!» дигән язу. Сабан туе алды көннәренең берсендә бу таякны Хәсән ага күреп алды.

—Ба! Синдә мондый осталык та бармыни?.. Нинди язу ул анда?

Мин укып күрсәттем. Таякны алып, үзе дә укып чыкты.

—Бу синең безненчә, мишәрчә, булып чыккан. Казаннар «шигырьчеләр» дип язалар...—дип хатамны төзәтте. Ләкин мин әле дә булса таяктагы язуда хата юк дип яшим. Татар «шигырь» дип гарәпчә язса да, «шигыр» дип төркичә әйтә,»Рязань»не «Рәзан» дигән кебек...

—Монда бит двойной мәгънә... «Көт» сүзең ударный булып чыккан. Аны тегеләй дә, болай да аңлап була... Әйтик, көтүгә әйләнгән шигырьчеләргә көтүче бул, дип тә. Бер көтү шигырьчеләр типтереп яшәгәндә, син үз чиратыңны көтеп утыр әлегә, дип тә... Кайсын уйлап яздың?

Мин, әлбәттә, ике мәгънәне дә күз унында тотып яздым, бигрәк тә рифманың матурлыгына кызыгып. Ләкин шигырьнең адресаты турында уйламаган идем. Һәм кинәт:

—Сезне уйлап яздым,—дип җибәрдем, үземнең үтә тапкырлыгыма куанып...

—Чынлапмы?.. Минем «тегендә» (ягъни—сөргендә) көтү көткәннәремне белепме?..

Таяк аңа ошады булса кирәк—шул таякны махсус сорап алып, Хәсән ага ике ел Аккош күле буендагы Сабан туйларына барып кайтты. Алдагыларына да

«резервировать» итеп куйган иде дә, барып чыкмады булса кирәк...

Бүгенге көндә дә ул таяк исән. Ул шәһәрдәге фатирымда саклана. Аңа кагылган саен йөрәгеп бәйләтергә жылы кул эзләгән олы шагыйребезнең үз куллары жылысын тойгандай булам... Һәм йөрәкне үкенү хисе кысып ала—ник таякны шагыйрьнең үзенә бүләк итә белмәдем?..

Кеше-күрше мөнәсәбәтләре, минемчә, әнә шулай шактый жылы иде безнең. Шигырь остасы, ижат океанында давылларны шактый күргән, татар шигъриятендә үз мәктәбен тудырган шагыйрь Хәсән Туфанның формада экспериментлар ясаудан баш тартмаган, метафораларда «мөгез чыгарырга» яраткан, юкны эзләү юлына баскан башка мәктәп укучысы Ренат Хариска принципиаль карашы шәхси мөнәсәбәтләргә бәйле түгел иде... Кем әйтмешли, пәри—башка, жен—башка...

## Әхмәт Рәшит:

Кемнең—кемнең, шигъриятебез классигы Хәсән Туфанның заманага, дөньяга, кешеләргә үпкә-рәнжүләре байтак булырга тиеш иде кебек. Гомеренең иң давыллы мизгелләре сталинчыл кара елларга туры килде, шул чорның зобаныйлары аның ышаныч-иманына кизәнүдән тәм табып яшәделәр, дус булып йөргән кайберәүләр хәтта аңа каршы юнәлтелгән компроматларга кул куюдан да тайчанмадылар. Туфан бөтенесен кичерде, бөтенесенең гөнаһларын ярлыкады. Чөнки ул кул житмәстәй бөек, көнкүреш ваклыкларыннан өстен иде. Бу олпат затның бердәнбер өзелеп сөйгәне—«патшалар ятлап алырлык» илаһи шигърият кенә иде.



*Хәсән Туфан (уңнан икенче), Равил Фәйзуллин (сулдан өченче) һәм Каракалпак әдипләре Тукай-Кырлайдагы Г. Тукай музее каршында. 1975 ел.*

Аның төрмә вә сөргеннәрдән соңгы тормышы безнең буын күз алдында үтте. Югыйсә шундый газап-кыерсытулардан соң шөкер итеп, калын-калын китаплар чыгарырга яисә бөтен дөньяга аһ-зар түгә-түгә, каргыш сүзләре әйтергә дә хаклы иде. Ул еламады, сыкранмады, сукранмады. Үзе булып калды. Ерак сәфәрләрдән кайткач та башыннан сыйпап кына тормадылар аның. «Искәндәр Рушан» тәхәллүсе белән:

Ничек мөмкин совет онынннан
Камыр басып чәкчәк ясарга.

Һәм миллӘтсез сыернын сөтен
Милли катык итеп ашарга,—

дип аның тарафыннан камчыланган үтә бәйнәлмиләл партократлар—Мәймүн Мәймүновичлар шагыйрь өстенә ничек ташланганнары хәтерегездәдер әле. Ул фани дөньядан реабилитацияләнүне кирәксенмичә кичте—булмаган гаебен танып ялварулы гариза язу аның өчен үлем белән бер иде.

Ул үзенең хаклыгына ышанып, аны үз һәм якын иткән халыкның кадерен белеп, алдагы көннәрнең аяз булуын теләп яшәде. Шуңа күрә дә ул бүген дә безнең сафта атлый, Татар иленең азатлыгы өчен көрәшә.

**Батулла:**

Омтыла жан бәйге аты сыман
Мәйданнарга һаман, яшәүгә.
Тагын бер кат шулай яшәр идек,
Ике килсә гомер әгәр дә.
Хәсән Туфан, 1957.

Әдәбият галимнәре «Югары шигърият, Бөек шигърият» күтәрмәсенә Пушкин белән Лермонтовны, Ахматованы, Цветаеваны, Бальмонт, Фет, Мандельштамнарны менгезеп сөйләшәләр.

Аурупа әдәбияты турында сөйләшкәндә бөек шигърият аланында Поль Верлен, Стефан Малларме, Аполлинер, Бодлер исемнәрен атарга күнеккәнбез.

Төрекләрдә—Әмрә, Бәйатлы кебек шагыйрьләргә мәдех укыйбыз.

Чыннан да, ул шулайдыр да. Ә без—татар зыялылары «Бөек шигърият» күтәртмәсенә кемнәрне куя алабыз? Әлбәттә, Кол Гали, Мәүлә Колый (Бәйрәмгали), Кандалый, Акмулла, Тукайларны һәм тагын башка бик күп шагыйрьләребезнең әсәрләрен әнә шул мәртәбәле күтәртмәгә куя алыр идек. Әмма Такташ, Сәгыйть Рәми, Дәрдмәнд шигърияте алда саналган бөек шагыйрьләребезнең ижатыннан бөреләнгән булса да, үзенчәлекләре дә шактый һәм алар аерым урын били. Такташ, Рәми, Дәрдмәндне символика берләштерсә дә, аларның ижатын азмы-күпме якынайтса да, Такташның символикасы аерым, Рәминең символикасы үзгә, Дәрдмәнднең символикасы бөтенләй башка. «Бөек шигърият» дигәндә без телибезме, теләмибезме, «элитар поэзия»не күз уңында тотабыз. Ягъни, аксакаллар, затлы катлам, падишаһлар гына аңлый торган үзгә бер ижат жимешләре белән эш итәбез. Тикмәгә генә түгелдер, «Шаһнамә» шаһлар өчен язылган «шаһәсәр», ягъни, «шедевр» диеп атала. Гади халык та шаһлар укый торган әсәрләрне үз итеп укый икән, бу инде мөкәммәллек, бу инде халыкның югары кимәлле милләт икәнен исбат итә торган галәмәт.

Әйе, Тукайны югары катламдагы миллионер да, игенче дә, мәгърифәтче дә, түбән катламдагы эшчесе дә егылып укыган. Әйе, татар халкының борынгыдан килгән бу зыялылыгы егерменче гасырның урталарына кадәр саклана килде.

Тукайны татар халкы гына түгел, үзбәге дә, әзәрбайжаны да, Кырым татарлары да, казахы да, башкорты да дәррәү укый иде. Менә шул вакытта Галимжан Ибраһимов Тукайны каты тәнкыйтьләп китап яза, Рәми белән Дәрдмәндне бөек шигърият киштәсенә куя. Юкса, Рәми белән Дәрдмәндне алай бигүк егылып укымый иде халык.

Кулына каләм алган зат, үзен шигырьгә багышларга теләгән ижат кешесе зиһене белән булмаса да, хиссияте белән сизенергә тиеш иде шуны: халыкның бар катламнарына да аңлашылырлык әсәр язаргамы, әллә аксөякләр өчен генә ижат башларгамы?

Мина калса, Хәсән Туфанның сизгер күнеле, аның ижат куәсе нәкъ менә шуны тойган. Туфан Тукай, Такташ, Рәми, Дәрдмәнд ижатыннан аз-азлап жәүһәр чүпләгән, аларны, шул жәүһәрләрне ул үз ижат сөрешендә уңышлы файдаланган, Туфанча үстергән һәм «Туфан» дигән бөек шигърият барлыкка килгән. Туфан бер үк вакытта аксөякләр шагыйре дә, бер үк вакытта ул халык шагыйре дә. Мондый сыйфатлы катнашма бик сирәк шагыйрьләрдә генә була.

Шагыйрьләргә хас уртак биш сыйфат бар.

**Илаһи куә**, ягъни кабилият, олуг сәләт, бүгенгечә әйтсәк, табигать (Аллаһ) биргән талант.

**Фәлсәфә,** бөек суфиларча фикерләү; мона кадәр без күргәннәрне иҗатта күрсәтә белү; мона кадәр башыбызга да килмәгән төшенчәләрне ачып салу; мона кадәр канун-кагыйдә диеп йөргәннәребезнен хата икәнен исбатлау куәсе.

**Әүлиялык,** шәхес иҗаты белән үз кавеменнән сизгеррәк, акыллырак булып, алда халыкны ни көтәсен юрый алса, әсәрләрендә шунарга ишарәләр ясап, һич югында, болай барсагыз, сезне алда һәлакәт көтә, диеп кисәтә алса, ул әүлияләр рәтендә кебек булыр.

**Фидаилек**, бар фидакарь җаннар, ягъни тырышып эшләүчеләр, хезмәт батырлары—алар күпчелек. Фидаилек—ул каһарманлык, ватанпәрвәрлек, ил-халык өчен үзенне корбан итәргә әзер булу, үзенне корбан итү.

**Фаҗигале язмыш**, алда саналган сыйфатлары булган кешенен шәхси хәяте гаять катлаулы, кыен һәм, гадәттә, фаҗига белән тәмамлана; аны җәберлиләр, кыерсыталар, ул түзми, үзенә үзе кул сала; аны үтерәләр, үтертәләр; ул ялгызлыкта, хәерчелектә, ул чит-ят илдә, ватаныннан еракта, горбәттә үләргә мәҗбүр ителә.

Кол Гали сугышта һәлак була, Сәеф Сараи горбәттә вафат, Колшәриф ватанын саклап һәлак була, Акмулла үтерелә, Бабич үтерелә, Такташны агулаганнар дигән фараз йөри, Җәлил үтерелә, Фатих Кәрим һәлак була һәм башка бик күп татар шагыйрьләре, сәнгатьчеләрнен фаҗигале тәкъдирләре мона дәлил. Үз үлеме белән вафат булган Сәйдәш тә, чынлыкта исә, үтерелде, анын иҗатын, рухын сындырдылар. Ул шәхес буларак яшәүдән туктарга мәхкүм ителгән иде.

Хәсән Туфаннын шәхесе менә шушы калыпка сыя да куя. Туфанны татар халкыннан аерып алып булмый. Халык язмышы—Туфан язмышы, Туфан язмышы—татар язмышы.

Туфанга табигать тарафыннан илаһи куә, Илһам бирелгән. Илһам ул байтак кешегә бирелергә мөмкин. Табигать сина куә биргән, син аны үстерергә, тәрбия итәргә, аны халкын файдасына, кешелек мәнфәгатьләренә кулланырга тиешсен. Шулай булмаганда сина бирелгән куә әкренләп сүнә һәм юкка чыгачак. Хәсән Туфан әнә шул Илһам диеп аталган акбүз атын һәрвакыт үстерде, тәрбия итте. Хәсән ага татар тарихын, татар әдәбиятын гына түгел, күрше халыкларнын, дөнья халыкларынын культурасын ныклап өйрәнгән, үз иткән кеше. Хәсән Туфан Илаһи куәсен баетыр өчен дөнья гизгән, сәяхәт иткән шәхес. «Урал эскизлары», «Каспий яры», «Ташкент багларында», «Отелло», «Могикан», «Овидий Назон» темалары шигырь булып Хәсән Туфаннын гомер юлына яткан.

Туфаннын Илаһи куәсе барлыкка китергән шигъри сурәтләр, астарлы сүзләр, кинаяле юллары дөньякүләм мәсьәләләрне күтәргәндә дә үзенен халкы, татарнын язмышы турында булыр, татар халкынын язмышы турында сөйләгәндә Туфан дөньякүләм проблемалар күтәрер.

Хәсән ага Туфан иҗаты белән генә түгел, тышкы рәвеше белән дә әүлияга охшаган иде. Салмак хәрәкәтле, йомшак тавышлы, чандыр-какча гәүдәле, ак-пөхтә иде ул остазыбыз.

Шагыйрь Туфаннын күнел сиземләве, чыннан да, әүлияларныкы кебек. Кулына яна гына каләм алган яшь Туфан 1925 елнын маенда көндәлегенә менә нинди шигъри юллар язып куйган.

Мин, егетләр, ахры,
Җүләрәям...
Әйтим әле исән акылдан:
—Күммәгез дә, нитмәгез дә,
Яндырыгыз мине!
Гомерем кебек даулы-шаулы төндә
Җилдә—давылда...

Шагыйрь Ана Телебезнен мөмкинлекләрен бик мул файдалана, әйтик, «җүләрләнәм» түгел, «җүләрәям», «саглам», «уфлап», «күн иренле бизгәк ятим» кебек көтелмәгән сүзләр, гыйбарәләр, шигырьдә ялтырап-балкып куя. «Хәсән Туфаннын шигъри теле» дип аталган фәнни хезмәт язарга алынучы яшь галимнәр өчен монда бай материал ята.

Инде әле яна гына укыган көндәлек шигыренә кайтыйк. Әйтерсең лә, Туфан үз гомерен алдан ук белеп, программалап куйган! Янды бит Туфан! Яндырылды бит Туфан! Кимчелекне җиңмәү үченнән янды, ялкынланып янды шагыйрь Туфан иҗат иткәндә, башка күп буыннар аның ялкыныннан алган яктылыкта өзлексез иҗат итәр әле. Үз халкының азатлыгы өчен үз йөрәген яндырып һәлак булган Данколарның берсе ул—Туфан.

Туфан—Шигърият аланында үзен корбан киткән фидаи зат.

Шигырьгә ул изге җан иясенә баккан кебек бага иде. Иң кыен вакытларда да, кире чыкмаслык тарлавыкларга китереп кыссалар да, Туфан шигыренә хыянәт итмәде. Димәк, халкына хыянәт итмәде. Күпме җәфа, нахак ялаларны күтәргән арык ине, «ертык йөрәге», «сыңар үпкәсе, ертык үпкәсе белән дә ул ютәл аша көлә белә» иде.

Әдәбиятыбызда ике тапкыр Шагыйрь исеме яулаган шәхесләр бар. Муса Җәлил Моабит шигырьләрен язмаган булса да, шагыйрь булып тарихта кала иде, әмма аның дөньяны тетрәндергән икенче чор иҗаты бар, шөкер. Фатих Кәримнең сугыш чоры иҗаты булмаса да, ул шагыйрь булып калган булыр иде. Әмма аның сугыш кайнаган урыннан язган утлы шигырьләре бар, шөкер. Нури Арслан шагыйрьләр рәтендә саналса да, олгаеп барганда да балкып китә алмаган иде, әмма гомеренең соңгы елларында «Нури Арслан» дигән олуг шагыйрь пәйда булды, шөкер. Әгәр зинданда ук юкка чыгарылган булса, Туфан шагыйрь буларак дәрәҗәле урында кала иде, әмма аның тоткынлыкта, аннан соң иректә язган олуг иҗат чоры бар, шөкер. Ул Шагыйрь исемен ике кат яулаган шәхес.

Әйе, Хәсән Туфан шигърияте—ул серләргә бай дөнья. Туфан шигырендәге серне ачу сиңа ләззәт бирсә, иҗат куанычы китерсә, шул серне башкаларга сөйләү икеләтә сөенеч алып килә.

Туфан дигән бөек шигърият бар! Әнә шул шигъриятне тагын-тагын ачасылар бар әле!

**Рәдиф Гаташ:**

Хәсән Туфан дигән исем (инде ерак офыклар чигеннән дә күзалларга мөмкиндер! Гасырның соңгы көннәре...)—газиз татарыбыз өчен бер асыл шагыйрь аты гына түгел, ә бәлки—халыкның үз холкы, акыл-фәһеме, яшәү рәвеше, җан авазы, тарихи, хәтта бер фаталь тәкъдир белән бәйле үз биографиясе кебегрәк. Шуннан инде—«сызылып-сызылып» күңеленнән чыккан шигырь нидасы, аһәне, моңы белән җан сурәте гәүдәләнә. Чын бер яңа дөнья булып янгырый бит—бары тик бөекләр генә йөртергә лаек булган бу исем дә: Ту-фа-а-а-н! Гасырлар чаңыдай... Анда—йолдызларга житкән югары илаһилык та, тик жирдән, татар туфрагыннан калыккан ягымлы, мөлаем, гадилек тә, пәйгамбәрләргә хас сабырлык, акыл да, шигырьгә бәйле асыл исемнәрдән калган олпатлык, затлылык та, фәлсәфи ышандыру, тотнаклылык көче дә бар кебек. Валлаһи, шулай ишетәм мин!

Безгә, сугыштан соңгы шигъри хәзинә белән генә таныш, тик шуны укып, шактый фәкыйрьләнгән Сүз сәнгатебезгә гашыйк булып, шигырьгә килгәннәргә (әле дә ярый Тукай, Такташ кебек кыйблабызны белә идек!) Туфан соңрак килеп ирешә. Башта Җәлил кайтты, аннан Бабич, Бурнаш исемнәре сискәндерде, аннары «менә шундый биеклек тә була ала, белегез!» дигәндәй, күңелләребезне Туфан тетрәндерде—әйе, әйе, инде Дәрдмәнд, С. Рәмиләр дә кайткан чор иде ул! Без, көтмәгәндә, үзебезнең гаҗәеп бай мирас, чын байлыклар варисы булуыбызны аңлап, шаккаттык... Тере Туфанны күргәндә, бу хисләр янә кабатланды.

Әмма, шагыйрьгә табыну, ул тудырган сүз могҗизасы, илаһи дөнья белән хозурлану, исерү—бер хәл; ә инде шундый олуг шагыйрьгә каләмдәш булып, егерме елга якын аны күреп-белеп яшәү бөтенләй башка нәрсә. Ул—үзе үк бер язмыш юлы, мөгаен. Шагыйрьләрнең мөнәсәбәтләрендә дә бу шулай. Дөнья бу! Беренче адымнарымны хуплап, хәтта Язучылар берлегенә тәкъдимнамә язып бирсә дә, мин остазымның яраткан шәкерте үк була алмадым. Әзләнүләрем, сәйяр һәм сәер җаным, холкым белән «ана каршы баш күтәргән» чаклар да булды бугай, секцияләрдә ярсып чыгышлар да ясарга, үземне түгел, бәлки яңа дип инанган, татар

шигырен биеклекләргә күтәрер дип ышанган алымнар, калыплар, иркенлек, хәтта ирек «даулап» тыпырчыну булмады микән бу? Ләкин, бу да һәр тынгысыз жан—шагыйрь үсеше өчен табигый хәл, мөгаен.



*Хәсән Туфан (уртада) һәм Рәдиф Гаташ (сулдан беренче) Әстерханда әдәбият атналыгында. 1966 ел.*

Хәзер анык әйтә алам: безнең чордашлардан аның зур шигъри мәктәбенең күренекле шәкертләре булып, С. Сөләйманова, Роберт һәм Рәшит Әхмәтжаннар, Зөлфәт, М. Әгъләм, Р. Зәйдуллалар саналырга хаклы, мөгаен. Бу—иҗат алымнары, өслүбе, тел стихиясе, традицияләр дәвамлылыгы буенча якынлыкларыннан чыгып әйтүем. Бик якын күргән шагыйрь энеләре—(Ш. Галиев, И. Юзеев һ. б.) башка мәктәп вәкилләре булса гаҗәпмени? Йәки башка олуг шагыйрьләр? Югыйсә, уртак максатларда, омтылышларда, заман куйган сорауларга саллы җавап эзләүдә без, гасыр ахыры шагыйрьләре, барыбыз да Туфанга якынбыздыр. Шиксез, бу—шулай. Әйе, Туфанга... һәм, әлбәттә, Такташ, Җәлил, Хәким кебекләргә. Чөнки асыл традицияләребез, Тукайдан соң безнең көннәрдә, нәкъ менә алар моны, гаме, сүзе белән безнең шигырь канына да кучкән дип беләм. Һәр олуг шагыйребездә шулай.

Ә узып баручы гасыр татар шигырендә, Аллага шөкер, күп якты, зур исемнәр калдырыр дип ышанам (күп бездә яхшы шагыйрьләр! Шигырь яши, яшәячәк!) Шулар арасында Хәсән Туфан исеме иң санаулыларның берсе булып, мөбарәк тәсбихтә янып торачак. «Бисмилла»дан соң, әлбәттә, аның аты да хәтерләрдә яңарачак, әйдәп торачак.

Безгә—бүген үк шуны аңлау, ихлас шатлану, горурлану бәхете язган. Ә бу—азмыни?

## Зиннур Мансуров:

«Нәрсәгә лә тормыш? Нигә лә?»—дип
Йөдәтмә лә, йөрәк, урынсыз...

Минем үземә ничектер шулай тоела: шагыйрь Хәсән Туфан гомере дәвамында шушы сорауга җавап эзләгәндер шикелле—каный башлаган чебиле аякларын әнисе күкрәк сөте белән «майлап» куйган чакта да, XX гасыр башында коерыклы йолдызның Кояш тирәсеннән үтеп китүен күргән мәлдә дә, Урал шахталарында «бакыр тамыры» буйлап шуышканда да, «Галия» мәдрәсәсендә Бабич оештырган яшерен түгәрәктә француз китаплары нигезендә гипнотизм һ. б. шуна охшаш кызык «фән»нәрне өйрәнгәндә дә, Такташлы Казанга кайтып, иҗатны гүзәл гамь итеп таныганда да, Кавказ һәм Урта Азия республикаларына җәяүле сәфәр кылганда ашугларны, багшыларны, акыннарны, манасчыларны тыңлаганда да, залим хакимият тарафыннан атарга хөкем ителгәч, гранаталарга уралып, самурайларның сугышчан машинасы астына ташлану, яисә торпедоның йөртүчесе сыйфатында дошман корабының йөрәгенә бәрелеп шартлау теләге турында югары органнарга үтенеч язганда да, татар шигъриятенең иң югары түбәсенә менүгә ирешкән аксакал буларак, гомеренең кояш батышында тагын бер мәртәбә Галей кометасын күреп калырга өметләнгәндә дә...

Нәрсәгә лә тормыш?.. Чынлыкта Хәсән Туфан үзенең шигырь-поэмалары аша әлеге мәңгелек сорауга бихисап дәрәҗәдә төрледән-төрле, хәтта кайчак берничә шигъри вариантта җавап бирергә омтыла. Без шагыйрьне романтикага кеше

җанының канатлары рәвешендә караучы хыялый итеп тә, үзе туганчы ук язылган реаль язмышның дәвамчысы итеп тә күрәбез. Аның яралы йөрәге әле галактика киңлекләренә күтәрелә, әле сталинизм зинданының тере инвентаренә әйләнә. Яшәү мәгънәсенә төшенер өчен гасабиланган шагыйрь материя, атом, матдәләрнең телен ачтыра һәм үзен дә «сөйли, җырлый, сагына торган» материя итеп күзаллый... Шуңа күрәдер дә Хәсән Туфанның биниһая олы иҗатында кеше хисләренең палитрасы монарчы сирәк очрый торган киңлек һәм тирәнлектә чагылыш таба, һәм, табигый ки, әлеге кабатланмас үзенчәлек шагыйрь кулланган сәнгать чаралары җыелмасының гаять бай булуын да күрсәтә. Эстетик тәҗрибән зур булса, әйе, зәвыгың да нечкәрәк була, йөз тоткан әхлакый кыйблаң да ачыгырак төсмерләнә.

Әдәбиятка фанатикларча бирелгән Хәсән Туфанда, мөгаен, шигърият күзәнәкләре чагыштырмача күбрәк булгандыр, һәм аларның һәммәсе дә моң, гамь, драматизм белән өретелгән ниндидер илаһи нурлардан тукылгандыр. Моның шулай булуын шагыйрь үзе дә сиздереп куя: «Әгәр дә кешенең иң драматик кичерешләрен дә, әйтик, яшәү дигән бөек бәхетнең соңгы ярына баскандагы хәлен дә, минуска түгел, ә плюска исәпләргә мөмкин булса, мин шактый бай кешедермен...»

Гадәттә, һәрбер иҗатчы «Нәрсә ле тормыш?» кебек сорауларга җавапны аналитик, интуитив алымнар һәм күңел ачышлары ярдәмендә эзләргә омтыла. Хәсән Туфан шигъриятендә исә аларның соңгы икесе өстенлек итә шикелле.

Гомумән, фикерләү эзлеклелеге шагыйрьләрдә сирәк очрый. Ә Туфанда бигрәк тә... Менә шундый шагыйранә холык-фигыль аның бәһаләп бетермәслек шигъри табышларга ирешүен тәэмин итә һәм кайбер югалтуларга да, әгәр шулай әйтергә ярьса, олы талант ияләренә бик үк хас булмаган күпмедер хаталануларга да китерә.

Табыш та күп булды, югалту да
Күченгәндә иске дөньядан...

Шагыйрьнең бераз гаҗәпләндерә торган «хаталану»лары җәмгыятьтә хакимлек итүче көчләргә карата мөнәсәбәттә күбрәк күзгә ташлана. Иҗат эшенә үтә дә таләпчән караган, каләмдәшләрен үтергеч дәрәҗәдә туры әйтеп тәнкыйтьли алган, көнкүрештәге яман күренешләрне рәхимсез рәвештә ача белгән, тормышта ниндидер мишәрчә «кирелеге һәм үҗәтлеге» белән аерылып торган олпат шәхес үзенең халкын дошманга әйләндереп канга батыручы тоталитар дәүләткә карата



*Сталин төрмәләрен «татып» исән-сау илгә кайткан әдипләр (сулдан уңга): Сөббух Рафиков, Хәсән Туфан һәм Ибраһим Салахов. 1956 ел.*

килешмәүчәнлеген эчке рух бунты рәвешендә эзлеклелек белән белдерергә җөрьәт итмәгән. Киресенчә, ГУЛАГ михнәтләрен уналты ел буена татыса да, җинаятьчел хакимият юлбашчыларына нигездә лояль мөнәсәбәттә торган. Югыйсә исән калган сәяси тоткыннарның күпчелеге соңыннан әдәбиятта үзләре канлы режимга карата хөкем карары белән чыктылар.

Әлбәттә, Туфан кебек трагик затка янә хөкемче булырга маташу—үз-үзенә гөнаһ китерүче көферлеккә тиңдер. Шулай да шагыйрьнең эчке каршылыкларын тулырак аңлау өчен болары турында искә алып үтү дә зарур, чөнки әлеге үрнәктә тоталитар идеологиянең ни дәрәҗәдә анга-канга үтеп керүе дә ачык күренә. Еш кына диссидент язучылар шулай искәртергә яраталар: төп куркыныч хакимият әзәрлекләвендә түгел, ә режим тарафыннан гипнозлануда. (Шайтан алгыры, шәкерт Хәсәннең мәдрәсәдә гипнотизм китапларын урлап укуы күз алдына килә). Гадәттә, олы иҗатлы әдипләрне зур елгаларга тиңлиләр. Ә совет хакимияте хөкем сөргән заманнарда мәгърур елгаларның агышын да яна үзәнгә кертеп җибәрергә мөмкин иде. Фаҗига менә кайдан башлана! Бөтен ил күләмендә котылгысыз идеологик мутация шаукымы тантана иткәндә, ай-һай, гөнаһлы фани затка нурлар сирпеп торучы фәрештә булып калу мөмкинме икән?! Эзопчарак язылган бер шигырендә әдибебез юкка гына шулай искәртмәгәндер:

Дөнья сина әйтә алыр, илем:
—Үзең кебек иде бу улың!..

Әмма үз-үзен ачу юлында санап бетергесез авыр сынаулар үткән Хәсән Туфан шул дәрәҗәдә олы шагыйрь ки, аерым тарихи шәхесләрне бәяләүдә бераз ялгышып китү генә аның зурлыгын кечерәйтә алмый. Бу җәһәттән һич тә шикләнмичә әйтергә мөмкин, ул Кол Галиле, Мөхәммәдьярлы, Кандалыйлы, Тукайлы, Дәрдмәндле халкыбыз кулындагы мөбарәк тәсбихнең бер төшен-буынын гәүдәләндереп тора. Аны ялгышлары белән бергә язылган милләт язмышыннан берничек тә аерып булмый. Шунысын да игътибарга алыйк: Хәсән Туфан туган телебез җирлегендә нииндидер илаһи әмер белән яратылган шагыйрь, тәрәккыятебезнең уникаль вакыйгасы буларак кабул ителә. Ә телнең теләсә нинди партияләргә яисә режимнарга караганда да борынгырак һәм озын гомерлерәк икәнлеге мәгълүм. Менә ни өчен аның күнел-калбеннән индерелгән әсәрләрендә гайре табигый ясалмалылык сизелми—шигырьләрне яшеннән соң сафланган һава итеп сулыйсың, баскыч-баскыч улаклардан агып ятучы көмеш чишмә суы итеп эчәсең, могҗизалы җәйге төннәрнең берсендә хуш исен тарата башлаган бөтнек итеп иснисең, мәһабәт мәчет тарафыннан ишетелгән гакыллы вәгаз итеп тыңлыйсың...

Нәрсәгә лә тормыш?..

Яшәешнең бөтен серләрен белеп бетергән аксакал булып күзалланучы Хәсән Туфан үзенең кабатланмас олы иҗаты белән әлеге сорауга бик тә тулы итеп җавап бирүгә ирешә. Үзенең инануынча, нәкъ Туфанча, чын шагыйрьләрчә җавап бирде.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Рецензияләр конкурсы*

## ИЛ ТУРЫНДА «ИЛ» КИТАБЫ

Шагыйрьләр дәүләт белән килешү төземи генә дөньяга киләләр икән дә килешү төземичә генә әсәрләр язалар, иҗат итәләр икән! Менә ни өчен дәүләт аларга хезмәтләре өчен түләми дә икән.

Бу хәлне төгәл аңлатырлык әйтемнәр дә юк бугай. Чөнки бу күзгә керер торган көферлек бит. Фәкать: «Вот где зарыта собака!»—дип кенә төкерәсе кала.

Бу минемчә, шагыйрьләрчә төкеренү, ә менә ханнарча ул болайрак була икән:

«—Йә?—диде ул түземсезләнеп.

—Тәкъсир!—Казый тагы башын иде.—Калада бер гидай шагыйрь пәйда булган.

—Бу яңалыкмы?—дип кычкырып җибәрде хан.—Ул дәрвишләр, суфыйлар, шагыйрь-шогырьләр бөтен каланы басып алды инде. Кая төкермә, берәр шагыйрьгә эләгә. Әрәмтамаклар!»

Бу сөйләшү Ркаил Зәйдулланың «Ил» исемле китабыннан, аның да «Хан һәм шагыйрь» исемле хикәясеннән.

Бу хикәяне укып бетерүгә һич котелмәгәндә ачу чыга. «Юк, юк! Алай булырга тиеш түгел. Шагыйрьләр андый булмый. Тәхет шагыйрьлектән, җаннан да югары була алмый!—дип кычкырасы, барлык шагыйрьләрдән сорашып фикерләрен беләсе килә башлый. Әмма уйланып каласың: Ркаил дигән шагыйрьгә дә, бу хакыйкатьне әйтеп бирү, шагыйрь хәлендә, әйтергә мәҗбүр булуы җиңел булмагандыр.

Ул әйткән әлеге хакыйкать миңа шундый тәэсир ясады да инде. Бераздан кайнаган уйлар ташкыны ярларына кайткан язгы судай үз уңаена ага башлыйлар. Ә ярда ак, зәңгәр, эре, вак бозлар утырып калган. Алары башта ярны, аннары терелеп килүче үләннәрне өшетә дә җиргә дым булып сеңә. Һәм... ул урыннарда үләннәр куе, биек булып үсеп китә.

«Хан һәм шагыйрь» хикәясен укыганнан соң да уй, җан үзәннәрендә шуңа охшашрак хәлләр була икән. Хикәя өтеп алган аң, җан инде бервакытта да бәхетне тәхеткә алыштырган шагыйрь хәленә төшмәячәктер.

Шагыйрь Ркаил Зәйдулла гаҗәеп оста итеп прозада да яңа образлар иҗат итә. Хан янына ул вәзир яки куштанны түгел, ә казыйны якын тота. Ханның шагыйрьләргә «әрәмтамаклар» дип җикеренүеннән соң язучы болай фикер йөртә.

«Казый астыртын гына елмаеп куйды. Бирдебәкнең (ханның) яшьлегендә шигырь язып маташуын, Ширванда калгай булганда шагыйрьләр диваны җыярга яратуын ул белә иде. Шагыйрьләрнең бергә җыелганда ханның көпшәк бәетләрен бер-берсенә кабатлап, тыела алмый көлүен дә ишеткәне бар иде. Әллә шуны сизеп алган Бирдебәк тәхеткә менгәч, шагыйрьләрне тәмам күралмый башлады. Үзең менә алмаган кыяга нәфрәт белән карау кеше өчен табигый бит ул».

Мин авторның мондый фикере белән дә килешмим, әлбәттә. Чөнки дөньяга яшәргә, иҗат итәргә, дөньяны танырга һәм аны тану аша үзен танытырга килгән шәхес үзе менә алмаган һәр биеклекне күрә алмаса, аңа нәфрәтләнсә, җимерүче көчкә әверелер иде. Ә иҗади шәхестә Соклану дигән бөек хис өстенлек итә. Андый күралмау аерым бер категория, тар күңелле, бу дөньяны иҗат итәргә, дөньяга, кешелеккә үзендә булган иҗади сәләтне бирү өчен түгел, ә типтереп яшәп, башкалар

һәм жир язмышына төкереп китәргә килгәннәр өчен генә хастыр. Әмма бу хикәядәге вакыйга кысасында автор нәкъ шундый психологияле ханга мөнәсәбәттә мондый фикерне әйтә икән, бу аклана. Чөнки хикәядән күренә: тар күңелле хан ил белән ничек идарә итү кирәклеген сөйләп йөргән шагыйрь Әхмәд Болгарыйны «Салкын ташка» (зинданга) дип кенә ысылдый. Хан шул ысул белән үзенең тәхетен ныгытмакчы һәм рухи вә матди байлыкларның бердән-бер хуҗасы булып калмакчы. Киләчәк хакында уйларга сәләтле хан, дәүләт эшлеклесе шундый гамәл кылырмы? Ә бездә, безнең үзебездә ничек әле?

Ничекме? Аны аңлау өчен 1938 елны гына да искә төшерү җитәдер. Ул елларда Язучылар союзында әгъза булып торган һәр язучы эзәрлекләүгә дучар ителә. Шулай булмаса, 1938 дә инде алынасы алынып, качасы качып, посасы посып беткәч, соңгы кеше—хуҗалык эшләре мөдире союз рәисе булып калыр идемени? Тагы нинди һөнәр кешеләре шулай соңгы кешесенә кадәр репрессиягә эләгә?

Ә тагы 1941—1945 еллар? Бөтен татар милләтенә бер-ике генә дистә саналган каләм әһелләрен ачыктан-ачык сугышка озату... Юкса Мәскәү үз язучыларын Татарстанның аулак шәһәре Чистайга китереп урнаштырган бит.

Ә Туфан, Бурнаш, Ибраһимов, Фатих Кәрим, Кәрим Тинчурин? Әйе, безнең бөтен шагыйрьләребез, язучыларыбыз да репрессия икмәген татыганнар шул!

Бүген шагыйрьләрне ачыктан ачык зинданга ташларга боерык бирмиләр шикелле. Әмма «Яшәргә» дигән сүз дә юк. Яшәргә дисәк, гомер бакый теләсә кайсы дәүләтнең хис вә акыл институтын хасыйл иткән язучы-шагыйрьләр ничек яшәргә тиеш икән соң? Шул сорауга җавап алганда гына хакимнәрнең каләм әһелләренә мөнәсәбәтен билгеләргә мөмкин ич.

Юк, шагыйрь үзенең итәк очын тотып йөрү өчен пажлар таләп итмәс! Ул хәттә өч көн рәттән бәйрәм дә итә алмас, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән асыл кием-салым, урын-җир, зиннәтле сарай да аңа кирәк түгел. Аңа бары тик дөньяны тану аша үзен, милләтен, халкын дөньяга таныту гына кирәк. Моның өчен аңа сәяхәт, сәяхәт, сәяхәтләр һәм җан халәтенең күпмедер тотрыклылыгын булдыру өчен гаиләсенең туклыгы-иминлеге генә кирәк. Һәм ... Ялгызлык кирәк.

Ә бездә очраклы рәвештә генә матди стабильлеккә ирешкән (монысы да бик тә чагыштырмача) өч-дүрт язучыдан башка кем бар андый? Шагыйрьләрдән бөтенләй дә юктыр. Мин белмим...

Ә менә ул заман шагыйре Әхмәд Болгарый—гидай. Мең еллар элек тә шагыйрь болай сөйләгән:

—Хан гадел хөкем итәргә тиеш. Ул салымнарны халык күтәрә алганча салырга, угры түрәләрне җәзаларга, илбасар сугышлар алып бармаска тиеш!

Шагыйрьләр бүген дә шул сүзне кабатлыйлар. Һәм бүген дә ханнар шушы хикәядәге кебегрәк җаваплыйлар:

—Менә син гаделлек турында сафсата сатып халыкны болгатасың—ахмак кешеләр, гаделлек табабыз дип, фетнәгә кузгала. Бераздан минем ясауларым аларны чебен урынына сыта. Елга кебек кан коелачак. Син шуны аңла, шагыйрь: ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас. Димәк, гаделлек турында сөйләп, син үзеңә ияргәннәргә гаделсезлек эшлисең. Шуңа күрә мин афәт чыкканчы ук синең башыңны чабарга боерам. Сиңа карата бу гаделсезлек булыр, чөнки син дә адәм баласы, сине дә Алла яраткан, әмма синең сафсатаңа ияречәк беркатлы бәндәләр өчен бу гаделлек булачак. Мин шулай күбрәк кешенең гомерен саклап калам.

Мантыйгы бар сыман да... Әйе шул, шагыйрьләр һаман да ач-ялангач, зинданга ябылмаган килеш тә бик астында бүген. Чөнки «зинданга ябарга!» дигән боерыкның сүзсезләре дә була икән бит.

Әмма шагыйрьләр бүген дә шуны кабатлыйлар:

—Хан гадел хөкем иткәндә бернинди дә фетнә кузгалмый!

Хикәядәге хан шикелле үк бүген дә шагыйрьләрне тәхеткә үк утыртмасалар да, яннарында йөртеп карыйлар хакимнәр һәм... бераздан алардан котылгач, иркен сулап куялар. Чөнки тәхеткә утырып алганнар һаман да «Күктә—тәңре», «җирдә—хан»—дип уйлыйлар бугай.

Күктә—тәңре... Кара инде, әллә ул заманнарда ханнар иманлы булды микән? Чөнки хәзерге хакимнәр үзләреннән дә югары көч барын бөтенләй исләреннән чыгарып, үлем һәм бакыйлык барын бөтенләй дә онытып, фәкать фанилык хәстәре белән генә яшәп китеп баралар түгелме? Һәм шундый «яшәеш»ләре белән олырак максатлы кешеләрнең нәфрәтенә юлыгалар. Чөнки «Ходай бүлеп биргән гомердә,

мәңгегә килгән кебек кыланып, үзең кебек ике аяклы кемсәләрне буйсындырырга маташып, ялтыравыкларга, чүпрәк-чапракка алданып, ыгы-зыгы дингезендә батакалка матавыклану шулкадәр мәгънәсез эш икән»леген алар бөтенләй онытталар. Әйе, исән-сау каласы килү, тәхет эргәсендә булашу Алланы да оныттыра, теге дөньяда җавап бирәсе истән чыга, тәмуг газаплары да ерагая...

«Ау тәмам иде»—киселгән шагыйрь башы капчыкта... Ә башкача чишелеш булырга мөмкинме соң?

«Хан һәм шагыйрь» хикәясе мәнә шундый уйлануларга китерә.

Ә менә Тимер бога (шул исемдәге хикәя каһарманы)—монысының башы да шул ук капчыкка керерме? Бу кешенең холкында ни җиңәр? Ихласлыктабигыйлекме? Мәкерме? Мәхәббәтме?

Бу хикәядә мәхәббәт тантана итә. Әмма хикәядә мәхәббәт су асты агымындагы көч булып килсә дә, җир өстендәге берсеннән-берсе пычрак күренешләрне җимереп китәрлек ташкын булып ташый алмады. Башкортның авыр хәләте, урысларның шакшы яшәешләре күңелне болгата, җанны җирәндерә—кыскасы, хикәя кысалары гына сыйдыра алмаслык пычраклык, кабәхәтлек кыстап тутырылган монда. Юкса бик тә төгәл, тарихи ышандырырлык (ибн Фазлан чыганаклары) детальләр белән бирелгән сурәтләүләр. Инкарь итәрлек берни дә юк.

Тарихи хикәяләр сине еш кына үзенең дөреслеге белән күкнең җиденче катына күтәрә һәм очынып барган күңелеңне шап итеп фани җиргә төшереп ташлый. Тарихи хикәяләрне сәнгати мавыктыргыч итеп язуның катлаулыгы да, авырлыгы да шунда инде. Язучы уйдырмасы бирә алырдай көтелгән шатлык булмый кала.

«Тәңре кылычы» хикәясендә дә Аттила һич көтелмәгәнчә. «... иң татлы үлем—хатын-кыз өстендә...» үлеп китә. Тик хикәядә гаҗәеп зур осталык белән яшәешнең бөек фәлсәфәсен тәшкил иткән кануннар сәнгати гәүдәләнешләрен тапканнар. Бу хикәяне укучы үзе теләгән теләсә кайсы сорауга җавап табааладыр. Мәхәббәт һәм мәкер, михнәт һәм ләззәт, коллык һәм хакимлек, байлык һәм гидайлык, законлылык һәм очраклылык, нәфес һәм тыйнаклык, акыл һәм ахмаклык, хан һәм шагыйрьлек, сату һәм сатылу, кыйбла һәм кыйбласызлык... Шулай чиксез дәвам итәргә мөмкин.

Кыйбла вә иман. Без каян киләбез дә кая китеп барабыз әле? Кем булып барабыз? Кыйбланнан яртышар адымлап кына тайпылсаң да, барыбер башка якка китәсең. Иманыңны тамчылап кына сатсаң да, барыбер, имансыз каласың. Ахыр чиктә барыбер үз-үзеңнән китәсең. Ә үз-үзеннән киткән кеше үзен кем итеп хис итә соң? Ахыр чиктә эт итеп...

Үз-үзләрен «без кечкенә кешеләр, бездән берни тормый, без берни эшли алмыйбыз», дип типтереп диярлек яшәп ятучы милләттәшләрем, мин сезгә «Шаһгали»гә әверелүнең җанлы сурәтен күрү өчен шушы «Шаһгали» хикәясен укып чыгарга тәкъдим итәр идем. Ата-баба гореф-гадәтләрен санга сукмый, «барыберләр» токымындамын дип, уйлап, сатылганнар хөкеменә килеп җитәләр дә бик соң, бик соңлап «җан» дигән төшенчә, ул гына да түгел, «бакыйлык җан» барын искә төшерәләр. Төшерми хәлләре юк, җан үзен-үзе сиздерә! Аны күпме генә яшерергә тырышсаң да, Вакыт галиҗәнәпләре җанны тормыш дингезендә мәңге батмас каек итеп йөртә дә синең алдыңа китереп куя. Хәйләсез дөнья хәерсез дисәләр дә, киләчәккә үзең булып бару өчен хәйлә генә берни эшли алмый. Ул вакытлы, көнлекче төшенчә генә шул. Киләчәккә син үзең булып фәкать милләтең белән бергә генә, аңа хезмәт итеп, бар сәләт, талантыңны хезмәт иттереп кенә бара аласың. Диңгезләр тамчылардан җыела икән, милләт җаны аның һәр кешесеннән җыелмый нидән җыелсын инде... Шаһгалиләр таркатa башлаган татар баласы язмышы Ркаилнең һәрбер хикәясенә күчеп кергән.

Милләт, милли аң таркалу атом төш таркалу сыман афәт ахрысы. Ул бер башланса, чылбырлы таркалу сыман тоела миңа. Тик кешегә Хода җан биргән. Шагыйрь Хәсән ага Туфан әйтмешли, ул гади генә материя түгел, аның сөйли, җырлый, сагына торганы. Димәк, сөйләр теле, җырлар җыры, сагына торган җире, заты, нәселе, милләте булырга тиеш. Димәк, ул шуларның барысы бергә булганда гына Кеше булып яши ала. Димәк, шушыларны саклап кала алганда гына ул үзе булып кала ала, киләчәккә үзе булып бара ала. Димәк, нәкъ менә шушылар чылбырлы реакцияне туктата алалар. Димәк, шаһгалиләргә шушындый гамәлләр чик куя ала.

Китапның икенче бүлегендә егерме хикәя. Егермесе егерме мең генә мәсьәләне эченә алмагандыр. Менә берничәсенә генә күзәтү ясап үтик әле.

«Төнге сәфәр» хикәясе мәхәббәт һәм мәкер, мәхәббәт һәм хәмер, хыянәт һәм тугрылык турында... Юк, алай түгел: мәңгелек төшенчәләр бервакытта да мизгеллек төшенчәләр белән рәттән тора алмый. Яшәү ярларын югалтканнар, елга дип сазга эләккәннәр хакында икән бу әсәр. Хикәяне укып чыккач: «Их, Луиза шул коньякны эчмәсә, бөтенләй башкача буласы иде бит дөнья!»—дип куясың.

«Дару» хикәясен укыгач, балачак, ихлас мәхәббәттән ераклашуның үз-үзеңнән ераклашу, ахыр чиктә, үз-үзеңнән китү икәненә анык төшенәсен. Әмма «алтыдагы—алтмышка» дип халык белми генә әйтми шул. Бала чакта чатнаган гына бөтенлекнең ярыгы зурая бара да—жанны гәүдәсеннән үк түгеп җибәрә икән. Ирхан (хикәянең төп герое) «ир»дән фәкать «хан»га гына әйләнеп кала.

«Бала». Хикәядә әлегәчә кешелек хәл итә алмаган мәсьәлә—мәхәббәт һәм җәза. Ана кеше бала таба. Ә ул—гарип. Аяк-кулы гына түгел, акылы да зәгыйфь. Һәм ана кеше гомерен шушы гарип балага багышларга дучар ителә. Ни өченме? Чөнки ул мәрхәмәтле. Ул гарипне Хода биргән, Хода гына аның гомерең өзә ала. Ә ул гариплләр, зәгыйфьләр саны үсә дә үсә. Кара газап, җир өстендә үк тәмуг газабына керүче аналар саны да. Һәм... бу хәлләрдән чыгу юлы да күренми. Ул баланың гарип туууында күп очракта ананың һич кенә дә гаебе юк. Кем гаепле? Кем Чернобыльне тудыра? Эчәрсу һәм һавабыз, инде дә җыйган ризыгыбызның сыйфаты нинди?

«Итек». Бу хикәяне укып чыккач, мин фәкать ике генә сүз язып куйганмын—хәерче шатлыгы. Әмма бу хикәя дә үзе бер ил. Күпләребезне җирдә фәкать шул нәни куанычлар һәм бердәнбер кешенең җылысы гына тотып тора, зурлары—юк...

«Алла» хикәясендә исә ирләренең ихтыярсызлыгымы, әллә кысылганлыгымы сурәтләнгән? Әмма хикәядә мишәрлекне артык алга сөрү, әллә ничек, теге ерак башкорт авылы диалектын алып, шуны яңа тел дип исбат итәргә маташуны хәтерләтте. Әнә шунлыктан ни олы мәгънәгә ия хикәянең асылы артка чигенде дә куйды.

«Ачкыч чыпта астында». Әйе, бу хикәядә сурәтләнгәнчә, дөньяда олы, матур гамәлләрне бозар өчен йозак кадәрле көчек тә җитә. «Шул чагында йозак кадәрле генә көчек каяндыр килеп чыкты да болытларны качырырлык әче тавыш белән өрә башлады» ди автор. Көчек болытны качыра алмаса да, җаннан шатлыкларны куа ала икән шул.

«Сөембикә» хикәясен укыганнан соң исә: «Их бу Ркаилне, ник Сөембикәнең монысын да илдән сөреп кол иттең инде?»—дип кычкырасы килә. Күңелдә әрнү. Сөембикә җаны шул аяк астында ялгыш басып сытылган тычкан сыман. Тагын кычкырасы, тагы чаң кагасы килә: татар кызлары, укып карагыз әле. Бу авыр хакыйкатьне язучы укучы укысын өчен генә шулай көндәлек «күлмәгенә» төреп биргән.

«Кызыл сыер» хикәясендәге үзе кызыл сыер сыйфатында калган мәхлук ир, «Йөз тәңкә» хикәясендәге ябышкак Фатих та тормышыбызның карадан кара яклярын ачып күрсәтәләр. Юк, андыйлар кешелеккә берни дә бирә алмый. Киресенчә, башкаларның яшәешләрен агулыйлар гына.

Мин китаптагы хикәяләрнең уртак яклары, тема, сәнгати чараларын билгеләп, төркемнәргә бүлеп карамакчы идем дә, булмады. Бу мөмкин түгел икән. Чөнки Ркаилнең «Ил» китабындагы һәр хикәясе үзенә бер ил, аларның һәрберсенең үз мантыйгы, үз максаты, фәкать шушы хикәядә, шушы ситуациядә генә үз асыллары ачыла ала торган шәхесләр икән.

Кешенең үз асылында саклап калдыра алучы факторларның ничек таркалуын язучы икенче бүлектәге хикәяләрдә аерым бер вакыйга аша күрсәтергә омтыла. Тик ул хикәяләр шулкадәр тыгыз ки, аларга повесть, хәтта роман кысалары да сыйдыра алмас барлыкларны шыплап тутырган автор. «Шаман» хикәясе күтәргән йөк—роман йөге, әлбәттә. Бу бик көчле психологик роман булыр иде. Кайбер хикәяләрне укып чыккач, җанда туган үкенү хисе Мәгъсүм Хуҗинның «Дус кыз» хикәясен Ркаил хикәяләре янына тартып китерде. Тик Мәгъсүм аганың бу хикәясе ни турында дип сорасалар, мин өздереп, мәхәббәт хакында дияр идем. Ркаил Зәйдулла хикәяләрендә исә мәхәббәт дөнья мәшәкатьләре, көндәлек ваклыклар эченә кереп кысылган. Әллә мәхәббәт шул фанилык сазлыгында чәбәләнгәнгә күрә дөньябыз шушы хәлләргә төште микән?

Тагы хикәя, тагы уй... Бу китап үзе дә шулай язучы шәхесе уйланып утыруы сыман төзелгән дә. Башта ерак тарихка сәяхәтләр кылынган, ул заманнарның ханнары һәм коллары, гавам, дала-зинданнары сурәтләнгән. Аннары язучы хикәяләре белән сине үз заманыңа якынрак кайтара. Шуларда үзебезне хикәяләп бирә, ничәмә ничә төрле кешеләр һәм... кеше түгелләр белән очраштыра.

Тарихи хикәяләрнең үз вакытында, шул заман колориты белән язылуы, һичшиксез, олы кыйммәткә ия. Ата-бабаларыбыздан ук килгән бу олы эшне дәвам итү, әлбәттә, кирәк. Юкса бабаларыбыз язган да бит, юк итеп кенә бетерелгәннәр шул. Шушы таләпләргә туры китереп иҗат итүче тагы бер олы шәхесебез бар. Ул—Марсель Галиев. Рабит Батулланың җыелма мәзәкләре дә шушы олы җан елъязмабызның бер тармагыдыр.

Өченче бүлектәге әсәрләр дә гаҗәеп бер төгәл мантыйк белән бирелгәннәр. «Ил», «Тел», «Дин». Әйе, теле, дине булган ил бик тә мантып китәргә мөмкин бит. Һәм шул илгә империя хуҗасы килеп, мөстәкыйльлек вәгъдә итеп, туйганчы алдый. «Тәхет бәхет китерә» (хикәят) дип уйлаучы куштан, шаһгалиләр моның янында тиреләреннән чыгарлык булып ялагайлана. Хәтта ул киткәч, Казанда каласыларын да онытып җибәрәләр. Шулай, кайберләре ияреп тә китә. Әмма күп үтәрме, «Читтә солтан булганчы» (хикәят) дип алар да кайту юлына чыгар. Чөнки гомер бер генә һәм ул бик тә санаулы гына көннәрдән гыйбарәт шул. Әмма картайгач инде илгә бирер сәләт тә, дәрт тә, дәрман да беткән—читкә сибелеп калган. Үкенечләр төяп кайтып егылгач, зимагур җырын гына җырларга кала:

Кайттым сиңа, туган авылым,
Сыйдырса әгәр гүрең...

Менә шулай—Ркаил Зәйдулланың «Ил» китабын укыйсың да ил язмышы хакында уйлар диңгезенә кереп чумасың. Язучының рухи түле гаҗәеп бай. Ркаилләр буынында, күпчелек прозаиклар шигырьдән прозага килделәр. Факил Әмәк, Рафаил Сибат, Зиннур Хөснияр, Вахит Имамов, Камил Кәримов, Марат Закир—болар барысы да шигырьдән азган язучылар. Телләре матур, кыйблалары анык, теләкләре зур. Үзләренең зурлыкларын таныйсы да, милләтенең аларны таныйсы һәм шул танылган каләм әһелләренә хөкүмәтенең яшел юл бирәсе генә кала. Дәүләте, хөкүмәте дә теле, иманы булган илне, дәүләтне торгызырга алына икән, бу язучылар соңгы тамчы каннарынача шул максатка хезмәт итәчәкләр.

Ә хәзергә «Нигез кычкыра» (хикәят):

—Сез, татарлар, кая барасыз? Нигез монда! Һәркем үз нигезен, үз туфрагын табарга, танырга тиеш!

«... ул күзгә күренмәс тамырлар аша рухымны тукландырып тора, шуңа күрә мин үземнең дүңгәләк түгел икәнлегемне төгәл беләм» ди Ркаил Зәйдулла «Читтә солтан булганчы» дип исемләнгән бу китаптагы соңгы хикәятендә.

Китапны яптым. Яптым да үземнең ике китап арасында еш кына адашып йөргәнлегемне аңлап алдым. Бу китапның икенчесе Марсель Галиевнең «Догалы еллар» китабы икән. Бу китаптагыча хикәяләү кискенлеге, тарихи фактларга байлык, хикәяләү алымнарының төрлелеге һәм теленең матурлыгы Ркаилгә дә хас. Кайбер хикәяләрендә шагыйрь-прозаикка гына хас җөмләләрнең асларына да сызып барганмын. «Тәрәзәләр капшанып пәрдә эзләделәр («Итек» хикәясе). «Анда—тәрәзәнең теге ягында—дөнья матур, дөнья киң иде. («Бала» хикәясе).

Мин Марсель Галиевкә: «Син $^1/_{32}$ ле ноталар белән язасың, билләһи, прозабызның Шопены син!» дип әйткәнем бар. Тере тарих елъязмасын язу өчен фани җирдән нинди биеклекләргә менеп төшәргә кирәген Марсель үзе генә беләдер. Бу нечкәлек чигенә Ркаилебез дә килеп җиткән икән, димәк, без шушы буынның зур проза осталарының үзенчәлекле шәхесе белән очрашабыз. Татар әдәбиятында Ркаил Зәйдулла биләгән урынны мин шулай билгеләр идем. Ә инде төрки әдәбиятлар арасында татар әдәбиятының тоткан урынын билгеләсәк, Ркаил Зәйдулла дигән язучыбыз төрки әдәбият дөньясында да үз биеклегендә кала.

Ә дөнья әдәбиятында барган бәйгеләрдә безнең татар язучыларының әлегәчә катнашмау сәбәпләре аңлашыладыр. Безгә бу өлкәдә дә ныклап эшкә алынырга күптән вакыт инде. Без бит дөньяда яшибез. Безнең дөнья халыкларына «олы татар милләте әсәре» дип тәкъдим итәр әсәребез нинди? Ул язылганмы, язылачакмы? Ә бәлки аны шушы «Ил» китабы авторы Ркаил Зәйдулла язар?

Мин бәйгегә дәшмим. Мин ил язмышы, милләтнең киләчәге хакында зур уйлануга гына чакырам. «Ил» китабы мондый уйлануларга ифрат та зур этәргеч бирә. Ул ил турында, чыннан да, «Ил китабы» дәрәҗәсендә язылган китап.

**Нәҗибә САФИНА**



*Коръән татар телендә*

# 5–МАИДӘ (ТАБЫН) СҮРӘСЕ

***(Маидә сүрәсе 120 аятьтән тора. Мәдинә-и Мөнәүвәрәдә вәхийның соңына ирешкән заманда иңдерелде. Маидә—табын, дәстархан, дигән сүздер. 112 һәм 114 нче аятьләрдә хәзрәти Гайсә заманында, күктән көтелә торган нигъмәт, ашъяулык, дәстархан турында сөйләнә, исеме шуннан килә.)***

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, иман китергәннәр, антыгызда *(вәгъдәгездә)* торыгыз. Хайваннарыгыз сезгә хәләл ризык ителде. Аятьтә саналганнардан *(харамнан)* башкасы. Ихрамда булсагыз, аучылык тыела. Аллаһ Үзе теләгәнен хөкем итә.

*(Ант, вәгъдә өч төрле. Коръәндә язылганча гына эш кылырмын, дип Аллаһ каршысындагы ант. Аллаһ исеме белән әйтелгән нәзерләр. Кешеләрнең үзара куешкан вәгъдәләре, сүзләре. Ихрам, ягъни харам, хаҗ вакытында ихрам бәйләү йоласы бар. Ихрам бәйләгән кеше махсус кием кия. Ихрам вакытында хәләл кылынган киекләрне ауларга ярамый.)*

**2.** Әй, иман китергәннәр, Аллаһ шәригатенен, харам айларнын, корбан чалунын, гәрданлыкларнын вә Раббыдан сәүдә файдасы һәм Анын ризалыгын эзләп Бәйт-ү Харамга килгәннәрнен дәрәжәсен төшермәгез, аларны рәнҗетмәгез.

Ихрамнан чыккач та ау башларга мөмкин. Харам мәчетенә кертмәгәннәре өчен син ачу тотып, явызланма. Игелек итүдә, яман эш кылудан саклануда бер-берегезгә ярдәмләшегез. Гөнаһ кылуда, дошманлык эшләрендә ярдәмләшмәгез. Гөнаһлы булып, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аллаһнын җәзасы бик тә хәтәр булыр.

*(**Харам айлар**—сугышырга ярамый торган айлар. Бәйт-ү Харам—харамлык, ярамаган эш кылырга ярамый торган бина. Гәрданлык—дини бәйрәмнәрдә мөселманлыкны, хаҗилыкны аерып күрсәтеп торучы бизәнү әйберләре: муенса, алка һәм башкалар. Корбанга чалынырга тиешле хайванның муенына матурлау-бизәү әйберләре, ягъни гәрданлыклар тагыла, бу очракта, әлбәттә, корбан гәрданлыгы турында сөйләнә.)*

**3.** Үләксә, кан, дуңгыз ите, Аллаһтан башка затка багышлап чалынган, буылып үлгән, *(таш, күсәк белән бәреп)* үтерелгән, биеклектән егылып үлгән, сөзеп үтерелгән, җанварлар ботарлаган хайван итен—үлеп житмәгәндә чалып калынганнан тыш—табына торган таш сыннарга багышлап чалынган итләрне ашау вә фал уклары *(ырымланган уклар)* белән үлчәү сезгә харам ителде. *(Андый итләрне ашау)* юлдан чыгу, дип атала. Бүген кяферләр сезне динегездән яздыру эшеннән ваз кичте. Хәзер алардан курыкмагыз инде. Минем җәзамнан куркыгыз. Бүген сезнен динегезне мөкаммәл иттем, сезгә дигән нигъмәтемне тәмам иттем вә сезнен өчен әзерләнгән Ислам динен хуп күрдем. Кем дә кем ашарына ризык табалмыйча, ачлыктан гаҗиз булса, *(харамны да)* ашый ала, гөнаһлы булмас дәрәҗәдә. Аллаһ ярлыкаучы вә кичерүчедер. **(4)** Нәрсәләр хәләл икәнелеген алар синнән сорый: Син әйт:

—Бөтен сыйфатлы вә саф нәрсәләр сезгә хәләл ителде. Аллаһ өйрәткәннәрне кулланып, сез аучылыкка өйрәткән җанварлар сезгә тотып биргән киекләрне ашагыз һәм Аллаһны онытмагыз. *(Ягъни, чалганда да, ашаганда да «бисмилла» әйтегез.)* Аллаһ каршында җавап бирүдән куркыгыз. Аллаһ сезне бик тиз җавапка тартачак. **(5)** Бүген

Журнал өчен Рабит Батулла әзерләде.

сезгә саф һәм сыйфатлы нәрсәләр ашарга хәләл кылынды. Үзләренә Китап индерелгән халыкларга бирелгән *(яһүди, христиан һ. б.)* ризыкларны ашау сезгә дә хәләл ителде. Сез ашый торганнар да аларга хәләлдер. Гыйффәтле мөселман хатыннары белән байтак еллар әүвәл Китап индерелгән халыкның гыйффәтле хатыннары да, мәһәрегезне бирү шартлы илә, намуслы булып, зина кылмаенча вә яшерен сөяркә тотмау шарты белән булган никах сезгә хәләлдер. Иман китермәгәннәрнен бу гамәле бушка чыгачак. Андыйлар Ахирәттә дә зыян күрәчәк.

**6.** Әй, мөэминнәр, намаз укырга ниятләгәч, йөзегезне, терсәкләрегезгә кадәр кулларыгызны, башыгызны мәсех итеп, тубыкларга кадәр аякларыгызны юыгыз. Әгәр дә сез тәһарәтсез икәнсез, буй абдәсте *(тәһарәт)* алыгыз *(баштан-аяк чайканыгыз)*. Хаста булсагыз яки сәяхәттә икәнсез яки бәдрәфтән чыккан булсагыз яки хатын белән булганнан соң вә су булмаган җирдә булсагыз, чиста туфрак-ком белән тәяммүм итегез, йөзегезне, терсәкләргә кадәр кулларыгызны сыпырыгыз. Аллаһ сезгә читенлек теләми, фәкать сезне саф-пакь итәр өчен һәм сезгә нигъмәт бирер өчен шуны таләп итә, бәлки сез шуна шөкер итәрсез? **(7)** Аллаһның сезгә булган мәрхәмәтен һәм Аңа биргән антыгызны исегезгә төшерегез.

Сез:

—Ишеттек һәм Сиңа итагать иттек,—дидегез. Бәс, сез Аллаһка *(биргән антыгызны бозудан куркыгыз)* итагатьле булыгыз! Шик юк ки, Ул сезнең күңелдә ни барын белеп тора. **(8)** Ий, мөселманнар, Аллаһ Хакыйкатен истә тотып, гаделлек белән шаһитлек кылучы кешеләр булыгыз. Башка бер халыкка булган ачуыгыз, сезне гаделсезлеккә этәрмәсен. Гадел булыгыз. Аллаһтан курку сездән ерак йөрмәсен. Аллаһка каршы баш күтәрүдән сакланыгыз. Аллаһ сез кылганнарның барысын да белеп тора.

*(Тәһарәт алу, саф, таза булу—ул тәннең сәламәтлеген саклау булса, кешенең рухи сафлыгы исә иман вә гаделлектер. Тәне таза, әхлаклы шәхестән дә кыйммәтрәк зат бармы икән бу дөньяда! Ислам, Коръән әнә шундый кешеләрдән торган җәмгыять корырга өнди.)*

**9.** Аллаһ Тәгалә иманлыларга һәм игелек кылганнарга ярлыкау вә олуг һәдия *(бүләк)* вәгъдә итте.

**10.** Инкарь итүчеләр һәм аятьләребезне ялганга чыгарырга тырышучылар өчен тәмуг вәгъдә ителгән.

**11.** Мөселманнар, Аллаһның сезгә биргән нигъмәтен онытмагыз, нинди дә булса бер кавем сезгә һөҗүм итәргә җилкенгәндә аларның кулын Аллаһ тоткарлады. Гаделсезлек кылып, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Мөселманнар бары тик Аллаһка гына ышана.

**12.** Хактыр ки, Аллаһ Исраил угылларыннан сүз алды. Араларыннан сайлап алып,унике өндәүче билгеләдек. Аллаһ аларга шулай диде:

—Мин сезнең белән бергә. Намазны дөрес укысагыз, зәкят бирсәгез, пәйгамбәрләргә инансагыз, аларга ярдәмчел булсагыз, Аллаһка булган изге вазифагызны үтәсәгез *(бурычка акча биреп торганда арттырып риба алмасагыз)*, гөнаһларыгызны каплармын, сезне арыкларыннан сулар агып торган җәннәтләргә кертермен. Ләкин моннан соң да кем инкарьлыкны сайлый, ул тугры юлдан язган хисапланыр. **(13)** Ант бозганнары өчен аларга ләгънәт ордык, аларны таш бәгырьле иттек. Алар *(изге китаплардагы)* сүзләрнең урыннарын алмаштырдылар. Үзләренә өйрәткән хөкемнәрнең *(Тәүратның)* ин әһәмиятле бүлекләрен (юри) оныттылар. Бик аз кешедән башка, алар арасындагылар өзлексез хаинлек кыла. Барыбер син аларны гафу ит, алардан үч алма. Шик юк ки, Аллаһ игелек кылганнарны сөя.

*(«Тәүрат бары тик бер генә нөсхә иде. Исраил угыллары—яһүдләр, бабилләргә әсир төшкәч, шул бердәнбер Тәүрат юкка чыга. Иреккә чыккач, алар хәтердә калганнар буенча Тәүратны яңадан язып чыгалар. Онытылыпмы, махсусмы, төп нөсхәдәге күп кенә урыннар китапка керми кала».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**14.** —Без—христианнарбыз,—дигәннәрдән дә сүз алдык, әмма алар үзләренә күндерелгән *(үгетләрнең, китапның)* мөһим бер бүлеген оныттылар. Шуңа күрә, алар

арасына Кыяматкә чаклы дәвам итә торган дошманлык салдык. Озакламый Аллаһ аларга кылмышлары турында хәбәр бирәчәк.

*(«Яһүдләр белән христианнар борын-борыннан дошманлашып, сугышып яшәгән. Аллаһ тарафыннан Гайсә пәйгамбәргә иңдерелгән Инҗилнең төп нөсхәсе шушы сугышларда юкка чыккан. Инҗилне хәтер буенча яза башлыйлар, шулай итеп, дөньяда бер-берсенә каршы төшә торган төрле-төрле инҗилләр барлыкка килә. Аерым мәзһәбләр барлыкка килә. Дөньядагы бөтен сугышлар, чынлыкта исә, кяферләрнең кара-каршы үзара сугышуыдыр. Бер дин әһелләре бер-берсен кыра, сыта, кол итә. Бу да Аллаһның вәгъдәседер».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**15.** Әй, китап әһелләре! Изге Китапта булган бик күп сүзләрне яшергәнлегегезне ачыкларга дип, Рәсүлебез килде. Кайбер хаталарыгызны ул күрмәмешкә салышыр. Чынлыкта исә, сезгә Аллаһтан бер нур, ап-ачык бер Китап инде.

*(Тәфсирләрдә төрлечә аңлатыла. «Кайбер хаталарыгызны ул күрмәмешкә салышыр» җөмләсе урынында «гафу итәр», «төшереп калдырыр» кебек гыйбарәләр язылган.)*

**16.** Аллаһның ризалыгын казанырга теләгән кешеләрне Аллаһ котылыш юлына күндерер, кодрәте илә Ул аларны караңгылыктан яктылыкка чыгарыр, тугры юлга күндерер.

**17.** —Шик юк, Аллаһ ул—Мәрьямнен углы Мәсих *(Гайсә)*,—дип әйтүчеләр чыннан да кяфер булды. Әйт син:

—Алайса, Аллаһ Мәрьямнең углы Мәсихне, аның анасын вә Җир йөзендәгеләрнең барысын да һәлак итәргә теләсә, кем Аллаһка каршы чыга алыр иде икән? Күкләрдә, Җирдә, икесенең арасындагы бөтен нәрсә Аллаһ хөкемендәдер. Ул теләгәнен яралтыр. Аллаһ бар нәрсәгә дә тулысы белән хаким.

**18.** Яһүдләр белән христианнар:

—Без Аллаһның угыллары вә аның сөеклеләре,—диләр.

Әйт син:

—Алайса, нигә соң Ул сез—гөнаһкярларны җәзалый? Дөресе, сез дә Ул яралткан *(барлыкка китергән)* бәндәләр бит. Ул теләгәнен ярлыкар, теләмәгәненә җәза бирер. Күкләрдә, Җирдә, икесенең арасында ни булса, барысы да Аллаһ милкедер. Ахырда, барыбыз да Аның янына кайтарылачакбыз.

**19.** Әй, китаплы халык! Пәйгамбәрләр озак килми торган арада Хакыйкатьне әйтеп бирер өчен сезгә илчебез килде. Сез соныннан:

—Безгә сөенечле хәбәрләр китерүче дә, яманлык турында кисәтүче дә булмады,—дип әйтмәсеннәр өчен дип, килде, һәм сөенче алырга, һәм кисәтүче буларак килде. Аллаһның бар нәрсәгә дә кодрәте җитә.

**20.** Исегездәме, Муса үз кавеменә ни диде?

—Әй кавемем, Аллаһның сезгә биргән нигъмәтен хәтерләгез сәнә; Ул сезнең арадан пәйгамбәр сайлап алды вә сезне милекле-дәүләтле халык итте. Галәмнәрдә һичбер кемгә бирмәгәнне сезгә бирде. **(21)**—Әй, кавемем, Аллаһ сезгә тәгаенләгән изге туфракка, *(Әрихә)* шәһәренә керегез һәм чигенмәгез, юкса, барын да югалтырсыз. **(22)** Алар шулай җавапланды:

—Әй, Муса, анда алыптай көчле халык яши, алар аннан чыгып китмичә, без һич тә анда керәчәк түгел. Әгәр алар чыкса, без, әлбәттә, керербез,—диделәр. **(23)** Куркып калганнар арасында Аллаһ рәхмәтен алган ике кеше бар иде. Алар әйтте:

—Алар өстенә капкадан керегез, керүгә үк сез җиңәчәксез. Әгәр сез чын мөэмин булсагыз, Аллаһка тапшырыгыз,—диделәр. **(24)**—Әй, Муса, алар анда чагында без ничек керик? Раббың белән икегез кереп сугышыгыз, без монда көтеп торачакбыз,—диделәр. **(25)** Муса әйтте:

—Раббым, мин үземнән һәм кардәшемнән башкага боерыкчы түгелмен, юлдан язган бу халык белән безнең арабызны өз!—диде. **(26)** Аллаһ әйтте:

—Алайса, кырык ел буена аларга бу җирдә яшәү тыела, шул еллар эчендә алар Җир йөзендә кангырып йөриячәк, юлдан язган бу кавем өчен син артык кайгырма,—диде.

**27.** Аларга Адәмнең ике углы турындагы дөреслекне аңлатып укы: алар икесе корбан чалды, берсенең корбаны кабул ителде, икенчесенеке кабул ителмәде. Шунысы әйтте:

—Һичшиксез, мин сине үтерәчәкмен!—диде.

Тегесе дә әйтте:

—Аллаһ тәкъва кешеләрдән генә корбан кабул итә!—диде. Һәм өстәп куйды: **(28)**—Әлбәттә, син мине үтерергә дип кул озайтсаң да, мин сине үтерергә дип кул озайтмам. Мин галәмнәрнең Раббысы Аллаһ каршысында гөнаһ эшләүдән куркам. **(29)** Мине үтерә калсаң, минем гөнаһларымны да, үзеңнекеләрне дә төяп, утка атылуыңны телим, залимнәрнең җәзасы шулдыр,—диде.

**30.** Көнчелек нәфесе вә нәфрәт аның *(Кабилнең)* зиһенен котыртты, аңа үз кардәшен үтерергә боерды һәм ул энесен *(Һабилне)* үтерде дә коточкыч югалтуга дучар булды.

*(Адәмнең балалары Кабил, Һабил, Әкълимә иде. Кабил белән Әкълимә игезәкләр иде. Әкълимәгә Һабил өйләнергә тиеш иде. Кабил дә Әкълимәне үзенә алырга теләде. Аллаһ аларның икесенә дә корбан чалырга кушты. Һабилнең корбанын Аллаһ кабул итте. Кабилнең корбаны кабул ителмәде. Кабилнең көнчелеге кузгалды. Ул Һабилне үтерде. Көнчелек кешенең иң яман гадәтләреннән берседер. Көнчелеген тыя алмаган бәндә, хәтта туганын да үтерә ала. Шуңа күрә, Ислам бу яман нәфесне богауларга, бетерергә өйрәтә. Кабил кебек гөнаһка батмагыз, ди.)*

**31.** Аллаһ Кабил янына бер карга җибәрде. Туганының мәетен ничек җирләргә өйрәтер өчен. Кылганына үкенеп ул:

—Языклар булсын миңа! Шушы каргадан да зәгыйфьмени инде мин, энемнең гәүдәсен дә җир куенына тапшыра алмыймын,—диде.

(*«Һабилне үтергәч, Кабил аның гәүдәсен кая куярга белмичә, көннәр буе күтәреп йөри. Карга килеп, аны ничек итеп җир казырга өйрәтте»*.

Шәех Ногмани тәфсиреннән.)

**32.** Менә шуңа күрә, Исраил угылларына шулай дип яздык:

—Кем дә кем кеше җанын кыймаганны үтерсә яки дөньяда бозыклык кылмаганны үтерсә, бөтен кешеләрне дә үтергән кебек булыр. Бер җанны коткарып калган кеше бөтен кешеләрне үлемнән коткарган кебек булыр. Пәйгамбәрләребез моңа ап-ачык дәлилләр китерде, әмма моннан соң да аларның күбесе *(гөнаһ кылуда)* хәттин аштылар.

(*«Исраил угыллары сугышып яшәде, төрле азгын уеннар вә фетнәләр кордылар, шуның аркасында меңәрләгән-йөз меңләгән җаннар кыелды, хисапсыз күп байлыклар әрәмгә китте»*.

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**33.** Аллаһка һәм Рәсүлгә каршы сугышканнарга вә Җир йөзендәге тәртипне бозарга маташучыларга җәза—аларны үтерү яки асып кую яки аяк-кулларын *(уң кул, сул аяк яки киресенчә)* кисү яки ватаннарыннан сөрү. Бу—аларның дөньяда казанган рисвайлыгы. Аларны Ахирәттә дә хәтәр газап көтә.

**34.** Сез аларны җиңеп, әсирлеккә алганыгызга кадәр тәүбә итсәләр, аларга теге җәзалар бирелми. Белеп торыгыз, Аллаһ ярлыкаучы һәм кичерүче.

**35.** Әй, мөэминнәр, гөнаһ эшләп, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аңа якынлашырга юллар эзләгез, Аның юлында Җиһад кылыгыз: котылырсыз.

**36.** Кяферләрнең кулында Җир йөзендәге байлыкларның бөтенесе булса, хәтта икеләтә артык булса да, Кыямәт көнендә җәзадан котылу өчен шул байлыкны бирсәләр дә, кабул ителмәс. Алар өчен әче газап бар. **(37)** Уттан чыгарга теләрләр, ләкин чыга алмаслар. Аларга бетмәс газап бар.

**38.** Угрылык итүче иргә, карак хатынга бер җәза: гыйбрәт өчен аларның куллары киселер. Аллаһ—кодрәт вә хикмәт ияседер.

**39.** Ләкин кем дә кем кылмышларыннан соң тәүбә итсә һәм игә килсә, шөбһәсез ки, Аллаһ аның тәүбәсен кабул итәчәк. Аллаһ—юмарт ярлыкаучы вә кичерүчедер.

**40.** Әллә белмисенме, Күкләрдә вә Җирдә ни булса, шул мөлкәт Аллаһныкыдыр, Ул теләгәненә газап бирер, теләгән кешесен ярлыкар. Аллаһ һәрнәрсәгә кодрәтледер.

**41.** Әй, Рәсүл, чын күңелдән иман китермичә, авызлары белән:

—Инандык!—дигәннәрнең вә яһүдләрнең көферлеккә омтылуларына исең китмәсен. Аллаһ аларның күңелен сафландырырга теләми. Алар өзлексез ялган тыңлый һәм синең янга килеп карамаганнарны тыңлый, *(Тәураттагы)* сүзләрне урыннарыннан кубарып алып, алмаштыралар.

—Әгәр сезгә шул бирелсә—алыгыз; бирелмәсә—алмассыз!—диләр.

Аллаһ берәрсен адаштырырга теләсә, адашканның файдасына син Аллаһка каршы берни дә эшли алмассың. Алар өчен дөньяда түбәнлек вә Ахирәттә *(махсус әзерләнгән хәтәр)* газап бар.

*(«Мәдинәдәге яһүдләр арасында зина кылучыларны тоталар. Боларга хөкемне Мөхәммәд чыгарсын, диделәр. Мөхәммәд, аларның хөкеме Тәуратта бар, диде. Зиначыларны таш атып үтерделәр. Яһүдиләр Тәураттагы хөкемнәрне яшерергә теләделәр».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**42.** Гел ялган тыңлыйлар, өзлексез харам җыялар. Сиңа килсәләр, теләсәң, хөкем ит, теләсәң, алардан йөз чөер. Йөз чөерсәң, алар сиңа һичбер зарар кыла алмас. Хөкем итсәң, гадел хөкем йөрт. Аллаһ гадел булганнарны сөя. **(43)** Кулларында Аллаһ хөкемнәре язылган Тәурат була торып, ничек инде алар сине хаким итеп куялар һәм соныннан синнән йөз чөерәләр? Алар иманлы бәндәләр түгел. **(44)** Тугры юлга житәкчелек вә *(тугры юлны)* яктыртучы нур булган Тәуратны иңдердек. Үзләрен *(Аллаһка)* багышлаган пәйгамбәрләр, Аллаһның Китабын саклау эше кушылган һәм Раббыга тәслим булган заһидләр белән дин галимнәре шуңа таянып, яһүдләрне хөкем иттеләр. Аларның барысы да моңа шаһит. Шуңа күрә, сез *(иманлы)* кешеләрдән курыкмагыз, *(имансыз калабыз дип)* миннән куркыгыз. Аятьләремне дөнья малына сатмагыз. Аллаһ иңдергәннәр белән хөкем итмәгән кеше кяферләрнең дә кяферәдер. **(45)** Тәуратта аларга болай яздык:

—Үлемгә—үлем, күз чыкса—күз, борын өзелсә—борын, колак өчен—колак, теш урынына—теш, җәрәхәт урынына җәрәхәт ясап, үч кайтарылырга тиеш. Кем боларны *(кан үчен алмаса)* гафу итсә, *(яки зыяны өчен түләсә)* ул кешенең гөнаһлары кичерелер. Кем Аллаһ иңдергәннәр белән хөкем йөртми, менә шулар була инде залимнәр.

*(Аллаһ иңдергән китапларга төрле карашлар бар. Ул китапларны танымаучы, аларга ышанмаучы, Корьәнне инкарь итүчеләр «кяфер» дип атала. Аллаһның хөкеме—гаделлек. Кяфернең хөкеме—гаделсезлек, золым. Андый кешегә «залим» диләр. Аллаһка буйсынмаганнарга тагын «фасикъ» та диләр.)*

**46.** Үзләреннән элек килгән Тәуратны дөресләүче һәм раслаучы итеп, Аллаһның җәзасыннан курыкканнарга тугры юл күрсәтер өчен һәм үгет-нәсихәт бирергә дип, тугры юлга юнәлтүче, шул юлны яктыртучы Инжилне биреп, Мәрьям углы Гайсәне пәйгамбәрләр артыннан пәйгамбәр итеп күндердек. **(47)** Инжилгә инанганнар, Аллаһ Инжилгә ничек язган, шулай хөкем итсеннәр. Кем Аллаһ иңдергәннәр белән хөкем йөртмәсә, менә шулар фасикъләр була да инде.

**48.** Сиңа да *(Мөхәммәд!)* әүвәлге китапны дөресләр өчен һәм саклар өчен хакыйкый Китапны *(Корьәнне)* күндердек. Инде алар арасында син Аллаһ иңдергән белән эш ит, сиңа бирелгән тугры юлны ташлап, аларның котыртыгына бирелмә.

*(Әй, мөэминнәр)* барчагызга бер шәригать, бер юл бирдек. Әгәр теләсә, Аллаһ сезнең барыгыздан да бер өммәт ясаган булыр иде. Ләкин шушы юл белән ул сезне сынамак була. Шулай булгач, игелекләр кылуда ярышыгыз, бер-берегезне уздырыгыз. Барыгыз да Аллаһка кайтачаксыз. Ни өчен аеры юлдан киткәнегезне Ул сезгә ап-ачык итеп күрсәтер.

**49.** Кешеләр арасында Аллаһ иңдергән белән хөкем йөрт вә аларның котыртыгына бирелмә. Аллаһ сиңа иңдергән хөкемнәрнең бер өлешеннән сине тайпылдыруларыннан саклан. Әгәр йөз чөерсәләр, белеп тор, Аллаһ шул гөнаһларның бер өлешен аларның башына *(бу дөньяда ук)* капламак тели. Инсаннарның байтагы юлдан язды. **(50)** Әллә соң алар җаһилият *(мәҗүсилек, наданлык)* заманнарын сагынамы?

Төпле белеме, иманлы халык өчен Аллаһтан да гаделрәк хөкем йөртүче башка берәү дә булмас. **(51)** Әй, иманлы бәндәләр, яһүдләрне, христианнарны дус итмәгез. Чөнки алар үзара дус. Аларны дус иткәннәр шулар кавеменнән кебек булыр. Шик юк ки, Аллаһ залимнәр кавеменә юл күрсәтмәс.

*(«Мөселманнар яһүдләргә, христианнарга карата булган нәфрәтләре аларның һичничек тә Исламны кабул итмәүләреннән түгел, Коръәндә ап-ачык күрсәтелгәне кеби, аларның мөселманнарга булган күрәлмәүчелеге, катгыян Исламны инкарь итүләре, еш кына яшерелмәгән, рәхимсез баскынчылыкка кадәр барып җиткән дошманлыгыннан килә». (В. Порохова, Коран. 658-б., 322 аңлатма.) Шуңа күрә, аларның тозагына капмас өчен, мөселманнарга үзара дуслыкны ныгытырга кирәк. Мөселманнар арасындагы икейөзлеләрдән, хаиннәрдән, койрык болгаучылардан, манкортлардан сакланырга кирәк. Яһүдләрнең, христианнарның ачык дошманлыгы мөселманнарга ул кадәр куркыныч түгел. Әмма мөселманнарның үзара тату булмавы, еш кына бер-берләренә зыян-зәхмәт салуы аннан да куркынычрак түгелме?)*

**52.** Син күрерсен, *(икейөзле монафикълар)* эчләрендә чир булганнар:

—Башыгызга бәла килүдән куркабыз,—дип кяферләр арасына кереп качар.

Ихтимал, Аллаһ сиңа җиңү иңдергәч яки үз тарафыннан бер әмер иңдергәч, алар күңелләрендәгеләр өчен үкенер.

*(«Күңелләрендә икейөзлелек чире булган хаиннәр, койрык болгаучылар үзләрен мөселман санасалар да, кяферләргә дус булырга тырышалар. Янәсе, алар куәтле кяферләрдән зыян күрербез, дип куркалар. Чын мөселманнарга җиңү, уңыш килүгә ук, тегеләр кяфер ягыннан мөселман ягына чыгалар».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**53.** Һәм шулчак мөэминнәр:

—Сезнең белән бергә булырга башларын ташка ора-ора Аллаһ исеме белән ант иткән бәндәләр шушыларммы инде?—диярләр.

Алар кылган бөтен эшләр заяга китәр һәм алар коточкыч югалтуларга дучар булачак.

**54.** Әй, иманлы бәндәләр, арагызда диненнән язган кеше булса, белеп торсын: Аллаһ үзе сөйгән һәм Аллаһны сөйгән мөэминнәргә кече күңелле, кяферләргә карата кырыс бер кавем китерәчәктер. Алар Аллаһ юлында Җиһад итәрләр вә һичбер куркытучылардан курыкмас. Бу Аллаһның Үзе теләгәненә биргән юмартлыгы. Аллаһның ярлыкавы вә гыйлеме киңдер.

*(«Исламга кермәгән кяферләр белән мөселманнар арасында мөртәтләр дә бар. Болары элек мөселман булып та, соңыннан диннән язып, Исламны ташлаган бәдбәхет—кабахәт кешеләр».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**55.** Сезнең дустыгыз бары тик Аллаһтыр, Рәсүлдер, иманлылардыр; алар Аллаһның әмерләренә буйсынучылар, намаз укырлар, зәкят бирерләр. **(56)** Аллаһны, Аның пәйгамбәренә вә иман китергәннәрне дус иткән кеше, һичшиксез, җиңү казаначак. Аллаһ тарафындагылар һәрвакыт өстен булыр. **(57)** Әй, иманлы кешеләр, сездән алда үзләренә Китап иңдерелгәннәрдән динегезне мыскыл иттермәгез, динегездән көлгәннәрне вә кяферләрне дус итмәгез. Гөнаһ кылып, Аллаһ каршысында җәза алудан куркыгыз, әгәр дә сез мөселман икәнсез.

**58.** Азан әйтеп, намазга чакыра башласагыз, *(кяферләр сезне)* мыскыллый башлый, *(гыйбадәтегезне)* көлкегә әверелдерергә маташа. Болай итүләре аларның уйлый белмәгән кавемнән икәнлекләрен раслый. **(59)** Аларга син болай диген:

—Әй, китап әһелләре, безгә иңдерелгән һәм безгә кадәр иңдерелгәннәргә ышанганыбызга күрәме Аллаһны да, мине дә хуп күрмисез? Алайса, сезнең күбегез юлдан язган бәндәләр.

**60.** Әйт син:

—Аллаһ хозурында булачак җәза мәсьәләсендә моннан да яманрак нәрсә булачагын сезгә сөйлимме? Кем Аллаһның ләгънәтен алды, Кем Аллаһның ачуына дучар булды, кемнедер Ул маймылга, кемне дуңгызга әйләндерде, кемдер Тагутка табына башлады. Менә шушылар инде иң яман урын алыр, шушылар инде

барысыннан да күбрәк тугры юлдан язганнар.

*(**Тагут**—Аллаһны танымыйча, азган, адашкан һәр кешегә әйтелә торган сүз. Шайтанга да «Тагут» диләр. Йазырда: араларыннан бер төркемне маймыл, дуңгыз вә Тагутка табынучылар, итте. Ягъни, алар маймылга, дуңгызга һәм шайтанга табына.)*

**61.** Яныгызга кергәндә алар Аллаһка ышанмыйча керә.

—Аллаһка ышандык,—диләр дә, ышанмаган көе чыгып та китәләр.

Аларның күңеленә ни яшерелгәнен Аллаһ бик яхшы белә. **(62)** Син аларның ярыша-ярыша гөнаһ кылганнарын, дошманлык иткәннәрен, күбесенең харам ашаганнарын күрерсең. Аларның кылмышлары никадәр әшәкедер. **(63)** Аларның дин әдәмнәре вә галимнәре әйтергә ярамаган сүзләр сөйләүдән һәм харам ризык ашаудан аларны тыйган булсалар иде! Аларның кылганы бик тә яман. **(64)** Яһүдләр әйтте:

—Аллаһның кулы богаулы,—диделәр.

Шулай әйткәннәренә күрә, аларның үзләренең куллары богаулы булыр, аларга каһәр иңәчәк. Киресенчә, Аллаһның кочагы җәелгән, теләгәненчә ярлыкау бирер. Хактыр ки, сиңа Раббыннан иңгән Китап аларның күбесенең азгынлыгын, көферлеген арттырыр. Алар арасына Кыяматкә кадәр дәвам итәчәк дошманлык керттек. Кайчан гына алар сугыш утын кабызмасын, Аллаһ аны сүндерә килде. Алар Җир йөзендә бозыклык таратырга атлыгып тора. Аллаһ бозыклыкны сөйми.

**65.** Әгәр дә китап әһелләре иман китереп, яманлык кылудан баш тартса иде, һәрхәлдә элек кылган яманлыкларын юар идек вә аларны нигъмәте мул җәннәтләргә кертер идек.

**66.** Әгәр алар Аллаһтан иңгән Тәүрат, Инҗил вә Коръән белән гамәл кылсалар иде, шөбһәсез, һәм *(Җир)* өсләрендәге, һәм *(Җир)* аяк астындагы нигъмәтләр белән туенырлар иде, байлыкка чумып яшәрләр иде. Аларның хәттин ашмаган *(бозык булмаган, тугры юлдан чыкмаган)* бер кавеме бар, ләкин күбесенең гамәлләре бик тә ямандыр.

**67.** Ий, Рәсүлем, Раббың индергәнне кешеләргә ирештер. Әгәр моны эшләмәсәң, илчелек вазифаңны үтәмәгән булырсың. Аллаһ сине кешеләрдән *(мәкердән)* яклаячак. Хактыр ки, Аллаһ кяферләр өеренә туры юл күрсәтмәс.

**68.** —Ий, китап әһеле, Раббыбыздан сезгә иңдерелгән Тәүрат, Инҗилне *(вә Коръәнне)* дөрес тотмасагыз, сезгә бернинди дә таяныч булмас,—диген.

Раббыңнан сиңа индерелгән *(Коръән)*, *(әлбәттә)*, аларның күбесенең көферлеген, азгынлыгын арттырыр. Кяферләрнең кирелегенә исең китмәсен.

**69.** Иман китергән кешеләр, яһүдләр, йолдызларга табынучылар, христианнар Аллаһка вә Ахирәткә инанып, игелек кылсалар, аларга куркыныч юк, аларга хәсрәт тә иңмәс.

*(«Коръән иңгәнгә кадәр, Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә чаклы кем нинди дин тоткан, кем нинди гөнаһ кылган, соңгы Пәйгамбәргә йөз тотып, чын күңелдән иман китерсә, шул иманыннан тайпылмаенча яшәсә, дөнья вә Ахирәттә аның өчен куркыныч юк».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**70.** Хактыр ки, Исраил угылларыннан *(Тәүрат буенча гына гамәл кылачакбыз, диган)* ант сүзе алдык һәм аларга пәйгамбәрләр күндердек. Берзаманны пәйгамбәр аларга күңелләре теләмәгән нәрсәләрне *(Илаһи хөкемнәрне)* китергәч, алар пәйгамбәрләрнең бер төрлесен ялганчыга чыгарды, икенчеләрен үтерделәр. *(Яхъя белән Зәкәрияне.)*

**71.** Болар өчен безгә җәза булмаячак, дип, алар *(Аллаһның хөкемнәренә)* сукыр-чукрак калдылар. Соңра Аллаһ аларның тәүбәләрен кабул итте. Ләкин аларның күбесе һаман сукыр-чукрак килеш кала бирде. Аллаһ аларның ни кылганын күреп тора.

**72.** Хактыр ки:

—Аллаһ—ул Мәрьям углы Мәсих *(Гайсә)*!—дигәннәр кяфер булды. Гәрчә Мәсих үзе:

—Әй, Исраил угыллары, Раббым вә Раббыбыз булган Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Һәм белеп торыгыз, кем дә кем Аллаһка тиңне эзли, мотлакан, Аллаһ аңа

җәннәтне харам кылыр, андый кешенең керәчәк урыны утлы тәмуг һәм залимнәргә *(анда)* ярдәм итүче булмас,—диде.

**73.** Хактыр ки:

—Аллаһ—өчнең өченчеседер,—дигәннәр дә кяфер булды.

Хәлбуки, бер Аллаһтан башка тәңре юктыр. Әгәр дә алар шулай кабатлауларыннан ваз кичмәсә, кяфер булганнар әче газапка дучар ителәчәк.

**74.** Аллаһка тәүбә итеп, алар ярлыкау теләмәсләрме икәнни? Аллаһ—юмарт ярлыкаучы вә кичерүчедер.

**75.** Мәрьям углы Гайсә *(Мәсих)* бары тик бер илчедер-рәсүлдер. Аннан элек тә күп кенә рәсүлләр килеп китте. Аның анасы да бик тә әхлаклы хатын. Һәр икесе дә икмәк ашыйлар иде. Күр, алар турында ничек ачык итеп әйтәбез, ләкин соңра ничек итеп *(Хакыйкатьтән)* йөз чөерәләр.

(*«Яһүдләр хәзрәти Гайсәнең намуслы, әхлаклы хатыннан туганына ышанмыйча, аның анасы турында төрле гайбәтләр сөйләделәр, имеш, Гайсә никахсыз, уйнаштан туган бала, диделәр. Коръән-и Кәрим бу гайбәтләрнең нигезсез икәнен исбат итә. Аларның икесе дә адәми зат. Чөнки алар икмәк ашый. Аллаһ икмәккә мохтаҗ түгел. Димәк, Гайсә Аллаһ була алмый».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**76.** Әйт син:

—Аллаһтан борылып, сезнең өчен файда да, зыян да эшли алмый торган зәгыйфькәме табынырга телисез? Барысын да белүче—ишетүче бары тик Аллаһтыр,—диген.

**77.** Әйт син:

Әй, китап әһеле, динегездә гаделсез рәвештә хәттин ашмагыз. Байтактан әүвәл юлдан язган, байтак кешеләрне юлдан яздырган вә тугры юлдан ераклашкан азгын бер кавемгә иярмәгез,—диген.

**78.** Кяферлектәге Исраил угыллары *(Аллаһ сүзен)* тыңламаулары вә *(азгынлыкта)* хәттин ашканнары аркасында Даут тарафыннан һәм Мәрьям углы Гайсә теле белән каһәрләнделәр.

**79.** Яман гамәлләр кылудан алар бер-берсен тыймады. Хактыр ки, алар кылган эш—зур гөнаһ.

**80.** Күбесенең инкарьчылар белән дуслашканын күрерсең. Күңелләрен аларга баглап, үзләрен алдан ук хәтәр нәрсәгә дучар иттеләр. Аллаһның ачуына тап булып, алар мәңгелек газап эчендә калачак.

**81.** Әгәр алар Аллаһка, Пәйгамбәргә вә аңа иңдерелгәнгә иман китермәс булсалар, тегеләрне дус итмәсләр иде, ләкин боларның күбесе тугры юлдан язды.

**82.** Дошманлык кылу нисбәтеннән караганда, кешеләр арасында мөселманнарга иң куркынычы яһүдиләр белән мөшрикләр *(күп аллалылар, потпәрәстләр, дәһриләр)* икәнен күрерсең. Алар арасында мөселманнарга иң якын торганнар:

—Без—христианбыз,—дип әйтүчеләрне дә табарсың. Чөнки алар арасында монахлар, галимнәр дә бар, алар бөеклеккә дәгъва итмиләр.

(*«Бу аятьләрдә телгә алынган христианнарның Хабәштанга (Эфиопиягә) күчеп, һиҗрәт итеп килгән мөселманнарны яхшы каршылап, аларга ярдәм иткән христианнар; хәзрәти Мөхәммәд белән солых төзегән Нәфран христианнары икәнлеге күп тәфсирләрдә фаразлана. Христианнарның яһүдләргә вә мөшрикләргә караганда, мөселманнарга якынрак торганнары хактыр. Гәрчә фанатик христианнарның хач-тәре яулары оештырып, мөселманнарга күп бәлаләр китергәнлеге тарихның иң әче-канлы сәхифәләрен тәшкил итә. Шулай да, дөнья мәшәкатьләренә кул селтәгән монахлар белән христиан галимнәре һәм алар тәэсирендәге христианнарның Исламга нисбәтән якынлыклары бар. Хәзрәти Пәйгамбәр килгәч, байтак кына монахлар куаныч белән каршы алдылар һәм аны көтелгән Пәйгамбәр буларак кабул иттеләр».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**83.** Рәсүлгә иңдерелгәнне *(Коръәнне)* тыңлаганда, Хакыйкатьне таныганнарына

сөенечтән, аларның күзләреннән яшь акканын күрерсең. Алар әйтер:

—Раббыбыз, иман китердек, безне Хакка шәһадәт иткәннәр сафына яз,— диярләр. **(84)**—Раббыбыз безне изгеләр арасына кертергә тели икән, ни өчен соң әле без алдыбыздагы Хакыйкатькә иман китермибез?

**85.** Шундый сүзләр сөйләгәннәренә күрә, Аллаһ аларга мәңге яшәр өчен, арыкларыннан чишмәләр агып ятучы җәннәтләрне бүләк итәр. Игелек кылганнарның әҗере менә шулдыр.

**86.** Инкарьчылар һәм аятьләремне ялганга чыгаручылар исә җәһәннәм кисәве булыр.

**87**. Әй, иман китергән кешеләр, Аллаһ хәләл кылган яхшы, саф нәрсәләрне харамга чыгармагыз вә хәттин ашмагыз. Аллаһ хәттин ашканнарны сөймәс.

**88.** Аллаһ сезгә хәләл кылган саф ризыкларны ашагыз вә үзегез баш орган Аллаһ каршысында гөнаһ эшләүдән куркыгыз.

*(«Бервакыт Гали, Ибне Мәсгут, Микъдат кебек кайбер сәхабәләр Госман бине Мазгун өенә җыелып, көне буе ураза тотарга, төннәр буе йокламыйча намаз укырга, хатыннар янына бармаска, ит ашамаска, иске-москы киеп йөрергә һәм калган гомерләрен шулай яшәп бетерергә, хәтта үзләрен кысырландырырга дип сүз куешалар. Рәсүли Әкрам бу турыда ишетүгә үк алар янына китте. Ул болай боерды:*

*—Мин шулай коллык итәргә дип, бернинди дә әмер бирмәдем. Тән һәм нәфес дигәннәрнең сездә хакы бар. Ураза тотыгыз, ләкин вакытында уразагызны өзеп, ризык җыегыз, вакытында йоклагыз. Мин намазымны укыйм, йокымны калдырмыймын, ураза тотамын, сәхәргә торамын, ит ризыкларын ашыймын, хатыннарымның ихтыяҗларын үтимен. Мин юлдан язган бәндә түгелмен.*

*Менә шушы вакыйгадан соң, югарыдагы аять иңдерелгән».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**89.** Мәкерсез, шаярып биргән антыгызны бозсагыз да, Аллаһ җавапка тартмас; фәкать шәригатьчә ант итеп тә, ул антны үз файдагызга бозганыгыз хәлдә сезне җәзалар. Бозылган ант өчен кәффарәт түләнә. Гаиләгезгә ашата торган ризыкның уртачасы хәтле микъдарда ун фәкыйрьнең тамагын туйдыру яки аларны киендерү яки бер колны азат итү фарыз. Боларны үти алмаган кеше өч көн тоташтан ураза тота. Ант эчкәннән соң, бозылган антыгызның кәффарәте шушы булыр. Сүзегездә торыгыз. Аллаһ сезгә ачык итеп аңлата, ихтимал, сез шөкер итәрсез.

*(Аллаһ исеме белән ант иткән кеше антын һичшиксез үтәргә тиеш. Әгәр дә ант итеп тә, эшләнәчәк эше харам яки яман икәне беленсә, ул кеше антын бозар; ул эштән баш тартыр һәм кәффарәтен бирер.* ***Кәффарәт****—гөнаһтан арыну өчен кылынган гадел эш.)*

**90.** Әй, мөселманнар! Хәмер эчү, азгын уеннар уйнау, табынгыч сыннарга баш ору, фал ачтыру, ырымланган уклар белән шобага салу шайтан гамәлләредер, шакшылыктыр, мондыйлардан ерак торыгыз: котылырсыз.

**91.** Исерткеч һәм азгын уеннар белән шайтан арагызда үч орлыкларын, дошманлык чәчә; Аллаһны искә төшерүдән вә намаздан биздерергә тели. Сез бу эшләрдән ваз кичә алырсызмы икән?

*(«Исламнан элегрәк заманнарда гарәпләрдә шәраб эчү йоласы бар иде. Аллаһ Тәгалә беренче мөселманнарны акрен-акрен генә исерткечләрдән биздерә башлады. Тыйды. Исерткечнең файдасына караганда, зыянының күбрәк икәнен искәртте. Соңыннан исерткеч эчкән килеш намаз укуны тыйды. Бу аять белән исертә торган эчемлекләрне харам кылды. Җаһилият вакытында гарәпләр ун данә ук сабы белән бертөрле отыш уены уйный иде. Ун укның җидесенә отыш язылган. Өчесе отышсыз, буш уклар. Отыш чыкканнар шул малны фәкыйрьләргә садака итеп тәгаенлый иде, әмма мал бәһасен оттырганнар түли торган булган. Оттырганнар үз малыннан колак каккан. Шуңа күрә, Ислам фәкыйрьләргә откан малдан түгел, хәләл малдан өлеш аерырга куша. Отышлы уеннарда уртага мал, акча кую тыела. Исереклекне тыю, азгын уеннарны рөхсәт итмәү, җәмгыятьнең һәм матди, һәм әхлакый ягын тазартыр өчен иң мөһим кануннардыр».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**92.** Аллаһка вә аның Рәсүленә итагать итегез һәм *(гөнаһ кылудан)* тыелыгыз.

Итагатьтән баш тартсагыз, белеп торыгыз ки, Рәсүлебезнең вазифасы *(бары тик Аллаһ хөкемнәрен)* сезгә дөрес итеп житкерү һәм анлатудыр.

**93.** Иман китергән вә игелек кылганнарга элек ашаган-эчкәннәре өчен гөнаһ юк, әгәр дә алар чын күнелдән *(гөнаһ эшләүдән)* саклансалар, иманнарын сакласалар, тагын да игелек кылсалар. Аллаһ игелек кылганнарны сөя.

**94.** Әй, иман китергән бәндәләр, Аллаһ кулларыгыз вә сөңгеләрегез белән ауланган җәнлекләр белән Аллаһны күрмичә дә аңа нык ышаналармы, юкмы икәнен сыный. Кем хәттин ашса *(тыелганнан артыгын кылса)*, шул эче газапка дучар.

*(Ихрам бәйләп, хаҗ йолаларын үтәгән вакытта киек-җәнлек аулау тыела, шул вакытта, мине берәү дә күрми, дип киек аулаган кеше гөнаһка батачак. Аллаһ барысын да күреп тора.)*

**95.** Әй, манлы бәндәләр, ихрамлы чагында киек-җәнлек үтермәгез. Арагыздан берәүсе *(ярамаганлыгын)* белгән көе җәнлек ауласа, аның әҗере җәзадыр. Арагыздан ике кешене хөкемдар итеп сайлагыз да, тотылган *(үтерелгән)* киекнең бәһасен билгеләтегез. Гаепле кеше үз хайванын чалып, шул киек микъдарындагы ит белән Кәгъбәдәге фәкыйрьләрнең тамагын туйдырыр. Яки гаепле адәм ураза тотсын. Шулай итеп, кылганнары өчен бәндә җавап бирергә тиеш. Аллаһ элеккесен гафу итә. Кем бу эшне кабат эшләсә, Аллаһ аны каты җәзага тартыр. Аллаһ һәрвакыт җиңүче һәм үч кайтаручы *(җәза бирүче)*.

**96.** Һәм сезгә, һәм юлчыларга, файда буларак, дингездә ау оештыру, тотылган ризыкны ашау хәләл кылынды. Ихрамлы чагыгызда коры җирдәге ау сезгә харам кылынды. Аллаһ хозурында җавап бирүдән куркыгыз.

**97.** Аллаһ Кәгъбәне—изге бинаны, харам аен, хаҗ корбанын вә алардагы гәрданлыкларны кешеләр файдасы өчен булдырды. Бу—Аллаһның күкләрдә, Җирдә ни булса, барысын да белеп торганын сез белсен өчен.

**98.** Белеп торыгыз, Аллаһның җәзасы әчедер. Аллаһның ярлыкавы, гафу итүе дә чиксездер.

**99.** Рәсүл өстенә төшкән вазифа фәкать *(Коръәнне)* ирештерү генә. Аллаһ яшермәгәнегезне дә, яшергәнегезне дә белеп тора.

**100.** Әйт син:

—Шакшы-яман белән сафлык-игелек бер түгел; хәтта шакшы-яманлыкның күпчелеге сезгә ошаса да. Акыл ияләре! Шулай булгач, сез гөнаһ кылудан, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз һәм *(тәмугтан)*, ихтимал, котылырсыз,—диген.

*(«Бу аять Исламның сан артыннан кумаганлыгын, бәлки, сыйфат өстенлеген күздә тота».*

*Хәйретдин Караман тәфсиреннән.*

*Яманлык күп булса да, игелек азрак күренсә дә, яманлыкның әле мотлак өскә чыкканы юк, Аллага шөкер.)*

**101.** Әйе, иманлы кешеләр, җавабы сезгә кайгы китерә торган нәрсәләр турында сорашмагыз. Коръән иңдерелгәч сорасагыз, ачык җавап табарсыз. Аллаһ сезне гафу итәр. Аллаһ юмартлык белән ярлыкаучы вә сабырдыр.

*(«Рәсүл-и Әкрам: Аллаһ сезгә (малы булганнарга) хаҗ кылуны фарыз итте, хаҗ вазифагызны калдырмагыз, дигәч, берәү: һәр ел саенмы, Рәсүлулла?—дип сорады һәм соравын тагын өч тапкыр кабатлады. Пәйгамбәребез бераз тын торганнан соң: әгәр дә мин хәзер: әйе, ел саен, дисәм, шулай фарыз булыр иде, алай эшләргә сезнең көчегез җитмәс иде,—диде.*

*Шушы аятьнең иңүенә бу вакыйга сәбәп булды. Онытканга түгел, кешеләргә кулай булсын өчен, Аллаһ кайбер нәрсәләрне ачык иттереп әйтми. Күп сораулар бирү эшне катлауландыра гына».*

*Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)*

**102.** Сездән алда килгәннәр дә шулай сораган иде, җавап алганнан соң да алар инанмады.

**103.** Аллаһ *(хайваннарны)* бахирә, саифә, василә, хам, дип атап, алар турында

күрсәтмәләр бирмәде. Ләкин кяферләр Аллаһка яла яга, чөнки аларның күбесенең башы эшләми.

*(«Исламнан әүвәл гарәпләрдә шундый йола бар иде. Алар биш тапкыр бозаулаган дөянең соңгы бозавы саулык булса, шул дөягә Бахирә исеме кушып, колагына тамга салып, иреккә җибәрәләр, шуннан соң ул дөяне саумыйлар, сөте таш сыннарга, потларга кала, имеш. Таш сыннар, потлар хөрмәтенә иреккә җибәрелгән һәм сөтен бары тик сәяхәтчеләр генә эчәргә тиеш булган дөяләргә Саифә диләр. Берсе саулык, берсе тәкә-игез бәрән китергән сарыкка яки ана дөягә Васила дип исем куша торган булганнар. Тәкә бәрән, үгез бозау потларга корбан буларак чалына. Ун тапкыр бозау атасы булган ата дөягә Хам исеме кушылган һәм ул да иреккә җибәрелгән. Имештер, кяферләр, шушы йоланы Аллаһ боерган, дип ялган сөйли».*

*Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)*

**104.** Аларга:

—Аллаһ иңдергәнгә *(Корьәнгә)* кайтарылыгыз, Рәсүл янына килегез,—дигәч, алар:

—Аталарыбыз тоткан юл безгә кадерле,—диләр. Аталары надан булып, яман юлдан киткән булсалар дамы?

**105.** Әй, иман китергән бәндәләр, жаныгызны коткару сезнең үзегездән тора. Сез тугры юлда булсагыз, азгыннар сезгә һичбер зыян кыла алмас. Барыгыз да Аллаһ хозурына киләчәксез. Ул сезгә ни кылганнарыгызны күрсәтәчәк.

**106.** Әй, иманлы бәндәләр, берәрегезгә әҗәл шаукымы янаса, үз арагыздан ике гадел кеше сайлагыз, алар васыятегезнең шаһитләре булсын. Сез сәяхәттә булып, *(чит кавем арасында калсагыз)* һәм якагыздан әҗәл тотса, *(башка диндә булган)* ике кеше васыятегезнең шаһите булсын. Инде алардан шикләнер булсагыз, аларны намаздан соң тотып:

—Туганнарыбызга файда китерәчәк булган очракта да, без бу васыятьне бозачак түгелбез. Аллаһ исеме белән ант иткән шаһитлегебезне яшереп калдырмаячакбыз. Әгәр шулай кылмасак, без гөнаһкяр булачакбыз,—дип, Аллаһ исеме белән ант иттерегез.

**107.** Шаһитләрнең гөнаһкяр икәнлекләре беленсә, *(мәрһүмнең васыятен бозып күрсәтсәләр)*, мәрхүмгә тагын да якынрак торган *(хакыйкый варислыктагы)* ике кеше тегеләрнең урынын алыр вә:

—Валлаһи, безнең шаһитлегебез тегеләрнең шаһитлегеннән дөрес. Без беркемнең хакына да кул сузмадык. Әгәр дә шулай була калса, без залимнәрдән булырбыз,—дип Аллаһ исеме белән ант итсеннәр.

**108.** Шаһитләр дөреслек белән шаһитлек итсеннәр өчен шулай эшләнә. Шаһитлеккә алынган шаһитләр: безнең шаһитлегебездән риза булмасалар, башка шаһитләр сайлаячаклар, дип куркып, гадел шаһитлек кылсыннар өчен. *(Ялган шаһитлек кылып, гөнаһлы булудан)* Аллаһтан куркыгыз һәм аны *(әмерләрен)* тыңлагыз. Азгын халыкка Аллаһ юл күрсәтмәс.

**109.** Килер бер көн, бөтен пәйгамбәрләрен Үз янына туплап, Аллаһ әйтер:

—Сез нинди җаваплар алдыгыз?—дияр. Алар җавап бирер:

—Без белмибез. Бөтен серләрне дә Син генә беләсең,—диярләр.

*(Кыямәт көнендә Аллаһ бөтен рәсүлләрен җыяр һәм аларның Җир өстендә кылганнары турында сораштырыр: Аллаһның хөкемнәрен сез кешеләр арасында таратып йөрдегез, кешеләр бу хөкемнәрне ничек кабул итте, чын күңелдәнме, юрамал гынамы, әллә инкарь иттеләрме, янәсе. Һәр кешенең күңеленә яшерелгәннәрне бары тик бер Аллаһ кына белә.)*

**110.** Аллаһ әйтер:

—Әй, Мәрьям улы Гайсә, сиңа вә синең анаңа күрсәткән юмартлыгымны хәтерлә. Ничек итеп сине изге рух *(Җәбраил)* ярдәме белән аяккка бастырдым. Бишектә чагында да ук, үсмер булганда да син инде кешеләр белән сөйләшә идең. Сиңа язуны, хикмәтләрне, Тәүрат белән Инҗилне өйрәттем. Балчыктан кош сыны ясап, аңа өрдең һәм кошка җан иңде, бу да минем рөхсәтем белән башкарылды. Янә минем рөхсәтем илә анадан туma сукырны син күрер иттең, тилчә тәнлене савыктырдың, мәетләрне Минем рөхсәтем илә тераттең. Исраил угылларының

мәкерле кулын сиңа кагылдыртмадым. Син ап-ачык дәлилләр китерсән дә, кяферләр ышанмады һәм:

—Бу сихердән башка эш түгел,—диделәр.

*(Бу аятьтә вә башка аятьләрдә дә гадәттән тыш хәлләр, могҗизалар тасвирлана. Могҗиза—кеше көченнән килми торган, бер карауда табигать кануннарына күрә, мөмкин була алмаган, башкалар өчен гайре табигый күренешләр. Корьән иңү дә могҗиза.)*

**111.** Хавариларга да Мин әйттем:

—Миңа һәм Минем пәйгамбәрләремә иман китерегез,—дидем.

Алар:

—Иман китердек. Безнең чынлыкта мөселман булуыбызга шаһит бул,—диделәр.

*(**Хаварилар**—пәйгамбәребезнең сәхабәләре кебек, хәзрәти Гайсәгә ияргән вә аңа тугры булган мөридләр.)*

**112.** Хаварилар әйтте:

—Әй, Мәрьям углы Гайсә, Раббыңның Күктән безгә дәстархан иңдерергә көченнән киләме?—диделәр. Гайсә әйтте:

—Мөселман икәнсез, *(көфер сөйләргә)* Аллаһтан куркыгыз,—диде.

**113.** Хаварилар исә:

—Дәстархан белән ризык төшсә, без рәхәтләнеп ашар идек, нәфсебезне басар идек, син дөрес сөйлисеңме икән, карап карыйк, могҗизага шаһит булыйк,—диделәр.

**114.** Мәрьям углы Гайсә:

—Әй, Аллаһым Раббыбыз, Күктән безнең өчен, бездән элек килгәннәргә дә, бездән соң килгәннәргә дә Син могҗиза сыйфатында бер табын иңдер, безне сыйла, бәйрәм булсын. Син ризык бирүдә иң юмарты бит.

**115.** Аллаһ болай диде:

—Мин аны сезгә иңдерермен, ләкин моннан соң да арагызда көфер сөйләүче табылса, *(ягъни Аллаһка ышанмаса)* Мин аны шундый бер җәза белән газапларммын ки, дөньясындагы башка берәүгә дә андый каты җәза бирелмәс.

**116.** Аллаһ әйтте:

—Ий, Мәрьям углы Гайсә! Мине дә, анамны да Аллаһтан башка ике Аллаһ иттегез,—дип кешеләргә син әйттеңме?

Гайсә әйтте:

—Син мотлакан паксең. Алай сөйләргә хакым булмаган көе, мин ничек авыз ачыйм, ди. Әгәр шулай сөйләгән булсам, Син аны мотлак ишеткән булыр идең. Мин Синең ни уйлаганыңны белмим. Шик юктыр ки, Син бөтен яшерен серләрне белеп торасың. **(117)** Син боерганнардан башка мин аларга һични сөйләмәдем. Мин аларга: минем Раббым һәм сезнең дә Раббыгыз булган бер Аллага гыйбадәт кылыгыз, дидем. Араларында яшәгән дәвердә аларга күзәтче булдым. Миңа үлем биргән вакытта да аларны Син күзәтеп тордың. Син һәр нәрсәне күреп-белеп торучы шаһит. **(118)** Әгәр дә аларга җәза бирсәң, алар, шөбһәсез, синең колларыңдыр. Аларны гафу итәргә уйласаң, синең ихтыярыңда, Син—җиңүче, Син—хөкемдар.

**119.** *(Кыяматтә)* Аллаһ әйтер:

—Менә бүген гаделләргә гаделлекләре файда бирә торган көн. Алар өчен агачлар арасыннан чишмәләр агып ятучы мәңгелек җәннәтләр бар. Аллаһ алардан, алар да Аллаһтан разый булачак. Менә шунда булыр бөек котылыш.

**120.** Күкләрнең, Җир эчендәгеләрнең хакиме—Аллаһтыр. Ул барысына да хаклы рәвештә кодрәтледер.

آمين الله اكبر

*Салих Сәйдәшевнең тууына 100 ел*

# СӘЙДӘШНЕҢ СИХРИ МОҢЫ

## РУХИ-ФӘННИ ТИКШЕРЕНҮЛӘР ТӘҖРИБӘСЕННӘН

*Минем музыканың асыл мәгънәсен аңлый алган кеше*
*рухи газаплардан азат булачак.*

Людвиг ван Бетховен.

Халыкның мәхәббәтен һәм ихтирамын Салих Сәйдәшев кебек үк бер генә татар композиторы да казана алмагандыр, мөгаен. Аның якты-көяшлы, җанга якын, сихри музыкасы безнең йөрәкләргә шулкадәрле тирән һәм нык үтеп кергән ки, ул үзенең рухи кыйммәте белән бөек Тукай шигъриятенә тиңләштерелә ала. Һәм, әйтергә кирәк, аның исеме татар музыка сәнгатендә яңа чор, XX гасырда чәчәк аткан профессиональ композиторлык иҗаты туу чоры белән бәйле.



Салих Сәйдәшевнең тууына 100 ел тулып килгән көннәрдә замандашларыбыз күңелендә композиторны хөрмәтләү һәм олылау хисләре кабаттан янара, әмма шул ук вакытта, хаклы рәвештә, мондыйрак сораулар да туарга мөмкин: бу сәнгаткяр татар һәм, гомумән, дөнья музыкасы өлкәсендә нинди урын тота, без аны рус музыкасын бөтенләй яңа баскычка күтәргән Глинка кебек даһи композитор дип атый алабызмы? Хикмәт шунда ки, С. Сәйдәшев иҗатын өйрәнүче музыка белгечләре бу мәсьәләдә төрлечәрәк караштa торалар. Алар, бертавыштан диярлек, композиторның моң-аһәңне гаҗәеп нечкә тоемлавын билгеләп үтәләр һәм шул ук вакытта XX гасырның катлаулы музыкаль палитрасы белән чагыштырганда, аның гармоник теленең беркадәр гади, хәтта беркатлырак булуын да искәртәләр. С. Сәйдәшев иҗатында опера, симфония, концерт кебек киң колачлы, монументаль жанрларның булмавына да игътибар итүчеләр юк түгел. Кыскасы, боларның барысы бергә композиторның иҗаты милли кысаларда гына яши, ул аның гадәти бер күренеше генә, дигән саксыз фикергә дә китерүе мөмкин.

Шуңа күрә татар музыка белгечләре арасында «татар профессиональ музыкасына нигез салучы дип кемне атарга сон?» дигән сорауга төрлечә караш яшәп килүе дә гаҗәп түгел. Мәгълүм булганча, С. Сәйдәшевкә кадәр вокаль һәм инструменталь әсәрләр иҗат иткән, беренче милли опералар тудыруда катнашкан С. Габәши чын мәгънәсендә профессиональ иҗатчы булып китә. Кайбер белгечләр, нәкъ менә шушыларга таянып, татар милли профессиональ музыкасына нигез салучы дип (сүз дә юк, күп эшләгән һәм зур сәләткә ия булган!), С. Габәши исемен атап киләләр. Бәхәсләр барышында С. Сәйдәшев файдасына да, С. Габәшине яклап та төрледән-төрле фикерләр әйтелә килә. Әмма куелган сорауга тулырак җавап бирү өчен, ихтимал, әлеге композиторларның иҗатына музыка белгечлеге күзлегеннән чыгып кына бәһа бирү җитенкерәми торгандыр. Бу җәһәттән, гомуми культурологик мәсьәләләрне дә читләтеп үтү ярап бетмәстер. Әйтик, болай дип әйтсәк, һәр ике шәхеснең дә рухи һәм сәнгати омтылышларының төсмерләрен, аеруча мөһиме,

аларнын эзлэнүлэренен актуальлеген һэм тормышчанлыгын, Замана Рухына туры килүен ачыклау алга килеп баса.

Ә инде С. Сэйдэшевнен ижатына төрлечэ бэя бирүнен асылына төшенергэ телэсэк, биредэ кызык кына нэрсэлэр ачыкланыр. Мэгълүм ки, төрлечэ фикерлэр музыкаль сэнгатьнен үзенчэлеген гомуми калыплар нигезендэ бэялэгэндэ, ягъни гакыл белэн интеллектуаль фикер йөртү мэсьэлэлэренэ кагылганда гына килеп туа. Әмма тирэн хислэргэ чумып С. Сэйдэшев музыкасын тынлаган чагында, анын гажэеп матур аһэнен, рухи дэртен, күнеллэргэ яшэү көче бирүен сизми калу мөмкин түгел. С. Сэйдэшевнен даһилыгы менэ шунда чагыла да инде.

Шулай итеп, бу очракта хислэр белэн салкын акыл йөртү арасындагы каршылыкка тап булырбыз. Шул ук вакытта, хислэр белэн фикерлэүне чагыштырып карап буламы сон? диярга дэ мөмкин. Әгэр булса, аларнын кайсысы хакыйкатькэ якын?

Бөек Алман шагыйре һэм акыл иясе Гете, хислэр гакылдан бик күпкэ тирэнрэк, дип исэплэгэн. Ул «гакыл ялгышса да, хислэр алдашмый» дигэн караштa торган. Рухият турындагы хэзерге фэн, ягъни антропософия[1] шагыйрьнен бу интуитив тоемлавын нигезли һэм тирэнэйтэ килэ; ягъни гакыл-фикер, хис һэм ихтыяр—жаннын төп көчлэре булып торалар. Алар бер-берсеннэн бик нык аерылалар, лэкин асылда «мин» һэм «гакылнын» берлеген тэшкил итэлэр.[2] Бары тик югары хис-кичерешлэргэ сэлэтле булу аркасында гына Кеше, гоман-хорафатлардан котылып, хакыйкатькэ ирешэ ала. Ижади-илаһи жан Кеше турындагы рухи-фэнни өйрэтмэлэр яктылыгында, анын бөек галэми «үлемсез индивид» (Гете) икэнлеген анлаган хэлдэ генэ туарга мөмкин. С. Сэйдэшевнен кабатланмас шэхесенэ дэ, мөгаен, шушы югарылыктан торып бэя бирергэ кирэктер.

Анын бэрэкэтле ижат эшчэнлеге озакка сузылган сөремле еллардан сон татар мэдэнияте уяну кичергэн чорга туры килэ. Мэгълүм булганча, XIX-XX гасыр араларында жэмгыять тормышынын барлык өлкэлэренэ дэ янарыш алып килгэн гайрэтле ижади көчлэр тарихи мэйданга чыга. Исламга карата яшэп килгэн догматик карашларны кире кагып, Мэржани дин өлкэсендэ бик күп үзгэрешлэр кертэ һэм музыканын шэхесне бар яктан да камил итеп тэрбиялэүдэ зур урын билэп торуын билгелэп үтэ. Шушы чорда татар эдэбияты күгендэ даһи Тукайнын сүнмэс кояшы күтэрелэ. Урманченын нэкыш, скульптура, графика өлкэсендэге ижаты ярдэмендэ татар сэнгатенен доньяны танып белүдэге яна мөмкинлеклэре ачыла. Гомумкүтэрелеш музыкаль сэнгатьне дэ читлэтеп үтми, акрынлап ул, бертавышлы сэнгать кысаларыннан арынып, полифоник янарышка юл ала башлый. Биредэ үзенен талантлы һэм заман рухы нечкэлеген тоярга сэлэтле булуы белэн С. Сэйдэшев шэхесе аеруча аерылып тора.

Монын шулай икэнлеген тирэнтен анлау өчен халыкларнын үзара аралашып, «тел-логать алмашып», бер-берсен баетып яшэү принцибын истэн чыгармаска кирэк. Анлашыла, бер генэ милли мэдэният тэ үзенен эчке кабыкларына гына биклэнеп яши алмый; үсеш барышында мая-ресурсларын сарыф итэ барып, ул, ахыр чиктэ, капма-каршы агымдагы күрше мэдэниятлэрдэге яна чыганакларга мөрэжэгать итэргэ мэжбүр

---

[1]Антропософия, теософиянен бер төре буларак, немец илаһият галиме Рудольф Штайнер (1861-1925) тарафыннан нигезлэнэ һэм сонрак рус (мэсэлэн, С. О. Прокофьев) һэм чит ил галимнэре тарафыннан үстерелэ.

[2]Антропософиядэ Кеше дүрт сыйфаттагы жан иясе буларак, ягъни күзгэ күренеп торган физик-тере тэн-гэүдэсеннэн тыш, кэрамэтчелек (гаиптэн хэбэр бирүчэнлек) күзэтүлэренэ генэ анлаешлы тагын өч асылга ия зат итеп бэян ителэ. Беренчедэн, бу—барлык космик көчлэр тээсире нэтижэсендэ барлыкка килгэн һэм организмнын яшэүчэнлеген үзенэ туплаган «эфир тэн» (борынгы философлар күзаллавынча, эфир тэн—ут һэм су белэн бергэ, барлык жан иялэренен материаль нигезен тэшкил итэ; икенче берэүлэр исэ аны мэнгелек хэрэкэт белэн тинлэштерэлэр). Икенчедэн, бу—Кояш системасынын, аеруча Ай планетасынын тээсиренэ бэйле «астраль тэн»; ул космик тирэлекнен табигый тээсирен тоткарлап тора һэм кешенен эчке чынбарлыгын эмоциаль кичерешлэр һэм гакыл (түбэн баскычтагы, «Мин—гакыл иясе») белэн тээмин итэ. Өченчедэн, бу—Кешенен югары баскычтагы «Мин—жан иясе» дигэн өченче асылы; Кешенен үз-үзен тотышына бэһа бирэ алучанлык башлангычы, Жаннын «тэрбиячесе»һэм «хужасы»; Кояш планетасы эшчэнлеге белэн билгелэнэ торган һэм шэхесне «канатландыра» торган «галэми—Мин» *(Штайнер Р. Теософия.—Ереван, «Ной».—1990, 18 б.).*

була. Әйтергә мөмкин, мондый каршылыклар эволюцион үсеш барышында ике күрше халык—рус һәм татар халыклары мәдәниятенен тамыр-нигезенә үк салынган. Аларнын беренчесе кешенен игътибарын, күпчелек очракта, тышкы дөньяга, әйбер-предметлар мохитына юнәлтүче, шул рәвешле, анын акыл, интеллектуаль үсешен тәэмин итүче тоньяк (көнбатыш) үсеш (цивилизация) тармагына якын тора. Шушы шартларда кеше күнелендәге рухи башлангычлар, нигездә, тышкы мохитны кабул итү тәэсирендә жанланалар. Рус православиесендәге иконаларны бизәүне, храмнарын купшы итеп жиһазлауны, һәртөрле кин колачлы бәйрәмнәр үткәрүне шунын белән анлатырга мөмкин. Татар мәдәнияте исә үзенен тамырлары белән Шәрыкъка барып тоташа һәм ул көньяк (көнчыгыш) үсеш тармагына керә. Бередә жан-рух күбрәк эчке чынбарлыкка юнәлтелгән һәм ул яшәү өчен кирәк булган кыйммәтләрне һәм тәэссоратларны да, әйберләр мохиты кичерешләренә караганда өстенрәк булган, эчке дөньялыктан алалар. Көнчыгыш халыкларынын икона язу, катлаулы дини йолалардан ваз кичүе дә шунын белән анлатыла. *Лэкин* сонгы дәвердәге үсеш тенденциясе бу ике юнәлешнен дә үзара якыная баруын, берләшүен күзәтә; бу исә, ахыр чиктә, яшәеш-тудырылышны тирәнрәк, дөресрәк, кинрәк анлауга китерәчәк.

Кызганыч ки, якынаю Рәсәйдә бигрәк тә аянычлы хәлдә үзенә юл яра. Могаен, XX гасырда дөньянын бер генә төбәгендә дә Көнбатыш Ауропадагы кебек шундый жимергеч көчләр хәрәкәткә килмәгәндер. Рәсәйне тулы бер гасыр буена тетрәтеп торган дәһшәтле хәлләр дини-рухи тормышнын сизелерлек сүлпәнәюенә китерде һәм, ни гажәп, шул ук вакытта дөньялыкны янача анлау чаткыларын тудырырга да ярдәм итте. Әйтик, славяннар христианлыкны кысрыклау нәтижәсендә, чиркәүгә барып гыйбадәт кылу, иконаларга табынудан мәхрүм ителгән хәлдә дә күнелнен яшерен почмакларында, йорәк түрләрендә рухи ныклык саклап калырга мәжбүр булдылар. Мөселманнар исә, кондәлек биш намаз уку мөмкинлеге калмагач, эчке дөньяга кереп бикләнүдән баш тартып, гомумкешелеккә хас галәми рух эзләү нәтижәсендә тышкы мохитка ныграк игътибар юнәлтергә кирәклеген анлый-тоя башладылар.

Рәсәйдә Көнчыгыш белән Көнбатышнын ике көчле агымы кушылу шартларында барлыкка килгән гаять катлаулы һәм каршылыклы күренешләр алдынгы карашлы шәхесләр күнелендә вульгар-материалистик катып калганлыкка карата нәфрәт тудырды һәм, нинди генә юллар белән булса да, рухиятне саклап калу теләген үстерде. Мондый чистарыну рус белән татар кебек Көнчыгыш Ауропанын боек халыклары өчен генә түгел, ә бәлки дөньякүләм цивилизация өчен дә чиксез зур әһәмияткә ия иде. Шуна күрә дә рухият-динне өйрәнү фәненен Рәсәйдә туачак менъеллыкта яна мәдәни үсеш чоры башланачак дип искәртүе бер дә гажәп түгел. Ул үзенен гомумкешелек үсешенә тәэсире ягыннан жирдә барган бөтен эволюцион хәрәкәтнен ин биек ноктасы булып торачак. Анын асылы Көнчыгыш белән Көнбатышнын рухи-дини агымнарын берләштерүдән, шәхестә «Мин—Гакыл иясе» («сотворец») дигән ин югары төшенчәне ныгытып, монарчы күрелмәгән яна, саф көчләргә юл ачудан һәм шул рәвешле кешеләргә чын эчке бәйсезлек бирүдән гыйбарәт булачак *(Штайнер Р. О России.—Спб., «Дамаск» , 1997).*

Татар халкынын гасыр башындагы үсеш юлларын билгеләгәндә, барлык затлы-зыялы шәхесләрнен дә, шул исәптән Салих Сәйдәшевнен дә, Ислам рухында тәрбияләнүен искәртеп үтәргә кирәктер. *Лэкин* алар, дин әһелләре хәзерли торган мәдрәсәләрдә укып белем алсалар да, консерватизм һәм чикләнгәнлек тарафдарлары булмадылар, фикри карашларында дөньялыктан ваз кичү юк иде; киресенчә, аларда ислам тәрбиясенә хас нәзберекләк, һәркемгә ярдәм итәргә әзер торучанлык һәм эчке сабырлык белән бергә, яна карашлы кешеләргә хас булган рухи активлык, идеалга омтылыш та нык сизелә иде. Шуна күрә дә алар үзләренә рухи терәкне Шәрык фәлсәфәсеннән генә түгел, ә бәлки Гете, Пушкин, Толстой кебек мәшһүр Ауропакүләм фикер ияләреннән дә алдылар.

С. Сәйдәшевнен даһилыгы халыкнын күнел төпкелләреннән бәреп чыкса да, ул, табигый рәвештә, ижатында милли һәм дөнья музыкаль культура казанышларын бергә тоташтырырга омтыла. Шул жирлектә татар музыкасына кешеләрнен анын уятып жибәрерлек, жаннарын жилкендерерлек көтелмәгән, бәрәкәтле яналык өсти, заманнын оптимистик кичерешләрен ишетергә чакыра. Авыр һәм катлаулы тормыш юлы үзган С. Сәйдәшевнен, билгеле, бу хакта күкрәк киереп сөйләргә бөтен әхлакый хакы бар иде.

## Профессионализмның төп чыганаклары

XX гасыр башында, мәдәни янарышнын яна этабында, татар музыкасы төп өч агым йогынтысында үсеш кичерә. Шуларнын берсе, консерватизм тармагы, нигездә халык авыз иҗатын дәвам итүче музыкантларнын эшчәнлеге белән бәйле иде. Гәрчә, беренчеләрдән булып профессиональ юлга аяк басса да, композитор С. Габәши дә шул агымга якын тора иде. Ул, һөнәри белемен рус музыкантларыннан алуына карамастан, рухани гаиләдә тәрбияләнүе сәбәпле, борынгы мәдәни мираска күнелендә чиксез тирән мәхәббәт саклый: балалык елларыннан бирле башлыча саф пентатоник (биш тавышлы) янгырашлы дини һәм борынгы халык җырларын тынлап үсә. Самими кичерешләр, саф мон белән сугарылган әлеге җырлар С. Габәшине тәмам әсир итәләр һәм анын күнел очышларын ТАО (ДАО-Тәнре)[1] кысаларында тотып торалар. Эчке каршылыклардан азат мондый пентатоник мотив рух-җанны гомумбашлангыч турында уйларга алып кайта, биредә кешенен «Мине», әйтерсен лә, мон эчендә эреп юкка чыга. Бу, борынгы заманнарда кешеләр логик-абстракт үзан белән түгел, ә бәлки пассив, кичерешләргә бай булмаган төркемчелек һәм карамәтчелек аны белән яшәгән чорда үзен аклап та килгән.

Татарларнын борынгы бабасы булган болгар мәдәнияте, үзенә күрә, әлеге карамәтчелекнен томанлы чагылышы да булып тора. Болгарлар әнә шул сыйфатларын, башка Аурупа халыкларына караганда, озаграк та (XIII—XIV гасырларга кадәр) саклап килгәннәр. Урта гасырларда мантыйкый-абстракт фикерләү актив үсеш алган һәм кешелеккә хас төшенчәләрне абстракцион һәм формаль гомумиләштерүләргә кайтарып калдырган **номинализм** күренеше үсеш ала башлаган Көнбатыш Аурупадан аермалы буларак, болгарлар объектив рухи дөньяны тәшкил итүче һәм төшенчәләр артына яшеренгән рухи фикерләү рәвешләре, фикри җан ияләре барлыгын күрсәтүче **реализм** агымы тарафдарлары иделәр. Номинализм белән реализм агымнары бер-берсен тулыландырып, үзенә мантыйкый-абстракт, «аяз» ан һәм образлы-рухи карамәтчелекне берләштергән яна төр фикерләүнен тууын тәэмин итәләр.

Шушы шартларда пентатоника болгарларнын рухи омтылышларын тулысынча канәгатьләндереп килгән. Ләкин болгарларнын тарих мәйданыннан китүе, «Мин—Гакыл иясе»нен яна формасын үзләштерергә керешкән Казан ханлыгы мәдәнияте барлыкка килү белән пентатоника рухындагы музыкаль фикерләү табигый янарыш процессын топкарлый башлый. Монгол яулары һөҗүменнән сон хәлләр тагын да мөшкелләнә төшә: алар үзләре белән ТАО мотивындагы тагын да борынгырак мәҗүсилек формаларны алып киләләр һәм казанлылар тагын берничә гасыр дәвамында пентатоника аһәне системасын «саклап калырга» мәҗбүр булалар. Татар көйләре белән чагыштырганда, бертөслерәк агышлы монгол музыкаль элементларынын топкарлап торучы көчкә әйләнүе озак еллар буена «җирле», «милли» дигән ялган япма астында яшерелеп киленде һәм шунын нәтиҗәсендә ул гавәм күнеленә тирән кереп урнашты.

Ничек кенә булмасын, шәхси үзан үсү барышында биш тавышлы система, һичшиксез, кинәергә тиеш иде. Иске караш тарафдарлары исә моны анлап житкермәделәр. Күрәсен, ТАО кичерешләре йогынтысы нәтиҗәсендә, С. Габәши, мелодик янгыраш кына түгел, ә бәлки гармоник башкарылыш та пентатоника закончалыкларына нигезләнеп үстерелергә тиеш дип исәпләп, татар музыкасында борынгылыкны саклап калу сәясәтен теоретик яктан нигезләргә омтылгандыр.

Мона капма-каршы агым тарафдарлары татар музыкасын ор-янадан, тамырдан үзгәртеп кору идеясен алга сөрәләр. Бу агымны, башлыча, халыкнын музыкаль анын тәрбияләүне инкарь итүче, Аурупа гармоник өлгесе белән берләштерү нәтиҗәсендә пентатониканы турыдан-туры дөнья мохитына алып керергә омтылучы Көнбатыш


[1] Дин белемендә (даосизмда) бу атама белән Борынгы Атлантида Бөек рухынын илаһилыгы турындагы бер үзенчәлеге атала һәм ул дини агымнар нигезендә яткан төшенчәләр дә шәхеснен аерымланып каралмавына элгәр булып торган рухи бердәмлек чорына карый. Бу дәвер б. э. к. VIII-VII гасырларда, борынгы Грециядә Сократ, Платон, Аристотель кебек бөек фикер ияләре пәйда булгач тәмамлана. Борынгы гыйбадәт кылу йолаларында, медитация вакытларында һәм үзенә күрә халык пентатоник көйләренә нигез булып торган ТАО-Тәнре мотивы көйләп сөйләү формасында болай янгыраган (*Штайнер Р. Проис-хождение зла. - Спб., «Дамаск», 2000. - С. - 230*).

Аурупа һәм кайбер рус музыкантлары яклап чыктылар. Мондый караш, әлбәттә, милли сәнгатьне үстерергә ярдәм итсә дә, шул ук вакытта, зур житешсезлекләргә дә китерделәр. Шушы юнәлештәрәк эзләнүләр алып баручы скрипкаче һәм композитор И. Козлов әсәрләрендә, мәсәлән, стильләр башбаштаклыгы, акланып житмәгән, милли жанны рәнжетә торган диссонанслар чагылыш тапты *(Кәрәм. Г. Яңа елны каршы алу.—«Ан», 1913, № 32, 42 б.).* Мондый янарышлар табигый Вакыт агышын узып киттеләр һәм житлекмичә туулары сәбәпле, яшәргә сәләтсез икәнлекләрен күрсәттеләр. Соңгысы татар музыкасы үсешен тоткарлап килүче консерватив тармакка да кагыла иде.

Әйе, капма-каршы бу агымнарның рухи янарыш канунарына буйсынып, әле бер-берсенә якынаюлары, әле читкә этәрелүләре жимергеч нәтижәләргә китерде. Бу үзен, бер яктан, традицион тармак вәкилләре С. Габәши белән Г. Әлмөхәммәтов, икенче яктан, Мәскәү консерваториясендә тәрбияләнгән Ю. Виноградов катнашында беренче татар опералары ижат итү барышында да сиздерде. Бу, бигрәк тә, әсәрнең мелодик һәм гармоник «теле» арасындагы каршылыкларда чагылыш тапты. Күп кенә тәнкыйтьчеләр белән бергә, С. Сәйдәшев тә әлеге кимчелекләрне билгеләп үтте һәм «халыкның музыкаль культурасын үстергәндә, нигез-тамырдан аерылып алга чабарга ярамый. Музыкаль анны ашыкмыйча, эзлеклекле рәвештә, заман рухын тоеп камилләштерергә кирәк» дип искәртте. *(«Кызыл Татарстан», 1929, 17 июнь).*

Дин-рух турындагы ан-белем тормышта гармониягә ирешү генә алга таба хәрәкәт итүне тәэмин итә ала, дип исәпли. С. Сәйдәшев шушы «алтын урталыкны» таба алган композитор. Аның жаны, бер яктан, тамырлары белән татар мохитына барып тоташса, икенче яктан, ул үзенчәлекле, беркемгә дә охшамаганча уйлый торган, яңа заман сулышын ачык тойган сизгер күңелле шәхес тә була. Балалык елларында ул алдынгы карашлы татар зыялылары арасында катнашып үсә, танылган музыкантлар белән бергә (кечкенә оркестрлар оеша башлаган чор бу!) Аурупа һәм рус классикасы әсәрләрен башкара. Билгеле, С. Сәйдәшевкә бернечә ел яшәп киткән Оренбург музыкаль мохиты да (беренче әсәрләрен дә ул шунда яза) зур йогынты ясый. Бирәдә, Татарстаннан читтәге бер төбәктә, пентатоника алай ук зур өстенлек алмаган була. Татар көенә хас салмак агым бу яклардагы биш тавышлы яңгырашның чикләреннән кыю чыгып китү, чиксез киңлекләргә омтылучы шашкын адымнар ясау, дәртле диатоник пассажлар куллану кебек дала культурасына хас күренешләр белән янәшә яшәгән.

XX гасыр башында Казанда да гадәти булмаган яңа ярымтон яңгырашлы һәм шуның нәтижәсендә көчле тәэсир көченә ия булган көй-мелодияләр дә туа башлаган (мәсәлән, «Баламишкин» көе әнә шундыйлардан). Традицион музыка өлгесендә яшәп килгән пентатониканы Аурупа гармоник системасы элементлары белән баетырга омтылыш, барыбер, нәкъ менә С. Сәйдәшев ижатында тулы гәүдәләнә һәм тулы канлы тормыш белән яши башлый; ягъни композитор капма-каршы ике агымны берләштерү могжизасына ирешә. Даһи ижат аерым бер, чикләнгән киртәләр эчендә генә яши алмаган кебек, С. Сәйдәшев тә көнбатыш шаукымы белән генә мавыкмый, Шәрык культурасына да йөз тотып, аның бигрәк тә заманга яңгырашлы, киң сулышлы, «Мин—Гакыл иясе»н үстерүгә юнәлтелгән чыганак-катламнарыннан оста файдалана. Әйтик, халык арасында киң таралган һәм яратып жырлана торган «Әдрән диңгез» әсәрендә композитор милли колакка ятрак яңгырашлы дини (борынгы Шәрыкта яшәп килгән әллохим—Аллага табыну) йоласы белән бәйле авазлар рәтен куллана. Дини йолага кагылышлы музыкаль мотивлар шәхси кичерешләрне, уй-фикерләрне тирәнәйтүгә юнәлтелгән; ул кешегә эчке мөстәкыйльлек һәм илаһи көч бирә.




Шулай итеп, С. Сәйдәшев ТАО ның урынсыз хакимлегеннән арына барып, пентатониканың чикләрен төрле яклап киңәйтә башлый. Аның әсәрләре яңадан-яңа матур бизәкләр, образлы сурәтләү чаралары белән баеп-ялтырап китә; аларда мажор һәм минор ладларның шатлык һәм төшенкелек халәтен белдерүче капма-каршы төсмерләре әледән-әле күбрәк урын ала баралар һәм болар барысы бергә нейтраль хис-кичереш белән генә чикләнгән пентатоникага бәрәкәтле сулыш өстәп жибәрәләр. Бары тик халык күңеленең тибрәлешләрен һәм яңалыкны тирәнтен тойган (шуннан аерылгысыз булган!) С. Сәйдәшев кебек чын даһи гына, капма-каршы агымнардагы уртаклыкны табып,

беренче карашка берләштереп булмастай күренгән нәрсәләрне бергә җыеп, татар музыкасының нигезләрен бозмыйча, әмма тамырдан үзгәртә алган булыр иде.

Сәйдәшнең замандашы, сәнгатьне тирән аңлаган М. Җәлил композиторның консерватизмнын (Шәрыкның) көчле агымында да югалып калмаган, игътибарны гармонияне үстерүгә генә юнәлтү кебек вакытыннан иртәрәк туган борылышларга да бирешмәгән гаять үзенчәлекле талантын бик тиз күреп ала: «Татар совет музыкасы өстендәге хезмәтнең күп өлеше танылган талантлы композиторыбыз Салих Сәйдәшев өстенә төшә. Сәйдәшев татар музыкасының үсешен яна баскычка күтәрде. Аның байтак елларга сузылган үрчемле хезмәте татар музыкасының үсешендә тулы гына бер дәвер булып исәпләнә ала... Габәши үз иҗатында борынгы шәрык музыкасына иярсә, Сәйдәш музыкасы үзенең беренче дәверендә күбрәк халык музыкасына, авыл моңына иярде... Шуның белән бергә Сәйдәшнең беренче дәверендә характерлы як-гармониядән бигрәк мелодиягә (көйгә) күп игътибар бирү, көй өстендә эшләү булды. Сәйдәш, әлбәттә, халык музыкасына сукыр иярмәде, аларны көчерү белән генә шөгыльләнмәде. Ул аларның өстендә эшләде һәм үзеннән бик күп иҗат байлыгын өстәде» *(«Татар совет музыкасы һәм композитор Ключарев.—«Коммунист» газитәсе, 1933, 30 ноябрь (№ 262).*

## Профессиональ музыканың нигезләре

Рухания фәнендә идеаллар вәгазьләнми, диелә. Бөек максатка бары тик аңгыйлемгә, хакыйкатькә изге нәрсә итеп карау аша гына ирешеп була. Гыйлем иясе булу кешегә үзенең инстинктларына хуҗа булу, хис-тойгыларны чистарту һәм сафландыру өчен аек акыл һәм зирәклек бирә. Борынгы Грециядә моны чиста кичерешләр, «гөнаһлардан» арыну аша (катарсис) рухи тынычлыкка ирешү (фотисмос) дип атаганнар. Тәүратта да, Коръәндә дә бу халәт «Изге Рухка сыгыну» белән аңлатыла. Бу исә, иң югары гомуми Хакыйкать буларак, кешенең ыругчылык, төркемчелек таныпбелүеннән арынып, шәхси мөстәкыйльлеккә ирешүенә, «Мин»е «Мин» булып өлгерүенә ишарә ясый һәм шул чагында Кеше Рухи Берләшүгә илтүче юлларны эзләргә тиеш. Бирелә ана мәгърифәт, дин һәм сәнгать ярдәмгә килә. Мәгърифәт—табигать кануннарын өйрәнүче, кешенең чынбарлыктагы урынын билгеләүче башлангыч чор булып тора; ул саф интеллектуаль, «баш белән уйлау» гыйлеме буларак, әлбәттә, кешенең рухи табигатенә әлләни зур йогынты ясый алмый. Зуррак йогынты ясарлык көчләр исә дин, дин гыйлеме һәм сәнгать өлешенә туры килә. Әйе, беләбез ки, совет хакимияте гомуми белем бирү турында закон кабул итеп, халыкны агарту юнәлешендә мөһим эш эшләде. Әмма дин гыйлемен һәм динне инкарь итү бик зур югалтуларга китерде, шушы шартларда «топ авырлык» әдәбият-сәнгать өстенә төште. Ә музыка өлкәсендәге уңышсызлык исә (аның кеше күңеленең иң тирән чоңгылларына да бик тиз үтеп керә алуы бәхәссез ки!), җәмгыятьтәге барлык иҗади көчләрнең үсешен тоткарлавы бик мөмкин иде.

Шушындый шартларда үз «өлешенә тигән көмешнең» авырлыгын аермачык тойган С. Сәйдәшев, баскыч артыннан яна баскычларны яулап, җитди рәвештә һәм киң колач белән татар профессиональ музыкасының нигезләрен төзергә керешә. Дөрес, бу юл бик катлаулы һәм бормалы була. Белгәнебезчә, баштарак татар профессиональ музыкасы халык иҗатында күп гасырлар буена чарланып, төзек бер системаны тәшкил иткән жанрларга—җыр һәм бию көйләренә таянып үсә башлый. Шәт, шулай булгач, композиторлык иҗатында кабаттан бернәрсә дә уйлап табарга, «могез чыгарырга» кирәк түгел икән ләбаса: әзер үрнәкне ал да, бераз үзгәртеп, Аурупа композиторлары эшләгән (сыналган!) калыпка сал—менә сиңа әзер яна музыка... Дөресен генә әйткәндә, көнлекчеләр нәкъ менә шулай уйладылар һәм эшләделәр дә.

Әмма С. Сәйдәшев, намуслы талант иясе буларак, мондый җиңел юлны сайлый алмый иде. Баштарак халык көйләрен драматик спектакльләрне музыкаль бизәү һәм тәнәфес вакытларында тамашачыларның күңелен ачу өчен генә эшкәртсә, соңрак аларга күптавышлылык өлгеләрен дә кертә башлый. Композитор М. Мозаффаров истәлекләренә караганда, шушы чорда ук Сәйдәшев оркестрда бергә уйнаган өлкән яшьтәге музыкантларны гаҗәпләндереп, халык көйләренә полифоник яңгыраш бирергә омтыла *(Сайдашев С. Материалы и воспоминания.—Казань, 1970.—С.—58-59).* Мондый эзләнүләр эзсез калмый, әлбәттә: композитор хор өчен дә яна көйләр

эшкәртә башлый һәм, гомумән, хор жанрын «күмәк жырлау» кебек тар кысалардан алып чыгарга омтыла. Яналык, билгеле, һәрвакыттагыча каршылыкларга очрый— кайберәүләр моны христиан (чиркәү) йогынтысына ияру, милли традицияләргә ят бер күренеш дип атыйлар. Әмма С. Сәйдәшев ярты юлда тукталып кала торган ижатчылардан булмый. Заман чор сулышын дөрес һәм тирәнтен тою нәтижәсендә концерт һәм спектакльләрдә дә хор элементларын торган саен күбрәк куллана, шул рәвешле профессиональ хор музыкасына нигез салына.

Чын-чынлап композиторлык ижатына керешкәч тә С. Сәйдәшев халык музыкаль өлгеләренә мөрәжәгать итүен дәвам итә; ләкин ул «күчерүче» генә түгел, композитор халык көйләрен мелодик яктан баета, ана яна бизәкләр өсти, үен коралларынын мөмкинлекләреннән кин файдалана. Хәер, форма өлгегә дә С. Сәйдәшев бөтенләй көтелмәгән яналыклар кертә. Әйтик, ике өлештән (әкрен бормалы һәм жанлы, житез өлешләрдән) торган озын көйләрнен берсен яна әсәргә нигез-зәмин итеп ала да, элеге кискен каршылыкларны үстерә барып, аны дәртле, марш төсендәге аһәннәргә алып чыга. Бу алымны тамашачылар хуплап каршы ала, чөнки алар бередә милли музыкаль фикерләүнен Аурорпа традицияләренә якынаюын тоялар, сиземлиләр.

С. Сәйдәшевнен вокаль ижаты да жанрлар төрлелеге ягыннан аерылып тора. Композитор жырлар язу белән бергә арияләр, вокаль ансамбльләр, хор өчен яңадан-яңа әсәрләр ижат итеп, татар музыкасынын офыкларын кинәйтеп жибәрә. Инструменталь музыка да бәрәкәтле ижатында яшәү хокукы алды. Шулай ук ул бию көйләренә жан өреп жибәрде; бию көйләре өчле ритмлы вальс мелодияләре белән баетылгач, бигрәк тә матур, дәртле, образлы яңгыраш алдылар. Махсус язылып, драматург, режиссер белән берлектә спектакль тукымасына ювелирларча оста чигеп кертелгән мондый жәүһәрләр гүзәл сәхнә әсәрләре тудырырга ярдәм иттеләр. Татар театр сәнгатенен жуелмас хәзинәсенә әйләнгән «Наемщик» драмасы әнә шундыйлардан. Композитор Ж. Фәйзинен шул еллардагы истәлекләреннән күренгәнчә, тамашачылар С. Сәйдәшевнен һәр яна әсәрен алкышлап, гөрләтеп кул чабып каршы ала һәм «вальс короле Штраус кабаттан Казанда туды!» дип, анын ижатына югары бәя бирә. (Гомумән, танылган драматург Кәрим Тинчурин белән берлектә ул бихисап музыкаль-сәхнә әсәрләре тудыра.) Кыскасы, ижатчынын нечкә тоемлы жаны вальс аһәннәренен хыялга канат биреп, хисләрне торгынлыктан алып чыгарга сәләтле икәнен бик яхшы сизенә.



*Салих Сәйдәшев һәм Кәрим Тинчурин*

Болай дигәч, С. Сәйдәшевнен (вальслар белән чиктәш!) марш музыкасын үстерүдәге эшчәнлеген, даһиларча алдан күрүчәнлеген (совет композиторлары арасында марш остасы буларак абруй казануын!) анлау кыен булмас, мөгаен. Композитор марш жанрынын бөтен өлкәләрендә дә ижат итеп (тантаналы, поход, яшьләрчә-спорт, матәм маршлары әнә шундыйлардан), камиллек үрнәкләре биреп калдырды. Ә «Совет Армиясе маршы» үзенә күрә бер символга, мәңге жуелмас хәзинәгә әверелде. Ул элеге әсәрен кыюлык, рухи күтәренкелек чаткылары уята торган жинү маршы рухында ижат иткән. «Совет Армиясе маршы»—чын мәгънәсендә рухны илаһи биеклекләргә күтәрә алырлык, жанга бетмәс-төкәнмәс көч бирерлек әсәр; шуна күрә Ватан сугыш елларында ул, рухи терәк булып, халык күнелендә яңгыраш япты; хәзер дә һәртөрле тантаналарда булсын һәм, гомумән, менә дигән концерт әсәре буларак та еш яңгырап тора.

Актер Нури Сакаевнын үлеменә багышлап язылган матәм маршы да әнә шундый мәшһүр әсәрләрдән саналырга хаклы. Юк, марш тынлаучыны гажизлек, өметсезлек чонгылларына алып төшми, ә бәлки шәрык рухына хас тирән уйланулар, илаһи кичерешләр аша Үлем ул—кешенен бер халәттән икенче халәткә күчүе, яратылышнын акыл ирешмәслек биеклегенә күчеп, кабаттан туу гына дигәнне анлатырга омтыла. Мона ирешү өчен композитор, Аурорпа музыкасында кабул ителгәнчә, маршны кискен яңгырашлы өлештән түгел, борынгы халык көйләренә якын

сәгадәтле аһәннәрдән башлый; һәр сулышыннан Ходайга сыгыну, әчтән генә рәхим-шәфкать сорап «аһ ору» саркып торган мөнәҗәт интонацияләреннән файдалана. Шул рәвешле композитор Кешенен Мәнгелек, Үлемсезлек белән алышы-биреше барлыгын, «Мин—Гакыл иясе»нен Мәнгелек башлангыч турындагы кичерешләрен сурәтли...

Әлбәттә, алда китерелгән мисаллар С. Сәйдәшевнен бай иҗатында «дингездән бер тамчы гына» булып торалар. Болары—ачык хакыйкать. Бу очракта игътибарны мәсьәләнен башкачарак ягына юнәлтәсебез килә.

## Язмыш белән—күзгә-күз...

*Даһи* кешеләрнен язмышлары үзләре туганчы ук *Ләүхел* Мәхфүздә—язмыш тактасында язылып, кәраматлек яки Изге төшләр аша алдан хәбәр ителгән була. Әйтик, Салихнын әнисе бик дини кеше була, төшләрнен юш килүенә бик ышана һәм ул кечкенә композитор туар алдыннан мондый гаҗәеп төш күрә: «Тан алды. Менә-менә, озакламый кояш та чыгар. Тәрәзәне ачып җибәрүем була, сирень куагына сандугач килеп куна да ярсып-ярсып сайрарга керешә. Ул сайрый да сайрый. Ә мин, сихерләнеп, тынлыйм да тынлыйм. Их, куркыта күрмим тагын дип, тәрәзә яныннан читкәрәк китеп баскан идем, карынымдагы бәбием җан биреп куймасынмы... һәм мин йокымнан уянып киттем». (*Саинова-Ахмерова Д. З. Салих Сайдашев. Страницы жизни и творчества композитора.—Казань, 1999.—С. 118*).

Менә шулай, башта ук, тумыштан ук «Ходай тамгасы белән» дөньяга килгән, теләп алган балалар башкалар кебек табигый каршылыклар белән көрәшә-көрәшә әкрен генә үсәләр үсәләр дә, көннәрдән бер көнне, ак белән караны аера башлагач, бу дөньяны анлаудан гаҗиз булып икеләнеп калалар. Шул чак алар, әйләнә мохитнын гына түгел, үзләренен эчке дөньяларынын да бик үк камил булмаганлыгын анлый башлыйлар, үзләрендә мен гаепләр табалар, үзләре белән үзләре көрәшәләр; җинәләр—җинеләләр... Мондый рухи тетрәнүләр, гадәттә, көндәлек мәшәкатьләрдән газаплырак та, татлырак та була. Һәм шушындый эчке кичерешләр, табу-югалтулар аша шәхес үзен чыныктыра, чарлана, ныгый һәм бер вакыт үзендә бетмәс-төкәнмәс көч-гайрәт—«Тукайлар җаны» сизеп «уянып китә». Бу—элек-электән үк Илаһи башлангыч дип атала.



*Салих Сәйдәшевнең әнисе Мәхүбҗамал апа*

Тормыш С. Сәйдәшевне бәбәкләп кенә тормый. Ул яшьтән үк әтисез кала, моны бала күнеле бигрәк тә авыр кичерә. Үсеп буйга житкәч тә газап-сагышлар сагалап кына тора—бәбәйләгәндә беренче хатыны үлеп китә, житмәсә, эшендә дә тырнак астыннан кер эзләп кенә торалар. Репрессияләр һәм идеологик чистартулар башлангач, сындырырга теләп, композиторны яраткан мохитыннан—күп мәртәбәләр театрдан куу белән яныйлар, куелган музыкаль спектакльләре өчен тиешле әҗерен түләмичә жанга тияләр. Дөрес, С. Сәйдәшев бу фани дөньяда материаль байлыклардан да өстенрәк кыйммәтләр барлыгын бик иртә анлап үсә. Монын шулай икәнлеге яшь чагында Салих гашыйк булып йөргән бер кызнын көндәлекләреннән дә күренә. Менә ул яшүсмер Салихнын нинди сүзләрен теркәп калдырган (сафлык һәм рухи ныклыгы ягыннан мәшһүр Бетховеннын тарихта мәгълүм «ерактагы мәгъшукасына» җибәргән сәламенә аһәндәш ич алар!): «Мин җәүһәрләр дә, бриллиантлар да бүләк итә алмыйм, йөрәгемне һәм сөюемне генә бирә алам. Бу дөньяда алардан да кыйммәтрәк бер нәрсә дә юк!.. Бәхет ул—ике кешенен бер-берсен чын йөрәктән ярата алуы... Бәхет ул—икен бергә була алу, бәхет ул—икен бергә эшләү, икен бергә иҗат итү, тормыш сукмаклары буйлап икен кулга тотынып янәшә бару һәм яна тормыш белән яшәү» (*Сайнова-Ахмерова Д. З. Салих Сайдашев. Страницы жизни...—С. 47-48*).

Изге Китапларда язып калдырылган хәзинәләрне Җирдән түгел, Күктән эзләргә

кирәклеген тоеп алган С. Сәйдәшев, иртәме-сонмы, «кара көчләр» белән мангайга-мангай бәрелешергә тиеш иде. Әйе, гадел, намуслы, вакыт агышын тирәнтен тойган иҗатчы буларак, ул Совет власте алып килгән тоталитар идеяләрне кабул итә алмады. Яшьлегендә «Ирек», «Тигезлек», «Туганлык» кебек шигарьләр чынлап та тормышка ашар дигән бөек үзгәрешләр чорында, ана демократиянен асыл җимешләрен татып карарга насыйп булган иде дә булуын, ул җин сызганып милли мәдәниятка хезмәт итәргә керешкән дә иде, әмма заманнын дәһшәтле фаҗигасе анын күз алдында уйналды. Пролетариат юлбашчылары үзләре күтәреп чыккан,беркайчан да үтәп була алмый торган шигарьләренә үзләре үк хыянәт иттеләр. Алар әле идеалларнын һәрберсе үз өлкәсендә: Ирек—рухи өлкәдә, Тигезлек—сәяси тормышта, Туганлык—икътисади мөнәсәбәтләрдә сакланса гына чынга әверелсен анлап житкермиләр иде *(Штайнер Р. Сущность социального вопроса.—Калуга, 1992)*. Диктатура урнаштырган һәм әлеге шигарьләрнен кулланылу өлкәсен бутап, большевиклар әшәкелекне әшәкелек белән җинәргә омтылдылар, ә монын һәлакәткә китерәчәге көн кебек ачык иде. Массакүләм репрессияләр чорында сыйныфлар көрәшенен, сәнгатьтәге партиялелекнен чын йөзе—җәмгыять үсешен тоткарлаучы ялган бер нәрсә икәнлеге ачылды, ә нәтиҗәсе шул булды—җаннарга вульгар-материалистик күзаллау чире кереп урнашты.

Шушы елларда С. Сәйдәшев бик күп фикердәш дусларын югалта. Халкы алдында тиндәшсез абруй казануга, музыка өлкәсендә зур хезмәтләре булуга да карамастан, эт типкесендә йөри. Массалар анын томалап килүче ялган идеалогиянен асылы фаш ителгәннән сон ул иллюзияләргә ышанычын югалта; гомере белән түләү ихтималы булса да партия сафларына керми. Бердәнбер терәк, күнел тынычлыгын иҗатта таба. Ул шунсыз яши алмый. Әмма алда бик зур сорау туа: шушы шартларда ничек итеп ихласлылыкны саклап калырга, идеалларга хыянәт итмәскә... Ул «астыртын»—эчке көрәш юлын сайлый—«халыклар атасы»на мәдхия җырламый, социалистик стройнын «җинүен» чагылдырган күләмле әсәрләр язудан баш тарта. Юк, бөтенләй өметсезлеккә бирелми, анын мәсләге—матурлыкка, яхшылыкка, изгелеккә дан җырлау! Боларнын нигезендә, әлбәттә, сабый чакта алган Ислам тәрбиясе ята.

Белгәнебезчә, мәдрәсәләрдә шәкертләрне яхшыны яманнан аера белергә өйрәтү, кеше жанындагы яшерен рухи башлангычларны изге юлга юнәлтү төп урынны алып торган. Тәрбия бирүдә, шулай ук, доньянын фанилыгын алга сөрүче котыртык тарафдарларына карата да агукайтаргыч кулланылган. Коръәндә ул—Шайтан, Тәүратта—Сатана, рухият фәнендә—Мефистофель яки Ариман («Заратустра»да) дип атала. Бу—халык ышануларындагыча, Аллаһы Тәгаләнен антиподы түгел; шулай да, күпмедер күләмдә доньяви тормыш белән хаклы рәвештә бәйләп торуына да карамастан, ул кешеләрне, агулы кармаклары аша, кол итәргә, хайвани дәрәҗәгә төшерергә сәләтле.



*Салих Сәйдәшев укыган Мөхәммәдия мәдрәсәсе*

Мәгълүм ки, мәдрәсәләрдә дини белемнен башлангычлары гына бирелгән. Әйтик, шәкертләр кешеләр җанындагы иблислек галәмәтләре турында житәрлек мәгълүматка ия булмаганнар. Иблис, Мефистофельдән аермалы буларак, кешене җирдән аерып алып, рухи галәмгә алып чыгарга омтыла, ә бу, үз чиратында, кешедә иҗади фантазия, сәнгати күзаллау тәрбияләүгә ярдәм итә. Шуна күрә, мөселман язма чыганакларында Иблис сәнгатьне яклаучы буларак гәүдәләнә *(Эрлих Р. Л. Иблис—музыкант. Записки коллегии Востоковедения при Азиатском музее.—Л. , 1930, Т.V.—С. 393)*. Икенче яктан, барлык тормышчан, доньяви

нәрсәләргә карата нәфрәт тойгысы, эгоизм, тормышка ашмаслык хыяллар белән мавыгу, хыялый дөнья матурлыклары белән хозурлану хисләре уятырга омтыла.

Рух иясе дөньялыктагы һәм үзендәге шушы ике капма-каршы затны (инкарь итмичә һәм ваз кичмичә) ачарга, теге яки бу якнын җанны берьяклы гына яулап алуына ирек бирмәс өчен аларны көч белән җиңәргә тиеш. XX гасыр башында мондый гыйлемне, әйткәнебезчә, Рудольф Штайнер нигез салган рух фәненнән алырга мөмкин була. Анын хезмәтләре Рәсәйдә дә басылып чыга һәм антропософиягә зур өметләр баглаган күренекле татар мәгърифәтчеләре һәм дин әһелләре тарафыннан кин яклау таба. Ләкин 20 елларда ул басмалар кара исемлеккә эләгә, аннары барлык мәдрәсәләрдә дә үзгәртеп кору өчен көрәш алып бармыйлар.

...Тарихи ераклыкларга күз салсак, тик аерым дини үзәкләрдәге алдынгы карашлы затлар гына серләр дөньясына үтеп керә алганнар һәм бик күп вакытлар узгач кына алар рухи камиллеккә омтылучы җаннарнын казанышына әверелгән. Дөньялыкнын барлыкка килүе турындагы борынгы риваятьләрнен берсендә хәбәр ителгәнчә, рухи дөньянын өчлекле төзелеше сере әнә шуннан гыйбарәт. Ягъни, Аллаһы Тәгалә кешене һәм галәмне яралту алдыннан ихтыяр көчен Мефистофель белән, фикер йөртешен Люцифер белән бүлешкән, әмма яратуын беркем белән дә уртаклашмаган.[1]ул аны бары тик үзендә югары иҗади башлангыч һәм рәхим-шәфкатьле «Мин»е булган рухи затка гына индергән. Борын-борын заманнарда бу зат, бөтен кешелекнен кумәк җаны буларак, рухи мохитта көн күрә. Бары тик яна чор исәбе башлангач кына, җан ияләреннән беренче булып үзе турында «Минем асылым—мин ул» («Я есмь») дип әйтә алган һәм минем «Мин»ем белән Аллаһы Тәгалә «Мин»е бердәм дип белдергән Иисуста гына бу зат индивидуаль чагылыш таба. Коръәндә ул Мәсих—Гайсә пәйгамбәр дип атала *(Коръән, «Ниса» сүрәсе, 171-172 аять)*.

Бу Рух һәлакәтләрдән коткара алырлык илаһи ярату кодрәтенә ия. Кешеләрнен нәкъ менә яратуга сәләтле булулары аркасында гына Люциферлыкка ( Иблислеккә ) һәм Мефистофельлеккә (Шайтанлыкка ) охшаш капма-каршы рухи агымнар үзара килешеп яши алачаклар; кешеләр ялгыш юлдан кереп киткән очракларда туу ихтималы булган яманлыкларны да бары тик ярату хисе генә җиңәргә сәләтле. Мона, гаҗәеп сабырлык, фидакарьлекләр күрсәтеп, фани дөнья ваклыкларыннан ваз кичкән очракта гына һәм барлык кешеләргә карата да мәрхәмәтле булганда гына ирешергә мөмкин.

Кызганыч ки, XX гасыр башында татар зыялыларына өчлек рухын кабул итәрлек хәзерлек мәктәбен үтәргә туры килми. Бу С. Сәйдәшевкә дә кагыла. Күрәсен, ул рухи көрәш ике көч арасында—Илаһи башлангыч белән яманлык белән яхшылыкка карата үз вәкаләтләрен арттырып җибәргән өчен хөкем ителгән Шайтан арасында бара дип фараз кылгандыр. Композиторнын эре формаларны үзләштерүдә икеләнүле караш торуы да шунын белән анлатыла. Югыйсә, әле иҗатынын башлангыч чорында ук, «Сүнгән йолдызлар» спектакленә язган увертюрасында соната формасы төзелешенен үзәк өлгеләрен тәшкил иткән музыкаль материалдан кыю файдаланган иде. Шушынын белән ул янача фикерләүнен үсешенә этәргеч тә ясаган иде. Ләкин сонрак, асылы белән деструктив күренеш дип исәпләп, шушы юнәлештәге эзләнүләрен киметә төште һәм 30 елларда Мәскәүдә укыган вакытында, яшьлеккә хас кирәмәтлеге белән, эре формадагы әсәрләр иҗат итүдән бөтенләй баш тартты *(Салих Сәйдәшев турында истәлекләр.—Казан, 1980, 50 б.)*.

Сүз дә юк, татар музыкасы үсешенен башлангыч чорында традицион формаларга таянырга тиеш дип исәпләве белән ул хаклы иде, чөнки мелодия һәм гармониянен янарыш кичерүе шартларында миллилекне нәкъ менә шушылар ярдәмендә генә саклап калырга мөмкин иде. Һәм С. Сәйдәшевнен шушындый принципиаль караш торуы татар профессиональ музыкасына дөрес юл сайларга ярдәм итте, ирешкән казанышларны югалтмыйча, милли янгырашнын дөнья музыкаль мәдәниятенә эзлекле рәвештә һәм табигый агым булып кушылуына зур йогынты ясады. Кыскасы, олуг сәнгаткяр үзенен артык зур күләмле булмаган әсәрләре белән гомумүсеш ориентирларын билгеләп, әйтерсен лә, заман таләпләрен үзләштереп бетермәс борын

---

[1]Христианнар бер Аллага ышануга килеп җитмәделәр... Христианнар: Ходай—ата, Ходай—угыл һәм Ходай—Изге Рухтан торган Тәнре, - диләр. Ягъни, аларча, Аллаһ өч Ходайнын берлегеннән хасил булып чыга. Аларнын өчесе өчкә аеры, өчесе берьюлы бер Аллаһ, янәсе *(Коръән, «Ниса» сүрәсе, 171 аять. —Х. Караман тәфсиреннән)*.

вакыт арбасы алдына чыгып чабарга омтылган кайберәүләргә ашыкмаска киңәш бирде. Чыннан да, 30 елларда, хәтта аннан соңрак та татар композиторлары тулысынча диярлек бу өлкәдәге эзләнүләрен туктатып тордылар (үз вакытында әйтелгән сүз генә калерле ләбаса!); ә 40 елларда исә татар милләтеннән булмаган композиторлар (М. Юдин, А. Леман) милли җирлеккә таянып инструменталь әсәрләр иҗат итеп карасалар да, теләгән нәтиҗәгә ирешә алмадылар. Бары тик 50 елларда, Р. Яхин, Ә. Бакиров, А. Монасыйпов, Р. Еникеев кебек яшь композиторлар менә дигән сонато-симфоник әсәрләр циклы иҗат иткәннән соң гына, өлкән буын вәкилләре дә бу эшкә җин сызганып керештеләр.

Ләкин бу вакытта алар арасында С. Сәйдәшев юк иде инде.

Әлбәттә, иҗатының җитлеккән чорында композитор эре формаларны инкарь итүенең, кайбер уңай яклары булуга да карамастан, үкенечле нәтиҗәләргә китергәнен бик яхшы аңлый. Шушы чорда ул кулдан ычкындырган мөмкинлекне кире кайтарырга теләп булса кирәк, опера иҗат итәргә керешә, әмма сугыш афәте аны да башка дөньяга бөтереп алып кереп китә. Концерт бригадалары белән берлектә фронтның алгы сызыгында, гастрольләрдә сугышчылар алдында чыгыш ясап, яралы күңелләргә шатлык, өмет, ярату хисләре өләшә. Әмма сугыш белән бергә аның җаныннан, соңгы тамчы булып, опера язу теләге дә өзелеп-тамып төшкән була, күрәсең. Сугыштан соң Кытайдан кайтып, Казанда беренче джаз оркестры оештырган, шул чорда үзе дә күп җәфалар чиккән О. Лундстрем истәлекләренә караганда, гомеренең соңгы елларында С. Сәйдәшев икеләнүле, газаплы уйлар өермәсе эчендә яши, Мәскәүдә укыган вакытында эре формаларны үзләштермәвенә әрнеп, үкенүле хисләр кичерә. Әйе, С. Сәйдәшев шушындый халәтләрдә дә олы җанлы, намуслы шәхес булып кала ала: яшьлегендә ирексездән җибәргән хатасын танудан тайчанмый...

Шушындый эчке тетрәнүләр генә җитмәгән, исеме тирәсендә тузга язмаган чыш-пыш йөргән, гайбәт таралуын күреп-сизеп яшәү композиторга бик тә авыр була. Җитмәсә, соңгы вакытта партия җитәкчелеге даирәсендә һәм музыкаль гавәм арасында итәк астыннан гына йөрүче «С. Сәйдәшев—талантлы шәхес, җырлар остасы, әмма ярымпрофессиональ, заманнан артта калган композитор» дигән уйдырмалар да төрле юллар белән аның колагына килеп ирешә, ирешә дә... бәгыренә утлы хәнҗәр булып кадала. Ләкин ул гомере буена татар музыкасын үстерү, үзәккә туплау буенча дөрес карашта торганлыкка инанып яши, бу мәсьәләдә бер генә карыш та, бер генә кәррә дә артка чигенергә уйламый, ә ярымпрофессиональлектә гаеп ташлаучыларны «теге чакта» вакыт агышын тоеп житкермәүчеләр дип кенә бәяли.

Шулай да Н. Җиһанов мисалында татар музыкасын тамырдан үзгәртеп коруны үзмаксат итеп куйган яңа лидерның пәйда булуы С. Сәйдәшевне сискәндерми калмагандыр. Әмма ана тышка бәреп чыккан, үзмаксат әйдәманлык ят нәрсә иде һәм актив эшләүче, тынгысыз җанлы яшь композиторның юлына аркылы төшү аның уена да кереп карамый. Әмма Н. Җиһановның лидерлыгы хакимлек төсмере ала башлагач, композиторның теләгеннән башка, җәмәгатьчелек С. Сәйдәшевне яклау юлына баса. Әлбәттә, ихтыярсыздан кабынып киткән бу хәрәкәт рәсми даирәнең композиторга ясаган хаксыз басымын җиңеләйтергә ярдәм итә, ләкин үзе белән Н. Җиһанов арасында кискен мөнәсәбәтләр урнашу нәтиҗәсендә, сәнгать әһелләренең ике төркемгә бүленүен күрү аның сизгер җанына яңа борчулар өсти. Югыйсә, аның музыкага багышланган фидакарь хезмәте аклауга да, яклауга да мохтаҗ түгел. Киресенчә, музыка өлкәсендә армый-талмый иҗтиһад итүе аерым иҗади шәхесләргә каршы түгел, ә бәлки аларны саклап калырга юнәлдерелгән иде ләбаса. Аның изге бурычы—музыка аша кешеләргә шатлык, бәхет, изгелек өләшү иде ич... Шуңадыр, композиторның юмартлыгы чикләрне белми. Музыкаль мираска кем исеме белән кереп калачагы белән исәпләшеп тә тормастан, еш кына яңа язылган әсәрләрен әле үзешчән сәнгать ансамбльләре музыкантларына, әле филармониягә яки радиога бушлай бүләк итә.

Гаҗәеп тыйнак, шул ук вакытта сынмас рухлы шәхеснең кичереш-борчулары, ихлас күңелдән булып та, мәсьәләнең бөтен тирәнлеген аңлап җиткермәүче кешеләрнең кирәк-кирәкмәгәндә дә ярдәм кулы сузарга әзер торулары нәтиҗәсендә, үзгәрәк юнәлеш алгандыр, мөгаен. Чөнки ул күңелендәге барлык яхшылыкны аерым шәхесләр белән бөрәшкә түгел, ә бәлки күпмелер күләмдә һәрбер кешеләрдә була торган һәм гавәм ихтыяры белән төзәтергә тиешле тискәре сыйфатларны тәрбияләүгә юнәлтә һәм сарыф итә килде. Композитор бары шушы очракта гына кешеләр арасында югары кимәлдәге бердәмлек, тигезлек, бер-береңә карата тирән хезмәт урнаштырырга мөмкин дип

ышанып яшәде. Илле еллык юбилее алдыннан мәшһүр «Дуслык турында жыр»ның туулы (Ә. Ерикәй шигыре) әнә шул хакта сөйли булса кирәк.

Хәзер инде Мефистофель композиторга юл куярга, хәерхак булырга тиеш иде кебек... Менә шушы чакта Мефистофель коралын кулга төшерергә, анын көчкуәтен Иблис белән көрәшкә юнәлтеп, үз-үзенне бәла-казалардан саклап калырга мөмкинлек тә бар иде дә бит. Ләкин соната формасын үзләштерү юнәлешендә мәсьәләләр хәл ителмәгәнлектән, ул аннан файдалана алмый кала. Иблис тә, үзенә каршы торырлык көч юклыгын сизенеп, вәсвәсәсен эшкә жигә... Беләбез, композитор ачык, кин күнелле, тиз аралашучан кеше буларак, халык музыкантлары белән берлектә «Кызыл почмак»ларда, эшче һәм авыл тамашачылары алдында чыгышлар ясый, чакырулы өй мәжлесләрен дә кире какмый. Шушы аралашулар нәтижәсендә ана сугыштан сонгы елларда татар мохиты авырый башлаган чир—монарчы Ислам дине тотып-тыеп килгән шәраб белән мавыгу чире йога.

Әмма дөреслекнен күзенә карап әйтергә кирәк, С. Сәйдәшев бервакытта да чама хисен югалткан шәраб колына әверелми (ә олуг шәхесләр турында арттырып сөйләүләр гадәти күренеш инде ул). Рухият фәне бу хакта болай дип икърар итә: үзенен асылы белән чиста күнелле шәхес кенә сәнгатьтә бөек ачышларга ирешергә мөмкин, сәрхүшбаш—юк *(Пятое Евангелие и мистерия Голгофы в свете духовной науки.—Одесса, «Путь познания», 2000.—С. 44).* Рухият турындагы өйрәтмәләр тагын болай дип тә өсти: тирән рухи кичерешләр дөньясына кереп чумган һәм шушы халәттән (һәртөрле бәйләнчек уйлар, идеялардән) чыгу юлларын таба алмаган күп кенә сәнгать әһелләре кайчак үзләре өчен шәрабнын үзенчәлекле, «шифалы» сыйфатын ачалар. Чөнки шәраб вакытлыча рухи-дини дөньянын тәэсир көчен томалый. Борынгы Грециядә шәраб алласы Бахус (Дионис-Люцифер) тарафыннан шәраб кешелеккә нәкъ менә шунын өчен, илаһи көчләрдән аерымланган мөстәкыйльлекне үстерү һәм шәхси үзанны уяту өчен бүләк ителгән дип исәпләнелгән.

Антропософик эзләнүләр яссылыгыннан торып караганда, хәзерге вакытта шәраб куллану ерак үткәннәрдән калган гадәт булып тора һәм, хәтәр нәтижәләргә китерү мөмкинлеген инкарь итмәстән, аны яхшылыкка юнәлтергә дә мөмкин. Шәрабнын кире тәэсире, ни гажәп, шәраб куллануга әчке каршылык аша, әйтерсен лә, шәхес анында «Мин—Фикер иясе»н нытытырга ярдәм итә. Рухият гыйлеме бу хакта чын сәнгатькяр халкыннан аерым яши алмый; ул замандашлары кичергән хисләр белән яшәгәндә генә чын мәгънәсендәге гүзәл үрнәкләр тудыра ала, дип исәпли. Нәкъ шунын нәтижәсе буларак, бөек шәхесләр халкы арасында кин таралган авырулар белән авырый башлыйлар, күрәсен. Аерым алганда, Рәсәйдә XIX-XX гасыр аралыгында күп кенә сәнгать әһелләре түбән катламнар өчен гадәти булган үпкә авыруыннан вафат булалар (Тукай белән Сәйдәшне дә шушы афәт якты дөньядан алып китә ләбаса).

Димәк, сүз әхлак турында гына барырга тиеш түгел.

С. Сәйдәшев шәхесенә кагылышлы анлашылмаучылыкнын асылын барлык замандашларыннан тирәнрәк итеп Б. Урманче анлады булса кирәк. Татар сынлы сәнгатенә нигез салучы буларак, С. Сәйдәшев кебек ул үзе дә олуг реформатор иде. Символик мәгънәгә ия: әлеге сәнгатькярләрнен һәр икесе яшьлек елларында Тукайнын шифалы йогынтысын тоеп калалар. Юк, алар гадәти танышлар гына булмыйлар, әйтерсен лә, шагыйрьнен фатихасын алып, анын яссылыгына күчәләр. С. Сәйдәшев мондый халәтне чакырулы концертларнын берсендә, Тукайнын жырлавына кушылып уйнаганда кичерә: кинәт шагыйрьнен авызыннан гөрләп кан китә һәм ул яшь Салихнын өстенә чәчрәп өлгерә. Рухиятне өйрәнү серенә төшенгән Гете билгеләп үткәнчә, «кан үзенчәлекле сыекча», кешенен «Мин—Төзелеш иясе»н шул тәэмин итә (бик борынгы заманнардан һәртөрле туганлашу, рух алмашу йолалары кан белән бәйләнгән). Әлеге очракта С. Сәйдәшев белән дә шундыйрак хәл булган, күрәсен.

Б. Урманче Тукай рухын башкачарак шартларда, бер төркем шәкертләр белән үлем түшәгендә ятучы шагыйрь янында дога кылып төн үткәргәндә, шагыйрь жаны гарешкә очкан мизгелләрдә кабул итә.

Б. Урманче белән С. Сәйдәшев 20-30 елларда ук таныш булалар. Аннары Урманче репрессияләнә, Казанга 50 еллар ахырында, ягъни С. Сәйдәшев вафатыннан сон гына әйләнеп кайта. Гажәп: «Сәйдәшев» белән «Жиһанов» өчен барган көрәш ыгы-зыгысы әле бу вакытта да тынып житмәгән була. Урманче боларнын берсенә дә катнашмый, үзенә хас сабырлык, төптән уйланучанлыгы белән татар профессиональ

музыкасы туу чорында аеруча зур өлеш керткән композиторларның—С. Сәйдәшев, Н. Жиһанов һәм Ф. Яруллинның сыннарын коя. Әйе, алар күренекле шәхесләр булу өстенә, күпмедер күләмдә иҗади антиподлар да иде һәм, белгәнебезчә, шушы хәл кайбер кешеләрдә теге яки бу композиторның музыка дөньясында тоткан урының түбәнсетеп күрсәтергә омтылу теләген уятты. Ләкин Урманчены боларның берсе дә кызыксындырмады, ул шушы өч композиторның иҗатында татар профессиональ музыкасының төп юнәлешләрен күрә алды.



*С. Сәйдәшев бюсты.*
*Б. Урманче эше.*

Ул, сәнгатьне тирәнтен аңлаучы шәхес буларак, С. Сәйдәшев музыкасындагы мелодизмны чын күңеленнән яратты, бетмәс-төкәнмәс шатлык, рухи ныклык өләшеп, тыңлаучыларны нур белән өртелгән илаһи биеклекләргә күтәрә алган талантына сокланып туя алмый иде. Н. Жиһановның көчле яңгырашлы, әмма бераз колакка ятышып бетми торган—диссоннанс тудыра торган музыкасында Б. Урманче тормыш динамикасын бөтен каршылыкларында чагылдырырлык заман чакыруын ишетте. Ф. Яруллин иҗатының иң биек ноктасы булып торган «Шүрәле» балетында рәссамны милли характер-образларның гаҗәеп колоритлы ачык-якты тоннарда тасвирлануы, хис-кичерешләрнең инструменталь чаралар ярдәмендә шундый да тирән ачылуы чын мәгънәсендә әсир итте.

Б. Урманче композиторларның сыннарын койган вакытта музыкадан алган тәэссоратларга гына ышанып бетмичә, һәр остаының рухын аңларга, беркатлы, субъектив бәя бирүдән ерак торырга тырышты. Шушындый иҗат алымы сынчыга С. Сәйдәшевнең һәрьяктан камил һәм тормышчан образын тудырырга булышты. Мәрмәр сынга карап бөек музыкантка хас эчке рухи матурлык, байлыкны да, сәдалек һәм сафлыкны да, тәрбияләлек һәм егетлекне дә тоярга мөмкин. Шуның белән бергә бу гүзәл әсәрдә С. Сәйдәшев иҗатындагы Бөек рух та чагылыш тапкан: ул—саф-чиста яратуРухы; ул—җылылык, шатлык яктылык өләшүче Изге Рух.

* * *

... Тормыш дәвам итә—Вакыт елгасы туктаусыз ага да ага тора. Кайчак С. Сәйдәшев иҗаты экренләп ерак үткәннәрдә калган кебек тоела башлый. Ләкин чынлап торып уйласаң, бер дә алай түгел икән—аның музыкасының бүгенге сәнгатебез үсешенә йогынтысы барлыгын күрсәтүче билгеләр әнә шул хакта сөйли. Шунысы куанычлы, композиторларыбыз С. Сәйдәшев әсәрләрен янача укып, янача эшкәртеп, иске җирлеккә «ямаулык» ямап кына калмыйлар, ул ачкан мәңгелек темаларга заман сулышы өреп, өр-яңа әсәрләр иҗат итәләр. Бу җәһәттән Р. Еникеевның Сәйдәш мелодияләренә нигезләнеп яшь пианистлар өчен иҗат иткән полифоник яңгырашлы «Сәйдәшстан» циклы аеруча игътибарга лаеклы. Биредә без «үзгәрешләр чорындагы» бөек импульслар тәэсирендә туган иҗатның яңа дәвер сәнгатенә җирлек булып торуын күрәбез. Асылына үткәннәр белән киләчәкне тоташтырып тора алырлык көч-куәт салынган орлык кебек, ул үсә-үсә үлемсезлегенә илтүче юлны туктаусыз дәвам итәр. Чөнки ул кешеләргә җан җылысы, яшәүгә өмет, сәгадәтле хис-кичерешләр алып килә...

Соңгы сулышында иҗат ителгән «Җырларым» әсәрен (М. Җәлил шигыре) нәкъ менә шулай кабул итәргә кирәк тә:

> Җырларым...
> Сездә минем бөтен тойгыларым,
> Сездә минем керсез яшьләрем;
> Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
> Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

**Шамил МОНАСЫЙПОВ,**
*Татарстанның халык артисты*

*Язучы һәм сәясәтче Фәүзия Бәйрәмовага 50 яшь*

# ӘНӘ ШУНДЫЙ ЙӨРӘК!

... Сиксәненче еллар ахырында һәм туксанынчы еллар башында башкалабыз Казан урамнары «Азатлык» дигән мәгърур сүзнең куәтле дулкыннарыннан гүләп торды...

Әйе, халыкның, милләтебезнең азатлыкка, бәйсезлеккә омтылудагы көчен тагын бер мәртәбә ачык итеп раслаган ул көннәр, ул көрәш сәхифәләре күнелләргә мәңгегә сеңеп калды. Уянып мәйданнарга чыккан халыкның алдында баручылардан Фәүзия Бәйрәмова исеме ул елларда «Азатлык» дигән бөек сүз белән янәшә йөри иде.

Ә соң аның үзен бу изге көрәшкә нинди юллар алып килде икән?



Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова 1950 елның 5 декабрендә Саба районының Сабай авылында, ун балалы гаиләдә туа. Әтисе Бөек Ватан сугышы инвалиды булганлыктан кечкенәдән үк авыр эшләрне эшләп, дөньяның ачысын-төчесен татып үсә.

1966 елда Олы Шынар сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач аны, яшьтән актив хәбәрче булуын искә алып, Саба районында чыга торган «Җиңү байрагы» газетасы редакциясенә эшкә чакыралар. Ул шунда ике ел эшләп, кичләрен укып Саба урта мәктәбен тәмамлый. Мәктәп яшеннән үк инде пьесалар, әдәби сценарийлар яза башлаган Фәүзия Бәйрәмова 1968 елда Казан театр училищесының режиссерлык бүлегенә укырга керә һәм аны 1971 елда уңышлы тәмамлап чыга. Аннары ул алган белеме буенча Казан телевидение студиясендә эшли, 1975—1978 елларда гаиләсе белән Монголиядә яши, анда төзелештә эшли.

Казанга кайткач Фәүзия Бәйрәмова газета-журнал редакцияләрендә үзен сынап карый. 1979—1984 елларда «Казан утлары» журналында корректор булып эшли башлый һәм шул чагында үзе дә актив рәвештә каләм тибрәтергә тотына. 1983 елда Фәүзия Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә, 1989 елда аны тәмамлап филолог дипломы ала.

Ижатка мәхәббәт, халыкка якын булырга омтылу Фәүзия Бәйрәмованы республикада чыга торган газета редакцияләрендә профессиональ рәвештә эшләүгә китерә. Ул 1985—1986 елларда «Татарстан яшьләре» газетасында, 1986—1987 елларда «Социалистик Татарстан» газеталарында эшли, газета битләрендә милләт тормышына багышланган күләмле публицистик язмалар белән чыгыш ясый.

1987 елда Фәүзия Бәйрәмова Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегенә мөхәррир булып урнаша һәм 1998 елга кадәр шул эшен дәвам итә.

Фәүзия Бәйрәмова зур иҗатка 80 еллар башында килә. Аның беренче күләмле әсәре—«Болын» повесте 1983 елны «Казан утлары» журналында басылып чыга һәм әдәби җәмәгатьчелектә жылы кабул ителә. Әдәбиятыбыз аксакаллары Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Фәрваз Миннуллин яшь язучының тәүге адымнарын хуплыйлар.

Менә, мисал өчен, Әмирхан Еники фикере: «... Фәүзия бик талантлы, һәм аның таланты гаять үзенчәлекле... ул үзен һич аямыйча, гүя бөтен нервлары белән бик кабынып-кайнарланып яза... Көчле яза. Аны укыганда инде салкын, битараф калу мөмкин дә түгел. Килешәсенме-килешмисеңме, яратасынмы-яратмыйсыңмы, ләкин барыбер анардан аерыла алмыйсын. Укучы кәефенә җайлашып тормый ул! Күтәргән проблемасы һәм алган вакыйгасы белән дә ул, әйтергә кирәк, укучының йокысын качыра... Кыю керә тормышка Бәйрәмова, һәр әсәрендә диярлек кеше язмышының фаҗигале якларын ача. ... ул укучыны да аяп тормыйча кешенең эчке җанына бик тирән үтеп керә».

Ә Фәрваз Миннуллин менә ничек яза: «Фәүзия Бәйрәмова повестьларының һәркайсы мавыктыргыч һәм үзенчәлекле, һәркайсы үзенчә кызыклы. «Болын»—«Битлек»кә, «Битлек» «Чакрым баганалары»на охшамаган кебек, «Күл балыгы» әлеге өч повестьның барысыннан да нык аерылып тора. Шул ук вакытта барысы да Фәүзиячә кабынып-кайнарланып, дуамалланып язылган. Барысыннан да хис ташкыны бөркеп тора. Повестьларын укыганда, үзеңне әле кайнар җилләр искән ком чүлендә итеп сизәсең, әле бер-бер артлы ишелеп, тәгәрәшеп килгән диңгез дулкыннары уртасында калгандай буласың...»

Әйе, Фәүзия Бәйрәмованың үз сүзендә нык тора белүе, халык тормышына битараф булмавы башта, сәяси көрәшкә кадәр ул язган әсәрләрдә чагылыш тапты. «Болын» повестендагы Алсуның Табигатькә—димәк, иркенлеккә, димәк, Ирекkә ни дәрәҗәдә гашыйк булуын карагыз сез! Болынның табигый матурлыгын харап иткән—аны сукалап ташлаган Алмазга ни хәтле нәфрәт, ни кадәр ачу ташый яшүсмер Алсу йөрәгендә!

«Күл балыгы»н алсак, биредә инде тар даирәдә йомылып калу, түбән дәрәҗәдәге мескенлек, коллык күренеше бик тә үтемле итеп күрсәтелә.

Татар халкының бөек шагыйре Һади Такташ язмышына багышланган «Атылган йолдыз» драмасында да кешенең үз-үзенә хыянәте төп проблема итеп алына, шагыйрь шәхесен шундый түбәнлеккә дучар итүчеләргә карата нәфрәт тудырыла.

Кыскасы, соңрак мәйданнарга һәм парламент трибуналарына чыкканчы Фәүзия Бәйрәмова иң элек үзенең әсәрләрендә көрәш тәҗрибәсе туплаган, үзенең һәм үзен тудырып-үстергән татар милләтенең мәхәббәт һәм нәфрәт юнәлешләрен ачыклаган икән!

Ялкынлы хискә төрелгән әлеге әсәрләр аның өчен хәтта үзенә бер төрле әзерлек үтү, репетиция дә булгандыр кебек—алда торган зур көрәшләр өчен йөрәкне һәм акылны чыныктыру, ныгыту, үстерү...

Олы иҗаттагы әнә шундый тәүге уңышлары белән канатланган Фәүзия Бәйрәмованың 1986 елда «Болын» дип аталган беренче китабы Әмирхан Еники кереш сүзе белән дөнья күрә, 1991 елда «Моң» исеме белән икенче китабы басыла.

Шул ук 80 елларда Фәүзия Бәйрәмова драматургия өлкәсендә дә актив эшли. Бу вакыт аралыгында аның «Аллалар ялгышы яки яңа матриархат», «Һәркемгә бер кояш», «Атылган йолдыз», «Сандугачның балалары», «Безне онытмагыз», һ. б. драма әсәрләре языла. Бу әсәрләр Минзәлә татар дәүләт драма театрында, Казандагы яшьләр театрында һ. б. куела, Казан телевидениесеннән күрсәтелә. 1998 елда «Безне онытмагыз» дип аталган пьесалар җыентыгы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә.

80 еллар ахыры... Совет империясе таркалу... Аңа кергән республикаларның ашыга-ашыга бәйсезлек алырга тырышуы... Автономиянең бик тә тар кысаларында яшәгән Татарстан да, татар халкы да үз азатлыгы өчен көрәш башлый. Кайнар йөрәкле иҗатчы Фәүзия Бәйрәмова бу көрәшнең үзәгендә кайный, аны әйдәүчеләрнең берсенә әверелә. Бер төркем милләтпәрвәрләр белән бергә алар 1988 елда Татар иҗтимагый үзәген оештыра. Фәүзия Бәйрәмова 1991 елга кадәр бу оешманың рәис-координаторларыннан берсе була. Ә инде 1991 елда ул «Иттифак» милли бәйсезлек партиясенең рәисе итеп сайлана. 1994—1997 елларда ул Милли Мәҗлес рәисе булып эшли. Бу елларда аның инициативасы һәм җитәкчелеге белән «Татар кануны», «Гаилә кодексы» кебек милләт өчен мөһим булган зур хезмәтләр эшләнә һәм халыкка җиткерелә.

1990 елда Фәүзия Бәйрәмова үзе туган Саба районыннан Татарстан Югары Советына депутат булып сайлана һәм 1995 елга кадәр республика парламентында тынгысыз эшчәнлек алып бара. Шул елларда аның байтак кына публицистик язмалары һәм китаплары да басылып чыга.

1994—1995 елларда «Аргамак» журналында Фәүзия Бәйрәмованың «Кара урман» исемле әсәре басыла. Бу әсәр өчен автор С. Сөләйманова исемендәге бүләккә ия була.

Соңгы елларда ул төрки-мөселман халыклары мәсьәләләре буенча уздырыла торган зур халыкара корылтайларда, конгрессларда катнашты һәм чыгышлар ясады. 1990 елда Германиядә, 1991 елда Бельгиядә һәм Голландиядә, 1992 елда Америка Кушма Штатларында, 1991—1998 елларда Төркиядә һәм Кипрда, 1996 елда Даниядә уздырылган форумнарда делегатлар аның чыгышын тыңладылар. Фәүзия Бәйрәмова бүген дә Кавказ, Кырым, Себер, Алтай, Идел буе төркиләре белән тыгыз элемтәдә тора.

Үзенчәлекле иҗади талантка ия язучы һәм кайнар йөрәкле, фидакарь җанлы сәясәтче үзенең бу юбилеена әнә шундый зур уңышлар белән килде. Ул бүген дә актив иҗади тормыш белән яши, иҗтимагый-сәяси вакыйгаларда катнаша, һаман да милләтебез мәнфәгатен кайгыртып йөри.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ.**

## *Роза Кожевниковага 50 яшь*



*Роза Кожевникова (Баубек) Әстерхан якларында туып үскән. Балачагында аның аягы кагылган кылганнар офыккача йөгереп һаман да Роза шигырьләрендә көмеш тавышлар белән көләләр әле. Һәм елыйлар... Шагыйрә безгә борынгы халыкның—ул карагаш ыруыннан!—моңын-сагышын, үкенечләрен китереп җиткерә. Чит телдә язса да (аны балачактан урыс мәктәп-интернатында тәрбияләгәннәр), милли хәтер шигырь булып аның канынннан ага. Шуңа күрәдер дә ул бик күп татар шагыйрьләрен урысчага тәрҗемә итте, аның ярдәме белән байтак халык татар гамен, татар яшәешен үзләренчә төшенә алды.*

*Кунак ашы—кара-каршы, ди халык. Менә мин дә бүген аның берничә шигырен татарчага тәрҗемә итеп—аның ана теленә!—укучылар хөкеменә тапшырырга уйладым. Бераз гына кыенсынып... Чөнки Хиссиятне бер телдән бер телгә күчерү шактый читен эш.*

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

# Роза Кожевникова

### Шагыйрьгә

**Берәр заман мәшһүр булырсың син...**
**Ләкин шушы ялган тантанага**
**Синең ишләр түгел, бүтән кешеләр**
**Типтерергә диеп ишек кага.**
**Күп елларга читкә тибәрелдең.**
**Чыксалар да сиңа күптән ясин,**
**Йөрәк каның тамган кәгазьләргә**
**Ләббәйкәле куллар кагылмасын.**
**Берәр заман...**
**Җитәр синең нәүбәт:**
**Хаклык чыгар сәләмәләр аша**
**Һәм намусны дәшәр.**
**Мәңге яшәр.**
**Мин бит сизәм—ул көн якынлаша...**

*Редакциядән:* Шагыйрәнең «Гроздь рябины» («Миләш тәлгәше»), «Два голоса» («Ике тавыш»), балалар өчен «Зимний дождик» («Кышкы янгыр») китаплары дөнья күрде. Юбилеена сайланмасы— «Меж светом и тьмой» исемле басма әзерләнә. Ул—Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Идел» журналының баш редактор урынбасары.

* * *

Сине инде беркем алыштырмас—
Җәйләрем дә синдә, салкын кыш та.
Чәлпәрәмә йолдызлардай язмыш,
Ялгышым да шунда, әр, сагыш та.

Сине инде беркем алыштырмас.
Мин бит күрәм моны, мин бит тоям:
Еллар аша, ерагайган саен,
Хатирәне мин якынрак җыям.

* * *

Сүрән яктылыкта синең шәүлә
Өмет өрәгедәй эри сыман.
Кышның исе килгән иртәләрдә
Киемемне сарган авыр томан.
Елмаюдан арды иреннәрем,
Керфекләрем инде бәсне имә.
Бу сагышның сәбәбе дә гади—
Вазадагы кипкән хризантема.

* * *

Язгы чәчәк күзен уянды да
Күзен салды:
Күптән сулган болын.
Соңгы җылы көнгә алдандымы?
Тойды менә салкын җилләр кулын.
Хәтернең дә кыек көзгесе бит
Үткәннәрне шулай күрсәтә гел...
Газиз тавыш анда, төсле төшләр.
Ә чынлыкта—күптән суынган көл.

## Туган ягым

*(Әстерхан шәлкеменнән)*

Идел тармагында[1] карап узам:
туган йортым ятим калган икән,
тәрәзәләре йомык, түбә тузган,
һәм яртылаш нигез җиргә иңгән.
И лаләле кырлар, ерак эскерт,
ә күпердән уңда—таныш атау,—
балачагымны син миңа искәрт!
Тизәк түтәннәре җиргә ята
кәҗәләрне черкиләрдән саклап.
Килгән чегәннәрдән калган иске
патефонны искә төшердем дә,
кузгатты ул йоклап яткан хисне.

Җикән камыш, кара бөрлегәннәр
минем сагышыма төренгәннәр.
Усал кигәвен дә газиз монда,
тикәннәр дә назлы күренәләр.
Ромашка күк баскан җил тирмәне,
һәм җил үзе минем сызгыруга
тынып кала, бакча сугарыла,
шыпырт кына кулас[2] төшә суга.
Таң-тирәкләр башын иеп кала,
якынлашам елга тамагына...
Ышанасы килә: без бит исән
туган яклар исән булса гына.


[1]Шагыйрә торган станция исеме—Дельта дип атала.

[2]Кулас—кечкенә көймә.

*Фатих Халидинең тууына 150 ел*

# МӘГЪРИФӘТЧЕ ӘДИПЛӘРЕБЕЗДӘН БЕРСЕ

Мәгълүм ки, XIX йөзнең беренче яртысына кадәр татар язма әдәбиятының төп нигезен Урта гасыр шәрык әдәбияты тудырган гуманистик идеяләргә таянып язылган дини һәм дини-мифологик әсәрләр тәшкил итә. Мәсәлән, «Сәйфелмөлек», «Мөхәммәдия», «Бәдәвам», «Рисаләи Газизә», «Һәфтияк», «Коръән» кебек китапларны шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин. Соңрак исә, ягъни 60 еллардан башлап, дәреслекләр, календарьлар, чын милли җирлектә дөньяга килгән проза һәм драма әсәрләре басыла башлый. Бу игелекле эшне беренчеләрдән булып татарның күренекле зыялылары—Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Габдрахман Ильяси башкара. Шулай итеп, XIX йөзнең соңгы чирегендә һәр елны 100-170 исемдә миллион, миллион ярым татар китабы укучыга тарала килә. Фатих Халиди нәкъ шул чорда әдәбият мәйданында беренче адымнарын ясый.



Укучы, һәрхәлдә, Ф. Халидине татар драматургиясендә Г. Ильясидан соң икенче драма әсәре биргән шәхес итеп кенә күз алдына китерә. Бу фикер бигрәк тә М. Гайнуллин, Я. Абдуллин, А. Әхмәдуллин, Г. Сәгъди, Б. Яфаров, Х. Мөхәммәтов, И. Нуруллин, Х. Гобәйдуллин, Г. Кәрам, К. Бәкер, Х. Хәсәнов, Г. Баттал, Ә. Мәхмүтов хезмәтләрендә чагылыш тапты. XIX йөзнең 90 еллары һәм XX йөз башында Н. Ф. Катановның «Деятель» журналында басылган мәкаләләре һәм рецензияләре аша әдип тәрҗемәче һәм календарьлар авторы сыйфатында ачыла. Күркәм традицияне дәвам итеп, соңгы елларда ул төзегән календарьларны археограф, әдәбият галиме М. Әхмәтҗанов кабат игътибар үзәгенә алды. Ул Ф. Халиди төзегән календарьларда нәшер ителгән кызыклы материалларны, шул исәптән, төрек әдәбияты үрнәге «Мәлхәмә» әсәреннән аерым өзекләрен матбугатта бастырып чыгарды *(«Татарстан», 1996, № 2 )*. Шулай ук XX йөзнең 70 елларында язучының Урта гасыр Шәрык һәм Европа тибындагы реалистик әдәбият үрнәгендә язылган, алай гына түгел, татар әдәбиятында Шәрык әдәбияты классик әсәре «Мең дә бер кичә» рухында дөнья күргән оригинал «Мең дә бер сәхәр»не әдәбият галимнәре тикшерү объекты итеп алдылар. Бу әсәргә тирән анализны филология фәннәре докторы Х. Миннегулов бирде *(Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар.—Казан, КДУ нәшрияты, 1998)*. Галим язучының төрек теленнән тәрҗемә итеп бастырган «Мең дә бер кичә» әсәренә дә киң тукталып үтә. Сәгыйдулла Хафизов та кандидатлык диссертациясендә «Мең дә бер сәхәр»не читләтеп үтмәде. Шәхсән минем тарафтан язылган диссертациядә дә Ф. Халиди иҗаты төрле аспектта өйрәнелеп, ул тудырган мирасны мөмкин кадәр ачуда беренче адымнар ясалды.

Шул рәвешле, Ф. Халиди 25-30 ел иҗат гомерендә драматург, язучы, тәрҗемәче, календарьлар төзүче буларак, XIX йөз ахырын—XX йөз башы әдәби процессында үз эзен салып калдыра.

* * *

Ф. Халиди 1850 елда (кызганычка каршы туган көнен ачыклап булмады) Тәтеш өязе (хәзерге Кама Тамагы районы) Яңа Сала авылында заманының укымышлы мулласы Хаммад гаиләсендә дүртенче ир бала булып дөньяга килә. Атасы шактый еллар Яңа Сала авылында имамлык вазифасын башкарганнан соң, якташы Хәбибулла Рахманколый (ул шул ук районның Бәки авылыннан) үлеп киткәч, аның кияве Әхмәд бине Сәгыйд димләве буенча, Казанның 4 мәчетенә (Зәңгәр мәчет) имам һәм мөдәррис итеп сайлана һәм гомеренең ахырына кадәр (1864) шунда имамлык кыла, балалар укыта. Кечкенә Фатихка абыйлары Мөхәммәдзакир һәм Мөхәммәдсабир кебек Бохарага барып белем эстәргә туры килми. Ул атасыннан башлангыч белемне алгач, шул вакытта танылган мәдрәсәләрнең берсе—Кышкар мәдрәсәсендә укуын дәвам итә. Кышкарда озак еллар укырга насыйп булмый, күрәсең, Казанга кайтып, Гайсә хаҗи Мусин кибетендә приказчик сыйфатында эшкә урнаша. Тора-бара китап сәүдәсе белән шөгыльләнә, үзе дә китап кибете ачып җибәрә.

Тормыш мәктәбенең һәрбер баскычын хәләл көче белән үткән Фатих әдәбиятка, шигърияткә нык тартыла. Ул күп укый, өйрәнә. Вакытына күрә ярыйсы гына урыс телен үзләштерүе приказчик булып торганда һәм календарьлар төзегәндә файда бирә. Ягъни, заманында интеллектуаль сыйфатларга ия шәхес һәм әдип дәрәҗәсенә ирешә. Ж. Вәлиди бу хакта менә ничек яза: «Ф. Халиди үзенең табигате белән әдәбият вә шигырь кешесе иде. Замана һәм мохитенә күрә сүзгә оста, тапкыр һәм мәзәкчән вә шуның белән бергә гали табигатьле «дөньясына исе китми торган» бер кеше иде» *(Ж. Вәлиди. Ф. Халиди. «Безнең байрак.»—1923, 10 апрель).* Бу фикерне язучының туганнан туган энесе, СССРның халык артисты Фуат Халитов истәлеге дә дәлилли. Ул гына түгел, Ф. Халитов аның әле беркемгә дә билгеле булмаган ягы—җырга, моңга гашыйк булуы һәм музыка уен коралларында оста уйнавына игътибар итә. Истәлек авторы Ф. Халидинең йөз-кыяфәтен, хезмәт сөючән ир-егет булуын түбәндәгечә сурәтли: «Фатих Халиди искиткеч гаҗәп кеше иде. Уртача буйлы, бик ябык та һәм кирәгеннән артык таза да түгел. Кыска гына итеп алынган чал чәчләр, кыска сакал һәм мыек, янып торучы кара күзләр, металлдан эшләнгән түгәрәк күзлек. Киемнәрен еш алыштырмый иде. Аны һәрвакыттагыча, җәен һәм кышын коңгырт кара төстәге сюртуктан, крахмалланган зәңгәр якадан, манжеттан күрергә мөмкин. Кыска юан бармаклар аның хезмәт кешесе булуын сөйлиләр. Ә Фатих абыйның ничек моңлы итеп мандолинада уйнавын мин бирелеп тыңлый идем. Ул татар халык көйләрен шундый моңлы уйный иде, аларның күбесен мин беренче тапкыр аның башкаруында ишеттем [...] Дөрес, Ф. Халиди күп вакытын язып үткәрде. Шигырьләр һәм хикәяләр язды, җырлар һәм пьесалар иҗат итте. Гомумән, Фатих абый иҗатына бик сак вә җаваплы карый иде». *(Истәлек Чаллыда яшәүче туганы Радик Халитовта саклана.)* Истәлектә Ф. Халитов, әдипне татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле Каюм Насыйрига якын тору нәтиҗәсендә реалистик әдәбиятка йөз белән борылды дип язса, Хәсәнгата Таһир исә, Ф. Халиди К. Насыйрига кардәш дип күрсәтә. Бу хакыйкатьтә раслана да кебек. Әдип гомере буенча К. Насыйрилар башлаган юлга тугрылыклы калып, Урта гасыр шәрык әдәбияты стилендә хикәятләр яза, тәрҗемә белән шөгыльләнә.


XX йөз башы сәяси күтәрелеше һәм иҗтимагый фикер үсешен Ф. Халиди аңлап бетерә алмый, күрәсең, бәлкем башка сәбәпләр дә булгандыр, 1912 елгы календаре басылып чыкканнан соң әдипнең иҗаты һәм тормыш биографиясенә караган материаллар сакланып калмаган дип әйтерлек. Әмма бу әле язучы иҗаттан туктаган дигән сүз түгел. Мәсәлән, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар һәм текстология мирасханәсендә 1921 елда басмага тәкъдим ителгән «XVIII гасырда Бохараның кыскача әхвале» исеме астында язучының бер кульязмасы саклана. Аны институтны оештыручылардан берсе Вәли ага Хаҗиев тапшыра. Х. Таһир 1920 елда Казанда булган көчле янгын вакытында язучы иҗатының күп өлеше юкка чыгуына басым ясый. Ул: «Садыйк Иманколый күрсәтүе буенча югарыда саналган (матбугатта басылып чыкканнардан тыш—З. М.) әсәрләреннән башка тагы «Гашыйк хәле бик яман», «Ишек кагучы Мирза *(«Рәдде бичара кыз»дагы Мирза түгел—Х. Таһир искәрмәсе)*, «Мәгърифә карчык» һ. б. әсәрләре дә булган имеш. 1920 елгы мәшһүр янгында бөтен әсәрләре янып тәләф *(әрәм-шәрәм—З. М.)*

булганлыктан ул әсәрләре хакында бернәрсә дә белмәдек»,—дип язды. Шунда ук календарьда һәм китап рәвешендә дөнья күргән шәрык стилендәге хикәятләреннән башка тагы 11 исемдә хикәяте барлыгын әйтеп уза. Монда икенче сәбәпне дә искә алырга кирәк. Ф. Халитов истәлегеннән күренгәнчә, Ф. Халидинең иҗат мирасы, балалары булмау сәбәпле, төрле кулларга күчеп таралып бетәргә дә мөмкин. В. Хаҗиев әле 20-25 еллар элек әдипнең кульязмаларын һәм тормышына кагылышлы материалларны табарга мөмкин иде дип уфтануын белдерде.

Шул рәвешле, мәгърифәтче язучы 11 исемдә 18 китап калдырып, 1920 елгы янгыннан соң, Яңа Бистәнең Кече Ямаш (хәзерге М. Гафури) урамындагы йортка күчеп, тормышын шактый фәкыйрьлектә үткәреп, 1923 елның 7 апрелендә вафат була. Кабере Яңа Бистә зиратында.

* * *

XIX йөзнең икенче яртысы—татар әдәбияты тарихында яңа әдәби жанрларның туу һәм үсү чоры. Бу елларда Урта гасыр Шәрык әдәбиятының үзенчәлекле әсәрләре белән янәшәдә татар реалистик әдәбияты беренче адымнарын ясый. Мәсәлән, 1886 елда М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин мелла» повесте, 1887 елда З. Бигиевнең «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» романы дөнья күрә. Драматургия жанрында да тәүге адымнар ясала. Г. Ильясиның «Бичара кыз» пьесасы 1887 елда нәшер ителсә, аңа җавап йөзеннән Ф. Халидинең 1888 елда «Рәдде бичара кыз» драма әсәре басыла. Милли драмалар саналган ике пьеса XIX йөзнең 90 елларында каршылыклы тыюларга карамастан, татар зыялыларының йортларында еш уйналган. Хәтта шәһәр яшьләре Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» әсәрен сәхнәгә кую өчен рөхсәт сорап цензорга үтенеч җибәрәләр. Рус зыялылары бу хәбәрне хуплап каршы алалар һәм «Волжский вестник» гәзитәсендә түбәндәге мәгълүмат урнаштыралар: «Шәһәрнең татарлар яши торган өлешендә озын колаклардан татарча спектакль куелачагы турында хәбәр таралды. Бу хәбәр бераздан «Казанский телеграф» гәзитәсендә дә басылган иде. Ул хәзер дөрескә чыга башлады. Безгә хәбәр итүләренә караганда, инде тиешле үтенеч тә җибәрелгән һәм, әгәр рөхсәт ителсә, татарча спектакль һөнәрчеләр клубында, ярлыларга ярдәм максаты белән, мөселманнар бәйрәме Ураза гаете көнендә куелачак икән [...] Хәзергә яшь мөселманнарга Казанда моңарчы күрелмәгән башлангычларына зур уңышлар телик. Куелачак әсәр «Рәдде бичара кыз» пьесасы икән. Казанлылар алга китә». Ләкин 1899 елда бу мөмкин эш булмый әле. Шулай итеп, зур өметләр баглаган тарихи вакыйга тормышка ашмый кала—патша власте аны тыя.



*Ф. Халиди. Гәүһәр шаһ турында хикәят. (КДУ китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә «1418 (т)» шифры белән саклана. 14 кәгазьдән тора.)*

XX йөз башында татар драматургиясен баетуда күп көчләрен куйган Г. Камал, Г. Исхакый, С. Рәмиев, Ф. Әмирхан һ. б. каләм тибрәтүче яшь буын вәкилләре татар рухын, милли психологиясен, аның аһәңен эченә сыйдырган драма әсәрләрен биреп, әдәби мохитта әһәмиятле роль уйнаган бу жанрны яңа баскычка күтәрделәр. Алар белән бергә Ф. Халиди дә яңа инкыйлаб күтәрелеше елларында бер-бер артлы «Морад Сәлимов» (1905), «Мәхрүсә ханым» (1906), «Саран, надан Теллә бай хикәяте» (1906), «Залим ачлык, яхуд испанияле Сәед Яхъя бәянында» (1906) пьесаларын язып бастыра.

Күп кенә мәгърифәтче язучылардагы кебек, драматургның алдарак саналып үткән әсәрләрендә дә, мәгърифәтчелек идеяләре Урта гасыр әдәби традицияләре һәм Европа тибындагы реалистик әдәбиятта гәүдәләнеш алган югары әхлакый тәрбия—персонажның акылы, зирәклеге, белем дәрәҗәсе белән янәшә куела. Тәрбиянең

урыны кешенең ан үсешенә бәйле итеп карала. Бу принцип Ф. Халиди иҗатының төп идея-тематик сызыгын барлыкка китерә. Нәтиҗәдә, чишелеш укыган, белемле, дини-әхлакый һәм дөньяви тәрбия алган унай образ файдасына хәл ителә. Шуларга өстәп, кешенең күркәмлеге, чибәрлеге, үз-үзен тотышы да язучы иҗатында әһәмиятле роль уйный. Болар аның драмаларында тәгәл үтәлә.

XX йөз башы һәм Октябрь инкыйлабыннан соң драматургның «Морад Сәлимов», «Мәхрүсә ханым» пьесаларына биргән бәһаләрдә кайбер тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре төрек әдәбияты тәэсире барлыгын яздылар. Соңгы тикшеренүләр күрсәткәнчә, чыннан да, аның аталган ике әсәрендә төрек сентименталь прозасына хас күренешләрнең өстенлек алуы моңа дәлил була ала. Шулай да, мәгълүм пьесалардагы персонажларның бирелешен, җирле традицияләр, заман проблемалары яңгырашын исәпкә алсак, аларны иҗади әсәр итеп карарга мөмкинчелек бар.

Урта гасыр шәрык әдәби әсәрләрендә гәүдәләнеш алган мәгърифәтчелек идеяләрен, сюжет төзелешен «Залим ачлык» драма әсәрендә дә очратырга була. Әдәбият галиме Азат Әхмәдуллин әсәр нигезендә Урта гасыр фарсы прозасы тәэсире барлыгын дәлилләү йөзеннән «Сәед Яхьяның король каршында хөкем тотуы «Бәхтиярнамә» повестендәге поэтик төзелешне искә төшерә»—дип язды *(А. Әхмәдуллин. Дөреслеккә ирешү юлында. Казан, 1993.)*. Шуңа карамастан, әдип, XX йөз башы тарихи вакыйгаларын, иҗтимагый процессны күз алдында тотып иҗат итә һәм татар драматургиясендә, беренчеләрдән булып, тарихи драма жанрына нигез сала. А. Әхмәдуллин бу жанрның тууын «беренче карлыгач» дип атый.

«Саран, надан Теллә бай хикәяте» драматург иҗатында чагыштырмача дәрәҗәдә үзенчәлекле әсәр. Исеменнән үк күренгәнчә, әсәр җиңелрәк, комедия рухында язылган. Ул ачыктан-ачык заманның тискәре сыйфатларын тәнкыйть утына тота, әдипнең каләме сатира юнәлешендә эшли башлый. Әсәрдә реаль тормыш сурәтләнүе дә үзенә җәлеп итә. Ягъни, А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә «мәгърифәтчелек реализм драматургиясендә тематик төрлелеккә омтылыш чаткыларын да күрергә була».

Дөрес, бүгенге күзлектән караганда, әдәби эшләнешләре ягыннан бу әсәрләрнең сюжет төзелеше шактый көпшәк. Характерлар тулылыгы, геройларның эш-гамәлләрен психологик нигезләү, мотивлаштыру, конфликтларның логик чишелеше түбән. Персонажларның образ буларак ачылуы, тулылануы, формалашуы башлангыч хәлдә генә. Алар күпчелек очракларда авторның хикәяләве, сөйләп бирүе аша гына тормышка ашырыла.

* * *

XIX йөзнең икенче яртысы—XX йөз башында әдәби тәрҗемәләр башлыча төрек әдәбиятыннан алына. Мәсәлән, «Тутыйнамә», «Кабуснамә», «Әбүгалисина», «Гөлрөх вә Кәмәрҗан», «Кырык вәзир», «Мең дә бер кичә» кебек мәгълүм әсәрләр татар теленә төрекчәдән тәрҗемә ителә. Бу эшкә, беренчеләрдән булып, татар мәгърифәтчеләре К. Насыйри, Г. Фәезханов, Ш. Рәхмәтуллин, Ф. Халиди керешә. Башкарылган уңышлы тәрҗемәләр укучының игътибарын җәлеп итеп кенә калмый, рус ориенталистларының да, бигрәк тә, Н. Катановның унай бәясен ала.

Ф. Халиди XIX йөзнең 90 елларында Шәрык әдәбиятының әхлакый, дини-дидактик әсәрләрен татар теленә төрекчәдән тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Алар арасында иң күренеклесе, Урта гасыр Шәрык әдәбиятының классик үрнәге «Мең дә бер кичә» әсәренең китап рәвешендә тулы килеш тәрҗемәсе булды. Ул аны төрек мәгърифәтчесе Закир Әхмәд Назыйр тәрҗемәсеннән ала. Х. Миңнегулов: «... татарча һәм төрекчә текстлар күләм һәм эчтәлек ягыннан үзара бер-берсенә якын. Ф. Халиди «кичә»ләргә бүленештә, хикәятләр урнаштырылышында Истанбул басмасындагы эзлеклелекне, системаны саклый»,—дип язды. Н. Катанов та тәрҗемәгә югары бәясен бирә. Бигрәк тә ул эчтәлекнең камил эшләнүенә игътибар итә. Димәк, тәрҗемәче «Мең дә бер кичә»нең төрекчә тәрҗемәсенә шактый төгәллек белән якын килгән, шәрык рухын, аның музыкаль аһәңен, милли яңгырашын ачык сиземләгән. Язучы «Мең дә бер кичә»не турыдан-туры төрек теленнән тәрҗемә итсә дә, аның 1896 елда дөнья күргән «Җиһанабад падишаһның угыллары кыйссасы» һәм 1897 елда басылган

«Болгарның солтан Гадел Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе» хикәяләре ижади әсәрләр. XX йөз башында да бу игелекле хезмәтен дәвам итеп, әдип Шәрык әдәбиятында киң таралган сюжет—Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтенә багышланган «Мәшһүр гашыйк—мәгъшук Ләйлә вә Мәҗнүн хикәясе»н 1902 елда Казанда бастыра. 1904 елда «Кемгә тиеш?» хикәятен нәшер итә.

Татар халкына борынгыдан «Ләйлә һәм Мәҗнүн» дастан варианты билгеле *(Татар халык иҗаты. Дастаннар.—Казан, 1984).* Дастан һәм Ф. Халиди иҗат иткән әсәрләр бер-берсенә нык охшашлар. Шулай ук Казан дәүләт университетының сирәк китаплар бүлегендә сакланган «Ләйлә һәм Мәҗнүн» төрек поэмасында да күп кенә газәлләр туры килә.

Гомумән, әдип XIX гасырның ахыры—XX йөз башында иҗат иткән тәрҗемә һәм ижади әсәрләрендә явызлыкны күрсәтүне максатка яраштлы тапмый, бәлки әхлак, зирәклек, акыл, аң-белемне беренче урынга куя. Ул шушы тенденцияләрне раслау өчен Урта гасыр әдәби традицияләрен үзенең идея-эстетик карашларына буйсындырып, югарыда атап үткән хикәятләрен ижади эшкәртеп укучыга ирештерә.

Урта гасыр шәрык хикәятләрендә гуманизм өскә чыкса да, бозыклык, явызлык—акылга, аң-белемгә, зирәклеккә кискен каршы куела. Ф. Халиди бу принципны сакламыйча, хикәятләрендә явызлыкны бик аз дәрәҗәдә генә тасвирлый. Аның әсәрләре шуның белән әһәмиятле дә.

Шул рәвешле, язучы, тәрҗемәче XIX йөзнең 90 елларында татар мәдәниятына Урта гасыр әдәби традицияләрен, гуманистик идеяләрен житкерү йөзеннән Шәрык әдәбиятының күренекле әсәрләрен төрекчәдән тәрҗемә итә һәм заманында алар югары бәһа ала. Мәсәлән, «Мең дә бер кичә»дән төрле хикәятләрне туплап китап рәвешендә 1907—1915 елларда кат-кат басылуын, атаклы «Ләйлә вә Мәҗнүн» хикәятенең 1908 елда кабат нәшер ителүен атап күрсәтү дә житә. Димәк, башка мәгърифәтче язучыларныкы кебек Ф. Халиди тәрҗемәләре дә популяр булган, укучы тарафыннан яратып кабул ителгән.

* * *


Ф. Халиди 1893 елдан башлап календарьлар төзеп бастыра башлый. Ләкин аларның күбесе сакланмаган. Безгә бары Н. Катановның «Деятель» журналында әдип төзегән 1896/97 ел өчен календарьга кыска гына күзәтүе барлыгы билгеле. Атап үткән календарьдан тыш бүгенге көндә язучының КДУ һәм ТӘҺСИ китапханәләрендә 1899 елга 25 еллык адреслы календаре, 1900, 1901, 1902, 1903, 1904, 1905, 1906, 1907, 1911, 1912 еллар өчен төзелгән кульязма һәм басма календарьлары сакланып калган.

Әдипнең календарьлары, башлыча, кульязма рәвешендә КДУның сирәк китаплар бүлегендә урын алган. Аларга беренче фәнни тасвирламаны күренекле археограф Альберт Фәтхи ясый *(*А. Фәтхи. *Кульязмалар тасвирламасы. V чыгарылыш. Казан: Казан универ. нәшрияты., 1960, 62 б.).* Ул әдипнең кульязма мирасын «Шәмсетдин Хөсәенов вәрәсәсе»исемле китап кибете (китап бастыру һәм сату белән шөгыльләнүче фирма) мирасханәсеннән 1936 елда Г. Кәтиев тарафыннан тапшырылуын күрсәтә.

Ф. Халидинең басылган бер генә әдәби әсәре дә, календарьлары кебек, цензор «чистартуларына» дучар ителмиләр. Календарьда бу күренеш күбрәк тарихи хезмәтләрне чагылдырган урыннарга яисә татар халкының аң-белемгә омтылышын тасвирлаган материалларга кагыла. 1902 елгы календарьда Казан тарихын сурәтләгән материалда цензор В. Д. Смирновның кызыл кара белән сызганы ике урында очрый. Мәсәлән, 7 май битендә: «Олуг кенәз Василий Темныйның гаскәрләренә харап идеп гаскәрләрне таратып, соңра»... җөмләсе һәм 11 май битендә: ... «Әмма руслар Казан шәһәрене әүвәл чолгап алган көнне шәһәр мөселман гаскәрләре чыгып, Мәскәү гаскәрене күп харап итте»... өзеге Смирновның ачуын кабарта. XIX йөздә татар халкының уянуы, милләт буларак формалашуы, мәгърифәткә омтылуына караган материал 1904 елның 27 июль—1 август битләрендә юкка чыгарыла. Моңа охшаш мисаллар цензор өчен җибәрелгән кульязма календарьларда еш кабатлана.

XIX йөз ахыры—XX йөз башы календарьларына хас традицион алымнардан башка (төрле мәгълүматлар, таблицалар, кинәшләр һ. б) төп өч юнәлеш бер-берсен тулыландырып, үрелеп бара. Алар әдәби һәм фольклор чыганаклары, татар халкы тарихына караган материаллардан торалар.

**1. Тарихи чыганакларны тасвирлау.** Язучы 1900 елгы календаренда татар тарихына караган материаллар (риваятьләр, легендалар, фактик чыганаклар һ. б.) җыюы хакында 15 тапкыр игълан бастыра. Бу хәбәр шуннан соңгы елларда күренми. Моның сәбәбе дә булгандыр, күрәсең. XX йөз башында басылган «Мен дә бер сәхәр» әсәре һәм кайсыбер драмаларында («Залим ачлык»... тарихи драмасы) тарихи риваятьләрне файдалануын шактый очратабыз. Болар авторны нык кызыксындырган Болгар һәм Казан ханлыгы чорына караган чыганакларга карый. Гаҗәп түгел: Ф. Халидигә кадәр яшәгән һәм иҗат иткән татар тарихчылары һәм язучылары Хисаметдин Мөслими, Таҗетдин Ялчыгол, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Әмирханов һ. б. кульъязма яисә басма хезмәтләрендә мәгълүм чорны чагылдырган материалларда тарихилыктан ерак торган информацияләр еш кабатланыгага да бәйле. Икенчедән, Явыз Иван Казанны 1552 елның 2(15) октябрендә басып алганнан соң, чын тарихи документларның юкка чыгуы сәбәпле, татар халкының үткәне караңгылык пәрдәсе артында калуын да истән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, 1899 елгы календарендагы «Казан шәһәре әхвалләре» бүлегендә 1552 елгы вакыйгадан соң, 1708 елда булган әһәмиятле чыганакны күрсәтү белән башлый. 1902 елгы календарьда да шул ук хәл кабатлана.



*Ф. Халиди. Календарь. 1906 ел өчен. (Кульъязма КДУ китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә «1451 (т)» шифры белән саклана. 186 кәгазьдән тора.)*

Календарьда басылган «Тәварихе Болгария һәм бик мөгътәбәр китаплардан күчерелгән» исеме астында (86—129 битләр) басылган материал татар халкының үткән тарихында тирән эз калдырган Болгар һәм Алтын Урда дәүләтенә караган Шәрык галимнәренең хезмәтләрен өйрәнеп язган Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар»... китабыннан татар тарихы өчен кызыклы урыннарны алып укучыга тәкъдим итә.

Ф. Халиди тәрҗемәләренә, календарьларына һәрвакытта игътибарлы Н. Катанов, Ш. Мәрҗани хезмәтләре белән таныш булмагандыр, күрәсең, әдип Болгар тарихын шәрык язучыларының хезмәтләренә нигезләнеп язган дип, аңа язучы һәм галим дәрәҗәсен беркетә. Моңа сәбәпләр дә бар, әлбәттә. Чөнки, 1902 елгы календаренда «Казанның үткәне һәм бүгенгесе» исеме астында басылган материалны Катанов рус теленә тәрҗемә итеп «Прошлое и настоящее Казани по одному татарскому рассказу» исеме белән 1904 елда «Деятель» журналында бастырып чыгара.

**2. Календарьларда хикәятләр.** Ф. Халиди татар әдәбияты тарихында беренчеләрдән драма әсәре бастыручы гына түгел, ә бәлки дивари календарьлар төзүдә тәүге адым ясаучы да, һәм үз остазларыннан аермалы буларак, әхлакый эчтәлектәге хикәятләр нәшер итүче дә. Әмма галимнәр тарафыннан язучының бу яңалыгы күрелмәде дә, танылмады да. Дөрес, заманында Н. Катанов 1902—1904 елларда басылган календарьларга күзәтү ясаган мәкаләсендә, әдипнең тәкъдим иткән хикәятләрен атап, кыскача эчтәлеге белән таныштырып бара.

Хикәятләрнең характер үзенчәлекләре төрле. Кысалы кыйссалар, күбесенчә, маҗаралы мәхәббәт темасын яктыртып, аларда әхлакый, дини-дидактик тәрбия проблемасы алгы планга куелса, нәсыйхәт, васыятьнамәләрдә исә һөнәрле булу, әдәплелек, татар халкының рухына туры килмәгән яман гадәтләр, аеруча, шәраб эчү, тәмәке тартуга мөнәсәбәт белдерелә. Беренчесе, күләме ягыннан шактый озын, ә икенчесе 1-2 биттән артмый.

Хикәятләрнең традицион башламында төп образларны Көнчыгышның күренекле дәүләт җитәкчеләре һәм хәкимнәре алып тора. Бу Ф. Халиди иҗатында Урта гасыр традициясенең дәвам итүенә бер мисал була ала. Шулай ук «Коръән»дә

тасвирланган акыллылык, зирәклек символына әйләнгән Локман хәким образы да еш искә алына. Конкрет шәхесләр арасында Һарун әр-Рәшид, Өммияһ, Габбас хәлифә һ. б. күренсә, хәкимнәрдән Аристотель, Сократ исемнәре белән очрашырга мөмкин. Шулай ук Борынгы Македониянең бөек яулап алучысы Искәндәр Зөлкарнәйнгә караган сюжетлар 1900 һәм 1902 елгы календарьда бәян ителә. Инде 1906 елгы кулъязма календарьда тасвирланган хикәятнең башламында Екатерина II исемен телгә ала. Әмма традицион башламда төп рольне Көнчыгышның танылган шәхесләре һәм Борынгы грек философлары уйный.

**3. Мәкальләр.** XIX йөзнең ахыры—XX йөз башында К. Насыйри, Г. Фәезханов, Ш. Рәхмәтуллин, Ф. Халиди кебек мәгърифәтче язучылар тарафыннан төзелгән календарьларда халык авыз иҗаты үрнәкләреннән берсе—мәкальләргә дә зур урын бирелә. Аларда борынгылык белән янәшә дә шул заманның рухы, җаны салынган. Бу тенденция Ф. Халиди календарьларында да сизелә... Мәсәлән, 1900 елгы календарьда автор башта хикәят сөйли, ахырдан хикмәткә туры китереп мәкаль урнаштыра. Киресенчә булу ихтималы да бар. Шул ук елның 3-8 февраль битләрендә элек хикәят тәкъдим итә, соңыннан хикәятнең эчтәлегенә якын булган «Тозсыз сүздән тозлы ботка тәмлерәк» дигән мәкаль бирә.

Кешенең белемен, акылын, зирәклеген чагылдырган мәкальләр белән дә календарьда очрашырга мөмкин. Мәсәлән, «Надан кеше тереклек итәр өчен ашар», «Кешенең гакылына сүзе дәлилдер», «Олугларга мәрхәмәт кылсаң, кечекләр сиңа хөрмәт кылыр» һ. б.

**4. Сынамышлар.** Календарьларның дөньяга килүе һәм таралуы табигать серләрен ачарга тырышу белән бәйле. Халык арасында киң таралган сынамышлар төрле ырым-ышануларда табигать могҗизаларын, сәер күренешләрен белергә омтылудан туганнар.

Ф. Халиди бер төркем сынамышларны татар халкы арасында популяр булган төрек әсәре «Мәлхәмә»дән алып, 1900 һәм 1903 елгы календарьларында урнаштыра. 1901 ел өчен төзелгән кулъязма календарьда җирле шартларны, географик үзенчәлекләрне эченә алган сынамышларны тәкъдим итә. Мәсәлән, «Эш эшләп ватылган кеше сызланса, һава бозылыр», «Картлар авыраеп, җилкә яки билләре сызланса, һава бозылыр», «Әгәр карга ябыгып килсә, ашлык уңар», «Кара карга килгәч, бер айдан кар китәр» һ. б.

Кыскасы, мәгърифәтче язучының татар мәдәнияты тарихында беренче булып дивари календарьлар чыгара башлавы һәм аларның К. Насыйри, Г. Фәезханов, Ш. Рәхмәтуллин календарьларыннан аермалы буларак, татар халкын тарихи чыганаклар белән таныштырырга омтылуы күзгә ташлана. Икенче яңалыкны да билгеләп үтү кирәк: сынамышлар, ырым-ышанулар, мәкальләр һәм тулы мәгънәсендә вәгазь, нәсыйхәт, васыять, кысалы кыйссалар формасын алган хикәятләрне нәшер итү календарьга әдәби юнәлеш бирә. Н. Катанов сүзләре белән әйтсәк: «Халидовские календари предназначаются главным образом для чтения и назидания хорошими примерами». Ф. Халиди башлаган традицияне шул заманның башка календарьчылары—Имаметдин бине Шәрифҗан, Мөхәммәтгалим Әхмәдуллиннар дәвам итәләр.

Шул рәвешле, XIX йөз ахыры—XX йөз башы татар әдәбияты тарихында сизелерлек эз калдырган күренекле мәгърифәтче язучы Ф. Халиди бөтен иҗат гомерендә Урта гасыр Шәрык әдәбиятының гуманистик идеяләрен һәм әдәби традицияләрен генә кабатлап калмыйча, җирле мәдәни, фәнни, әдәби алымнарны да уңышлы файдалана, шуның белән ул Урта гасырлар тибындагы әдәбият белән татар реалистик әдәбиятын тоташтыручы күперне салуга үз өлешен кертә.

**Зөфәр МӨХӘММӘТШИН**

# *Xəsən Tufannıņ tuuına 100 yıl*

## Xəsən Tufan

### TƏRLE YILLARDAN ŞİĞERLƏR

### Ak qayın

Yafraqları yəşel aq qayınğa
Yul buyınnan aqlar kildelər,
Aq qayınnıņ yarlı awıldaşın
Bilbawına asıp kittelər.

Asuçılar kitkəç, sorıy qayın:
—Awırtmıymı muyınıņ, Xəybulla?
—Awırtuğa tüzər idem, qayın,
Tın aluı bigrək awır la.

Bılbaw qısa, qayın, sulışqaynı,
Buşatsana şuşı bilbawnı!
—Buşatır da idem bilbawıņnı,
Min qayında andıy qul barmı?

—Bəgelsənə, qayın, ielsənə,
Ayaqlarım cirgə timəsme?

—Bəgeler idem, buyım qatı minem,
Ütər xəl yuq sineņ kiņəşne.

—Səlam tapşır, qayın,—dide yeget,
Tınıp qaldı şunda annarı...
Ber endəşte qayın, əç endəşte,
Bütən ber süz işetə almadı.

Yafraqları qoyıla aq qayınnıņ,
Yafraqları qoyıla yəş kebek.
Əle bulsa tirbələder təsle
Şul qayınğa asqan yəş yeget.

Əytsəgez lə şuşı aq qayınğa:
—Yılama sin, qayın, appağım,
Kiņ qırlarda üze genə tügel,
Eze də yuq inde yatlarnıņ.

*1933*

### Awırğan minutlarda

Əytkən ideņ, yərək:
Az diməsəņ,
Yəzgə citü minem niətem...
Yuq, anda uq citep bulmastır şul,
Aqsıy-tuqsıy ğəmer itəseņ.

Yazmış, axrı,
Ğəmer gəllərenə
Şaqtıy irtə qıraw təşerde:
Yıraq əle qışqa, ə sarğaydım
Yəşen suqqan usaq şikelle.

Yıraq əle qışqa,
Sibelə ləkin,
Sibelə yafraq, sibelə cil sayın...
Awarğa da inde cil cayına
Həm yoqlarğa məmkin, məğayın?

Kiņəş birə yəp-yəş sabıy irtə:
—Yat əle, yat, Xəsən abıy,—di.
Bulmıy, bulmıy: küzne yomdım isə,
Təşkə kerə Nazon Ovidiy.

Yatsam da min əndə ayu kebek,
Tınıp bulmıy ləkin, iptəşlər;
Təşkə kerə barıber Nazıym Xikmət,
Təşkə kerə Gertsen-İskəndər![1]

*1942*

[1] İ s k ə n d ə r — Gertsennıņ psevdonimı.

## İldə nilər bar ikən?

Tışta nilər bar ikən:
Yullar zəngər qar mikən?
Boz tərəzə alsulana,
Pojar mikən, tan̡ mikən?
Tışta nilər bar ikən?

Bezdə də tan̡ tuğandır,
İnde ul da torğandır,
Bergə çaqlar isenə təşep,
Kün̡elləre tulğandır...
Bezdə də tan̡ tuğandır.

Uylıydır ul: «Saw mikən?
Eçe tulı zar mikən?
Xəsrətləren taratırğa
Təməkese bar mikən?
İsən mikən, saw mikən?»

Aqlı kiemen kigənder,
Bəlki, qaytır, digənder,
Zən̡gər qarnı yıra-yıra
Vokzallarğa kilgənder...
Bəlki, tabılır, digənder...

İldə nilər bar ikən:
Yullar zən̡gər qar mikən?
Hawadağı alsu şəwlə
Pojar mikən, tan̡ mikən?
İldə nilər bar ikən?

*1944*

## Ağıla da bolıt ağıla...

Ağıla da bolıt ağıla
Tuğan-üskən cirlər yağına;
Tərəzəgə çirter də yan̡ğır,
Nərsə əyter tuğannarıma?!
Ağıla da bolıt ağıla...

Nərsə əytsen: berni belmi ul,
Xəbəre yuq minem yərəktən.
Mine barı çılatıp ütte
Kukuruzlar belən berrəttən...
Nərsə əytsen: berni belmi ul.

Roman kebek kün̡elle sin, yul!
Azmı sində ğemer uzdırdım,
Niçə kiem çabata sində,
Niçə kiem itek tuzdırdım!
Roman kebek kün̡elle sin, yul!

Ə sin, yan̡ğır, iskə təşermə
İtegemnen̡ niçek ikənen...
Yalanayaq kildem dənyağa,
Şulay ğına, bəlki, kitərmen,
Ə sin, yan̡ğır, iskə təşermə!

Zirat bit ul sabantuy tügel,
Nigə anda kienep kitərgə?
Bu dənyanın̡ ber par itegen
Nigə yuqqa ərəm itərgə?
Zirat bit ul sabantuy tügel.

Ağıla da bolıt ağıla
Tawlar aşa Qazan yağına;
Tərəzəgə çirter də yan̡ğır,
Nərsə əyter tuğannarıma?!
... Ağıla da bolıt ağıla...

*1951*

## Kaysığıznın̡ qulı cılı?

Dənya mine
Üzgərtte:
Yılamasqa əyrətte.
Külmək cin̡en yırtasımı? —
Bəylise bar
Yərəkne.

Suğışlardan zamana
Tuqtap torğan arada,
Yaralarnı yamaştırıp
Yata idem
Dalada:

—Qayt!..—dip xatlar kildelər...
Yullar... ozın idelər...
Qayttım.
—Busı alqaları,
Busı—qəbere...—didelər.

Əgər tağın kilsələr:
—Saw!—dip xəbər birsələr,
Vulkannarğa kerer idem,
Şundadır ul... disələr.

Birde dənya kirəkne,
Yılamasqa əyrətte...
Qaysığıznıņ qulı cılı? -
Bəylise bar yərəkne...

*1956*

## Baqçalarğa nilər bulğan?

*Fərida Kudaşevağa*

Baqçalarğa nilər bulğan:
Sanduğaçlar sayramıy?..
Bu Qazannıņ şuşı yağı
Yərəgemə yaramıy.

Sayramıy la sanduğaçlar
Ni qayında, ni talda:
Ufalarğa kitkən alar,
Ufalarda sez barğa.

Şundadır şul sanduğaçlar,
Seznen tirədəder şul;
Seznen cırnı bezdən elek
Şular əyrənəder şul...

Beznen xəlne sorasağız,
Beznen xəllər «Uf!» inde:
Sez kitkənnən birle bezdə
Sanduğaçlar yuq inde.

Xalıq əytə:
—Baqçalarnı
Xarap itte şul ğına!
—Nişləp beznen Qazan,—
dilər,—
Çara kürmi soņ moņa?

Sayramıy la sanduğaçlar
Ni qayında, ni talda:
Ufalarğa kitkən alar,
Ufalarda sez barğa.

*1959*

# 2000 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

2000 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү турында. № 6
Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча дәүләт комиссиясе турында Россия Федерациясе хөкүмәте Карары. № 3

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Фәйзуллин Р. Китап гасыры китәме? № 1

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ахунов Г. Көз нурым. *Хастаханә көндәлеге*. № 2
Баян Ә. Хәтер дәрьясында. *Парчалар*. № 12
Галиева Г. Тулгак. *Повесть*. № 7
Гариф Н. Мин сезнең арада яшәдем. Эссе. № 3
Гариф Н. Ул үлде... Яшәү турында баллада. № 11
Гыйләжев А. Күңелем серләре. *Куен дәфтәрләреннән*. № № 11, 12
Гыймадиев А. *Хикәяләр*. № 10
Имамов В. Утлы дала. *Тарихи роман*. № № 1, 2, 3
Латыйп К. Үр арты үр. *Сугыш хатирәсе*. № 6
Латыйфи Ф. Бәйсез этләрне атарга. *Роман-нәсер*. № 12
Мирхәйдәров Р. Иртәләгән сагыш. *Роман*. № № 8, 9, 10
Сибат Р. Ялгызак. *Моңсу роман*. № № 4, 5
Тимергалин А. Игезәкләр. *Повесть*. № 6
Фәизов Р. Гаделлек иясе. *Хыялый повесть*. № 11
Хәлим А. Казыктагы итальян. *Хикәя*. № 9
Хисмәтулла Р. «Оныкларым, сез бәхетлеме?» *Лирик повесть*. № 4

ШИГЪРИЯТ

Афзал Г. Үз кадерен белгән юлчы. *Шигырьләр*. № 1
Әгъләм М. Хәтер иляре. *Шигырьләр*. № 8
Әхмәт Р. Гомер уртасы. *Шигырьләр. (Р. Гаташның кереш сүзе белән)* № 9
Әхмәтҗан Роб. Шәҗәрәм тирәге. *Шигырьләр*. № 11
Әхмәдиев Н. Сөюебез күптән күккә ашты. *Шигырьләр*. № 12
Баян Ә. Гомерләрдән моң һәм сүз кала. *Шигырьләр*. № 1
Вәлиева Р. Сүнмә әле, өмет йолдызым. *Шигырьләр. (Р. Гаташның кереш сүзе белән)* № 5
Габдерәхим Ф. Татарга да бәйрәм килми калмас. *Шигырьләр*. № 3
Гадел Ә. Күтәрелә безнең күнелләдән ай. *Шигырьләр*. № 7
Галиев Ш. Сулар ага, уйлар ага. *Шигырьләр*. № 12
Гаташ Р. «Жыр—Ике Мең ишеген шакыганда...» *Робагыйлар*. № 1
Гәрәева С. Алмагачтан алма төште... *Шигырьләр*. № 3
Гыйззәтуллина Ф. Шул көннәрдән тәсбих тезәмен. *Шигырьләр*. № 7
Гыйләжев И. Иң зур куаныч. *Шигырьләр*. № 3
Жиһангирова Ш. Дөнья буйлап үтеп барышлый. *Шигырьләр*. № 8
Закиров Р. Мөлдер-мөлдер аһәнмоннар бар. *Шигырьләр*. № 8
Зөлфәт. Бездән калыр—шигъри сүз генә... *Шигырьләр*. № 2
Ибушев Г. Көмеш янгыр, күк чәчәк... *Шигырьләр. (Р. Фәйзуллинның кереш сүзе белән)*. № 5
Иделбикә. Дүртьюллыклар. № 4
Измайлова Н. Мин—ялгызлар илендә. *Шигырьләр*. № 1
Маннап Ш. Моңсу парчалар. *Шигырьләр*. № 4
Мансуров З. Бәгыремдә өннәр бәргәләнә. *Шигырьләр*. № 9
Мингалим Р. Кичер, Аллам! *Шигырьләр*. № 3
Мингалим Р. Котлаулар-багышлаулар. *Шигырьләр*. № 11
Рахман Р. И Кешем! *Шигырьләр*. № 4
Рәхим Г. Татар мадонналары. *Шигырьләр*. № 12
Рәшит Ә. Эзли-эзли ул борынгы эзне... *Шигырьләр*. № 5
Сафина Н. Кеше булып яшәү—язмышым. *Шигырьләр*. № 6
Татар шагыйрьләре—Сәйдәшкә. № 11
Туфан Х. Сүз кушасы килә талларга. *Шигырь*. № 4

Фатыйхов В. Сиртмәле кое чиләге. *Шигырьләр.* № 8
Фәйзуллина М. Кыш бабай. *Шигырьләр.* № 6
Харис Р. Һарут белән Марут. *Поэма.* № 10
Шабаев М. Ярты төн бәйрәме. *Поэма.* № 4
Шәрипов Р. Казан утлары. *Шигырьләр.* № 5
Шәрифуллина Э. Су бирегез! *Шигырьләр.* № 11
Шиһап Р. Мәхәббәт көче. *Шигырьләр.* № 3
Юзеев И. Заман хисләренә кагылам да. *Шигырьләр.* № 2
Янсуар Л. Яфрак ярам, кошка әверелэм... *Шигырьләр.* № 7
Яруллин Ф. Илаһи бер яктылык. *Шигырьләр.* № 6

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Бертольт Брехт. *Шигырьләр. (Л. Шагыйрьҗанның кереш сүзе белән).* № 6
Мицкевич А. Кырым сонетлары. *(Ә. Синугылның кереш сүзе белән).* № 7

ЯҢА ИСЕМНӘР

Әхмәтгалиева А. Соңгы өмет. *Хикәя. (М. Вәлиевнең кереш сүзе белән)* № 2
Гаффарова С. *Хикәяләр. (Ф. Латыйфиның кереш сүзе белән)* № 1
Нурзилә. *Хикәяләр.* № 7

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Әмирхан Ф. Милләт тәрәкъкый иттерү. № 3
Галиев Г. Каракош сыртында. № 7
Толымбай Г. Фамилия ясаучылар. *(Р. Рахманиның кереш сүзе белән)* № 11

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Юзеев И. Эзләдем, таптым, югалттым... *Ике пәрдәле драма.* № 10
Яруллин Ф. Бер көрәшү—үзе бер гомер. *Комедия.* № 1

ПУБЛИЦИСТИКА

Әхмәтҗан А. Ватаннан еракта туган җырлар. № 11
Камалов Б. Үткәннәргә борылып карасам. № 1
Миңнуллин Т. «Бетте көч, сынды кылыч...» № 11
Мостафин Р. Татар Зоргесы. № 10
Сафин Ф. Җаек буе—яу җире. № № 7, 8
Сафина Н. Фидакарьләр вөҗдансыз булмый. № 4
Шәмсетдинов Г. Милли сәясәт һәм милли матбугат. № 6

ҖИҢҮНЕҢ 55 ЕЛЛЫГЫНА

Биктимерова Т. Урман кисте кызлар. № 5
Кәбирова А. Зур өлешебез бар. № 5
Маликов Ә. Хәтер яралары. *Шигырьләр.* № 5
Мәҗитов З. Йөрәк аша узды сугыш. № 3
Мостафин Ш. Батырларыбызны барлар чак. № 5
Надиров И. Искә төшә сугыш еллары. *(Р. Фәйзуллинның кереш сүзе белән)* № 4
Сафаров Р. Әҗәл белән янәшә. № 4

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әхмәдуллин А. Эзләнүләр бәрәкәтлеме? № 8
Вәли-Баржылы М. Ир-ат турында. № 10
Гаташ Р. «Сәфәрләргә чыксаң белерсен...» № 4
Сафиуллин Ю. Сәхнә әсәрләребез нинди? № 2
Сверигин Р. Үткән ел прозасына бер караш. № 7
Сибат Р. Прозабыз Ахуны. № 9
Поэма турында сөйләшәбез. № 9
Хәсәнова Ф. Ренат Харис шигърияте. № 5

БҮГЕНГЕ ӘДӘБИЯТ

Киләчәккә карап *(«Казан утлары» журналы редколлегиясенең киңәйтелгән утырышыннан).* № 1

РЕЦЕНЗИЯЛӘР КОНКУРСЫ

Закирҗанов Ә. Онытырга хакыбыз юк. № 8
Минһаҗева Л. Хаталар да булмаса... №3
Сафина Н. Ил турында «Ил» китабы. № 12
Солтан И. Йөрәк тибеше. № 9
Тимбикова К. Шагыйрәнең хыялында йөрткән китабы. № 6
Шәрәфиев Р. Үткәннәрдән безгә гамьнәр калган. № 5
Шәрәфиев Р. «Безне кемнәр аңлар?» № 7
Шәрипов С. Тәкъдирдән узып булмагач... № 11
Фәттах И. Асылыбызга кайту. № 11
Хатипов Ф. Якты җирлектәге һәлакәт. № 3
Хаҗиева М. «Утырып уйлар уйладым». № 4
Юныс М. Бәхетле мескенлек. № 2

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Бәшир Ф. Онытылган әдип Касыйм Биккол. № 3
Гыйләҗев Т. Тукай һәм Вәлиди. № 4

## ЮБИЛЕЙЛАР

Ф. ХАЛИДИНЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Мөхәммәтшин З. Мәгърифәтче әдипләребездән берсе. №12

З. БИГИЕВНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Миңнегулов Х. Бәхтияр әдип. № 10

Ф. КӘРИМИНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Гайнетдин М. Яңа мәдәниятебезнең «баш конструкторы». № 3

С. РӘМИЕВНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Рәмиев С. Таң вакыты. *Шигырьләр.* № 2

Х. ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Булатова К. Тәнәкә хатлары. *Шигырьләр.* № 9
Вәлиулла И. Мәңгелек бәхет эзеннән. № 11
Зур талант, якты шәхес иде... (*Шагыйрь турында әдипләребез*). № 12
Шабаев М. Аның кулы жылы иде. № 7

С. СӘЙДӘШЕВНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Монасыйпов Ш. Сәйдәшнең сихри моңы. № 12

С. БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Салих Баттал. Туган ягыма. *Шигырьләр.* № 8

Н. ДӘҮЛИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Маннапов Ш. Кайтмый еллар, кайталар жырлар... № 6

С. САБИРОВКА 85 ЯШЬ

Әгъләм М. Үз заманы баласы. № 5

Я. АБДУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Гаффарова Ф. Милләткә хезмәт юлында. № 1

Ә. КӘРИМУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Мәхмүтов Х. Фәнни библиографиябезгә нигез салучы. № 5

М. ХӘСӘНОВКА 70 ЯШЬ

Әхмәдуллин А. Олы галим, күренекле жәмәгать эшлеклесе. № 6

М. ХУЖИНГА 70 ЯШЬ

Зөлфәт. Тыкрыктагы аулак сукмак. № 5
Хужин М. *Хикәяләр.* № 5

В. ЮНЫСКА 70 ЯШЬ

Вәлиев Р. Гомерлек мосафир. № 10
Юныс В. Ибрай абзый «кардиуны». *Әсәрдән өзек.* № 10

Р. ИДИЯТУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Гаташ Р. «Тормыш—хуш исле бер чәчкә...» № 2

Ф. БӘЙРӘМОВАГА 50 ЯШЬ

Вәли-Баржылы М. Әнә шундый йөрәк! № 12

Р. НИЗАМИЕВКА 50 ЯШЬ

Низамиев Р. Ачам еллар дәфтәрен. *Шигырьләр. (М. Шабаевның кереш сүзе белән).* № 2

Р. КОЖЕВНИКОВАГА 50 ЯШЬ

Кожевникова Р. Шагыйрьгә. *Шигырьләр.* № 12

## ФӘН

Әмирхан Р. Чишмәләрдәй чылтыраган ижат. № 9
Вәлиева А. Тел дәрьясының ике ярында. № 9
Вәлиев Р. Туры сүзле баш бирмәс шәхес *(Тарихчы галим Әгъдәс Борһановка 80 яшь).* № 10
Галләмов Р. Татар халкы оешуга яңа караш. № 8
Гарифуллин Д. Тарихи хәтеребез илчесе. № 9
Ибраһимова Л. Дастаннарда—халык язмышы. № 10
Миңнуллин Ж., Мәрданов Р. Мирас бөртекләп жыела. № 9
Нәбиев Р. Монгол яуларына тагын бер караш. № 7
Хәбипова З. «Идегәй» үткән юл. № 1

## ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Мәхмүтов М. Коръән сүзе татар телендә. №№ 5, 6
Мәхмүтов М. Коръәнне тәржемәсез укып буламы? № 7

## КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

1—Фатиха (Ачучы) сүрәсе. № 8
2—Бәкара (Сыер) сүрәсе. № 9
3—Гыймран (Мәрьямнең атасы) сүрәсе. № 10
4—Ниса (Хатыннар) сүрәсе. № 11
5—Маидә (Табын) сүрәсе. № 12

## ХӘТЕР

Әхтәмов Ш. Дәһшәтле көннәрдә. № 7
Зарипов М. Хакыйкатькә юл озын. № 8
Фронт хатлары (*И. Газиның А. Шамовка язган хатлары).* № 11
Хәмидуллин Л. Үз кыйбласын тапкан шәхес. № 3

## СӘНГАТЬ

Бәйрәмова Г. Шагыйрь артист. № 6
Гарифуллин Д. Илһам шәжәрәсе. № 2
Гәрәев М. Балетның шигъри тылсымы. № 3
Минлебаев К. Талант һәм тыйнаклык. № 7

Рәхимова Б. Моннар һәм уйлар. № 1
Тимбикова К. Мәхәббәт—бер генә! № 11
Шәрифуллина Н. Зур ижат балкышлары. № 10

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Арсланова Т. Курай моны кайта. № 3
Маннапов Ш. Язмышларыбыз уртак. № 1
Маннапов Ш. Монга әверелгән гомер. № 7
Фәйзуллин Р. Бөек төркилектә без олуг. № 9
Шәрипов Ә. Игелекле хезмәт. № 2

### ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ АНТОЛОГИЯСЕННӘН

Зәки Ш. Шигырьләр *(Р. Гаташның кереш сүзе белән).* № 10

### МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫ

Галимуллин Фәрит. «Ислам императоры»—Рәшит Казый. № 3

### МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

Батулла Р. Дәүләтле Надир Дәүләт. № 2
Дәүләт Н. Шагыйрь Шаһвәли Келәүли ижаты. № 2

### БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Кәримова Н. Ипи пешердек. *Хикәя.* № 11

### ЮМОР-САТИРА

Маннап Ш. *Мәзәкләр.* № 5
Нәсин А. *Хикәяләр.* № 4

### «КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН

Фәйзуллин Р. «Кемнәр бар да, кемнәр юк!» №2

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Энгель Нигъмәтуллинга 70 яшь . № 11
Заһирә Гомәровага 70 яшь. № 4
Фәрит Хатиповка 70 яшь. № 1
Хәлим Җәләлгә 60 яшь. № 4
Мөхмүт Газизовка 60 яшь. № 2
Мансур Шиһаповка 60 яшь. № 5
Зөфәр Фәтхетдиновка 60 яшь. №11
Камил Кәримовка 50 яшь. № 7

### БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Фатих Халидинең тууына 150 ел. № 12
Халикъ Садриның тууына 110 ел. № 8
Гомәр Галинең тууына 100 ел. № 6
Мәхмүд Максудның тууына 100 ел. № 1
Мөхәммәт Әблиевнең тууына 100 ел. № 8
Гомәр Толымбайның тууына 100 ел. № 4
Хәсән Хәйринең тууына 90 ел. № 2
Җәвад Тәрҗемановның тууына 80 ел. № 7
Әнәс Галиевнең тууына 80 ел. № 4
Әнәс Каринның тууына 80 ел. № 6
Шамил Шаһгалинең тууына 80 ел. № 6
Малик Хәмитовның тууына 70 ел. № 8
Илдус Ахунҗановның тууына 70 ел. № 4
Таһир Нурмөхәммәтовның тууына 70 ел. № 4
Эдуард Касыймовның тууына 70 ел. № 11
Тәүфикъ Камалиевның тууына 60 ел. № 2

### ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Киң колачлы иҗатчы. № 8
Минлебаев К. Шагыйрь җанлы сәнгатькәр. № 2
Шаһиева Р. XVI гасыр ядкаре. № 1
Шаһиева Р. Гүзәллек мәҗнүне. № 3
Шаһиева Р. Казанның җәмигъ мәчете. №12

### УКУЧЫ СҮЗЕ

№ 2, № 3, № 5, № 6, № 8, № 11

### ИМЕШ-МИМЕШ ТҮГЕЛ

Әхмәтов Ш. Мәзәкләр. № 2

### ЯҢА КИТАПЛАР

№ 1, 2, 4, 5, 6, 8, 9, 12

### ЛАТИН ИМЛАСЫНДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

Баттал С. Туган ягыма. *Шигырьләр (Салих Батталның тууына 95 ел).* № 8
Гарифуллин Д. Тарихи хәтеребез илчесе. *(Дамир Шәрәфетдиновка 60 яшь)* № 9
Гаффарова Ф. Милләткә хезмәт юлында. *(Академик Яхъя Абдуллинга 80 яшь).* № 1
Гыйбрәтле тормыш юлы... *(Әнәс Галиевнең тууына 80 ел).* № 4
Киң колачлы әдип вә галим. *(Гомәр Толымбайның тууына 100 ел).* № 4
Рәмиев С. Таң вакыты. *Шигырьләр.* № 2
Татар шагыйрьләре—Сәйдәшкә. № 11
Тәрҗемә остасы. *(Таһир Нурмөхәммәтовның тууына 70 ел).* № 4
Туфан Х. Сүз кушасы килә талларга. *Шигырь.* № 4
Туфан Х. Шигырьләр. №12
Укучыларыбыз иҗаты *(Г. Саттар-Мулилле, И. Кыямов, Р. Нуруллин шигырьләре).* № 1
Укучы сүзе. № 6
Чын әдәбиятчы иде... *(Илдус Ахунҗановның тууына 70 ел).* № 4
Шәрипов Ә. Игелекле хезмәт. № 2

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан №№1—12

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### МАТБУГАТ—2001

Мәскәүдәге Бөтенроссия күргәзмә үзәгендә ачылган «Матбугат—2001» күргәзмәсе кысаларында «Татарстан гаммәви мәгълүмат чаралары бүген һәм иртәгә» дигән экспозицияне тәкъдир итү булды.

Тәкъдир итүдә күргәзмәдә катнашучыларны Татарстан Президенты М. Шәймиев котлавы белән таныштырдылар. Күргәзмәне ачып, оештыру комитеты рәисе М. Ненашев Татарстанның биредә күрсәтелә торган газета һәм журналларына югары бәя бирде. Татарстан матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министры З. Вәлиева Мәскәүдәге матбугат күргәзмәсен милли бәйрәмебез—сабантуй белән чагыштырды, чөнки ул бик күпкырлы, күптөрле һәм күптелле. З. Вәлиева алдагы елларда ин яхшы язмаларга, Россиянен ин яхшы басмаларына бәя бирү өчен бу күргәзмәне конкурс рәвешендә үткәрергә тәкъдим итте.

### ТӨРКЕСТАННЫҢ 1500 ЕЛЛЫК БӘЙРӘМЕНДӘ

20 октябрьдә Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин житәкчелегендәге Татарстан делегациясе Казакъстан Президенты Нурсолтан Назарбаев чакыруы белән Төркестан каласының корылуына 1500 ел тулу тантаналарында катнашты. Делегация составында мәдәният министры Илдус Тарханов, Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, журналыбызның редколлегия әгъзасы Хатыйп Миннегулов, журналистлар, артистлар бар иде.

Татарстан кунаклары шәһәрнең истәлекле урыннары, бөек шагыйрь һәм фикер иясе Әхмәд Ясәви хөрмәтенә куелган корылмалар белән танышты, Казакъстан һәм чит ил вәкилләре белән аралаштылар. Ф. Мөхәммәтшин Ясәви исемендәге казакъ-төрек халыкара университетының актлар залында уздырылган фәнни-гамәли конференциядә Казакъстан һәм Төркия президентлары, ЮНЕСКО вәкиле, Кыргызстан, Әзербайҗан делегацияләре житәкчеләре белән берлектә чыгыш ясады, төрки халыкларының тарихи һәм мәдәни бәйләнешлары, Ясәви ижатының татар рухи тормышындагы роле хакында сөйләде.

### ВАТИКАНДА ОЧРАШУЛАР

26 октябрьдә Ватиканда Казан мэры Камил Исхаков Рим Папасы Иоанн Павел II белән очрашты. Очрашу барышында төп өч мәсьәлә тикшерелде: Казанның меңъеллыгына әзерләнү, Татарстан башкаласында католик кафедраль храмын төзү һәм Казан Изге Алла Анасы иконасын үзенең ватанына кайтару.

Папа Иоанн Павел II храмны төзүгә фатиха бирде. Изге иконаны Казанга кайтару мәсьәләсе белән кызыксынды һәм бу тәкъдимне алга таба тикшерү зарурлыгын күрсәтеп узды. Иоанн Павел II Татарстан делегациясе алып килгән сувенирларны—милли бизәлешле матур халатны, түбәтәйне, «Борынгы Казан», «Ислам диненең жирдәге сәнгате» дигән альбомнарны рәхмәт әйтеп кабул итте.

Шул ук көнне Казаннан килгән кунаклар—Казан мэры Камил Исхаков, Татарстан Президенты янындагы дәүләт киңәшчесе Рафаэль Хәкимов, Татарстанның Россия Федерациясендәге Вәкаләтле вәкиленең беренче урынбасары Михаил Столяров архиепископ, Ватиканның Премьер-министры урынбасары һәм эчке эшләр министры Леонардо Сандри белән очраштылар.

### «ТАТАР ИЛЕ»НДӘ БӘЙРӘМ

1990 елда, милли күтәрелешнең иң кайнар вакытында, Казан киоскларында «Татаринформ» исемле бюллетень пәйда булды. Ул дөньяда сибелеп яшәүче милләттәшләребезнең проблемаларын күтә-рүне, үзара хәбәр алмашуны максат итеп куйды. Ул бүген «Татар иле» һәм «Татарские края» булып чыга. Берләштерелгән редакция 20 октябрь көнне «Идел-пресс» бинасында үзенең 10 еллыгын билгеләп үтте. Газетаның урыс телле басмасы «Татар-Информ» агентлыгының Интернет сәхифәсенә дә кертелде.

### ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫН ИСКӘ АЛУ

30 октябрьдә Камал театрында Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның тууына 75 ел тулуга багышланган «Хәзинәле гомер» дигән зур әдәби-музыкаль кичә булып узды. Быел вафат булган олуг әдибебезне

зурлау һәм искә алу кичәсе булды бу тантана. Татарстан Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, халык шагыйрьләре И. Юзеев, Ш. Галиев, язучылар М. Галиев, В. Имамов һ. б. үзләренең чыгышларында Гариф Ахуновның татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре, һәм гомумән, халкыбызның рухи тормышындагы роле турында сөйләделәр. Кичәдә, шулай ук әдипнең якташлары, күренекле сәхнә осталары катнашты һәм чыгыш ясады.

* * *

Шул ук көнне Казанның Новаторлар урамында Гариф Ахунов яшәгән йорт диварына мемориаль такта кую тантанасы булды. Мәрмәр тактага «Бу йортта 1968-2000 елларда Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов яшәде» дип язылган.

## М. ГАФУРИ КИЧӘСЕ

16 октябрьдә Г. Камал театрында татар-башкорт әдәбиятлары классигы Мәҗит Гафуриның тууына 120 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булды.

Әлеге кичә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллинның М. Гафури тормышы һәм иҗаты турындагы чыгышы белән башланып китте. Аннары Камал театрының күренекле артистлары Ринат Тажетдинов, Илдус Әхмәтҗанов, Хәлим Җәләл М. Гафури әсәрләреннән өзекләр укыдылар. Яраткан җырчыларыбыз Рөстәм һәм Муса Маликовлар, Зилә Сөнгатуллина, Айдар Фәйзрахманов, Искәндәр Биктаһиров һәм башкаларның чыгышларын да тамашачылар бик җылы кабул итте. Кичәне Айдар Хафиз һәм Зөһрә Шакирҗан алып барды.

## ЕВРОПАДА ТАТАР МОҢНАРЫ

Татарстан Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Рәшит Кәлимуллин Люксембургта ел саен уза торган «Дөнья музыкасы көннәре» фестивалендә булып кайтты. Анда композиторның «Ардити-квартет» (Лондон) башкаруында дүртенче кыллы квартеты яңгырады.

Р. Кәлимуллин фестивальдә якташыбыз, дөньякүләм танылган композитор С. Гобәйдуллина белән дә очрашты. Казан мэры үтенече буенча, ул Софья ханымның 70 яшьлегенә багышланган фестивальне туган шәһәрендә дә үткәрү ниятенирештерде һәм маэстро бу тәкъдимне теләп кабул итте.

## ТӨРКИ ГАЛИМНӘР КАРДӘШЛЕГЕ

Төркиянең Измир төбәгендәге Чишмә дигән шәһәрчектә төрки телләр буенча IV халыкара корылтай уздырылды. Анда Татарстаннан академик Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелегендә бер төркем галимнәр катнашты. Фоат Ганиев, Флера Сафиуллина, Флора Әхмәтова, Нурмөхәммәт Хисамов кебек күренекле белгечләребез тирән мәгънәле чыгышлар ясадылар. Корылтай эшеннән соң төрек галимнәре кунакларны Төркиянең тарихи урыннары белән таныштырдылар.

## ҮЗБӘКСТАНДА ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

Ташкентның милли-мәдәни үзәгендә "Халыкларның мәдәниятен үстерүдә һәм берләштерүдә хатын-кызларның урыны" дигән темага түгәрәк өстәл булды. Очрашуны Үзәк Азия халкы мәдәнияте Ассамблеясенең хатын-кызлар төркеме оештырды.

Үзбәкстан Республикасының атказанган табибәсе Әлфия Халикова анда татар хатын-кызларының Үзбәкстанда мәгърифәт һәм мәдәнияткә керткән өлеше турында сөйләде. "Татар хатын-кызларыннан тарих фәннәре докторы Разия Мөэминова, геология фәннәре докторы Тәлига Хәйруллина, ботаник профессорлар Разия Якупова, Ләйлә Шәмсевәлиева һәм башка галимнәрнең, СССРның халык артисткасы Галия Измайлова кебек сәнгать эшлеклеләренең исеме бөтен дөньяга мәгълүм" диде ул. Хәзер республикада йөзгә якын татар галиме һәм меңләп мәдәният хезмәткәре бар.

Түгәрәк өстәлдә катнашучылар киләчәктә Үзәк Азия күләмендә генә түгел, бәлки дөньякүләм хатын-кызлар арасында хезмәттәшлекне ныгыту турында сүз алып бардылар.

## ТЕАТРГА ЯҢА БИНА

12 октябрьдә Уфада татар «Нур» театры үзенең яңа бинасында быелгы тамашаларын башлап җибәрде. Бу шатлыклы вакыйга белән театр коллективын Уфаның күпсанлы тамашачысы гына түгел, күрше өлкә республика, шул җөмләдән Татарстан җәмәгатьчелеге вәкилләре дә кайнар котлады.

Сезон Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәре буенча куелган спектакль белән башланып китте. Премьера әлегә театрның кечә залында куелды. Зур залда төзелеш эшләре бара, озакламый тамашаларны анда да күрергә насыйп булыр дип ышандыралар.

## КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ БЕЛЕМЛЕ ХАЛЫК

Кырымда халыкның белем дәрәҗәсен тикшерү үткәрелгән. Аннан күренгәнчә, һәр мең Кырым татарының өч йөзе югары белемгә ия. Урыслар арасында бу сан 159, украиннар арасында 86. Бу яктан татарлар бары тик яһүдиләрдән генә калыша икән. Аларда һәр мең кешенең өч йөз алтмышы югары белемле.

## МӘРҖАНИ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

Әтнә районының Ш. Мәрҗани исемендәге Комыргужа урта мәктәбендә Шиһабетдин Мәрҗани музее ачылды. Тантананы Татарстан вице-премьеры Илгиз Хәйруллин ачып җибәрде. Район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Хәмит Галимҗановның, академик Яхъя Абдуллинның, Ш. Мәрҗанинең оныгы Суфия Мостафинаның, музей җитәкчесе Гөлнур Вәлиеваның һәм башкаларның чыгышлары игътибар белән тыңланды.

Тантанага галимнәр, язучылар, дин әһелләре, музей хезмәткәрләре, укучылар, авыл халкы күпләп җыелган иде. Тантана барышында Ябынчы авылының Ш. Мәрҗани туган йортның нигезендә бөек мәгърифәтче рухына багышлап дога кылынды.

## ЯҢА БАСМАНЫ ТӘКЪДИМ ИТҮ

Казанның 1000 еллыгына әзерләнү уңаеннан «Мәгариф» нәшрияты язучы Ф. Латыйфиның «Хыянәт» романын мәктәпләр өчен яңадан бастырып чыгарган иде. 26 октябрьдә Ш. Камалның музей-фатирында китапны тәкъдим итү кичәсе булды. Анда Г. Камал театры артистлары башкаруында әсәрдән өзекләр, борынгы татар көйләре яңгырады. Ф. Латыйфи китап сөючеләрнең күпсанлы сорауларына җаваплар бирде. Чыгыш ясаучылардан «Мәгариф» нәшриятының баш редакторы Ж. Кәлимуллин, язучылар һәм галимнәр Л. Шагыйрьҗан, Н. Гамбәров, Ф. Сафин, И. Хәлиуллин, Б. Хәмидуллин h. б. китапны русчага тәрҗемә итеп чыгару, аның буенча нәфис фильм төшерү мәсьәләләренең дә заман таләбе буларак өлгереп җиткәнлеген әйттеләр.

## КҮРШЕЛӘРЕБЕЗДӘ

Менә 10 ел диярлек инде Мордовия республикасының Ләмберә районында татар мәдәни үзәге эшләп килә. Ул район хакимияте карары белән бу төбәктә татар халкының гореф-гадәте, йолаларын, авыз иҗатын, һөнәрчелеген торгызу, ана телен үстерү максатын күздә тотып оештырылган иде.

Үзәк каршында мәдәният йорты, мәктәп һәм китапханә эшли. Мәдәният йортында махсус методист бар. Үзәк урындагы язучы, журналист, укытучылар белән тыгыз бәйләнештә. Төрле бәйрәмнәр, мәдәни чаралар үткәрүдә халык та булыша. Үзәк каршындагы «Чулпан», «Умырзая» ансамбльләре бу төбәктә генә түгел, күрше район, республика, өлкәләрдә дә абруй казана бара.

## ӘСТЕРХАН ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕ

Өлкәнең 25 мәктәбендә педагогия училищесында, Хаҗи Тархан исемендәге Ислам университетында татар теле укытыла. 2000-2001 уку елында аларның барысында да компьютер сыйныфлары оештырылачак. Бу хакта өлкә хакимияте махсус карар кабул иткән.

## ҖЫРЧЫ ИСЕМЕНДӘГЕ БӘЙГЕ

Мәскәүнең милли-мәдәни мохтарияте мәшһүр җырчыбыз Хәйдәр Бигичев истәлегенә багышлап бәйге игълан итте. Бәйге Мәскәүдә яшәүче татар халкының бөтен сәнгать көчләрен берләштерүне, яшь җырчыларны барлау, аларның осталыгын үстерүне максат итеп куя. Бәйгедә аерым җырчылар, вокаль ансамбльләр, үз әсәрләрен башкаручылар да катнаша ала. Номинацияләрдә үзешчән сәнгатькярләр һәм профессиональ башкаручылар аерым карала.

* * *

25 октябрьдә Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге, Театр әһелләре берлеге күренекле шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәрзия Фәйзуллина-Тәрҗеманова 70 яшь, иҗат эшчәнлегенә 50 ел тулуга багышланган «Энҗе чәчәк» дигән әдәби-музыкаль кичә үткәрде.

## МИЛӘҮШӘ КҮРГӘЗМӘСЕ

Сәүдә-сәнгать палатасының «Камиль» галереясында яшь рәссам Миләүшә Нуруллина хезмәтләреннән торган күргәзмә ачылды.

Анда натюрморт жанрындагы 25 әсәр урын алган. Рәсемнәрдә аеруча чәчәкләр хакимлек итә. Миләүшә—танылган язучы Вакыйф Нуруллинның кызы. Рәссам үзе дә әдәби иҗатны чит күрми. Шул рәвешле картиналарының исемнәре дә «Шомырт җиле», «Язгы нәни шайтаннар», «Бежар балеты» ише поэтик аһәң алган.

## ШАГЫЙРЬ—ВИЦЕ-ПРЕЗИДЕНТ

Октябрь аенда Мәскәүдә Россия Ясалма акыл ассоциациясенең чираттагы съезды булды. Анда кибернетика һәм информатика, фәндә һәм халык хуҗалыгында компьютер технологияләрен кулланунын актуаль проблемалары белән шөгыльләнүче бер төркем татар галимнәре дә катнашты. Съездда Ассоциациянең вице-президенты итеп техник фәннәр докторы, Казан дәүләт университеты укытучысы, шагыйрь Җәүдәт Сөләйман сайланды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

## КАЗАННЫҢ ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ

Борынгы риваятьләр һәм тарихи чыганаклар XVI гасыр Казанын чәчәк ату чорында һәлак булган, хәзинә-байлыклары, таш һәм агач сарайлары, мәчет-тәрбәләре, хикмәтле китаплары һәм сансыз-хисапсыз һөнәрчелек әсәрләре белән бергә югалган серле дәүләт, камил цивилизация итеп сурәтлиләр. Җиһанга дөньякүләм мәгълүм «алтын таҗларын», «тәхетләрен», рыцарьларын һәм бөек шигърияten, Мөхәммәдьяр, Кол Шәрифләрен биргән бу чор—татар милли тарихының үре, гали ноктасы булып күз алдына килеп баса. «Казан» дигән төшенчәнең ачылган һәм әлегә безгә мәгълүм булмаган катлаулы мәдәни эчтәлеге татар иҗатының тышкы һәм эчке яшерен бизәгенә—магик көченә әверелгән. Бүгенге көн мәдәниятенең шул чор тудырган сәнгать архетипларына барып тоташуы моның ачык дәлиле.

Ситез манаралы җәмигъ мәчет тә «Казан» дигән шушы күләмле миф-чынбарлыкның гүзәл бер кыйпылчыгы. Аның хакында атаклы тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани әйтеп калдырган, ул халык риваятьләрендә олуглап телгә алына. XVI гасыр чыганакларының берсе—«Казан тарихы» («Казанская история») язганча, нәкъ менә аның янында шәһәрнең язмышын хәл итүче соңгы орыш булып үтә: Казан сәете Кол Шәриф һәм аның фидакарь шәкертләре дошман тарафыннан чәнчеп үтереләләр.

Казан Кремлендә казыну эшләре алып баручы археологлар һәм архитектура белгечләре, кирмән эчендә берничә мәчет булган, аларның берсенең нәкъ менә төп мәчет булуы мөмкин дип раслыйлар. Петербургта чыгып килгән «Православие дине энциклопедиясе» (1906) Явыз Иван Казанны алгач, бөтен мәчетләрне «җир белән тигезләп», алар өстенә чиркәүләр корырга боера, шул исәптән, мәчетләрнең берсенең нигезе өстенә («на месте разломанной мечети») хәзерге Благовещение храмының бинасын сала башларга куша, дип яза. Бу вакытлыча корылма 1562 елны таш чиркәүгә әйләндерелә. Күптән түгел генә Благовещение соборында табылган мөселман каберташы бу бинаның элеккеге мөселман мәчетенә мөнәсәбәте булганлыгын раслаучы факт... Кайбер чыганаклар мәчетнең урыны хәзерге Спас кальгасыннан бераз югарырак, Казан кирмәнен урталай ярып үткән Таҗик ермагы өстендә булган, ди. Берәүләр мәчетне таш бина булган, икенчеләре—агачтан корылган, ди. Ташмы, агачмы, анысын хәзер ачыклау кыен. Ләкин шунысы хак, аны сүтеп, гөмбәзләрен кисеп, олауларга төяп, Мәскәүгә алып киткәннәр. Хәтта мәчет тулаемы белән Мәскәүгә илтеп куелган һәм анда кабат торгызылган дигән фикерләр дә юк түгел. Казан тарихчысы М. Худяков, мәсәлән, беренчеләрдән булып, мәчетнең прототибын Мәскәүдәге—халык телендә Василий Блаженный чиркәве дип йөртелгән собордан эзләргә куша... Русия башкаласының үзәк мәйданында 1555-1559 елларда калкып чыккан бу мәһабәт бинаны байтак рус һәм чит ил тарихчылары мөселман архитектурасы образын иңдергән, Казанны алу чорының «гаҗәеп трофее», җиңү һәйкәле дип саныйлар.

Мисыр хәрби кампаниясе чорында ислам динен кабул иткән Наполеон аны Мәскәүдә беренче күрүгә, бер дә шөбһәләнмичә «мәчет» дип атый. Ә рус православиесе, бу соборны мәҗүсигә саный һәм 1650 нче елларда анда гыйбадәт кылуны тыя.

Храмның кирпеч катламнарын зондаж ысулы белән өйрәнгәндә, А. В. Бунин үзенең «Шәһәрләр төзү тарихының» II томында (Мәскәү, 1979), аның стенасына батырылган агач каркас—бурасыман әйбер табылу турында яза. Шулай ук рус елъязмаларында чагылып үткән хәбәрләр арасыннан осталарның ниндидер зур «нигез», күләмле «агач модель» белән эш итүләре ачыклана. Бу «каркас»ның—соңыннан таш белән әйләндереп алынган, ә аңача Казаннан төяп китерелгән «Кол Шәриф» мәчете булуы бик мөмкин. Чиркәүнең гөмбәзләре дә агачтан юнып, сырлап, чынаяк белән бизәп кыршауланган «суган башларын»—чалмаларны хәтерләтә.

Ә шулай да, Һиндстан, гарәп илләре, Төркия, Урта Азиянең иң шөһрәтле корылмалары белән аваздаш бу «чалмалы чиркәү»—«тез чүктерелгән» мәчет нинди мәдәни мохитта туып чыккан соң?

Безнең уйлавыбызча, бу корылманың идеясе бары тик бу илләр белән экономик, сәяси һәм мәдәни арадашлыкта яшәгән, шәрык шигъриятеннән, сәнгатеннән азыкланган, уйлау ысулын үзендә эреткән Казан җирлегендә генә туа алган. Аның нигезендә—бөек фарсы шигърияте, Фирдәүси, Низами, Дәһләви әсәрләренең эстетик канунын тәшкил иткән, алардан төрки шагыйрьләр Кол Гали, Мөхәммәдьярларга күчкән фәлсәфи уйдырма—«Хәшт-и-бехишт»—«сигез җәннәт» образы ярылып ята. Бу образның мәгънәсе—кеше бу дөньяны үз кулы, зәвыгы, гүзәллек тойгысы һәм күңел җылысы бәрабәренә илаһи бер гөлбакча—җәннәт итеп төзи ала; гүзәллек—бөек гамәл, бары тик гүзәллек—сәнгать тәэсире белән генә кешенең рухын нечкәртергә һәм камилләштерергә мөмкин.

Димәк, татар җирендә туган, аннан Русиянең башкаласына күчкән күпманаралы мәчетнең илһамчысы шигърият... Бу—география, континентлар, милләтләр, телләр, конфессия, зәвыклар тоташкан җир—фарсы шигъриятендәге гүзәл утопия ватаны—Казан...

**Р. Шаһиева,**
*сәнгать белгече*

---

## Конкурс йомгаклары

Әдәбиятыбызның тәнкыйть тармагын җанландыру максатыннан чыгып шушы елның гыйнвар аеннан «Казан утлары» журналында иң яхшы рецензияләргә ачык конкурс игълан ителгән иде. Редакциягә байтак язмалар алынды, аларның иң уңышлы дип табылганнары журнал битләрендә басылып чыкты.

Ел буе дәвам иткән конкурсның нәтиҗәләре түбәндәгечә:

**I урын** һәм 1000 сум күләмендәге акчалата бүләк **Фәрит Хатипов**ның «Якты җирлектәге һәлакәт» рецензиясенә *(3 сан)*;

**II урын** һәм 750 сум күләмендәге акчалата бүләк **Кояш Тимбикова**ның «Шагыйрәнең хыялында йөрткән китабы» рецензиясенә *(6 сан)*;

**III урын** һәм 500 сум күләмендәге акчалата бүләк **Рәфыйк Шәрәфиев**нең «Үткәннәрдән безгә гамьнәр калган» (5 сан) һәм «Безне кемнәр аңлар?» *(7 сан)* рецензияләренә бирелә.

Редакция шулай ук Миргазиян Юныснын «Бәхетле мескенлек» *(2 сан)*, Ләйлә Минһаҗеваның «Хаталар да булмаса...» *(3 сан)*, Миләүшә Хаҗиеваның «Утырып уйлар уйладым...» *(4 сан)* һәм Нәҗибә Сафинаның «Ил турында Ил китабы» *(12 сан)* рецензияләрен уңай яктан билгеләп үтә.

Иҗади ярыш киләсе елда да дәвам иттерелә. 2001 елда журналда басылган **иң кызыклы әдәби тәнкыйть язмасы** 2,5 мең сум күләмендәге акчалата бүләк белән билгеләп үтеләчәк.

Редакция

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Казан архитекторлары фаразынча, Казандагы җәмигъ мәчет бинасы шундый булган. *Рәссам Ф. Халиков рәсеме.*

**Тышлыкның икенче битендә:** Хәсән Туфан портреты. *Марсель Галиев эше.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь Рафис Корбан.




Батырлар китабы—Книга Героев. Төзүчеләре—коллектив. Казан: Татарстан китап нәшрияты. 2000.—396 бит. Тиражы—5000 данә.

Әлеге китапка Татарстанда туып-үскән, эшләгән, яшәгән якташларыбыздан һәм республикабыздан читтә гомер кичергән милләттәшләребездән Советлар Союзы Герое исемен йөртүче 378 кеше-шәхес турында энциклопедик характердагы белешмәләр, фоторәсемнәр урнаштырылган. Бу юнәлештә элек нәшер ителгән китаплардан аермалы буларак, «Батырлар китабы»ның янәсына Алтын Йолдызлы каһарманнарыбыз турында Россия Саклану министрлыгы Үзәк архивындагы Бүләкләү кәгазьләреннән алынган язмаларның кыскача сөземтәсе кертелгән.

Җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан республикабыз күләмендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча «Батырлар китабы»—«Книга Героев», «Елның иң яхшы китабы» дип табылып, махсус Дипломга лаек булды.

Тарихи-документаль бу басманы дөньяга чыгарудагы хезмәтләре өчен, китапның баш мөхәррире Дамир Шакировка, консультант һәм кереш сүз авторы Шаһинур Мостафинга, рәссам Рушан Шәмсетдиновка, иҗади-эшче төркем җитәкчесе Булат Хәмидуллинга Кол Гали исемендәге премия дә бирелде.

Бу китапны түбәндәге адрес буенча соратып алдырырга була: *420503, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19 нчы йорт. Татарстан китап нәшрияты.*

Индекс 73210



Рафис Корбан

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)